
ISSN 0206-




# КАЗАН УТЛАРЫ

9. 1983



# КАЗАН УТЛАРЫ

1922 елның май аеннан башлап чыга

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

9

1983

## Бу санда

КПСС ҮЗӘК КОМИТЕТЫНЫҢ ИЮНЬ (1983 ЕЛ) ПЛЕНУМЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА!

Х. НИЗАМОВ. Колхоз мәктәптән башлана . . . 3

КОЛ ГАЛИНЕҢ ТУУЫНА 800 ЕЛ

М. ГОСМАНОВ. Кол Гали — халык хәтерендә сигез гасыр . . . 13
Н. ФӘТТАХ. Кол Гали. Трагедия . . . 16
Х. ГОСМАН. Ерак чыганаклар . . . 44
Н. ЮЗИЕВ. «Кыйссалардан, хикмәтләрдән күрекләрәге...» . . . 47
Н. ХИСАМОВ. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының идея проблематикасы һәм сәнгатьчә эшләнеше . . . 53

Ф. ХӘСНИ. Бераү килә, бераү китә... Повесть . . . 62
Н. АРСЛАНОВ. Йөрәгеннән алдым. Шигырьләр . . . 75
Ф. БӘЙРӘМОВА. Болын. Повесть . . . 82
Ф. ЯРУЛЛИН. Ишекләр. Шигырьләр . . . 127
Рәш. ӘХМӘТҖАНОВ. Кол Галиләр рухы. Шигырьләр . . . 130
Ә. ГАДЕЛ. Алпамша. Шигырьләр . . . 135

«АВЫЛ ОФЫКЛАРЫ» КОНКУРСЫ

Ә. РӘШИТОВ. Сез кемнең варислары! Очерк . . . 138

БҮГЕНГЕ ПРОЗА: ГЕРОЙЛАР, ПРОБЛЕМАЛАР

Ф. ГАНИЕВА. Әдәбият — үл сүз сәнгате . . . 143
Дискуссиягә укучы кушыла . . . 151

ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ

Ф. ГАЛИМУЛЛИН. Халатың ак, күңелең пакь булса . . . 156

НИЯЗ ДАУТОВКА 70 ЯШЬ

Ф. ШӘМСЕТДИНОВА. Бәхетле иҗат юлы . . . 159

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

**М. ГОСМАНОВ. Тирән эзләр, үзәк тамырлар** . . 161

**«Яшь ленинчы» һәм «Ялкын» бездә кунакта** . . 182

КАЛӘМДӘШЛӘРЕБЕЗ — СССР ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ЯҢА ӘГЪЗАЛАРЫ

**Н. ИЗМАЙЛОВА, Җ. ДӘРЗАМАН, Т. ӘЙДИ** . . . 188

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары** . . . . . . 189

**Тышлыктагы сурәтләр** . . . . . . . . . . . 192

*Баш редактор* **РЕНАТ ХАРИС**

**Редколлегия: ШАМИЛ БИКЧУРИН, МАНСУР ВӘЛИЕВ, РАЗИЛ ВӘЛИЕВ, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, РӘИС ДАУТОВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ,** *җаваплы секретарь* **РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН,** *баш редактор урынбасары* **РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ, ЗӘКИ НУРИ, РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, СИБГАТ ХӘКИМ, НИЛ ЮЗИЕВ**

---

Техник редактор *Р. Сөләйманова*
Корректорлар *Ф. Кадыйрова, Г. Салихҗанова*

---

**Адрес редакции: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.**

**Телефоннар:** баш редактор — 53-07-60, баш редактор урынбасары — 53-07-09, җаваплы секретарь — 53-07-09, проза бүлеге — 53-07-61, поэзия бүлеге — 53-07-61, тәнкыйть бүлеге — 53-07-63, сәнгать бүлеге — 53-07-63, очерклар бүлеге — 53-07-61, хатлар бүлеге — 53-07-63, корректорлар — 53-07-65, техник редактор — 53-07-65, машинисткалар — 53-07-60.

Производствога бирелде 27.06.1983 ел. Басарга кул куелды 24.08.1983 ел. ПФ 11215. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 65044. Заказ Я-228. Бәясе 90 тиен.

Типография издательства Татарского обкома КПСС.
420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2.

© «Казан утлары», 1983 ел.

КПСС ҮЗӘК КОМИТЕТЫНЫҢ ИЮНЬ (1983 ЕЛ) ПЛЕНУМЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА!

**Хәләф Низамов,**
КПССның Актаныш райкомы беренче секретаре

# КОЛХОЗ МӘКТӘПТӘН БАШЛАНА

*...Укытуны җитештеручән хезмәт белән кушу — тәрбиянең яхшы чарасы.*

(КПСС Үзәк Комитетының Генеральный секретаре иптәш Ю. В. Андроповның Пленумда ясаган речендән)



Безнең әдәбиятта авылга багышлап язылган әсәрләр күп: романнар да, повестьлар-хикәяләр дә, поэмалар да, шигырьләр-җырлар да җитәрлек. Алардагы иң матур юллар, минемчә, авыл кичләренә бәйле. Ул, эңгер-меңгер төшкәч, яшьләрнең су буена җыелулары, ул айның серле яктысы, ул йолдызларның җемелдәшүләре һәм, әлбәттә, караңгылыкны сискәндереп җаннарны җилкендереп яңгыраучы гармун моңы — барысы да әдипләребез тарафыннан гасырдан-гасырга төрледән төрле төсмерләргә төрендереп тасвирланганнар....

Берсендә, район үзәгеннән шактый ерактагы авылга баргач, аптырап-сискәнеп калдым. Кич иде инде, нәкъ менә җырларда сокланып җырлана торган айлы, тын, җылы кич иде. Караңгы да төште, хуҗалыктагы эшләрнең түгәрәкләнер чагы җитте, капка төбенә сулу алырга, гәп сатарга чыккан карт-коры да кереп ятты. Көтәм. Юк кына бит! Нигә ерак урам чатыннан гармунчы егет һаман чыкмый соң? Икенче яктан, аңа җавап биреп, сыздырып җибәрүчесе дә ишетелми. Дөнья тутырып, көлешә-көлешә, чыркылдашып үтүче кызлар кайда?

Өстән таптатып киткәндәй колак тондыргыч тырылдык тавыш белән берьюлы әллә ничә мотоцикл узды. Ачык тәрәзәдән бүлмәгә, бөр-

келеп, тузан кәрде, әче май исе тулды. Буш вакытта нишләргә белми йөдәгән яшүсмерләр, авылның әле бер, әле икенче башына атылып-бәрелеп, шактый озак йөрделәр. Егетләрнең кайберләрә, башкалардан аерылыбрак тору өчен, мотоциклларның тавыш тоныклау җайланмасын алып аткан, андыйларының тырылдавы түбәннән кереп, үкчәннән чыга. Бу яңа төр «кичке уеннар» вакытында авыл өстендә колак тондыргыч мотор гөрелтесе, магнитофоннар бакыруы эленеп торды.

Тираннан уйландырырлык хәл иде бу. Колхоз җитәкчеләре:

— Авылда кызлар юк,— дип офтанып сөйләделәр.— Кичен клубка унбиш-егерме егет килә. Шар сугалар, телевизор карагандай итәләр дә берәм-берәм таралып бетәләр. Өсләренә карарга кызганыч: озата барырга, капка төбендә яки ындыр артында серләшеп утырырлык бер кыз да булмагач, аларга күктәге аең ни дә, йолдызыңның җемелдәве ни?! Күңелләре китек. Әнә шул машина, мотоцикл, магнитофон белән юанып яшиләр...

Күңел төшенкелеге — яман хәл. Әмма бусы да — мәсьәләнең бер ягы гына әле. Колхоз-совхоз җитәкчеләре соңгы елларда көннән-көн көчлерәк механикалаша барган хуҗалыкларга кадрлар җитенкерәмәүдән зарлана башладылар. Өр-яңа машина кайта — ышандырып тапшырырга кеше юк. Терлек санын арттырабыз — сыеры, танасы, бозавы меңнәр белән исәпләнә, аларны тәрбияләргә, сөтен саварга кеше җитешми. Кайбер колхозларда хәтта төркем-төркем сыерларның тәүлек буе савылмый калган очраклары булгалады. Сәбәпләрен тикшереп карагач, хәйран калырлык хакыйкать ачылды — соңгы ун-унике ел эчендә районнан унөч меңләп кеше шәһәрләргә киткән. Башны хафага салырлык һәм кичекмәстән тиешле чаралар эзләргә мәҗбүр итәрлек мәсьәлә иде бу.

Азык-төлек программасы кебек, авыл хуҗалыгындагы эшләрне тамырдан яхшырту буенча олы бурычны күздә тотканда, әлеге чара бик тиз арада үтәлергә тиеш иде.

Колхоз-совхозларыбызның җитәкчеләрен райкомга җыеп, аяныч бу хәлне уртага салып, иркенләп бер киңәшләштек. Иң әүвәл авылдан кемнәрнең һәм ни сәбәпле китүләрен ачыкладык. КамАЗ, Түбән Кама предприятиеләренә, Атом электр станциясе төзелешенә кызыгучыларның күпчелеге урта мәктәпне тәмамлаган яшьләр булып чыкты. Хуҗалыкның иң алдынгы сафында атларга тиешле, өлкәннәрнең җегәре дә, белеме дә җитмәстәй кыенлыкларны җигелеп тартырдай егет-кызлар китә. Ник китәләр? Чөнки шәһәрдә яшәү рәхәтрәк: тиешле сәгатеңне тутырып, эштән кайтасың да, иң затлы киемнәреңне киеп, төзәтенеп-ясанып, такыр юлдан тек-тек басып, мәһабәт культура сарайларына, стадионнарга, ашханә-рестораннарга рәхим ит!

Уртак нәтиҗәгә килдек. Димәк, җиргә хезмәт күрсәтүләрен теләсәң, төп таянычың булырдай яшьләрнең күңеленә үтеп кер һәм аларга шәһәр кешеләренекеннән ким булмаган шартлар тудыр икән. Максатлар ачыклангач, кичекмәстән башкарылырга тиешле эшләрне, җаваплы кешеләрне билгеләве ул кадәр үк кыен түгел инде. Юллар турыдан-туры районның урта мәктәпләренә илтә иде. Шунлыктан бурыч нигездә, ВЛКСМның район комитетына, халык мәгарифе бүлегенә йөкләтелде. КПССның район комитеты исә бу өлкәдә башкарылачак һәр эшне даими контрольгә алды, кирәк чакта, һәрьяклы ярдәм күрсәтергә әзер торды. Алдан шунысын әйтеп куярга мөмкин: авылларыбызда үскән балаларда туган якка мәхәббәт соңгы елларда көчәя төшкән икән, җиргә карата мөнәсәбәтләре ягымлылана башлаган икән — монда иң зур казаныш итеп, бездәге бердәмлекне санарга кирәк. Барысының да: мәктәпнең дә, комсомол оешмаларының да, колхоз-совхоз һәм район җитәкчеләренең дә, ата-аналарның да бер үк теләк белән януы гына уңай нәтиҗәгә китерә ала.

1981—1982 уку елының буеннан-буена урта мәктәп коллективлары унынчы классларда аңлату алып бардылар. Педагогика кагыйдәләре дә, халык гадәтләрен, ата-ананы олылау зарурияте дә — һәммәсе истә тотылды. Укучылар белән индивидуаль әңгәмәләргә аеруча игътибар ителде. Класс җитәкчесе бер яктан аңлатма үткәрә, клуб мөдире шул ук укучыларны үз карамагындагы күңелле чараларга тарту әмәлен карый, колхоз председателе аларның хуҗалыкка бик кирәк икәнен тәкърарлап тора. Әле укучылар, әле аларның ата-аналары белән тыныч кына, салмак кына, әмма бик даими рәвештә сөйләшәләр.

Ниһаять, беренче шатлыклы хәбәр килеп иреште: «Теләкәй урта мәктәбенең унынчы класс укучылары бөтенесе дә үз колхозлары «Маяк»та калырга теләк белдергәннәр!» Күп көч куеп ирешелгән бу беренче җиңүне мөмкин кадәр хупларга, зурларга кирәк таптык.

Район слеты оештырылды. Актаныш культура сараена авылларыбызның яшь игенчеләре, терлекчеләре, урта мәктәп чыгарылыш класс укучылары һәм, әлбәттә, барлык җитәкчеләр җыелды. Трибуна Теләкәй урта мәктәбенең район күләмендә беренче буларак изге теләк белдергән укучылары карамагына бирелде.

— Әйдәгез, кадерле балалар, күңелегездә шундый фикер уянган икән, бөтен район алдында авыз тутырып, күкрәк киереп әйтегез! — дидек.

Комсомол оешмасы секретаре Айсылу Мәгъдәнова сүзләре Теләкәй урта мәктәбе чыгарылыш класс укучыларының уртак карары булып яңгырады.

— Безнең «Маяк» колхозына сыер савучылар кирәк; кайвакыт, өй борынча йөреп, савымчы эзлиләр, әбиләргә ялыналар. Без авылыбызны шул хәлдә калдырып, китеп барыйкмы?! Минемчә, колхозыбызга шушы кыен хәлендә чакта ярдәм итү — безнең изге бурыч. Аннары колхоз да безнең киләчәккә булган теләкләрне искә алыр. Хәзер авылга белемле кадрлар кирәк. Без укуларыбызны дәвам итәрбез, колхоз идарәсе, һичшиксез, безгә ярдәм кулы сузар...

Айсылу сүзенә егетләр кушылды. Алар бүгеннән тракторга, комбайнга утырырга ризалар иде.

Чыгышлар гел шул юнәлештә барды. Авылга булышырга алынучы укучыларның берсе дә: «Без унны бетердек, шул җитте, инде гомер буе фермада сыер тиресе көрәргә яки тракторда утырып картаерга да ризабыз»,— димәде. Һәркемнең тагын да укырга теләге барлыгы сизелеп торды. Хәзер үк колхоз эшендә калулары хуҗалыкның зур бурычларын тирәннән аңлаудан, аңа ихлас күңелдән ярдәм итәргә теләүдән икән. Монысы — тәрбия эшләребезнең иң кыйммәтле ягы. Тагын да укырга теләүчеләргә без биш куллап ярдәм итәргә әзер идек.

Теләкәйлеләрнең күркәм башлангычына тирә-күршедәге урта мәктәпләрнең иң алдынгы укучылары кушылды. Алар да, трибунага чыгып, үз колхозларында киләндә бер ел эшләргә сүз бирделәр, дус-ишләрен дә мөстәкыйльлеккә шул юлдан атлап китәргә өндәделәр.

Слет районның барлык чыгарылыш класс укучыларына һәм колхоз-совхоз яшьләренә бик үтемле Мөрәҗәгать кабул итте. Ул: «Дуслар! Хезмәт юлыбызны туган җиребездән башлыйк!.. Якты эзебез, киләчәк буынга үрнәк булырдай изге эшләребез калсын»,— дигән сүзләр белән тәмамлана иде.

Ел буена дәвам иткән аңлатуларыбызның һәм бу слетның тәэсире көткәннән дә яхшырак нәтиҗәгә китерде. Өлгергәнлек аттестаты алган укучыларның 313е Актаныш җирендә колхоз-совхоз эшенә ярдәм итәргә калды.

Яшьләрнең, сүз тыңлап, халга кереп, туган җиргә хезмәт итәргә алынуы әле беренче адым гына икән. Шуннан соң безнең җилкәгә мең

төрле яңа мәшәкать йөкләнде. Иң алдан яшьләрне даими эш белән тәэмин итәргә кирәк иде. Ул аларның мәктәптә алган белеменә, хезмәт дәресләрендә өйрәнгән һөнәренә дә туры килерлек булсын, җаннында рәхәтлек тудырсын, хакы да әйбәт түләнсен. Икенчедән, яллырын ничек уткәрү дә, көнкүрештәге ихтыяҗлары да истә тотылырга тиеш. КПССның район комитетында шушы бурычларны эшлекле төстә хәл итүчән штаб төзелде. Аны җитәкләү райкомның икенче секретаре Равил Камильяновка йөкләтелде. Идеология секретаребыз Рәфига Галиева аның белән кулга-кул эшләргә алынды. Райкомның башка хезмәткәрләренә дә төрле хуҗалыкларда калган яшьләрнең хәлләрен белеп тору, аларга ярдәм итү бурычы тапшырылды. Бары тик бик җитди, эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштырып һәм практик аралашып тору гына бу беренче бөреләрне кырау сугудан, җил-яңгырдан саклап калачак иде. Аз гына илтифатсызлык күрсәттеңме, өч йөздән артык энтузиастның берсенең генә күңелен сындырдыңмы — киләчәктән уңыш өмет итмә. Адәм баласының дәртен ике тапкыр сүндермиләр, бер сүндердеңме, кабат кабызырмын димә. Бу кырыс хакыйкатьне без барыбыз да тирәннән аңлап, җан-тән белән тоеп тордык.

Мәгълүм ки, зур бер хуҗалык кадрле гвардия, колхозларга хезмәт күрсәтергә әзербез дип белдергән икән, без дә аның һәр утененә колак салырга, теләкләрен үргә алырга тиеш идек. Укучылар арасында моннан ике-өч ел элек үк югары уку йортларына китү турында хыяллана башлаганнары да бар иде. Иптәшләренең ихлас тәкъдимнәрен хуплау йөзеннән, алар да беренчел теләкләреннән баш тартып торырга булдылар. Нур Баян исемендәге колхозда калучылар арасында Пучы урта мәктәбен алтын медальгә тәмамлаган Рушания Исламова, аттестатындагы бишлеләр арасында бер генә дүртлесе булган Фәнүсә Гыйлметдинова кебек, илнең теләсә кайсы югары уку йортына барып кереп, студентлар төркеменә кушылырдайлары байтак иде. Аларның кайсы юрист, бер ише врач яки укытучы һөнәре турында хыяллана. Бу колхозның председателе Таһир Әхмәев алда укырга теләге барларны канатландырып кына торды.

— Теләсәгез, ел буе вуз программалары буенча консультацияләр оештырттырам,— диде.— Мәктәбебез укытучылары, сез теләсәгез, кирәкле темплар буенча кабатлау дәресләре үткәрерләр... Ну, аннары сезгә тагын бер үтенеч булачак — институт дипломы алгач, туп-туры үзебезгә кайтасыз! Безнең авылга юрист та, врач та, инженер да кирәк!..

Председатель Таһир Әхмәев яшь-яшь әле. Шулай да кемгә ни әйтергә, нинди җиргә кайсы җимне сибәргә икәнен яхшы чамалый. Аның үз авылы яшьләрен колхозда калдырырга ниятләп алып барган эше һичнинди очраклы ышандыруларга яки хәйләле вәгъдәләргә корылмаган. Ул барын да халык алдында ачык аңлатып, яңа башлангычның бүгенгесен һәм киләчәген күрсәтеп, аңа бәйле кыенлыкларны яшермичә эш итә. 1981—1982 уку елыннан соң колхозга ярдәмгә килгән яшьләр идарәнең игътибар үзәгендә тордылар. Иң әүвәл, авыр имтихан айлары үткәч, яшьләр Мәскәүгә сәяхәткә барып кайттылар. Бусы — ял өчен генә. Аннары председатель Таһир абыйлары белән бер автобуста Брежнев шәһәренә, Түбән Камадагы предприятиеләргә сәяхәт ясадылар. Бу юлда җитәкченең максатлары шактый күп төрле иде. Яшүсмерләр Түбән Кама шәһәре янындагы Шәңгәлче авылының заманча җиһазландырылган терлекчелек комплексын күрделәр. Автоматик җайланмалар. Ап-ак халат киеп кенә эшләүче горур кыяфәтле савымчылар — иң абруйлы шифаханәләрдәге табиплар диярсең! Моны күрү авылның киләчәге әнә шундый, дип ышандыру өчен кирәк иде.

Авылның саф һавасы, гүзәл табигате, шифалы суы белән генә мактанырга ярамаганны чамалап, Нур Баян исемендәге колхоз, беренче

булып, кайбер тармакларда ике сменалы эшкә күчте. Хәзер урта белемле кызлар караңгыдан-караңгыга сыерлар арасында гомер уза дип зарлана алмыйлар. Җиде сәгатен тутырып кайта да — дүрт ягы кыйблаl Аларга дигән төшке ашны авылның иң оста пешекчесе өлгертә. Чәе, сөтле ашы да — җаның теләгәнчә, колхоз хисабына өлгертелә.

Савымчыларның һәрберсенә кием шкафлары бүленгән. Кызлар, эш сәгате тулуга, ферма киемен салалар да, Европадагы теләсә кайсы шәһәрнең иң үзәк урамында кәеф-сафа корып йөрүче кешесеннән аерып алгысыз матур кыяфәткә кереп, авылга төшәләр, ял итәргә кайталар. Озак көттермичә, башка колхозларда да фермаларны ике сменалы эшкә күчерделәр. Яшьләр генә түгел, гомер буе шунда сыер сауган, бозау үстергән хатыннар да бик канәгать. «Кара инде,— диләр,— элегрәк ничек башка килмәгән соң бу безнең? Тәүлек буе шул фермага бәйле була идек: киләбез дә китәбез, киләбез дә китәбез. Өеңдә дә әллә ни майтара алмыйсың, фермада да басылып кына эшләп булмый. Хәзер икеләнеп тору юк, җиде сәгать буе, бөтенең бер булып, эшлисең дә кайтып китәсең. Җаның тыныч — терлекләр кулдашыңа кала...»

Яшьләр буш вакытларын ничек үткәрәләр диярсез. Анысы да уйланылган. Бәхеткә каршы, безнең як кешеләре табигатьләре белән үк сәнгатькә, музыкага гашыйклар. Пенсиягә чыккан әби-бабайлардан алып, әле мәктәпкә дә йөри башламаган сабый балаларга чаклы үзешчән сәнгать түгәрәкләренә йөри. Район культура йортында, ел әйләнә диярлек, аларның ярышы үткәрелә.

Республикада, концерт-спектакльләр смотрын ике елга бер тапкыр гына оештырырга, дигән күрсәтмә дә бар. Безнекеләр моңа риза түгел. «Ничек була инде ул? — диләр.— Ел буе тик тор да икенчесендә генә ярышка чык, имеш. Без өйрәнүдән туктамаска тиешбез!»

Болай фикерләүдә дә хаклык бар кебек. Шуңа күрә без, һәвәскәрләр теләген искә алып, сәнгать түгәрәкләренең эшен туктатып тормаска, бер елны — республика күләмендә сынашыр өчен, икенчесендә иҗади отчет төсендә ярышлар үткәрергә карар кылдык. Урта мәктәпне тәмамлап, колхоз эшендә калган егет-кызларыбыз исә бу иҗат коллективларының төп терәгенә әйләнде. Фермадан, иген кырларыннан кайтып, бераз ял итәләр дә культура йортына, төрле түгәрәкләрнең репетицияләренә җыелалар. Катлаулы уен коралларында уйнарга өйрәнәләр, берничә тавышлы хорда катнашалар, сюжетлы хореографик чыгышлар ясыйлар — барысына да шул яшьләр башлап тотына. Колхоз идарәләре исә түгәрәк членнарына яңадан-яңа костюмнар, кыйммәтле уен кораллары алдырып тора, өйрәтүче профессиональ осталар да чакыртыла.

Авылда кызлар да күпләп кала башлагач, волейбол, чаңгы кебек спорт уеннары да җанланып китте. «Маяк» колхозы савымчы кызлары Нур Баян исемендәге колхоз кызлары белән волейбол ярышы ачып җибәрделәр. Быел Нур Баян исемендәге колхозда эштә калган Айрат Гыйззәтуллин комбайнда бик әйбәт эшләү өстенә чаңгы ярышында да осталык күрсәтте. Аның инде зурларга бирелә торган II нче разряды бар.

«Яшьләр тирәсендә җыры-биюе, спорт ярышлары гөрләп инде аның,— диярсез.— Шулай да аларның эшкә ярдәме турында күбрәк сөйләшик әле». Авыл хуҗалыгы шактый катлаулы. Хәзер бит аның сыер-сарыгы да бары тик фән кушканча гына тукланырга, режим белән савылырга-кыркылырга өйрәнгән. Бозау үстерүе, дуңгыз симертүе, куян үрчетүе — барысы да тәҗрибә, белем таләп итә. Бер тармакта гына дилбегәңне ычкындыра башла, хуҗалыгыңның көймәсе комга терәлә дә кала. Ун ел буе китап-дәфтәрдән аерылмаган бала-чага баштанаяк механикалаштырылган ул фермаларда, «К-700», «Нива», «КамАЗ»

шикелле машиналарга таянучы игенчелектә ничек эшләрләр соң?» Хәтта мондый сорауны бирүче булмаса да, һәр җитәкче бу хакта алдан ук уйларга тиеш.

Карап торырга шактый четерекле күренгән шушы мәсьәлә безнең район күләмендә тулысынча мәктәпләргә тапшырылган. Билгеле ки, һәр мәктәптә хезмәт дәресләре бар. Әмма күп җирдә урта мәктәпне тәмамлаучы, өлгергәнлек аттестаты алган яшьләр һичнинди һөнәрсез калалар. Аларга ышанып, бернинди эш тә тапшыра алмыйсың. Димәк, өлгермәгәннәр әле алар. Безнең район балаларына аттестат белән бергә хуҗалыкның берәр тармагында эшләрлек һөнәр буенча документ бирелә.

Бу яктан «Октябрьның XII еллыгы» исемендәге колхозның уңышлары аеруча зур. Ул үзләрендәге Сәфәр урта мәктәбе укучыларын өйрәтүгә, җаен колхоз эшенә тартуга бик зур игътибар бирә. Председатель Марс Шәвәлиев, партия комитеты секретаре Рәмдис Шаһиянов, мәктәп директоры Ренат Шакиров — бары бер булып, колхоз белән мәктәп тормышын аерылмаслык юлга салганнар. Марс Шәвәлиев хәзер иркен сулап:

— Без колхоз эшендә кеше көченә кытлык сизмибез,— дип кенә җибәрә.— Тугызынчы класс кызлары, җәйге каникулларының бер аенда фермадагыларны ял иттерә, моңарчы савымчыларга отпуск бирү проблема иде. Менә, җаен таптык. Кызлар тырышалар. Алар эшләгән арада да сөтнең кимегәне юк...

Сәфәр мәктәбендә укучы егетләр арасында эш бүлешү тагын да җайлырак көйләнгән: тугызынчыны тәмамлаучылар, урак өстендә, комбайнга утыра, сигезенче класс малайларын үзләренә ярдәмче итеп алалар. Аңлашыладыр: бер ел үтә, былтыргы ярдәмчеләр мөстәкыйльлеккә чыга. Узган елда абыйларыннан өйрәнгәнне үзләреннән кечеләргә тапшыралар...

Укучыларны зур хезмәт дөньясына озату өчен, Сәфәр урта мәктәбендә гаҗәеп киң колачлы тәрбия алып барыла. Мәктәпнең бинаһая иркен, биек бер залында булачак механизаторларга дәрес бирелә. Монда машина йөртү мастеры, укытучы Наил Сәхәбетдинов өйрәтмәләрен тыңлыйлар. Бу укытучы җаен «Колос» комбайнында эшли. 1982нең уңышын җыйганда, ул 6 мең 700 центнер ашлык суктырды. Менә шундый укытучы ул безнең! Аның карамагына тапшырылган залга өр-яңа комбайн, күпчәкле һәм чылбырлы тракторлар кертеп куелган. Аларның һәр детален күрергә һәм эшләтеп карарга була. Машиналарның аерым частьларын хәрәкәтләндерү электрга көйләнгән. Стеналарга эленгән әсбапларда әлеге машиналарның төзелешенә, эшләү ысулларына кагылышлы сораулар һәм җаваплар бар. Укучы, дәрес барышында, алардан теләгәнчә файдалана ала. Инде үзенә җавап бирер вакыт җиткәч, ул кулындагы күрсәткеч таяк белән тиешле җавапка төртеп кенә күрсәтә. Шул чак, укытучыдан тыш, автоматик җайланма да «телгә килә»: җавабың дөрес икән, югарыда «гөлт» итеп ут кабына, ялгышсаң, залны яңгыратып, кыңгырау чыңлый башлый, әйтерсең, синең хатаңа машиналарның да ачуы чыга!

Нәкъ шундый ук мөмкинлекләр кызларның сыер саву җайланмаларын өйрәнү кабинетында да бар. Саву аппаратын эшләтеп карарга телисең икән, рәхим ит! Сорауларга әзерләгән җавапларыңның дөреслеген беләсең килсә, автоматик таблога күз сал, әйтә дә бирә.

Кыскасы, мәктәпне тәмамлаучылар колхозга ярдәм итәрлек кадрлар булып чыксыннар өчен, укытучылар коллективы да, колхоз идарәсе дә ихлас күңелдән тырышканнар. Хәтта мәктәпнең диварлары да туган җирне, авылдашларны хөрмәт итәргә өнди кебек. Бусагадан атлап кергән укучыны колхоз алдынгыларының, хезмәт һәм сугыш ветераннарының фотосурәтләре каршылый. Алар — шул ук укучыларның

эти-әниләре, әби-бабайлары яки кардәшләре. Дәрестән икеле билгесе алып чыксаң, ул сурәтләр каршыннан ничек узарсың?

Озын коридор стенасына авыл күренешләренең, колхозга килгән хөрмәтле кунакларның, үзешчән сәнгать түгәрәгенә катнашучыларның, мәктәптә уздырылган мөһим чараларның фотосурәтләре эленгән. Борылышларга, бер каттан икенчесенә күтәрелә торган баскыч өсләренә берсенән-берсе гыйбрәтлерәк сүзләр язып куелган. Балалар «Укуыбыз, хезмәтебез — туган Ватаныбызга!», «Тормышта юллар күп — син кайсын сайларсың?» кебек ул язуларның берсен күреп, игътибарсыз калса да, икенчесен яки өченчесен укыганда, һичшиксез уйланып куяр. «Колхоз мәктәптән башлана!» — дигән үзе кыю, үзе бик тә дөрес сүзләрне дә мин шушы Сәфәр урта мәктәбендә күреп алган идем. «Кыю» диюем шуннан — бу сүзләр колхоз хәтле колхозны бер уч укучылар һәм укытучылар коллективына бәйләп куя сыман. «Дөрес!» — дим, чөнки, чыннан да, колхозның бүгенгесе никадәр генә көчле булса да, аның киләчәге мәктәпкә, балаларга барып тоташа. Шул хакыйкатьне аңлаган җитәкчеләрнең генә эше алга китәчәк, хуҗалыгы кадрларга сусамаячак.

Сәфәр урта мәктәбендәге, балаларны киләчәк хезмәткә әзерләү мөмкинлекләре хәзергә бик сирәк мәктәпләргә эләгә. Андыйлар илдә дә бармак белән генә санарлык. Бәхеткә, бу авылда яңа мәктәп белән бергә үк диярлек, зур спорт сарае да ачылды. Мәктәпнең спорт дәресләре колхозның спорт сараенда үткәрелә ала, ә мәктәпнең шундый ук залына комбайн һәм тракторлар кертеп куярга мөмкинлек туган. Бу мәктәпнең төрле кабинетларында җиде телевизор бар. Уку программасына кагылышлы тапшыру башлана икән, укучылар аны һичнинди ыгы-зыгысыз тамаша кыла ала.

Монда беренче булып әйтелгән әлеге «Колхоз мәктәптән башлана» дигән хакыйкать хәзер башка колхозларыбызның җитәкчеләренә дә бу өлкәдә җитди эш алып барырга кирәклеген раслады. Әле мәктәптә чакта ук балаларны колхоз эшенә кызыктыру чаралары шактый актив үткәрелә. Председательләр үз колхозларында урта мәктәп булдырырга тырышалар. Бу — гади эш түгел. Яңа урта мәктәп ачу колхоз хисабына бер бина салып бирү белән генә чикләнми. Председатель үз җилкәсенә мең төрле яңа мәшәкатьне алырга, мең җирдә мең төрле җавап тотарга тиеш була. Шуңа да карамастан, районда яңа урта мәктәпләр ачыла. Бу уку елын «Игенче», Киров исемендәге совхоз һәм «Таулар» колхозы балалары да яңа салынган үз урта мәктәпләрендә каршыларлар.

Киров исемендәге совхоз җитәкчеләре дә мәктәп коллективы белән тыгыз элемтәдә тора. Монда тугызынчы классның кырыклап укучысы, укудан аерылмыйча, бозаулар карарга алынганнар. Ике йөзгә якын бозау балалар тәрбиясенә күчкән. Һәр укучы 25 ләп бозау карый. Бу — алар атнага бер-ике көн иртән, дәресләр башланганчы, сәгать 6 га фермага бара, укудан соң тагын сәгать ярым чамасы эшләп кайта дигән сүз. Укучылар бик төгәл график төзегәннәр. Фермада исә аларны өйрәтеп торырга бер остаз бар. Кыенмы бу эш? 9 нчы «Б» классы укучылары Әлфия Гарипова белән Рәмилә Нәгыймова миңа икесе берьюлы:

— Юк! — дип җавап бирделәр.— Без әле фермадагы эштән соң үзешчән сәнгать түгәрәгенә дә йөрибез...

Әлфиясе — шигырь сөйләргә, Рәмилә җырларга ярата икән. Ай азагында балалар хезмәт хакы алалар. Хак дигәннән, комбайнда эшләүче егетләр дә, җәен савымчыларны ял иттерүче кызлар да, узган уку елыннан соң бер ел колхозда эшләргә тәвәккәлләгәннәр дә күп акча алулары белән шапырынырга һич ашыкмыйлар. Дөресен әйтергә кирәк — аларның хезмәт хакы шактый чыга. Җәен комбайнда эшләгән

Сәфәр урта мәктәбе егетләреннән Илнур Кунафиев, мәсәлән, әтисенең комбайнында урдырып — 723 сум, Разил Салихов — 429 сум, Гөлүс Галимәрдәнов 398 сум акча алган. Киров исемендәге совхозның укудан аерылмыйча бозау үстерүче балалары аена 18—20 сумлап хезмәт хакы эшли. Нур Баян исемендәге колхозда сыер саварга калган кызларның керемен тикшереп караган идек — аларныкы да шактый чыга. Фәнүсә Гыйльметдинова җиде айга — 1365 сум, Алия Газетдинова — 1231 сум, Рәҗүдә Төхвәтуллина 1308 сум алганнар. Яшьләрнең күбесе хезмәт хакының күпме булуы белән кызыксынмый да икән. Егетләр хәтта бухгалтериягә дә керми, акчаларын алырга әниләрен генә җибәрәләр.

Аларны күбрәк хезмәттәге ярыш, сынашуда җиңү кызыктыра. «Маяк» колхозыннан Римма Арсланова республиканың яшь савымчылары ярышында беренчелекне яулап алды. Егетләрдән Нияз Идрисов Татарстанның яшь тракторчылары арасында өченче урынга чыкты. Мондый уңышлар балаларны гына түгел, безне дә шатландыра. Акча җыюга кызыгып кына калган бала ата-анасын да, колхозны да кинәндерә алмас иде ул. Бусы — бер. Икенчедән, аларның акчага мөкиббән китмәве безнең еллар буе алып барган тәрбия эшләребезнең дә дөрес юнәлештә икәнлеген күрсәтә. Безгә моны белеп тору бик кирәк, чөнки бу юлда беренче адымнар гына ясалды бит әле. Алда тагын да катлаулы бурычлар тезелгән. Бердәмлегебезне югалтмыйча, ирешелгәннәрдән артык һаваланмыйча, бер-беребезгә ярдәм итәргә әзер торган хәлдә, башкарасы эшләр байтак әле.

Бердәмлеккә кат-кат басым ясавым юктан түгел. Узган ел, һич көтмәгәндә, ата-аналар тарафыннан каршылык сизелде. Кайберләре ачыктан-ачык әйттеләр:

— Авылда үзебезнең чиләнүебез дә житкән, китсеннәр! — дию челәр булды.— Рәхәтләнеп шәһәрдә яшәсеннәр!

Андыйлар хәтта үзенең бөтен тапканын шәһәр җирендә үз урынын таба алмыйча интегеп яшәүче баласына җибәреп торырга да риза. Картлыгын ялгызлыкка хөкем итүе турында да уйламый, кабатлап тик тора: «Бар, балам, кит, калага урнаш!»

1981—1982 уку елын тәмамлаучыларның икенче слетында гыйбрәт итеп сөйләрлек хәл булды. Анда, мәктәпне алтын медальгә тәмамласа да, Нур Баян исемендәге колхозда эшкә калган Рушания Исламованың әнисе чыгыш ясады.

— Мин монда утырган әти-әниләргә берничә сүз әйтер идем,— дип башлап китте ул.— Былтыр, алтын медаль алып, юристлыкка укырга китәргә әзерләнгән кызыбыз: «Мин фермада эшкә калам!» — дип кайтып әйткәч, сабырсызланып еларга тотынган идем. Минем үземнең дә фермада эшләп караганым юк. Алмадай кызымны тиздән тиреская батып эшләргә ничек чыгарып җибәрим, дип, бик кайгырдым. Айлар үтте. Өебездә шушы чордан да рәхәтрәк вакытларны хәтерләмим. Үз күзләрең белән баланның яныпкөеп эшләп йөрүен күрүдән дә ләззәтлерәк кичереш юк икән ул! Раушаниям күзгә күренеп җитдиләнә, кешеләрне танырга өйрәнә, хезмәтнең тәмен татый. Баланың шул адымнарын күреп тору, кирәк чакта киңәш бирү — үзе зур бәхет ул. Без, әле буйнга да утырмаган балабызны ашык-пошык ерак шәһәрләргә озатканда, бик хаталанабыз икән. Бу чыгарылыш укучылары бездән, үзләренең әти-әниләреннән акыллырак булып чыкты...

Мондый чыгыш бик кирәк иде. Чөнки кайбер ата-аналар, балаларын авылда калдырмас өчен, шул дәрәҗәгә барып җитәләр ки, хәтта үзләре дә, йорт-җирләрен таркатып, шәһәргә күчәргә җыендылар. Теләсә нинди югалтуга риза, баласы колхозда гына эшләмәсен, янәсе.

Ата-аналарның бу теләге белән дә санашмыйча ярамый. Аларның күңеле изгелектә бит — балаларын яхшы шартларда яшәтергә тыры-

шалар. Шуны аңлап, без, үз чиратыбызда, колхозда калган балаларның теләк-омтылышларын исәпли башладык. Үзләренә дә мөрәҗәгать иттек: «Әйтегез! — дидек.— Ни телисез? Кулдан килгәнчә ярдәм итәрбез, шәһәр кызларыннан, егетләреннән ким булмассыз!»

Чәчрәп чыгып, үз шартларын тезеп китәрләр дип уйлаган идек тә — юк, алай сабырсызланмадылар. Шулай да акрын-акрын аңлаттылар.

— Әнә, безнең күрше кызы Казаннан елтыр йонлы тун киеп кайткан да әллә кем булып йөри,— ди берсе.

— Аякларында — импортный читекләр! — дип, икенчесе өстәде.

Яшьләрнең заманча киенәселәре килә икән — шул аңлашылды. Районның сәүдә оешмалары аша яшь колхозчыларыбызга һәйбәт туннар, Югославиядә, Чехословакиядә тегелгән аяк киемнәре кайтарттык. Врачларыбыз, парикмахерларыбыз чәчләрен-битләрен, тешләрен-күзләрен, дигәндәй, төзәтеп җибәрделәр. Аерып алып кара син аларны хәзер Казан кызларыннан! Әллә кайсы шәһәрләрдән гастрольгә килгән артистларның концертларына чакыртып кына алабыз үзләрен. Иң алгы рәттә утыралар — хур кызлары диярсең!

Канатландырып җибәргәч, егетләр-кызлар үзләре дә авылны шәһәр кебек үк итәргә тырыша башладылар. Бу җәһәттән кызык бер хәл искә төште. Иске Сәфәр авылындагы яңа культура сараеның вестибюлендә Казандагы Яшьләр үзәге ресторанындагы кебек кечкенә фонтан ясаганнар. Арадан берсе карап-карап торган да:

— Нишләп балыгы юк соң моның? — дигән.— Яшьләр үзәгендәге фонтан бассейнында балыклар йөзеп йөри бит!

Шул сүзне ишетеп калган малайлар йөгерттерел, су буена төшеп киткәннәр дә, инештән олы коштабакны тутырганчы, эт балыгы сөзеп менгәннәр. Икенче көнне карасалар, Иске Сәфәр культура сарае вестибюлендәге бассейнда эреле-ваклы балыклар да йөзеп йөри икән. «Менә хәзер әйтеп кара, кайсы ягы белән Казаннан ким!» янәсе...

Беренче адымнар безне шактый нәрсәгә өйрәтте. Авылда калырга теләк белдергән балалар белән әңгәмәләр үткәргәндә, аларның табигый сәләтләрен ачарга тырышу да бик кирәк икән. Барысы да савымчы яки механизатор гына булмаска да мөмкин бит. Бу яктан Нур Баян исемендәге колхоз җитәкчеләре аеруча сизгер җанлы булып чыктылар. Алар быел колхозда калган кайбер кызларның да механизаторлыкны хуп күрүен белеп алганнар. Кызларга дип, көпчәкле, өр-яңа тракторлар саклап торалар. Таһир исемле егетнең атлар яратуы беленгән. Таһир Ризаев ел саен авылда, Актанышта гына түгел, хәтта Минзәлә, Тукай районнарына барып та ат чабышында да катнаша икән. Чаптарын ел әйләнә, председательдән яшергәли-яшергәли, тәрбияләп тота, ди. Колхозда исә йөздән артык ат бөтенләй кыргыйлыкка чыгып бара. Авыл халкы, мең бәясенә төшүен исәпләп тормый, тизлегенә кызыгып, бер көлтә салам өчен дә, кырга трактор яки машина куа. Атның алыштыргысыз үз урыны, үз рәхәте бар. Нур Баянлылар әнә шул игелекле хайванның элекке абруен кире кайтарырга ниятләп торалар. Бу юлда аларга урта мәктәпне быел тәмамлаган Таһир Ризаев һәм аның берничә дусты ярдәм итәчәк.

Быелгы чыгарылыштан соң колхоз эшенә килүчеләр безне тагын да ныграк сөендерә. Аларның алдында былтыргы апа-абыйларының матур үрнәге бар. Быелгылар бәргәләнмичә, шикләнмичә киләләр. Язын Пучы мәктәбенең 10 класс укучысы Әнзия Ханнанова:

— Без шушы авылда үсеп, урта белем алдык. Инде Туган җиребезгә аз булса да хезмәт итәргә тиешбез. Без бит аңа муеннан бурычлы,— дип сөйләгән иде.

Уйлап карасаң, япь-яшь кыз бала нинди акыллы сүзләр әйткән! Барыбыз да шул фикердә яшәсәк, һәр кеше үзен үстергән Җир алдын-

дагы бурычын, җаваплылыгын һәр даим тоеп торса, бөтен сәләтен, көчен җирне матурайтуга юнәлтсә, тормыш тагын да мулрак, ямьлерәк булыр иде!

Бәхеткә каршы, безнең актанышлылар, бу яктан, мактауга лаек. Хуҗалыкларыбызның иң җаваплы тармакларын, шулай ук район күләм эшләрне үз җиребездә туып үскән, туган ягын ихластан яратучы кадрлар әйдәп бара. Колхозларда да шул ук күренеш. Мәсәлән, Нур Баян исемендәге колхозның председателе Таһир Әхмәев, партия оешмасы секретаре Рифкат Гыйлфанов, парткабинет мөдире Рәсим Шагалиев, баш зоотехнигы Зөлфәт Фәрдиев, баш экономисты Зөһрә Галиева — барысы да Пучы мәктәбен бер үк елда тәмамлаганнар, хәзер югары белем алган һөнәр ияләре. Баш инженер Фирдәвес Ләесов та — аларның яшьтәше.

Һәр тармакта яшьләр үсеп килә. Районның күз өстендә кашы саналган Инсаф Камалетдинов, Ясәви Хөсәенов, Кәрам Гарипов, Гадел Сәләхетдинов кебек өлкән яшьтәге председательләребезнең карусыз хезмәте аларга берникди хикмәтле сүз белән дә төшендереп булмастай хакыйкатьне аңлатып тора. Аларның Актаныш җиренә күрсәткән игелеге буыннан-буынга телдән төшерми сөйләрлек.

Инде менә чагыштырмача яшь тоелган кадрларыбызга да алмаш әзерләү мәсьәләсе килеп басты. Эзләнүләр безне мәктәпкә илтте, һәм, ышанып әйтергә кирәк, ялгышмадык. Сәфәр укучыларының үзләренә әләм итеп язып элгән сүзләре бик дөрес: колхоз мәктәптән башлана! Б а ш л а н а! Күркәм башлангычны үстереп җибәрү, чыныктыру, рухи дөньябызның ихтыяҗына әйләндерү, сәнгатьтә сурәтләү, җырларда яңгырату — безнең бурыч.

# Кол Галинең тууына 800 ел

ЮНЕСКО (БМОның белем, фән һәм культура мәсьәләләре буенча махсус оешмасы) тарафыннан Парижда төрле телләрдә чыгарыла торган «Яңалыклар» исемле информацион бюллетеньнең быелгы 5 санында тарих фәннәре докторы профессор М. Г. Госмановның шагыйрь Кол Галигә багышланган мәкаләсе басылып чыкты. Түбәндә шул мәкаләне кереш сүзе белән бергә тәкъдим итәбез.

*1983 елда Идел буендагы төрки телле халыкларның урта гасырларда яшәгән шагыйре, болгар-татар язма поэзиясенә нигез салучы Кол Галинең туына 800 ел тулу билгеләп үтелә. Шагыйрь — мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» поэмасының авторы. Бу поэманың кульъязма нөсхәләре Ленинградта, Казанда, Берлинда, Дрезденда һәм Закавказьеның гыйльми үзәкләрендә саклана.*

## Миркасыйм Госманов

# КОЛ ГАЛИ—ХАЛЫК ХӘТЕРЕНДӘ СИГЕЗ ГАСЫР

Ул XIII гасырның беренче яртысындагы зур давыллы вакыйгалар чорында иҗат иткән. Бу чорда Чыңгыз хан яуларының һөҗүмнәре нәтиҗәсендә җир йөзеннән күпләгән шәһәрләр югала, Евразиянең этно-политик картасы да яңадан төзелә.

Шагыйрьнең тормышы хакында әзек-әзек кенә мәгълүматлар сакланып калган.

Аның исеме Кол Гали була. Ул Болгарда, Хәрәземдә белем ала, мөселман Көнчыгышының мәдәни үзәкләренә сәяхәтләр кыла. Шагыйрьнең үлеме 1236 елга — «Бөек шәһәр» Биләр каласын Батухан гаскәрләре яулап алган вакытка туры килә дип уйлыйлар...

Шагыйрьнең бер әсәре — Урта гасырлар Идел буеның иң күренекле иҗат җимеше булган «Кыйссаи Йосыф» поэмасы — тулысынча сакланып калган һәм ул татар халкының күңелендә, йөрәгендә иң мактаулы урын алган. Археографик тикшеренүләр күрсәткәнчә, Идел буеның һәм Урал алдының татарлар яшәгән һәм хәзер дә яши торган җирләрендә «Кыйссаи Йосыф» поэмасының басма яисә кульъязма нөсхәләре сакланмаган бер генә йорт та булмаган диярлек. Соңгы 25 ел дәвамында, Идел буенда һәм Урал ягы төбәкләрендә үткәрелгән гыйльми экспедицияләр нәтиҗәсендә, поэманың 100 гә якын яңа күчермәләре табылды; алар XVIII—XIX гасырларда элеккерәк язылган үрнәкләрдән күчереп алынганнар.

Татарлар арасында бу әсәр басма рәвештә дә киң таралган: 1839 елдан башлап ул тулы килеш 70 мәртәбәдән күбрәк басылган.

Әсәрнең сюжетына Коръәннең 12 нче сүрәсендә китерелгән хикәя — Ягъкуб пәйгамбәр хәлләре һәм аның улы Йосыфның үз туганнарының көнчелеге аркасында җәфалар чигүе — нигез итеп алынган.

«Кыйссаи Йосыф» поэмасының халыкта гаҗәп киң таралуын аның төрки телләрдә төрле вариантлары барлыкка килүе раслый. Кол Гали поэмасы, үзенең чагыштырмача архаиклыгына карамастан, татарлар арасында иң популяр һәм теле, поэтик агышы ягыннан аңлаешлы, халыкның милли рухына якын әсәр булып кала бирә.

Әсәрнең теле аңа киң катлау укучылар һәм тыңлаучылар игътибарын юларга мөмкинлек тудырса, поэманың мавыктыргыч эчтәлеге, автор карашының гуманизмы һәм демократиклыгы аны халыкка рухи яктан якын иткән.

Поэманың үзәгендә ил белән идарә итүче хөкемдар һәм халык иминлеге проблемасы тора. Автор әсәрнең төп герое Йосыф образы аша хөкемдар кешенең нинди сыйфатларга ия булырга тиешлеген күрсәтергә тырыша. Ул чор җәмгыятьтәге гаделлек барыннан да элек хөкемдарга бәйле булганлыктан, ул, шагыйрь фикеренчә, иң башта рухи яктан күркәм сыйфатка, шулай ук зур акылга, алдан күрә алу сәләтенә, баһадирларча көчкә һәм үз халкына карата тугрылык хисенә ия булырга тиеш. Кол Галинең телендә Йосыфка карата тугрылыклы, хыянәтсез дигән мәгънәдәге «сыйтдыйк» сүзе юкка гына бик еш кулланылмый. Әсәрдә Йосыф чыннан да бик тугрылыклы итеп тасвирлана: ул тәңре алдында да, карт атасына мөнәсәбәттә дә, үзенең җәмгыять каршындагы бурычына, ниһаять, Зөләйхага карата да ахыргача тугры булып кала.

Аның җәмгыять каршындагы тугрылыгы Мисырда зур кытлык хөкем сөргән вакытта ил-халык турында кайгыртучанлыгы аша гәүдәләнә. Атасына тугры калуы исә Йосыфны озак еллар буе михнәт чигәргә, рәхәтлекләрдән баш тартырга мәҗбүр итә. Чөнки, аның инануынча, бары тик Йосыфның чыдам һәм түземлелеге генә әтисенең газапларын җиңеләйтә ала икән. Әтисен һаман истә тотып яшәү аны түбәнлекләрдән, гөнаһлардан саклап кала...

Үзен кол итеп сатып алган Мисыр патшасына да ул тугрылык саклый; шуңа күрә дә Йосыф гүзәл Зөләйханың аздыргыч тәкъдимнәрен кире кага. Инде Зөләйханың никахлы ире булгач, Йосыф гомеренең ахырынача аңа тугры кала, шәрык хөкемдарларына хас булганча җариялар тотмый, Зөләйха үлгәннән соң да яңадан өйләнми, бәлки, тол килеш кала биреп, балаларын тәрбияләү белән шөгыльләнә...

Поэманың күп кенә сәхифәләре мәхәббәт темасын поэтик һәм фәлсәфи яктан ачуга багышланган. Кол Гали әсәрендә мәхәббәт мистик планда бирелми. Дәртле, ихлас дөньяви мәхәббәтнең гәүдәләнеше сыйфатында Зөләйха тасвирлана. Төшендә күргәннән соң аның Йосыфка гашыйк булуын, күп газапларга тарыса да, барыбер үз максатына ирешә алуын, шулай ук гашыйк булган гүзәл кызның кайнар хисләрен шагыйрь гаҗәп оста сурәтли; Зөләйханың сөйгән кешесенә багышланган сүзләре шагыйрәнә ихлас яңгырый.

Кол Гали, шулай итеп, кешенең дөньяви мәхәббәткә хаклы булуын раслый. Әмма, ди ул, чын бәхеткә кеше бары пакь вөҗдан, намус белән генә ирешә ала. Тик, Зөләйханың бер кат ялгышканы шикелле, хыянәт юлына басарга ярамый...

Аталар һәм балалар мөнәсәбәте — поэманың үзәгендә торган төп мәсьәләләрнең берсе. Галимнәр хаклы рәвештә билгеләп үткәнчә, поэманың шәрык халыкларында таралган вариантларында бу момент традицион характерга ия. Әмма Кол Гали поэмасында ата-аналар белән балалар арасындагы мәхәббәт һәм ата кешенең бәхеткә хокукы мәсьәләсе социаль яктан калкытып куела, чын-чыннан кешелекле рәвештә хәл кылына. Сюжет агышы буенча Ягкубның иң сөекле улы урлана һәм коллыкка сатыла. Ләкин Ягкубка мондый кайгы очраклы гына килми: бу җәза аңар Йосыфны имезүче хатынның нарасый улын коллыкка сатып җибәргәнлеге өчен илаһи каргыш сыйфатында бирелә.

Ләкин Ягкубның менә шулай җәзалануын сурәтләгәндә Кол Гали схематизмга батмый. Ата газабын автор бик кешелекле рәвештә ача. Кайчакларын хәтта Ягкуб бер үзе генә газапланмый, бәлки аның белән бергә әйләнә-тирәсендәгеләр дә газап чигә. Бу юнәлештә поэмадагы көчеген югалткан ана бүренең кайгысын тасвирлау да гаять гыйбрәтле. Мөгаен, менә шушы дулкынландыргыч хәлләр һәм аларның бик кешелекле төстә яктыртылуы «Кыйссаи Йосыф»ны татар укучыларының иң яраткан әсәрләренең берсенә әверелдергәндер. Поэманың телдән-телгә күчә килгән күп вариантлары күрсәткәнчә, халыкта әсәрдәге Ягкуб — Йосыф сызыгына аерата әһәмият бирелгән. Шуңа күрә халык еш кына очракларда әсәргә автор тарафыннан

куелган «Кыйссаи Йосыф» исемне үзгәртеп, аны «Йосыф китабы» яки «Ягкуб һәм Йосыф китабы» дип атаган. Шулай ук әсәрнең аерым бүлекләрен яттан сөйләгәннәр, аның өзекләрен кич утырган вакытларда көйләгәннәр; мәдрәсәләрдә исә бу китапны уку әсбабы итеп тә файдаланганнар.

Көйләп уку турында сүз чыккач, шуны да искәртеп үтик: дәртле Зөләйха белән тугрылыклы Йосыф образлары Казан татарларының җыр репертуарларында киң урын алган — алар хакында аерым дүртьюллыклар да, сюжетлы җырлар да иҗат ителгән. Кол Гали тудырган образларның фольклорга шулай тирән үтеп керүе авторның әсәр тукымасына борынгы фольклор һәм этнографик мотивларны мул итеп сеңдерүе белән аңлатылса кирәк.

Кол Гали әсәрендәге Зөләйха үз сөйгәне Йосыфның чәчен үнике толымга бүлеп үрә. Ә мондый күренеш — ирләрнең толым йөртүләре — төркиләрдә ислам динен кабул ителгәнче таралган сыйфат иде. Борынгы төркиләр кеше үлгәннән соң аның җаны кош булып очып китә дип ышанганнар. Аларның мондый инанулары борынгы чор төрки таш сыннарында да чагылыш тапкан: мәрхүмнең кыяфәте күкрәгенә кош утырткан килеш сурәтләнгән. Ягкуб аксакалның үлемен тасвирлаганда Кол Гали шундый ук традицион образга мөрәҗәгать итә:

Шәриф тәндин аерылды гъәзиз җаны,—
Кош(к)а биңзәп оҗмах таба очар имди.

Бу бик борынгы мотив Идел буе төрки-татар шагыйрьләренең күбесе (Хәссам Кятиб, Мөхәммәдьяр һ. б.) иҗатында кабатлана-кабатлана, егерменче гасырга кадәр килә һәм яңа чорның бөек шагыйре Габдулла Тукай иҗатында исә тирән социаль көч белән яңгырый:

Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы,—
Шат яратса да, җиһанга ят яраткан раббысы...

Үз иҗатында мөселманча китап традицияләре белән җирле төрки халыкларның фольклор мотивларын органик рәвештә бергә кушып җибәргән Урта гасырлар шагыйре Кол Галинең исеме менә инде сигезенче гасыр татар халкының күңел түрендә яши — халык характеры оешуда аның әсәре шифалы чишмә кебек чыганак булган.

## Нурихан Фәттах

# КОЛ ГАЛИ

ӨЧ ПӘРДӘЛЕ ТРАГЕДИЯ

**Катнашалар:**

Гали — болгар шагыйре.
Ураз бәк — кыпчакларның Бурлы ыруы башы.
Чәчәк — Ураз бәк кызы.
Энҗе бикә.
Хаҗи бәк — Галинең агасы.
Актай — баш карачы (вәзир).
Инәл кам — Бурлы ыруында дин-йола башлыгы (шаман).
Беренче юлчы (Шәмсетдин).
Икенче юлчы.
Өченче юлчы.
Ярмыш — Болгар илчесе.
Тукаш — сәүдәгәр.
Күгеш — Хаҗи бәкнең өй-агасы.
Бикә — Ураз бәкнең хатыны.

Аксакаллар, илчеләр, сакчылар, кораллы ирләр, хезмәтче хатыннар, хан кешесе, улагчы (ашыгыч хәбәр китерүче).

Вакыйганың урыны — урта гасырдагы Болгар дәүләте һәм Кыпчак далалары, вакыты — монгол яулары чоры, ягъни 1220—30 еллар.

**БАШЛАУ**

Гали шигырь укый:
Без — тузан бөртеге Мәңгелек юлында.
Тузанның гомере — Газраил кулында.

Әйтегез, ни мәгънә дөньяга туудан,
Билгесез бер тузан бөртеге булудан?!

Кайгырма, Кол Гали, зарланма язмыштан —
Тузаннар мең төрле матдәдән яралган:

Берәүләр түгәләр агачтан я таштан,
Башкалар ялкыннан бүленеп таралган.

Кайгырма, туганым, зарланма язмыштан,
Бик кыска гомерле булсаң да тумыштан.

Кызганмый үзеңне балкып ян һәм яндыр,
Гасырлар күгендә ялкынлы эз калдыр!

Буыннан буынга нәселең таралсын,
Үтердем аны дип Газраил алдансын.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### Беренче күренеш

**Киез өй эче. Өй уртасында, жир идәндә учак яна. Учак янында Гали утыра. Ул нидер яза. Бер арада эшеннән туктый да тышкы якка колак салып тыңлап тора.**

Гали *(тора, йөренә, үз алдына сөйләнә).*
Тышта төн. Тавышлар тынган.
Канат җәйгән йокы һәр якка.
Тик мин генә уяу, байгыш сыман,—
Йокы качты миннән еракка.
Тышта төн. Учаклар сүнгән.
Караңгылык хаким бу җирдә.
Тик бер учак яна ялкынланып
Минем өйдә... ярлы бер өйдә.
Җирдә төн. Йолдызлар ерак.
Томаналык, кыргый торгынлык.
Тик яралы күңелемдә дәрли
Уй-хыяллар, белми тынгылык.
*(Көрсенә.)*
Кемгә кирәк бу далада, Гали,
Ялгыз учак, яралы күңел?
*(Түшәмдәге төннек аша күккә карый.)* Кешеләр дә, йолдызлар да күрми сине, белми сине, шагыйрь Гали. Йолдызлар — ерак, кешеләр — йокыда. *(Яңадан йөренә.)* Юк, ялгышма, Гали! Башлаган эшеңне син тәмамларга тиеш! *(Учак янына утыра, яза, сыза.)*

**Чәчәк керә. Кыюсыз гына атлап, елмаеп учакка якынлаша. Арттан Галинең күзләрен буа.**

Гали. Кем бу? Кем бу?! Энҗе, синме?
Саташаммы әллә югыйсә?!

Чәчәк *(корт чаккандай кулын тартып ала. Тешенке).* Мин Энҗе түгел, мин — Чәчәк.

Гали. Чәчәк? Син? Бу вакытта?!

Чәчәк. Син миңа икенче тапкыр «Энҗе» дип эндәштең. Кем ул Энҗе?

Гали. Чәчәк... Алсу чәчәк, тиңсез чәчәк!
Нидер булган сиңа. Ни булды?

Чәчәк. Ни булганын мин үзем дә белмим. Күзгә йокы керми. Син безнең Бурлы ыруына килеп кушылганнан бирле көннең яме качты, төннең тынычлыгы качты. Инал кам сине бозучы, күз буучы ди.

Гали. Инал кам?

Чәчәк. Мөселманнар алар барысы да бозучылар, күз буучылар, ди. Кешеләрне, терлекләрне бозу өчен төне буе учак ягып, өендә нииндидер яман эшләр эшли, ди синең турыда.

Гали *(аягүрә баса).* Син шуңа ышандыңмы?

Чәчәк. Белмим. Минем үз күзләрем белән күрәсем килде.

Гали. Минем күз буганныммы?

Чәчәк. Синең, учак ягып, нидер эшләгәнеңне.

Гали *(кәгазь-каләмен Чәчәккә күрсәтә).* Менә, күр — мин язам.

Чәчәк. Ни язасың?

Гали. Кыйсса... җыру.

Чәчәк *(ак кәгазьне караштырып).* Алай икән. Нәрсә турында соң ул синең җыруың? Батырлар турындамы, бер-берсен яратышкан кыз белән егет турындамы?

Гали. Минем җыру Йосыф атлы җегет белән Зөләйха атлы кыз турында.

Чәчәк. Алар яратышалармы?

Гали. Яратышалар.

Чәчәк. Кызы Зөләйхамы? Энҗе кем соң алайса?

Гали. Энҗе... Энҗе ул... сиңа охшаган бер болгар кызы.

Чәчәк. Син аны яратасыңмы?

Гали. Мин аны яраттым, Чәчәк!

Чәчәк. Кайда соң ул болгар кызы?—

Гали. Ул еракта, моннан бик еракта!
Упкын ята безнең арада.

Чәчәк. Син аны яратасыңмы?

Гали. Карале, әйдәле ул турыда сөйләшмик, Чәчәк.

**Тышта, якында гына күк күкри, яшен яшьнәп китә. Чәчәк, куркып, ирексездән Галигә сыена. Икесе дә төннек аша күккә карыйлар.**

Чәчәк. Мин куркам. Яшен нясенең кемгәдер ачуы бар. Сине генә сукмаса ярар иде, Гали! Төннегеңне дә япмагансың, ичмасам.

Гали. Нишләп мине генә сугар икән соң ул? Сукса, икебезне дә...

Чәчәк *(коты алынып)*. Ни сөйлисең, Гали?! Тәңре каршында минем бер языгым да юк.

Гали. Нишләп минеке бар дип уйлыйсың?

Чәчәк. Мин уйламыйм, Инәл кам әйтә.

Гали. Ул шулай гел мине яманлыймыни?

Чәчәк. Ул сине яратмый, Гали. Ул сиңа каршы атамны да котырта.

Гали. Атаң... Ураз бәк нәрсә ди?

Чәчәк. Ул да сине өнәп бетерми. Хәрәзем ханы Мөхәммәт солтан кыпчакларны жиңгәч, Сугнакны туздыргач, ул бигрәк тә ачулы сезгә.

Гали. Мөхәммәт солтанның Сугнакны туздыруына минем янсә башка болгарларның ни катнашы бар?

Чәчәк. Мин анысын белмим. Мин бернәрсә дә белмим, Гали! Алар сине мөселманнарның яшерен шымчысы дип уйлыйлар.

Гали. Менә сиңа кирәк булса!

Чәчәк. Кач син, Гали, моннан! Кач тизрәк!

Гали. Кыпчакларга каршы. Ураз бәккә каршы мин берниндн яшерен эш алып бармыйм. Шикләнәләр икән, тикшерсеннәр, сорашсыннар.

Чәчәк. Тикшерә башлагач, соң булыр. Инәл камга беркем каршы килә алмый. Ул сиңа күптән теш кайрый, Гали!

Гали. Беләм. Очрашканда ул мине күрми узып китә.

Чәчәк. Гали, качыйк икәүләп! Ишетәсеңме, Гали, мин синең мәңгелек юлдашың булырмын!

Гали *(яратып, иркәләп)*.

Карлыгачның канатыдай кашларың бар,
Сәйләннән сыман тезләп торур тешләрең бар,
Ефәк сыман йомшак дәхи чәчләрең бар,—
Сине күрсә тотлыгадыр телем имди!
Балкыр иде бәхет нуры, булсак бергә,
Мәхәббәтнең сарайларын корсак бергә!
Ләкин язмыш аяк чала һәрчак безгә,
Нихәл итим — вөждан кушмый андый эшкә!

Чәчәк *(читкә тайпыла)*. Сез, болгарлар, барыгыз да белекле, укымышлы. Яратышу турында сез әнә нинди жырулар чыгарасыз — үзегезнең күңелегез таш кебек!

Гали *(юатмакчы була)*. Туктале, тукта, Чәчәк...

Чәчәк *(кырыс)*. Туктыйсы юк! Кара аны, иртәгә соң була күрмәсен! Сау бул, жыручы. *(Ишеккә ташлана, туктый, кинәт жылап жибәрә. Бик каты итеп күк күкри. Жылаудан туктап, Галигә борылып карый.)* Мине Инәл камга кияүгә бирмә келиләр! *(Жылый-жылый чыгып китә.)*

Гали. Чәчәк! *(Артыннан ташлана, туктый, кире борыла. Каты итеп тагын күк күкри.)*

## Икенче күренеш

Гали.

Килде, керде. Тынычлыкны бозды.
Котны алды, татлы шом салды!
Бар нәрсәнең өсте аска килде,
Күңелемне биләде-алды.

*(Йөренә.)*

Иртә таңнан көтү куасың бар,—
Житәр, Гали, ташла эшеңне.

*(Кәгазь-каләмен жыештыра, урын-жир әзерли башлый.)*

**Кинәт тышта эт өргән тавышлар ишетелә. Кемнәрдер ишеккә якынлаша. Гали сагаеп тыңлый.**

Тыштан тавыш. Өйдәләрме? Адашкан юлчыларны төн кунарга кертсәңезче?

**Гали ишек янына килә, тыңлый.**

Гали *(үзалдына)*. Килеп тә життеләрмени?! Кемнәр? Кемнәр генә булмасын, сак булырга кирәк, Гали. *(Идәндәге төргәкләр арасыннан кылычын ала, биленә тага, озын чапан итәге белән каплап куя.)*

Тыштан тавыш. Без — юлаучылар. Барлыгы өч кеше. Арыдык, ачыктык, юлны югалттык.

Гали *(ишек артындагы кешеләргә)*. Ишек ачык — түрдән узыгыз, юлаучылар. Өем тар, күңелем иркен. Яхшы кешеләргә учагым ягулы, казаным асулы. Яман кешеләргә ут та юк, ит тә юк. Яман кешенең юлы читтән узсын.

**Ишектән бер-бер артлы өч ир кеше керә. Өсләрендә озын киемнәр, билләрендә ян-**

чык, кыныпы пычак ише нәрсәләр. Буйсыну белдереп, кулларын кушыралар, Гали алдында баш ияләр.

Беренче юлчы. Без — мөселманнармыз. Бездән уемызда яманлык имәс.

Гали. Түрдән узыгыз, яхшы кунаклар.

Беренче юлчы. Илегез имин улсын, терлек-туарыгыз чук улсын, тук улсын. Безгә монда Бурлы ыруы җәйләүләре булырга тиеш дигәннәр ирде. Без инде өч көн, өч төн киләмез. Икенче көн авызымызга бер тәгам ризык алганымыз юк. Атларымыз арыды, үземез үләр чиктә. Карангыда ут күрдек тә килдек. Кемнең җәйләве, кемнең ялгыз өе бу, мәрхәмәтле хуҗа?

Гали. Сез эзләгән Бурлы ыруының җәйләве бу, юлаучы. Мин Бурлы ыруының башы Ураз бәкнең карасы Гали торырмын.

Беренче юлчы. Гали дисеңме? Син дә мөселманмени?

Икенче юлчы. Менә куаныч!

Гали. Әйе, мөселманмын. Ләкин минем мөселманлыгымнан кемгә — куаныч, кемгә — юаныч.

Беренче юлчы. Мөселман кешенең динсез, кыргый кыпчакның карасы булуы — күңелсез хәлдер.

Гали. Миңа чыннан да күңелсез иде. Сез килгәч, күңелле булып китте. Әйдәгез, утырыгыз, сөйләгез — каян киләсез, кая барасыз? Ниләр күрдегез, ниләр ишеттегез? *(Тиз-тиз генә казан аса, учак янына табын әзерли, вак-төяк савыт-сабалар китереп куя. Ул арада юлчылар учак тирәсенә утырышалар.)*

Беренче юлчы. Без күргәнде сөйләргә сүз җитмәс, Гали туган.

Икенче юлчы. Без сөйләгәннәрне тыңларга түземлелегең җитмәс, Гали туган.

Өченче юлчы. Без сөйләгәндәрде тыңласаң, күңелең күтәрелер, дип әйтеп булмайды.

**Гали турсыктан, ягъни тире капчыктан агач касәләргә кымыз агыза.**

Гали. Ярый, кунаклар, сезнең белән очрашу хөрмәтенә кечкенә туй ясап алыйк. Өемдә ни бар — барысы да сезнең алда. Сез сөйләячәк сүзләр күңелсез булганлыктан, казанда ит пешкәнче, күңелләрне кымыз белән күтәрә торыйк. *(Кымызны әүәр алдыннан беразын учакка түгә, эчә, касәне Беренче юлчыга бирә.)*

Беренче юлчы *(касәне ала, кымызның беразын учакка сибә, эчә, касәне Икенче юлчыга бирә)*. Тәмле телең, яхшы сыең өчен рәхмәт, хуҗа!

Икенче юлчы *(касәне ала, кымызның беразын учакка сибә, авыз итә, касәне Өченче юлчыга бирә)*. Җакшы! Булуы житкән!

Өченче юлчы *(касәне ала, кымызның беразын учакка сибә, эчеп бетерә, касәне Галигә бирә)*. Ай-йай, күз алдары яктырып кетде!

Гали *(касәгә яңадан кымыз агыза, эчә дә Беренче юлчыга бирә)*. Берне авыз иткәч, күз алларыгыз яктырды, икенчене авыз иткәч, телләрегез чишелсен.

Беренче юлчы *(эчә, иптәшенә бирә)*. Син, Гали туган, безнең телләрне чишәргә ашыкма. Тыныч сәгатьләрең озаккарак сузылсын.

Гали. Сез, юлаучылар, бик серле сөйләшәсез. Шулай да кемнәр сез — инде әйтсәгез дә ярыйдыр?

Беренче юлчы *(Галигә текәлеп карый)*. Гали! Син үзең кем?

Гали *(сискәнеп китә, нидер сизенеп, шулай ук Беренче юлчыга текәлеп карый)*. Мин әйттем: мин Ураз бәкнең карасы Гали торырмын, дидем.

Беренче юлчы. Анысын ишеттек. Минем уйлавымча, син — Ураз бәкнең карасы Гали — Болгар ханының Мәликә хатыннан туган төпчек улы торырсың!

Икенче юлчы. Болгар ханының дисеңме?

Өченче юлчы. Ой-бой! Теге батыр Галиде әйтәсеңме?

Гали *(кулыннан әйбере төшеп китә)*. Тс-с, кычкырып сөйләшмәгез! Каяле, ишек артында берәрсе юк микән... *(Тора, кунаклардан читләшә, чапан итәге астыннан кылычын тартып чыгара, серле юлчылар каршына килеп баса.)* Әйе, мин — Ураз бәкнең карасы — Болгар ханының төпчек углы торырмын. Агам Хаҗи бәкнең мәкере аркасында миңа яла якпылар, атама каршы баш күтәрергә ниятләүдә гаепләп, мине туган илемнән качарга мәҗбүр иттеләр. Минем кемлегемне монда беркем белми. Белмәскә тиеш. Төшендегезме? Инде әйтегез: өчегезне берьюлы чабып ташлыйммы, әллә берәм-берәм чапсам да ярармы?

Беренче юлчы. Гали! Гали углан! Чынмы бу? Ышанмыйм, ышанасы килми. Я алла, я тәңрем, нинди кыямәт көннәре килде безгә? Аксөякләрнең кадере калмады, бар дөньяга коллар, кыргыйлар баш булды. Мин дә синең кебек үк туган иленнән... Болгардан качып киткән бәхетсез бәндәмен... казначы Сәйфетдин углы Шәмсетдин торырмын. Танысыңмы, Гали?

Гали. Туктале, тукта... Шәмсетдин? *(Ныгытып карый.)* Әйе шул, Шәмсетдин!

Шәмсетдин. Казна байлыгын үзләштергән дип, минем атама да ялган гаеп тактылар. Атамны яргуламак[1] булдылар. Котылу юлы калмагач, караңгы бер төндә каекларга төялдек тә...

Гали. Беләм! Барысы да истә. Моннан биш-алты ел чамасы әлек булды бу хәлләр.

Шәмсетдин. Дөрес, Гали углан!

Гали. Сез качып киткәннән соң ике-өч ел үткәч, хан сезне аклады бугай.

Шәмсетдин. Безне?! Барыбызны дамы?!

Гали. Сине дә ике энеңне ахрысы. Атаңны акламадылар.

Шәмсетдин. Я алла, я тәңрем! Шундый зур куанычтан кинәт йөрәгем тукталгандай булды. Мин әле ишетмәгән идем. Атам инде күптән җир куенында. Акласа, аны бары тәңре генә аклар. Ике энем шулай ук теге дөньяда. Бу дөньяда бары мин генә калдым — куанычымның чиге-чамасы юк, Гали!

Гали. Болай булгач, әйдәгез әле туйны яңадан башлап җибәрик.

**Учак янына утырышалар, яңадан чиратлашып кымыз эчәләр.**

Гали. Син, Шәмсетдин, кая юл тотасың?

Шәмсетдин. Әлегә тикле кая барырымны үзем дә белми идем, хәзер — туптуры Болгарга! Бары Болгарга гына!

Гали *(хыялланып)*. Болгар... Син нинди бәхетле, Шәмсетдин!

Шәмсетдин. Карале, Гали туган, безнең Чирмешән яры буендагы ике катлы таш өебез әле дә исән микән? Кире бирерләр микән?

Гали. Аклагач, мөгаен, бирерләр.

Шәмсетдин. Бирмәсәләр дә кайгырмыйм. Баш кына исән булсын! Баш исән булу кирәк, Гали туган, баш! Кешегә бу дөньяда шуннан башка берни кирәкми. Менә мин шуны аңладым. Байлык, дәрәҗә, сарайлар, хатын-кызлар, бала-чага, киемсалым... — барысы да чүп-чар, көл-тузан. Алар бер көн эчендә юкка чыгарга мөмкин. Ничек тә үзеңне сакларга кирәк. Мин — галим. Үргәнечтә шәкертләргә дин гыйлеме үгрәттем. Болгарга, ханбалыкка[2] кайткач, мәдрәсә ачам, балалар укытам.

Икенче юлчы. Укыта алырсың микән?

Өченче юлчы. Булмас инде ул мәдрәсәләр ачып балалар укыту. Дөньяның рәте китте. Йәэҗүҗ-Мәэҗүҗ кузгалды.

Шәмсетдин *(кинәт сүрелеп кала, төшенкелеккә бирелә)*. Болар — минем юлдашлар, Гали. Без бергә... качтык.

Гали. Каян? Ник? Моннан качтыгыз, аннан качтыгыз. Сез качтыгыз, мин качтым. Кем генә качмыйча, курыкмыйча яши соң бу дөньяда?

Шәмсетдин. Гомере буена кеше үлемнән качып яши. Синең сыман без дә үлемнән качтык, Гали.

Икенче юлчы. Без дәһшәттән качтык, Гали! Чин-Кытай ягыннан Чыңгыз атлы илбасар калыкты.

Өченче юлчы. Бохара, Сәмәрканд, Үргәнеч... — барлык шәһәрләр, авыллар җир белән тигезләнде. Кеше сөякләреннән таглар өелде, Гали!

Шәмсетдин. Җир йөзендә Чыңгыз ханга каршы торырлык көч юк, Гали. Хәрәзем ханы Мөхәммәт солтан, илен-көнен ташлап, чирүен[1], хатыннарын, балаларын ташлап, каядыр көньякка качып китте. Углы Җәләлетдин Чыңгызга каршы торырга тырышып карады,— булдыралмады.

Гали. Монда ишетелгәләгән имеш-мимешләр, алайса, чын?

Шәмсетдин. Кая ул чын булмаган! Үргәнечне җиде ай камап тордылар. Алдылар, таладылар, җимерделәр. Карт анамны, өлкән хатынымны күз алдымда кылыч белән чаптылар, яшь хатынымны, буй җиткән кызымны күз алдымда мәсхәрә иттеләр, Гали! Биш яшьлек углымны сөңге башына кадап, янган утка ыргыттылар, Гали! Анысы да күз алдымда булды. Чытырдап яндыи... кара күмергә, көлгә калганчы, Гали! Төнлә төшләремә керә, саташып кычкырып уянам. Кемдер минем яшерелгән бик күп алтыным бар дип әйткән — шуны таптырдылар. Ябып тоттылар. Төнлә сакчыларны алдап качтым. Колак төбемдә туктаусыз җылаган, ялварган тавышлар ишетелә. Кайчакларда акылдан шашардай булам!

Гали. Аларны син безнең якларга да килеп җитәрләр, дип уйлыйсыңмыни, Шәмсетдин?

Шәмсетдин. Кая ул җитмәгән! Алар кояш чыгыштан кояш батышка тикле барлык илләрне-йортларны басып алмакчылар, барлык халыкларны үзләренә буйсындырмакчылар. Каршылык күрсәткәннәрне алар

---

[1] Яргулау — хөкем итү.
[2] Ханбалык — башкала.

[1] Чирү — гаскәр

бернинди кызганусыз юк итәләр, бары үзләре теләп буйсынганнарны гына исән калдыралар.

Гали. Аңлашыла. Барча дошман шулай итә: каршылык күрсәткәннәрне үтерә, каршылык күрсәтмәгәнне исән калдыра. Мөхәммәт солтан сыман, бар нәрсәне ташлап, бары үз башыны коткару өчен генә качып йөрсән, дошман тагын да ныграк кыюлана, оятсызлана.

Шәмсетдин. Алар дошман гына түгел, алар — динсезләр, кыргыйлар! Алар яшен ташы кебек, алар — Нажагай[1] кебек!

Икенче юлчы. Алар җил-давыл кебек, язгы ташу кебек!

Өченче юлчы. Аларга каршы торырдай көч юк дөньяда!

Гали *(аягүрә баса, ике куллап кылычына таяна)*. Барлык кешеләрнең котын алу өчен яу алдыннан сезнең кебек коткычыларны җибәрәләр. Менә шулай сөйләнеп, сез Кыпчак даласында коткы таратасыз. Хәзер Болгарга кайтып, сез анда да шушы ук сүзләрне сөйләячәксез...

Шәмсетдин. Ниткән коткы булсын? Без күргәнне сөйлибез!

Гали. Күргәнне төрлечә сөйләргә була. Туктаган бер җирдә әлегечә шомлы итеп сөйләсәгез, дошманга сез алдан ук җиңү яулыйсыз. Моның өчен сезнең башыгызны чаптырырга кирәк!

**Шәмсетдин кинәт билендәге пычагына тотына. Ике юлчы да аякларына басалар, коралларына тотыналар.**

Шәмсетдин *(калтыранып)*. Минем башны... син... чабарга җыенмыйсыңдыр ич, көтүче Гали?

Гали *(үз-үзен көчкә тыеп)*. Юк, мин синең башыңны чабарга җыенмыйм, казна талап качкан Сәйфетдин углы Шәмсетдин. Чүбек тутырган кабак башың үзенә булсын. Яудан синең котың алынган, ихтыярың сынган. Мин сине аңлыйм, шунлыктан синең түпаслыгыңны кичерәм. Ләкин син шуны да онытма: җир йөзендә Сәмәрканд, Бохара, Үргәнечләр генә түгел, синең туган шәһәрең Бөек Булгар бар, Суар, Ашлы бар, Җукәтаулар, Ташкирмәннәр бар. Безнең уртак йортыбыз нзге Болгар бар, иксезчиксез далаларны биләгән кыпчаклар бар. Тагын да арырак китсән, Урыс бар, Кафтау, Франк бар. Җимерелгән, таланган Хәрәзем шәһәрләре турында тыңлаганда, мин менә шуларны уйладым, Шәмсетдин!

Шәмсетдин *(мыскыл белән)*. Уйласаң да, уйламасаң да, син инде берни дә кыра алмассың, көтүче Гали. Синең эшең беткән. Болгар турында атаң кайгыртсын.

Гали. Шәмсетдин! Ничек телең бара?!

Шәмсетдин. Үз башың турында уйласаң, синең өчен тагын да яхшырак булыр, көтүче Гали.

Гали *(ярсып)*. Гөнаһлы итмә — сыпыр яхшы чакта!

Шәмсетдин *(ишеккә таба чигенеп)*. Син нәрсә? Ярар, кыздык, бетте. Әйттем нә кайттым.

Гали *(Шәмсетдиннең юлдашларына карап)*. Сез дә! Өчегез дә! Исән чакта...

Шәмсетдин *(йомшап, ялагайланып)*. Мондый вакытта яхшы адәм этен дә куалап чыгармас.

Икенче юлчы *(ишеккә таба чигенә)*. Синең әле чын яуны күргәнең юктыр, Гали.

Өченче юлчы *(ишеккә таба чигенә)*. Күрергә язмасын, ходай!

Гали *(кылычын җайлап тотып)*. Саныйм: бер, ике...

Өченче юлчы *(учак өстендәге казанга карый)*. Ит кенә әрәм кала.

Икенче юлчы *(кымыз тулы турсыкка карый)*. Кымызы да.

Гали. Ит пешкән. Алыгыз. Турсыкны да алыгыз.

**Юлчылар итне, турсыкны алалар.**

Шәмсетдин *(ишек төбендә)*. Кызып киттем. Кичер, Гали.

Гали *(коры)*. Сау бул, Шәмсетдин.

Шәмсетдин. Сау бул, Гали.

Гали *(йомшап)*. Буләргә кайтып җитә алсаң... зиратка барып... анам каберенә сөйлә минем хакта.

Шәмсетдин. Сөйләрмен, Гали.

**Чыгалар. Тышта ерагая барган тояк тавышлары ишетелә. Күк күкри, яшен яшьни.**

## Өченче күренеш

**Гали ялгыз.**

Гали.

Яшен яшьнәп, күк күкрәтеп болыт кила,
Үз юлында бар нәрсәне кырып кила.
Бозмы, ташмы — нәрсә явар яңгыр илә?
Ни яуса да, кан-яшь кила, үлем кила!
Дала ачык җил-давылга. Чыпчык кача
Башын саклап посар өчен тыныч җирдә.
Алып-батыр кошлар гына кыю оча —
Һич куркытмас кара болыт бөркетләрне!
*(Көрсенә, йөренә.)* Ә син үзең бөркетме

[1] Нажагай — кыпчакларда яшен алласы.

соң, әллә чыпчыкмы? Шәмсетдинме, Гали угланмы?! Ах, Гали! Үкенечле синең язмыш! Кул-аягың бәйле, телең — богауда! Чыпчык булмый, кем син тагын, мескен, Гали?! *(Туктый, кискен үзгәреп.)* Булмый! Ярамый! Күктән кан исе килә, көек исе килә! Мөхәммәт солтанны җиңгән дошман Кыпчак даласында гына туктап калмас. Кыпчактан соң — Болгар!

Болгар... Синең туган йортың. Анаң кабере. Карт атаң, туганнарың, туган халкың... Менә мондый хәтәр чакта Болгарга син кирәк, Гали! Синең кебек сугышчылар кирәк.

Ләкин..., ничек кайтырга үз йортыңа, үз атаң янына?! Кул-аяклар бәйле, юллар ябылган. Бердәнбер өмет — кыйсса. Атамның аяк астына егылырмын да: ханга, Болгарга турылыклы икәнлегемне исбатлау өчен, мин сиңа багышлап гүзәл кыйсса иҗат иттем, бөек ханым, диярмен. Һәм ул мине гафу итәр.

Тизрәк, тизрәк язып бетерергә кирәк. *(Гали ашыгып язарга тотына.)*

## Дүртенче күренеш

**Ураз бәкнең киез өе. Идән уртасында учак, учакта — ут. Түгәрәк өйнең стенасына төрле бизәкләр, ау күренешләре, җәнлек сурәтләре төшерелгән тукымалар элengән. Идәндә бай келәмнәр, җәнлек тиреләре. Түрдә бай җиһазлы биек урын. Өйнең ишеге сәхнәнең сул ягында. Түрдәге биек урында, тамашачыга йөзе белән, Ураз бәк утыра. Сул ягында — бикә. Уң якта, түбәндәрәк ике аксакал. Бәкнең сул ягында, шулай ук түбәндәрәк — ике аксакал. Ураз бәкнең башында чын ташлар белән бизәлгән очлы бүрек. Бәктән кала барысы да ялан баш. Озын чәчләре үрелгән.**

**Пәрдә ачылганда Инәл кам бәкнең өен арыклый, ягъни явыз рухларны куалый: барабан кага, кычкырып-кычкырып җибәрә. Иң ахырда өй эчендәге «җеннәрне» ачык төннектән тышка куалап чыгара.**

**Инәл кам аеруча игътибарга лаек. Кам (шаман)— борынгы төрки халыкларда дин-йола башлыгы. Камның өстендә йоны тышка калдырып, ат тиресеннән тегелгән тун. Бернича үремгә үрелгән озын чәчләре җилкәсенә төшеп тора. Кулында иләк сыман бер яклы барабан. Барабан кысасындагы аркылы тимергә шөлдерләр тагылган. Колакларында — алка, кулында — кечкенә тукмак. Һәрбер хәрәкәтеннән шалтыршолтыр тавышлар чыга. Кам кызу канлы, житез, кискен. Бик тиз кызып китеп, шашу дәрәҗәсенә җитәргә мөмкин.**

Инәл кам *(такмаклый).*
Чыгың, чык! Чыгың, чык!
Сезнең урын монда түгел,
Сезгә монда кулай түгел.
Чыгың, чык! Чыгың, чык!
Сикереп чык, йөгереп чык,
Үлә-казала очып чык!

**Учак янына килә. Аксакалларның бирсе касә белән аңа кымыз бирә. Кымызны кам аз-азлап кына утка сибә — утка йолак (корбан) бирү йоласын башкара. Такмаклый:**

Илгә тереклек биргән,
Өйгә җылылык биргән,
Ияләрне сөйдергән,
Күрмәсләрне[1] көйдергән
Кырык уллы Ут-ана,
Кырык күзле Ут-ана,
Кырык телле Ут-ана,
Кырык җирдә Ут-ана!

[1] Күрмәс — җен.

Илдән — йолык!
Миннән — йолык!
Бәктән — йолык!

Ураз бәк *(ишек ягына карап кычкыра).* Керсен!

**Гали керә. Ике ягында ике сакчы.**

Гали *(баш орып).* Йорт-илең имин булсын, өең, караларың сау булсын, терлекләрең көр булсын, бәк. Олуг тәңре үзеңә, бикәңә чиксез күп яшь бирсен.

Ураз бәк. Шулай булсын. Исәндәдер, кәтүче Гали, моннан биш-алты ай элек, ач-ялангач килеш, өтәләнгән килеш син минем бусагама килеп егылдың.

Гали. Барысы да исемдә, бәк.

Ураз бәк. Син әйттең: мин Болгардан, дидең. Агам белән тыныша алмадым. Атамнан калган байлыгымны тартып алмакчы булып үтермә кәләделәр, шуның өчен илемнән качып киттем, дидең.

Гали. Барысы да дөрес, бәк!

Ураз бәк. Мин сиңа ышандым, кыз-

гандым, тамагынны туйдырдым. Киярена кием бирдем, торырына өй бирдем.

Г а л и. Сүзең дөрес, бәк!

У р а з б ә к. Минем алда, бикә белән аксакаллар алдында сүзеңне кабатла.

Г а л и. Сүземне кабатлыйм: син мине ач үлемнән коткардың, син мине өйле, атлы, киемле иттең. Син мине үз канатың астына алдың, Ураз бәк.

У р а з б ә к. Шулай булгач, көтүче Гали, инде тагын әйт: яхшылыкка яхшылык тиешме, әллә яхшылыкка яманлык тиешме?

Г а л и. Яхшылыкка яхшылык тиеш, Ураз бәк.

**Аксакаллар, хуплау белдереп, җиңелчә гөрелдәп алалар.**

И н ә л к а м *(кискен)*. Син ялган сөйлисең, Болгар мөселманы!

Г а л и. Ни уйласам, мин шуны сөйлим, изге кам. Мин әйтәм: яхшылыкка яхшылык тиеш, димен. Син шуны ялган дисеңмени?

И н ә л к а м. Сүзең чын, эшләгән эшләрең — яманлык!

Г а л и. Мин Ураз бәкнең көтүләрен көтәм. Бу эшне мин яман эш, дип әйтмәс идем, изге кам.

**Аксакаллар, теләктәшлек белдереп, ирексездән янә гөрләшеп алалар.**

И н ә л к а м. Синең яман эшләрең дә җитәрлек, Болгар мөселманы!

У р а з б ә к. Шулай, синең яман эшләрең дә бар, көтүче Гали. Монда без сине шуның өчен яргуларга чакырдык.

Г а л и. Төшендереп бирсәгезче, бәк.

У р а з б ә к. Син, көтүче Гали, төне буе учак ягып, качып-посып, өеңдә ниндидер шикле эшләр эшлисең. Нишлисең син төне буе?

И н ә л к а м. Нишләсен! Мөселман китапларына карап, бозу, күз буу эшләре эшли!

А к с а к а л л а р:

— Кешеләргә, терлекләргә талау китерә!

— Моның өчен ат койрыгына тагарга кирәк аны!

— Утта яндырырга кирәк — эзе калмасын безнең далада!

И н ә л к а м. Кырыкка тураклап, үләксәсен кырык җиргә күмәргә!

**Тынлык.**

А к с а к а л л а р:

— Инәл кам белеп әйтә!

— Кырыкка тураклап, кырык җиргә күмәргә!

У р а з б ә к. Син ни диярсең шуңа, көтүче Гали?

Г а л и *(киеренке)*. Мин шуны әйтермен, Ураз бәк: төннәр буе мин үз өемдә учак ягып, качып-посып, мөселман китапларына карап, бозу, күз буяу эшләре белән шөгыльләнмим. Ни өчен дигәндә мин үзем... китап язам!

**Гомуми аптыраш. «Кит аннан!» «Булмасны!» дигән сүзләр ишетелә.**

У р а з б ә к. Кабатлап әйт: нишлисең?

Г а л и. Кабатлап әйтәм: мин китап язам. Көндез минем вакытым юк, мин бары төнлә генә үз иркемдә.

Б и к ә. Китапны кешеләр язамыни?

И н ә л к а м. Китапны мөселманнар күктән индерелгән диләр!

Г а л и. Дөрес, кайбер мөселманнар, барлык китапларны да изге санап, күктән индерелгән дип уйлыйлар. Син дә, изге кам, мөселман китапларын күктән индерелгән дип, изге дип уйлыйсыңмыни?

И н ә л к а м. Тфү-тфү! Телеңә — тилчә!

У р а з б ә к. Яра-ар, көтүче Гали. Син кызык итеп сөйлисең. Мин сине белмәгәнмен. Синең тынычлыгың, кыюлыгың миңа ошый. Инде әйтеп бир: ни язасың ул китапка?

Г а л и. Җыру язам, Ураз бәк.

**Аксакаллар көлешә башлыйлар.**

Б и к ә. Җыруны китапка язалармыни? Беренче тапкыр ишетәм.

А к с а к а л л а р:

— Җыруны телдән әйтәләр!

— Җыруны думбырада чирталәр!

У р а з б ә к. Әйтеп, чиртеп күрсәт безгә, көтүче Гали. Бирегез аңа думбыра!

**Галигә думбыра бирәләр.**

Г а л и *(думбыра чиртә, такмаклый)*.

Җырулардан, кыйссалардан
иң затлысын,
Ялыкмастан тыңлау өчен иң татлысын
Китап эчрә тезә барам иң аклысын,—
Моны белү тиеш сезгә, и наданнар!

И н ә л к а м. Тукта!

У р а з б ә к *(ачулы)*. Синең нинди җыручы булуың аңлашылды, көтүче Гали.

А к с а к а л л а р.

— Җыруы үз башына!

— Син языклы, көтүче Гали!

У р а з б ә к. Беренче языгыңны кире кага алмадың. Синең тагын ике языгың бар. Аларын да кире кага алмасаң, сине үлем көтә, җыручы Гали!

Г а л и. Әйт, Ураз бәк — минем тагын нинди языкларым бар?!

У р а з б ә к. Икенче языгың шул: төннәрен синең янга ниндидер шикле кешеләр килә. Кемнәр алар? Ник киләләр алар синең янга?

Инэл кам. Кемнәр булсын — Хәрәзем мөселманнарыннан шымчылар килә!

Аксакаллар:

— Кыпчакларга каршы тагын яу чапмакчы була микәнни аты корыгры Мөхәммәт солтан?

— Үләксәсен этләр җыйгыры, Бурлы ыруын да канга батырмакчы буладыр!

Ураз бәк. Дөресме шул, көтүче Гали?

Гали. Дөрес түгел, Ураз бәк.

Инэл кам. Караңгы төшкәч, сиңа ят кешеләр килгәнен мин үзем күрдем!

Аксакаллар:

— Мин дә күрдем!

— Күрдек, үз күзебез белән күрдек!

Гали.

Ярлы өем, ялгыз өем — юл буенда.
Ишек ачык көн буена, төн буена.
Миңа керми, кемгә керсен соңга калган,
Ачыккан һәм дәхи анда юлдан язган?!
Юлаучыны кире бору юк уемда.
Ләкин алар шымчы түгел — моны белең!

Инэл кам. Шымчы!

Ураз бәк. Ник шымчы түгел, көтүче Гали?

Гали.

Солтан иле Хәрәземне яу баскан, бәк!
Кыпчак кайгысы юк анда. Ул качкан, бәк,
Ташлап барын — илен-көнен, чирүләрен,
Чыңгыз ханга көнбатышка юл ачкан, бәк!

Аксакаллар:

— Авызыңа бал да май, көтүче Гали!

— Мөхәммәт солтанның башы аягы астына килсен!

— Килгән инде!

Ураз бәк *(тынычсыз)*. Бу сүзләрең чынмы, көтүче Гали?

Гали.

Чын, Ураз бәк! Аксакаллар, һәммәсе чын!
Ләкин нигә сөенергә моның өчен?!
Бүген солтан, иртәгә — без: Кыпчак,
Болгар
Татып карарга бик мөмкин дошман көчен!
Чыңгыз ханны явыз диләр, кансыз диләр,
Ул җимерткән шәһәрләрне сансыз диләр,
Ул магулны фиргавендәй комсыз диләр.
Андый катил әлегәчә булмас имди!
Сез, кыпчаклар, таралгансыз киң далага,
Буйсынмыйсыз берегез дә уртак ханга.
Сезне җыну берни тормас дошманнарга —
Берләшергә кирәк безгә яу алдында!

Инэл кам. Болгар беләнме?!

Гали. Болгар белән дә, башка кыпчак ырулары белән дә, изге кам!

Ураз бәк. Хәрәзем җиңелгән өчен башыма кайгы аласым юк! Минем үз кайгым үземә житкән.

Аксакаллар:

— Шулай, кайгы баштан ашкан!

— Хәрәземне җир йотса да, ис китмәс!

— Үз далабыз исән булса, безгә шул җиткән!

Ураз бәк. Көтүче Гали, синең икенче язынг кире кагылды.

Аксакаллар:

— Языгы юк!

— Икенче языгын кире какты!

Инэл кам *(сикереп торып)*. Аның өченче языгы бар!

Ураз бәк. Әйе, синең өченче языгын бар, көтүче Гали.

Гали. Анысы ни?

Ураз бәк. Кызым Чәчәк кетмәгәндә чиргә сабышты. Йокы аралаш саташып, «Гали» дип кычкыра. Бу — бозу чире. Монда син гаепле булырга тиеш.

Гали *(каушап)*.

Чәчәгем чиргә сабышкан,
Чәчәгем сулганмы әллә?!

Ураз бәк. Өченче языгыңны таныйсыңмы, көтүче Гали?

Гали. Кызыңны күрәсем килә, Ураз бәк!

Бикә. Керсен, әллә чире китәр.

Бер аксакал. Теләгән утәргә кирәк.

Ураз бәк *(ишек ягына кычкыра)*. Әйтегез, кызым Чәчәк керсен.

**Чәчәк керә. Кайгылы. Түргә уза, кулын кушырып, атасы-анасы алдында баш ия. Галигә каршы якта туктап кала.**

Гали *(үз алдына)*.

Сылуымның нурлы йөзен кайгы баскан!
Күрсәнезче! Мәхәббәте баштан ашкан!
Ни кылаем аның өчен мин саташкан?
Сөенечтән күңелем хуш булыр имди!

Чәчәк. Нигә кирәк булдым мин монда, атам-анам, аксакаллар?

Ураз бәк. Без монда көтүче Галине яргулыйбыз. Синең чиргә сабышуында ул гаепледер дигән шигебез бар. Атаң-анаң алдында, аксакаллар алдында турысын әйт: бозу, чиргә сабыштыру теләге белән ул сиңа каршы берәр төрле яманлык эшләмәдеме?

Чәчәк. Әйе, бу кеше... көтүче Гали аркасында мин чиргә сабыштым, саргайдым, аяктан егылдым. Шулай да аның монда бер языгы да юк.

Инэл кам. Юк?!

Чәчәк. Әйе, юк. Көтүче Гали миңа каршы берниндә яманлык эшләмәде. Мин аны үзем... яраттым!

Бикә. Яраттым дисеңме?!

Инал кам. Ярату юк! Күз буу, сихер генә бар!

Чәчәк. Ярату булмаса, синдә юктыр, изге кам. Миндә — бар! Атам-анам алдында, Бурлы ыруының аксакаллары алдында, олуг тәңре каршында ант итеп әйтәм: мин Галине генә яратам!

Гали *(Чәчәккә омтыла)*. Чәчәгем! Кабатлачы тагын шул сүзне!

Бикә. Атасы, бу ни эш бу?!

**Аксакаллар аптырашта. Чәчәк, Галинең омтылышын күреп, күз алдында үзгәрә: башын калкыта, Галигә елмаеп карый.**

Ураз бәк *(аягүрә баса)*. Мин, Бурлы ыруының башы Ураз бәк, бикә белән, аксакаллар белән берлектә көтүче, жыручы Галине яргуладым... Гали! Синең соңгы сүзем бар: мине мактап жыру әйт!

Гали *(башын калкыта, думбырасын алып аягүрә баса, күтәреп)*. Син миңа авыр эш куштың. Армый-талмый Мактарга сине, Ураз бәк, телем бармый. Изгелегең өчен рәхмәт. Көчләмәгел. Хакимнәрне жырда мактау миннән булмый.

Ураз бәк *(ачулы)*. Син үзеңә үзең баз казыдың, жыручы Гали. Боерам: болгар качагы Галине утта да яндырмаска, ат койрыгына да такмаска, кырыкка турап, кырык жиргә дә күммәскә. Жыручы Галине, ирегең алып, мәңгелек кол ясарга!

Гали *(коты алынып)*. Мәңгелек кол ясарга?! Юк, Ураз бәк! Утта яндыр, ат койрыгына так, кырыкка турап, кырык жиргә күм — бары тик кол гына ясама! Шагыйрь кол булмый, кол шагыйрь булмый!

Ураз бәк. Була, шаир Гали!

Инал кам. Кол син, кол!

**Пәрдә төшә.**

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### Беренче күренеш

**Болгар башкаласы Бүләр. Хажи бәк сарае. Кайдадыр артта басынкы гына музыка уйный, жырлаган, тыелып кына көлгән тавышлар ишетелә. Биек терәкләр тезелеп киткән залда күләгәләр сыман хезмәтчеләр узып китә.**

**Эшсезлектән арыган, йончыган кыяфәттә, әкрен генә атлап, Энҗе бикә килеп керә. Аның ике ягында ике хезмәтче хатын.**

Энҗе бикә *(бер кечкенә бүлмәгә керә)*. Бөтен сарайда шушы бүлмәдән дә тын, аулак урын юк. Тәрәзәдән карасаң, Чирмешән буйлары, яшел болыннар күренә. Дөнья кайгылары онтыла, очар коштай булып күңел талпына башлый. Никтер жылыйсы килә, кемгәдер сыенасы килә. *(Хезмәтче хатыннарга.)* Чыгып торыгыз — минем уйланып утырасым килә. Көйчеләргә әйтегез — уйнамасыннар. Юк — уйнасыннар! Тик әкренрәк.

**Хезмәтче хатыннар шыпырт кына чыгып китәләр. Энҗе бикә ялгыз.**

Энҗе бикә. Бертуктаусыз әчем поша, күңелемне сагыш кимерә. Байлык дисәң — байлык житәрлек, дан вә шөһрәт бары да баштан ашкан. Тик шулай да миңа нидер житми. Бүген тагын мин Галине төштә күрдем. Боек, күңелсез. Үзе кылыч кайрый. Куркуымнан котым алынды. Нәрсә булыр икән?

**Хезмәтче хатын керә.**

Хезмәтче хатын. Кичер, бикә. Өй агасы Күгеш сине эзли.

Энҗе бикә. Аз гына да котылып торып булмый Күгешләрдән, борчулардан!

Хезмәтче хатын. Бик тә кирәк ди, бикә.

Энҗе бикә. Керсен.

**Хезмәтче хатын чыга, Күгеш керә.**

Күгеш. Хажи бәкне сорап, кешеләр килгән, бикә. Көтсеннәрме, кайтып китсеннәрме?

Энҗе бикә. Мин үзем дә Хажи бәкне көтәм.

Күгеш. Алайса, көтмәсеннәрмени?

Энҗе бикә. Кемнәр килгән? Нинди эш белән?

Күгеш. Башкыртлар калан китергәннәр.

Энҗе бикә. Тагын кемнәр?

Күгеш. Чирмеш бие Актанай, аннары Жукәтаудан Ибраһим бәк, аннары урыслар...

Энҗе бикә. Урыслар ни йомыш белән?

Күгеш. Иделдә Ашлыдан түбән балык тотарга рөхсәт сорыйлар.

Энҗе бикә. Тагын кемнәр?

Күгеш. Күп инде анда. Олысы да, кечесе дә Хаҗи бәккә килә. Хаҗи бәк сарае хан сараена әйләнде, бикә.

Энҗе бикә. Юкны сөйләмә, Күгеш. Хаҗи бәк сараеның хан сараена әйләнгәне юк әле. Хан үз урынында, Хаҗи бәк үз урынында.

Күгеш. Алайса, кайтып китсеннәрмени, бикә?

Энҗе бикә. Чит ил сатучыларыннан беркем дә юкмыни?

Күгеш. Нишләп булмасын, бар. Кырымнан, Мисырдан, Румнан, Куябыдан...

Энҗе бикә. Ник башта ук шуларны әйтмисең? Кемнәр килгән? Нәрсәләр алып килгәннәр? Бүләккә ятрак, затлырак әйберләр юк микән?

Күгеш. Бик бай киенгәннәре дә бар. Таныш йөзләр дә күренгәли. Аннары, качаклар, бикә... Үргәнеч, Бохара якларыннан. Анда каты яу бара ди, бикә.

Энҗе бикә. Әйтмәле шул качакларны! Бу арада күбәеп киттеләр әле алар.

Күгеш. Әйе, бикә, ул яклардан көн дә шомлы хәбәрләр килә.

Энҗе бикә. Күгеш, ул турыда берни әйтмә! Шомлы хәбәрләр, аллага шөкер, үзебездә дә җитәрлек.

Күгеш. Алайса, бикә?..

Энҗе бикә. Тагын кемнәр?

Күгеш. Каралардан берничә кеше, галим-голәмә, шагыйрьләр.

**Хезмәтче хатын керә.**

Хезмәтче хатын. Хаҗи бәктән кеше кайтты, бикә. Хаҗи бәк әйткән, бүгенгә кайталмыйм, Сараландагы утарга китәм, анда ашыгыч эшем бар, дип әйткән.

Энҗе бикә. Менә ни өчен эчем пошкан икән көне буена! Ярар, ул анда типтерсә, без монда типтерербез. *(Хезмәтче хатынга.)* Андагыларга әйт: бүген кич аш-су ясыйбыз. Табынны көндәгедән илле кешегә артыграк әзерләсеннәр.

Хезмәтче хатын. Әйтермен, бикә. *(Чыга.)*

Күгеш. Алайса?..

Энҗе бикә. Әйе, «алайса», Күгеш! Каралар, качаклар кайтып китсеннәр. Чит ил сатучылары, болгар сатучылары, галим-голәмә, шагыйрьләр бүген миңа аш-суга килсеннәр. Башкыртларга, чирмеш бие Актанайга, Җүкәтау Ибраһимга, урысларга әйт: Болгарда беренче — хан, икенче — Хаҗи бәк, диген. Хаҗи бәктән узып, беркем берни эшли алмый, диген. Бүгенге ашсуга киләсе кунакларны яхшырак кара. Юк-бар бүләк бирердәйләрнең, шомлы хәбәр сөйли торганнарның берсен дә якын җибәрмә.

Күгеш. Шулай итәрмен, бикә. *(Чыга.)*

Энҗе бикә *(ялгыз).* Беләм мин синең Сараландагы ашыгыч эшләреңне! Мин — читлектәге кош кебек. Ул әнә өенә кайтып керсә керә, кермәсә юк. Хәер, аның кайтып кермәве яхшырак та.

**Актай керә, тамак кыра.**

Актай. Кызым, исәнме.

Энҗе бикә. Әти! Әтием! Нинди акыллы син — кирәк чакта гына килдең дә кердең!

Актай. Әти кешеләр кирәк чакта гына акыллы булалар да, кызым.

Энҗе бикә. Бүген иртәдән бирле мин сине уйладым, әти.

Актай. Минем сине исемнән чыгарганым да юк, кызым!

Энҗе бикә. Минем сиңа гына әйтәсе сүзләрем бар, әти.

Актай. Минем дә сиңа гына әйтәсе сүзләрем бар, кызым.

Энҗе бикә. Башта син сөйлә, әти.

Актай. Кияү кайтмадымыни? Бүген ул атасы хан янында булды.

Энҗе бикә. Беләм, әти.

Актай. Синең, кызым, дөньяда белмәгән нәрсәң юк икән. Сабыр ит, белмәгәнеңне дә ишетерсең.

Энҗе бикә. Сөйлә, әти, сөйлә.

Актай. Менә шул, кызым, хан белән Хаҗи бәк арасында бик каты сөйләшү булды. Бер ел эчендә Гали табылмаса, мин сине үземнең варисым итеп билгеләячәкмен, дигән иде хан үзенең өлкән улына. Хаҗи бәк бүген варислык сорап килде.

Энҗе бикә. Шуннан, шуннан, әти?

Актай. Хан һаман Галине таптыра.

Энҗе бикә. Үле Галинеме?! Акылдан шашканмы әллә ул?

Актай. Юк, кызым, хан акылдан шашмаган, ханның күзе ачыла башлаган. Хаҗи бәк артыгын кылана, тупас, кансыз. Ул инде күптән үзен варис итеп, хәтта... хан итеп тота!

Энҗе бикә. Кызык. Киявең турында син элегрәк бер дә андый сүзләр әйтми идең.

Актай. Астыңа су йөгерсә, әллә ниләр әйтерсең, кызым!

Энҗе бикә. Шулай укмыни, әти? Күңелсез сүзләрне әллә бүгенгә сөйләшмибезме?

Актай. Юк, кызым, бүген башлаган сүземне мин иртәгәгә калдырырга күнек-

мәгән. Хажи бәкне хан үзенең варисы итмәячәк. Менә шул минем сүзем.

Энже бикә. Менә ни өчен әчем пошкан икән көне буена! Хажи бәк хан була алмаса, мин кем генә булырмын икән соң? Үз киявеңне тәхеткә дә утырта алмагач, ник бирдең соң мине аңа?

Актай. Кияүгә бирү-бирмәү, кызым, кайчагында, бирүгә генә карамый, бирелүгә дә карый. Тора-бара син миңа: ник мин хан кызы булмаганмын, дия башларсың!

Энже бикә. Шулай да... Хан әллә мәңге яшәмәкче була?

Актай. Тәүгилде яклылар Фатыйма бикәнең Алтынташ углын варис итәргә кирәк, дип сөйләнәләр.

Энже бикә. Хан кинәт үлеп-нитеп китсә, шул тиле-миле дигәндәй... шул җебегән Алтынташ тәхеткә утырырмы? Ул чагында без: син, мин, Хажи бәк... Фатыйма бикәнең табанын яларбызмы?

Актай. Ул чагында безгә кем табанын яларга туры килер — анысын әлеге әйтеп булмый. Әлегә шуны гына әйтергә була, ул чагында беркем дә безнең табаныбызны яламаячак, кызым.

Энже бикә. Андый эш беркайчан да булмас!

Актай. Алай җиңел уйлама, сәвекле кызым Энже бикә. Язмышның төбе — мәкер. Бер көнне ул сине күккә чөя, икенче көнне аяк астына салып таптый. Кешеләр ханнан җылырак урын, майлырак калҗа эләктерү өчен бер-берсенең бугазын чәйнәргә әзер торалар.

Энже бикә. Фатыйма бикә углы турында хан үзе нәрсә уйлый икән?

Актай. Хан Галине таптыра. Үлеме, тереме — Галине табып китерегез, ди, шунсыз мин аның үлеменә дә, гаепле булуына да ышанмаячакмын, ди. Миннән соң Болгар тәхетенә утыру өчен аннан да төплерәк беркемне дә күрмим, ди.

Энже бикә. Нишләп ул аны әлегрәк — Гали исән чакта әйтмәде икән соң?

Актай. Менә анысын сорарга башыма килмәгән, кызым! Хан әйтеп бирмәсә дә, Галинең нинди ир икәнлеген син үзең дә белергә тиеш идең.

Энже бикә. Син ялгышасың, әтием: мин аның кемлеген бик яхшы белдем. Ләкин ул чагында хан Галине түгел, Хажи бәкне якынрак күрде түгелме соң? Тәхеткә бернинди хокукы булмаган, үләнче «кара» дип йөртелгән надан анадан туган Галине син үзең дә бик үк мактамый идең. Нишләп алай фикерең үзгәрде?

Актай. Минекен генә түгел, бик күпләрнең фикерен үзгәртте Гали углан. Буш вакытын күбрәк каралар белән уздыра торган Галигә баштарак беркем дә ышанып карамады. Инде сугышчы Гали уңда да, сулда да дошманнарны җиңеп кайткач, бик күпләр аның булдыклы ир икәнлеген танырга мәҗбүр булдылар. Күпчелек аның ягына авышты куйды. Синең белән без менә шул үзгәрешне сизми калдык. Әйе, байлыгы аның юк дәрәҗәсендә иде, хан катында да ул түбәнрәк утыра иде. Хан үзе дә, мин дә Болгар йорт өчен, тәхет өчен аның алыштыргысыз кеше булуын бары ул юкка чыккач кына аңлый алдык.

Энже бикә. Кирәк чагында үзең аңлый алмаган өчен син мине аңсызлыкта гаепләргә җыенмыйсыңдыр ич, әтием?

Актай. Юк, кызым, мин бары шуны гына әйтмәкче булам: үзең өчен кемнең файдалырак булырын син миннән башка да аңлый алдың. Син бит туганнарның икесен дә «яраттың»! — Гали читтә кан койганда, мыштым гына Хажи бәк белән шаярдың.

Энже бикә. Җитәр, әти!

Актай. Җитмәс, кызым. Моңарчы әйтмәдем — бүген әйтәм.

Энже бикә. Әйт, әйт — барысын да әйт!

Актай. Әлегә барысын да әйтмәм, шулай да бер нәрсәне әйтми булдыра алмыйм: ханга гына түгел, безгә дә Гали кирәк!

Энже бикә. Болай булгач, син — минем туган атам, хан алдында Хажи бәкне якламаячаксыңмыни?

Актай. Мин алай димәдем.

Энже бикә. Син әле генә мине тотнаксызлыкта, хыянәттә гаепләдең. Син үзең дә шундыйрак түгелме соң, атам?

Актай. Ярый әле, кызым, исемә төшердең — минем сиңа бик тә яшерен сүзем бар икән. *(Як-ягына карана.)*

Энже бикә. Куркытырмын дип уйлама, әти. Хажи бәк турында, Гали турында нәрсә генә әйтсәң дә, минем инде аз гена да исем китми. Хажи бәк, бер нәрсәгә карамыйча, варис булырга, тәхетне яулап алырга тиеш. Син аңа булышачаксың, әти! Син баш тартсаң, мин үзем тотыначакмын!

Актай. Синең булдыклы бала булуыңа мин шикләнмим, кызым. Шулай да исеңнән чыгарма: хан инде карт, киленнең серле елмаюларына гына эреп төшмәячәк. Шуны да борыныңа киртеп куй: Хажи

бәккә жину яуласаң, син үзеңә баз казыячаксың.

Энже бикә. Кызык.

Актай. Иң кызыгы шул, кызым: Хажи бәк белән син менә бер ел торасың, шулай да синең балаң юк.

Энже бикә. Әти, кагылма минем авырткан җиремә!

Актай. Синең авырткан җирең — минем дә авырткан җирем.

Энже бикә. Күренмәгән имчем калмады. Барысы да: булыр, диләр, тагын берике ел көтәргә кушалар.

Актай. Без бер ел да, ике ел да көтәрбез, тик Хажи бәк кенә көтәргә теләми.

Энже бикә. Тагын Хажи бәк!

Актай. Хажи бәк булмыйча, кем булсын? Ул синең балаң юклыгына пошына.

Энже бикә *(үртәлеп)*. Әти, казынма минем күңелемдә! Әйтәсе сүзеңне әйт тә...

Актай. Әйтер сүзем шул: синең ирең Хажи бәк Тәүгилделәр белән астыртын эш йөртә.

Энже бикә. Юк! Тәүгилде тархан Хажи бәкнең явыз дошманы. Син үзең әле генә әйттең: Тәүгилде яклылар Фатыйма бикәнең Алтынташ углын варис итмәкче булалар, дидең.

Актай. Әйттем, кызым. Тик мин сиңа Тәүгилде тарханның Көнсылу атлы гүзәл кызы барлыгын әйтмәдем бугай?

Энже бикә. Көнсылу?!

Актай. Көнсылу, кызым, Көнсылу. Яшьрәк тә, чибәррәк тә.

Энже бикә *(җылау катыш)*. Әти!

Актай *(тыңламыйча)*. Синең ирең Хажи бәк, менә шул гүзәл Көнсылуга өйләнеп, берьюлы ике куян атмак була. Хажи бәк Тәүгилде тархан кияве була калса, ул чакта Алтынташ турында беркем авыз ачмаячак. Әйе, кызым, Хажи бәк Болгар тәхетенә утырса, ул чагында синең дә, минем дә кояшыбыз сүнәчәк. Син сөйкемсез икенче хатынга әйләнерсең, минем урынга баш карачы булып Тәүгилде тархан менеп утырыр.

Энже бикә. Рәхмәт, әти — үтердең! Мин инде күптән сизенәм аны *(җылый)*. Менә ни өчен эчем пошкан икән көне буена!

Актай. Шулай итеп, коткарса безне Гали генә коткарачак.

Энже бикә. Кайда соң ул, кайда? Үлеме, тереме?

**Күгеш керә, тамак кыра.**

Актай *(Күгешне күреп)*. Кем кирәк, ни булды, Күгеш?

Күгеш. Бикәне күрергә телиләр.

Энже бикә. Кемнәр?

Күгеш. Караларның, качакларның барысын да кайтарып җибәрдем. Берсе — Үргәнеч качагы...

Энже бикә. Качакларны күрергә теләмим, дип әйттем түгелме соң мин сиңа?!

Күгеш. Ул качакның сиңа гына әйтәсе сүзе бар, имеш. Куанычлы сүз, ди.

Актай. Керсен.

Күгеш *(Энҗе бикәгә)*. Алайса?..

Энже бикә. Әйе, «алайса»!

**Күгеш чыга, Шәмсетдин керә, Энҗе бикәнең аяк астына егыла.**

Шәмсетдин. Иленез имин улсын, терлек-туарыңыз чук улсын. Мән ярлы качакның үтенечено колак салып, бер ягы ай, бер ягы кояш тик балкыган гүзәл йөзеңездә күрсәткән чөн, улуг бикә, аллаһе тәгалә, бу дөньяда барлык теләкләреңә ирештерсен, теге дөньяда йете кат оҗмах ишекләрен ачып, урыныгызды түрдә әйләсен!

Энже бикә. Минем теге дөньядагы урыным турында кайгыртуыңны куеп тор. Сүзеңне кыскарак тот: йомышың ни?

Шәмсетдин. Бик кыска тотсам, аңлашылып йетмәс, дип куркамын. Шул сәбәптин бераз тарих сүзләргә рөхсәт итсәңезче, бикә.

Актай. Тарихыңның баш өлешен мин сөйли алам: син, Үргәнеч качагы, Болгарда казна талап качкан Сәйфетдин углы Шәмсетдин торырсың. Үргәнечтә дә син, атаң сыман, берәрсен талагансыңдыр да качып киткәнсеңдер. Инде менә сыеныр урын эзләп, телеңне бозган булып, яңадан Болгарга кайткансың. Шулаймы, качак Шәмсетдин?

Шәмсетдин *(аягүрә баса, кинәт үзгәреп)*. Яртысы шулай, яртысы шулай түгел, баш карачы Актай! Мин Сәйфетдин казначы углы Шәмсетдин торырмын. Тик мин Үргәнечтән кеше талап качмадым. Анда минем үземне таладылар. Угрылар анда башка. Анда кан-яшь, үлем, Актай!

Энже бикә. Миңа әйтәсе куанычлы сүзең шулмы?

Шәмсетдин. Кичер, бикә. Анысына да житәрмен. Дөрес, мин монда — үземнең туган җиремә сыену урыны эзләп кайттым. Ханның безне ярлыкавын, атам Сәйфетдин казначының ике катлы таш сараен кире үзебезгә бирүен ишеттем дә...

Актай. Син ялган сөйлисең, Шәмсетдин. Атаң-казначының барлык байлыгы—

таш, агач өйләре, көтүләре, көтүлекләре, коллары, чуралары — барысы да тартып алынды. Синең агач өең...

Шәмсетдин. Минем агач өйдән жилләр искән, Актай!

Энже бикә. Хажи бәк аша син шул агач өеңне дауламак буласыңмы?

Шәмсетдин. Юк, бикә, мин атамның ике катлы таш өен кайтарып алмакчы булам!

Актай *(мыскыл белән).* Ничек итеп?

Шәмсетдин. Мин аны сатып алмакчы булам, баш карачы Актай. Минем ике катлы таш сарайга гына торырлык байлыгым бар.

Актай *(көлеп).* Әйттем ич кемнедер талап качкан дип!

Шәмсетдин. Мин Болгар ханының Бүләрдән качып киткән кече углы Галинең кайдалыгын беләм. Менә шул минем байлыгым.

Энже бикә. Гали дисеңме?!

Актай *(исе китмәгән булып).* Гали, имеш! Син тагын ялган сүз сөйләргә тотындың, качак Шәмсетдин. Гали углан, атасы ханга каршы эш алып баруда, ханны үтереп, аның урынына тәхеткә утырырга тырышуда гаепләнде. Аның яклылар төнлә Гали өендә кулга алындылар. Барысының да башлары чабылды. Гали углан үзе качты, Чирмешән аша чыкканда, аркасына ук тиеп, суга батып үлде. Аның үлгәнен үз күзләре белән күргән кешеләр бар.

Шәмсетдин. Мин дә аны үз күзләрем белән күрдем... тере килеш.

Энже бикә. Тере килеш!

Шәмсетдин. Тере килеш, бикә. Сез миңа атамның ике катлы таш сараен кире кайтарып алырга булышсагыз...

Актай. Угры Сәйфетдин казначыныц ике катлы таш сарае, хан боерыгы белән, миңа бирелде.

Шәмсетдин. Ә?! А-а!.. *(Актайның аяк астына егыла).* Актай, үтермә!

Актай. Шулай, Шәмсетдин, атаңның таш сараен сиңа Энже бикәдән дә түгел, Хажи бәктән дә түгел,— миннән ялынып сорарга туры киләчәк. Ләкин синең Гали турындагы ялган хәбәрең минем өчен сукыр бер тиен дә тормый.

Энже бикә. Әти! Ул дөресен сөйли!

Шәмсетдин. Коръән белән, атам-анам белән, барлык изгеләр белән ант итәм — ялган түгел!

**Энже бикә түшәмнән асылынып торган бауны тарта. Хезмәтче хатын керә.**

Энже бикә. Кара, каләм, кәгазь кертегез.

**Хезмәтче хатын чыга. Икенче бер хезмәтче, тәбәнәк өстәлгә куеп, кара, каләм, кәгазь кертә. Актай сүзсез генә кәгазьгә нидер яза. Хезмәтче өстәлне алып чыга.**

Актай *(Шәмсетдингә).* Менә сиңа язу. Сүзең чын булып чыкса, үзеңнең агач өеңә, каралтыларына — юкка чыккан барлык байлыгыңа торырлык жир-су, өй, каралтыкура алырсың.

Шәмсетдин *(язуны ала, укый. Күрсәтеп).* Аз рак шул, Актай.

Актай. Атаңның таш сараен онытг. Яңа өй өчен урынны ханбалыкның үзең теләгән төшеннән бирермен. Теләсәң, таш сарай салырсың. Булышырмын. Хәзергә менә шуны алып тор. *(Куеныннан акча тулы янчык алып бирә.)*

Шәмсетдин *(янчыкны ала).* Бай бул, Актай! Болай булгач, әйтәм. Болгар ханының Мәликә хатыныннан туган кече углы Гали углан кыпчакларның Бурлы ыруында, Ураз бәк урдасында булыр. Мин аны шунда күрдем. Минем тагын ике юлдашым бар, капка төбендә минем чыкканны көтеп торалар. Ышанмасагыз, алардан сорый аласыз.

Энже бикә. Я алла, Гали исән! Гали исән!

Шәмсетдин. Исән, бикә, исән! Мин сезнең бер-берегезне үлеп яратуыгызны беләм. Белмичә, бөтен ханбалык сөйли. Шуңа да куанычлы хәбәремне иң әлек сиңа әйтмәкче булдым. Менә ул бәхет, Шәмсетдин! *(Кулындагы акчалы янчыкны югары чөя.)* Чирмешән яры буена атам нигезенә яңадан яңа сарай салдырам. Жир астыннан су кертәм. Таш мунча салам, бакча үстерәм. Берәр яшь, чибәр кызга өйләнеп жибәрәм. Баш исән булсын, Шәмсетдин, баш!

**Актай бауны тарта, Күгеш керә.**

Актай *(Күгешкә).* Сакчылар керсен.

**Күгеш чыга, кораллы сакчылар керә.**

Энже бикә. Әти, ни булды?

Актай *(сакчыларга, Шәмсетдинне күрсәтеп).* Менә бу кешене хәзер үк зинданга илтеп ябыгыз. Капка төбендә тагын ике йолкыш булыр — аларын да шунда озатыгыз. Бу — бикәнең боерыгы.

Энже бикә *(Актайга карый, икеләнеп).* Әйе... минем дә боерык. Әти!

Шәмсетдин. Ә?! Э-э...

Бер сакчы *(бикәгә баш иеп).* Баш өсте, бикә.

Актай. Зиндан башлыгына әйтегез: минем янсә бикәнең боерыгыннан башка беркая чыгармаска, беркемне янына җибәрмәскә. Теге икене бергә япсалар да ярый.

Шәмсетдин. Э-е... Бу ни бу?! Син мине алдадың. Мин кычкырам!

Актай. Башың исән калуын теләсәң, кычкырмассың.

Шәмсетдин. Сез мине алдадыгыз. Сез — ялганчылар.

Актай *(сакчыларга)*. Тагын берәр сүз әйтсә, авызын томалагыз.

**Сакчылар Шәмсетдинне алып чыгып китәләр. Күгеш керә.**

Күгеш. Хан сараеннан кеше килгән.

Актай. Керсен.

**Күгеш чыга, хан кешесе керә.**

Хан кешесе. Актай, мин сине алырга килдем. Хан сине тиз арада үз янына чакыра.

Актай *(каушап)*. Ни булды? Ханның хәле начарландымы әллә?

Хан кешесе. Ханның түгел, Болгарның хәле начар. Яңа хәбәр алынды: Җаек буена магуллар басып кергәннәр. Болгарга яу килә, Актай!

Энҗе бикә, Актай *(бергә)*. Яу килә?!

Хан кешесе. Хаҗи бәккә дә хан сараена килергә боерык бар.

Энҗе бикә. Ул өйдә юк. Хәзер чакыртып кеше җибәрәм. Яу килә! Шул гына калган иде. Минә ни өчен эчем пошкан икән көне буена!

## Икенче күренеш

**Кыпчак даласы. Бурлы яруында Галинең ярлы өе. Төн. Уртада сүнәр-сүнмәс учак яна. Учак тирәсендә түгәрәкләнеп дүрт кеше утырган. Берсе — Гали, калганнары — Болгар илчеләре. Бер-берсенә якын килеп, алар үзара яшерен сүз алып баралар.**

Ярмыш. Бөтен Бүләр корт күчедәй мыжгып тора, Гали! Чыңгыз ханның Җаек буена басып керүе бик күпләрнең йокысын ачты. Ар, чирмеш, мукшы, башкырт якларыннан ханбалыкка кораллы көчләр килә. Көч күп, ләкин... таркау.

Гали. Ах, шул таркаулык! Болгарны какшаткан, агач корты кебек туктаусыз кимергән нәрсә — һәрвакыт шул таркаулык булды!

Ярмыш. Атаң картайды. Дәүләт эшләре белән бөтенләй диярлек кызыксынмый. Бар эшне Хаҗи бәк үз кулына алды.

Гали. Тәүгилде тархан кем яклы? Җүкәтау Ибраһим кем яклы?

Ярмыш. Тәүгилде тархан Хаҗи бәк белән тартышырга чамалый. Җүкәтау Ибраһим, беркемгә катышмыйча, үзенә аерым көч туплый.

Гали. Гаскәр башы кем?

Ярмыш. Әйтеп торам лабаса — таркаулык! Гаскәр башы юк. Билгеләнмәгән.

Гали. Ах, Болгар! Ах, ятим, бичара Болгар! Беләм, аңлыйм. Ерактан ук барысын да күреп торам! Берәүләр чын күңелдән янып йөри, икенче берәүләр, ыгы-зыгыдан файдаланып, үз эшләрен җайларга маташа. Шушы көнгә тикле гаскәр башы билгеләнмәгән! Атам нәрсә уйлый, Ярмыш? Кемгә таянмакчы була?

Ярмыш. Хан кемгә таянырга да белми. Ул сине көтә, Гали!

Гали *(аягүрә баса)*. Мине көтә? Ник? Башымны чаптырыргамы?

Ярмыш. Ул сине гаепле дип уйламый, Гали.

Гали *(тынычлыгын җуеп)*. Шулай ук микән? Әгәр ул мине гаепсез дип уйлаган булса, минем яклы кешеләрнең башын чаптырмаган булыр иде!

Ярмыш *(аягүрә баса, башкалар да торалар)*. Боларның барысы да — агаң Хаҗи бәк эше, Гали.

Гали. Хаҗи бәк... Таркаулыкның башы — Хаҗи бәктә. Күп нәрсәне ул аңлый алмый. Хан булу белән ул барлык теләкләремә ирешермен, барлык дошманнарны җиңәрмен дип уйлый. Халык белән, гаскәр белән түгел, берүзем җиңәрмен дип уйлый!

Ярмыш. Шуңа күрә дә аны халык яратмый, гаскәр яратмый.

Гали *(йөренә)*. Ярмыш! Болгарлар! Без барыбыз да чиктән тыш хәтәр көннәрдә яшибез. Магуллар без белгән башка бер дошманга да охшамаган. Әгәр дә мәгәр Чыңгыз хан чирүләре Идел-Чулман буйларына килеп җитә калсалар, Хәрәзем шәһәрләре кебек, безнең шәһәрләрне дә җир белән тигезләячәкләр, безнең халыкны да

чебен урынына кырачаклар. Изге йортыбызны, туган халкыбызны саклап калу өчен безгә кичекмәстән берләшергә кирәк! Аңлыйсыңмы, Ярмыш?! Аңлыйсызмы, болгарлар?! Берләшергә кирәк. Болгарның үз ырулары гына түгел, күршеләр белән дә — кыпчаклар белән, урыслар, төн халыклары белән берләшергә кирәк!

Я р м ы ш. Сүзләрең алтын, Гали!

И л ч е л ә р. Дөрес, Гали!

Я р м ы ш. Актай да, Энже бикә дә шундый ук фикердә.

Г а л и *(йөрүеннән туктап)*. Энже бикә?! Ул инде «бикә» мени?

Я р м ы ш. Ул сине дүрт күз белән көтә, Гали!

Г а л и. Энже бикә... Хажи бәк хатыны! Ә мин аны һаман элеккечә дип хыялланам!

Я р м ы ш. Гали, мин сиңа ялганлый алмыйм. Сиңа яла ягу да, синең өеңә басып керү дә — барысында да Хажи бәк кулы уйнаганын син инде аңлыйсыңдыр. Хажи бәк сиңа тиешле тәхетне генә түгел, Энжене дә тартып алмакчы булган.

Г а л и. Һәм ул аны алган да! *(Туктый, кискен үзгәреш белән.)* Шулай булгач... туктале, шулай булгач... мин кем янына кайтырмын соң?

Я р м ы ш. Туп-туры Энже белән Актай янына! Хан белән очрашуны-көрешүне — барысын да Актай үзе җайлаячак. Синең кайтуыңны ишетү белән, бөтен ханбалык синең якка чыгачак, Гали! Барлык гаскәрне, бернинди икеләнүсез атаң синең кулга тапшырачак, Гали!

Г а л и *(үзалдына сөйләнгән сыман, әкрен, тантаналы)*.

Болгар миңа кирәк, мин — Болгарга.
(Ана белән бала кебек без.)
Тагын кемгә кирәк Гали? Ханга?
Агам Хажи бәккәме соң әллә?!

**Туктый, дәһшәтле итеп.**

Кем җибәрде сезне минем янга?
Яшермичә әйтеп бирегез!

Я р м ы ш. Син безгә ышанмыйсыңмыни, Гали?! Актайның, Энженең йөзек тамгасы сугылган менә бу битеккә ышанмыйсыңмыни?! *(Кулындагы битекне селкеп күрсәтә.)*

Г а л и *(төшенке)*. Юк, ышанмыйм.

Я р м ы ш *(хәтере калып)*. Мин сине сугышчы вә шагыйрь дип белә идем. Син монда икенче кешегә әйләнгәнсең, Гали. Хуш, без киттек! *(Ишеккә юнәлә.)*

**Башка илчеләр дә кузгалалар.**

Г а л и *(беравык артларыннан карап тора, икеләнүен җиңеп, газаплы)*. Туктагыз. Монда мин, әйе, икенче кешегә — Шәмсетдингә әйләнә башлаганмын бугай... үз башымны бар нәрсәдән кадерлерәк күрә башлаганмын бугай...

Я р м ы ш *(кире борылып)*. Гали!

Г а л и. Мин китәм сезнең белән. Үзем кайтам. Ни генә булмасын, мин Болгарга — атам янына, халкым янына кайтырга тиешмен!

Я р м ы ш *(Галине кочаклый)*. Гали!

И л ч е л ә р:

— Тиздән төн уртасы җитә!

— Таң атканчы безгә Бурлы ыруыннан чыгып китәргә кирәк.

Г а л и. Мин әзер. Минем үзем белән аласы бер генә әйберем бар, ул да булса — кыйсса китабым! *(Төргәкләр арасыннан китабын актарып ала. Учакка бер күз ташлый да ишеккә юнәлә.)* Әйдәгез, кузгалыйк!

Я р м ы ш. Хәерле сәгатьтә!

**Тышта ниндидер кыштырдау ишетелә. Барысы да тынып калалар.**

Г а л и *(ишек янына ук килеп)*. Кем бар анда?

**Кинәт ишек ачылып китә. Өй эченә берьюлы дүрт-биш коралды ир килеп керә. Иң алда Инәл кам. Кулында артыш таягы. Гали артка чигенә.**

И н ә л к а м. Миңа каптың, кол Гали! Инде ычкына алмассың. Мин сине көнтөн күзәттем. Миңа өстеңә бастым — хәзер инде сине беркем дә коткара алмас. *(Илчеләргә.)* Кузгалмаска! Коралларыгызны салырга!

Г а л и. Бу ни эш бу, изге кам? Болар минем кунакларым.

И н ә л к а м. Колның кунагы булмый! *(Галигә таягы белән кизәнә.)*

Г а л и. Юк, изге кам, колның да кунагы була! *(Инәл камның югары күтәрелгән кулын тотып ала, каера. Камның таягы төшеп китә, кам егыла.)*

И н ә л к а м. А-а-ы-ы!

**Коралды ирләр ярдәмгә ташланалар, болгарлар коралларына тотыналар.**

Г а л и *(болгарларга, тыныч)*. Ярамый. Коралларыгызны ташлагыз! *(Инәл камга.)* Тор, изге кам. Моннан соң коллар белән ягымлырак сөйләшергә тырыш.

**Инәл кам тора, таягын ала. Болгарлар коралларын ташлыйлар.**

И н ә̀ л к а м *(ярсуына буылып)*. Туктале, моның өчен мин сине!.. ...

Г а л и *(коралды ирләргә)*. Без буйсынабыз. Илтегез безне бәк янына.

**Коралды ирләр Галине, болгарларны алып чыгалар.**

## Өченче күренеш

**Ураз бәк өе. Түрдә — Ураз бәк, аның янында бикә. Аксакаллар. Инәл кам. Гали һәм болгар илчеләре.**

Ураз бәк *(Галигә)*. Шулай итеп, болар синең кунакларың булып чыга инде?

Гали. Әйе, бәк, минем кунакларым.

Ураз бәк. Каян килгәннәр, нишләп йөриләр алар минем җиремдә?

Гали. Болар — болгарлар. Адашканнар.

Ураз бәк. Таллыкта яшеренеп яткан иллеләп кеше дә адашканмы?

Ярмыш. Без барыбыз да адаштык, бәк. Ут күрдек тә, кемнәр икән, дип, җәяүләп кенә килдек.

Ураз бәк. Кемнәр сез, кая юл тотасыз?

Ярмыш. Хан йомышы белән без Кырым ягына юл тотабыз.

Ураз бәк. Нишләп юлыгыз турыдан түгел, кыектан китте?

Гали *(дулкынланып)*. Ураз бәк! Мин — синең колың. Мин сиңа беркайчан да ялган сөйләмәдем. Хәзер дә мин сиңа бары дөресен генә сөйләргә телим.

Ураз бәк. Тыңлыйм — сөйлә, кол.

Гали. Болар — чыннан да минем кунакларым! Көтелмәгән кунакларым. Алар ханбалыктан — Бүләрдән килгәннәр. Алар мине... эзләп килгәннәр, бәк!

Ураз бәк. Эзләгәннәр, тапканнар, урлап китмәк булганнар. Минем колымны. Син миңа агаң белән ызгышуың турында әйткән идең. Агаң синең үлгән, яки үтергәннәр, я ул синең белән татулашырга теләгән. Бүләрдә сине байлык көтә, карт анаң, хатының, балаларың көтә. Шулай булмаса, шул тикле җирдән сине эзләп килмәгән булырлар иде.

Гали. Мине Бүләрдә карт анам да, хатыным, балаларым да көтми, байлык та көтми. Анда нәрсә көткәнен мин әлегә үзем дә белмим. Ханбалыкта мине я балта, я... тәхет көтә, бәк.

Ураз бәк. Я балта, я тәхет?!

Гали. Болгар тәхете көтә, ханлык көтә, Ураз бәк!

**Ураз бәк, таңга калып, аягүрә баса. Башкалар да аягүрә басалар. Бары Инәл кам гына урынында утырып кала.**

Инәл кам. Алданма, Ураз бәк! Үлемнән котылмак булып, ялган сөйли оятсыз колың!

Ураз бәк. Ялган түгел, изге кам. Җаекның уң ягыннан кыпчакларны кыс рыклап чыгарган Гали углан турында далада белмәгән-ишетмәгән кеше юк.

Гали. Дөрес, син ишетеп белгән Гали углан мин булам, Ураз бәк. Инде яшеренеп торуның кирәге калмады. Болгарга, Кыпчак далаларына куркыныч килә. Дусларым, якыннарым мине ханбалыкка чакыралар. Ирек бир миңа, Ураз бәк!

**Ураз бәк үз урынына утыра, башкалар да утыралар.**

Ураз бәк *(яңадан коры, рәсми кыяфәткә керә)*. Һы, ирек... Син, тәхеткә утырасы кеше, колга ирекнең алай җиңел генә бирелмәгәнен беләсең булыр. Болгар бай, көчле. Аның җир-суы иксез-чиксез. Сине тәхеткә утыртырга җыенган дусларың, шундый ерак җирдән килгәннәр икән, буш кул белән генә килмәгәннәрдер. Шулай ук алар сине, хан буласы кешене, бик аз бәягә бәяләргә дә җыенмыйлардыр.

Ярмыш. Без аны коллыкта дип белмәдек, бәк.

Ураз бәк. Шулай да сез аның кайдалыгын белгәнсез!

Гали *(тынычсыз)*. Әйт, Ураз бәк, күпме сорыйсың?

Ураз бәк. Синең өчен мин алтын белән... бер мең сорыйм, кол Гали.

Ярмыш. Бер мең!

Илчеләр:

— Күп, бик күп!

— Бездә андый акча юк!

Гали *(үзалдына)*. Менә нинди кыйбат синең башың, Гали!

Ураз бәк *(илчеләргә)*. Чыгарыгыз акча янчыкларыгызны!

**Илчеләр тәләр-теләмәс кенә куеннарына тыгылалар, акча янчыкларын чыгарып, Ураз бәккә бирәләр.**

Ярмыш. Менә, йөз сум.

Илчеләр:

— Минеке кырык сумга өч тиен тулмаган булыр.

— Барысы шунда.

Ураз бәк *(янчыкларның авырлыгын чамалап карый)*. Аз. Бу җитми. Сине шушы ике йөз сум чамасы акчага биреп җибәрсәм, бу синең өчен бик зур түбәнлек булачак, Гали углан!

Ярмыш. Минем сиңа бер киңәшем бар.

Ураз бәк. Син безнең берәребезне тотык[1] итеп алып каласың, бер-ике айдан без сиңа...

Ураз бәк. Миңа чылтырап торган мең акча кирәк. Кая ул акча? Мәгез теләнче тиеннәрегезне! *(Ачу белән янчыкларны хуҗаларына ыргыта.)*

**Авыр тынлык.**

Гали. Ураз бәк! Син сораган акча булыр. Тулысынча булыр! Тик акчаны түләр алдыннан минем сиңа бер шартым бар. Тыңлыйсыңмы?

Ураз бәк. Турә[2] буенча, син — минем колым. Сату-алу йоласы буенча, син миңа бернинди шарт куя алмыйсың. Шулай да мин сине тыңлыйм, Гали углан.

Гали. Мең алтын акча түләнгәч, Болгарга озатып кую өчен миңа син мең кешелек чирү бирерсең.

**Ярмыш сискәнеп китә, искәрмәстән: «Мең кешелек чирү!» дип ычкындыра, башка илчеләрнең колаклары үрә тора. Аксакаллар, үзара пышылдашып, ымлашып алалар. Ураз бәк, дәрәҗәсен саклап, тып-тын утыра. Барысы да аның авызына карап калалар.**

Ураз бәк *(әкрен, уйланып)*. Шартың авыр, Гали. Шартың... урынлы, Гали! Сине озатып кую өчен мең кешелек чирү бирермен. Тик син миңа акчаңны чыгарып салмадың әле. Миңа акча кирәк, Гали!

Гали. Ураз бәк! Кичә таңда синең урдаңа Тукаш атлы сәүдәгәр туктады. Ул Болгарга юл тота булыр. Чакыр аны монда.

Ураз бәк. Ярар, карап карыйк. *(Ишек ягына кычкыра.)* Әйтегез, Тукаш сәүдәгәр керсен!

**Тукаш керә.**

Тукаш *(Ураз бәккә баш ия)*. Олуг тәңре иләнә-көнәнә — иминлек, үзенә байлык бирсен, бәк.

Ураз бәк. Шулай булсын, Тукаш. Минем сиңа сүзем бар.

Тукаш. Сүзеңне тыңлыйм, бәк.

Ураз бәк. Син, Тукаш сәүдәгәр, каян кая юл тотасың? Байлыгың ни, күпме?

Тукаш. Мин Бөек Болгар йортының ханбалыгы изге Бүләргә юл тотам, бәк. Мин күп илләрдә булдым: Мисырда, Румда, Кырымда... Юлым уңмады, дип әйтә алмыйм. Тик менә дөньялар бозылып тора. Син миннән бурычка тавар алмакчы буласыңмы?

Ураз бәк. Миңа тавар түгел, акча кирәк, Тукаш. *(Галига күрсәтеп.)* Менә бу минем колым торыр. Ул синең белән сөйләшмәк була. Сөйләш аның белән.

Тукаш *(Гали ягына борыла)*. Тыңлыйм. Сөйләп кара сүзеңне, кол.

Гали. Тукаш! Күзеңне ачыбрак карале — каршыңда кем тора?

Тукаш *(җентекләп карый)*. Кем дип әйтим?.. Кара, Гали углан түгелме соң? Булмас!

Гали. Булган инде, Тукаш! Син ялгышмадың, мин — элекке Гали углан. Хәзер мин — кол, Тукаш! Коллык богавымны өзеп, мин Болгарга кайтырга тиешмен. Ураз бәк минем өчен мең алтын сорый. Ишетәсеңме, мең алтын! Бир син аңа мең алтынны — мин сиңа үземне үзем сатам, Тукаш!

**Тынлык.**

Тукаш *(каушап)*. Ни сөйлисең, Гали?! Күләргә җыенасызмы әллә миннән?

Гали. Язмыш миннән көлә, Тукаш! Әйт, күпмегә бәялисең минем башны?

Тукаш. Туктагыз әле... нишләп болай соң әле бу?

Гали. Кабатлап әйтәм: Ураз бәк минем баш өчен мең акча сорый. Алтын белән.

Ураз бәк. Әйе, алтын белән. Мең акча.

**Тукаш эндәшми.**

Гали. Ник тынып калдың, Тукаш? Мең алтынга тормаç дип уйлыйсыңмыни? Атам кулына тапшырсаң, ул сиңа ике мәртә бирер, Тукаш! Бүләргә генә алып кайт мине... Болгарга! Яу килә, яу! Ашыгырга кирәк, Тукаш! Ник дәшмисең, кансыз сәүдәгәр?!

Тукаш. Мин синең нинди язмыш аркасында бу хәлгә төшүеңне белмим, Гали углан. Төпченеп тә тормыйм. Сине бу коллыктан йолып алу минем өчен зур бәхет булачак.

Гали. А-а, тәңрем!

Тукаш *(куеныннан бер-бер артлы ике акча янчыгы чыгара, берәм-берәм Ураз бәккә бирә)*. Менә сиңа биш йөз, менә сиңа биш йөз, Ураз бәк. Алтын белән. *(Галига.)* Син, кол Гали, моннан соң ирекле!

Гали. Ирекле?! Тукаш, әйт тагын!

Тукаш. Миннән ирек сиңа, Гали.

Гали *(Тукашны кочып ала, күз яшьләре белән)*. Тукаш! Коткаручым!

Тукаш. Мин — сәүдәгәр. Мин тиреяры, күн белән, кием-салым, бал, корал белән сату итәм. Белем күп жирләрдән мин

[1] Тотык — нинди дә булса шартның үтәлүен тәэмин итү өчен тоткарлана торган кеше.
[2] Турә — борынгы төркиләрдә төрле кагыйдәләр җыелмасы, закон, тәртип.

Болгарга гыйлем китаплары алып кайтам, белем аз җирләргә Болгарның үзеннән алып китәм. Ләкин минем беркайчан да кеше башы белән — кол галимнәр, кол шагыйрьләр башы белән сату иткәнем юк. Кеше белән сату итү минем барлык үтәләкләремә каршы килә. Болгарның олуг бер шагыйрен, алып ирен шундый хурлыктан коткаруны аллаһе тәгалә изге эшем итеп кабул итсә, миңа шул җиткән. Мин, Гали углан, синнән бурыч язуы алып тормыйм. Мин синең сүзләреңә ышанам — Бүләргә кайткач, син бурычыңны миңа ике мең итеп түләрсең.

Гали. Ике мең итеп түләрмен, Тукаш. Менә болар — болгар таныклары. Алар безнең килешүне раслаудан баш тартмаслар.

Ярмыш. Баш тартмабыз, Гали углан.

Ураз бәк *(акчаларның авырлыгын чамалый, янчыкларны чишеп-чишеп карый. Ярмышка, Галигә эндәшеп)*. Безнең сатуалу эше шуның белән тәмам. Хәзер сез барыгыз да — минем кунакларым. Хәзер олы туй ясыйбыз. *(Ишек ягына кычкыра.)* Әйтегез, кызым Чәчәк керсен!

**Чәчәк керә, атасы-анасы каршына килә, кулларын кушырып, тезләнгәндәй итә.**

Чәчәк. Ни сүзең бар, атам?

Ураз бәк. Теге көнне син, кызым, минем алда, анаң белән аксакаллар алдында Галине яратуың турында әйтеп, безне таң калдырган идең. Мин баштагы уемнан кире кайттым: мин сине Инәл камга бирмәскә булдым.

Инәл кам. Бәк! Миңа биргән сүзеңне бозсаң, тамырың корыр!

Ураз бәк *(камны тыңламыйча)*. Мин сине Гали угланга бирергә булдым, кызым.

**Аксакаллар аптыраша. Инәл кам урынга егыла.**

Бикә. Минем белән киңәшү юк, сөйләшү юк!

Чәчәк. Бай бул, атам!

Ураз бәк *(Галигә)*. Гали углан, минем белән туганлашуга син каршы түгелсеңдер ич?

Гали. Каршы түгел, Ураз бәк!

Чәчәк. Гали! Өнемме, төшемме?! *(Галинең күкрәгенә каплана.)*

Гали.

Язмыш мине кызганмады — утка салды.
Яндым-көйдем. Миннән бары тузан калды.
Мин терелдем!— Язмыш көлде, суга салды.
Утта янмас, суда батмас мин, Чәчәгем!
Менә безгә елмайды ул — кавыштырды!
Кайгыбызны сөенечкә алыштырды!
Рәхмәт аңа — икебезне табыштырды.
Өнме, төшме — үзем дә белмим, Чәчәгем!

**Ишектән сакчы керә, ашыгып, Ураз бәк янына килә, нидер әйтә. Ураз бәк үзгәреп китә, сакчыга нидер әйтә, сакчы ашыгып ишеккә юнәлә. Тыны бетеп улагчы, ягъни ашыгыч хәбәр китерүче килеп керә. Ураз бәкнең аяк астына егыла.**

Улагчы. Бәк! Аксакаллар! Кунаклар! Яу килә! Көнчыгыштан көткән яу көнбатыштан килә. Магуллар Болгар диңгезе[1] артыннан үтеп, Каф-тау аша Кыпчак далаларына үтеп керделәр. Кыпчакларның урыслар белән берләшкән көчләре Калка суы буенда тар-мар ителде. Дошманның Җәбе, Субутай атлы батырлары күп көч белән Иделгә якынлашып киләләр.

**Гомуми каушау, ыгы-зыгы.**

Ярмыш *(Ураз бәккә)*. Без хәзер үк юлга чыгабыз, бәк. Безнең кулга алынган кешеләрне, атларны кире кайтарып бирүеңне үтенәм.

Ураз бәк *(бик нык каушаган, куркынган)*. Нәрсә ул сезнең атлар, кешеләр! Сез китәрсез дә котылырсыз. Ялан-япа далада ун мең, йөз мең атлар, кешеләр белән, көтүләр белән мин нишләрмен?!

Тукаш. Син, Ураз бәк, үз илеңдә. Синең җитәрлек кораллы ирләрең бар. Тавар төялгән дөяләрем белән, утыз-кырык кешем белән шыр далада мин нишләрмен дә, кем канаты астына сыенырмын?!

Ярмыш. Минем сездә эшем юк. Ураз бәк, безне тоткарламавыңны үтенәм. Син, Тукаш, кайгырма. Син — бай. Яу килеп басса, алтын бирерсең дә котылырсың. Биреп котылырга безнең менә берниебез дә юк.

Улагчы. Дошман кылычыннан алтын биреп кенә котылып булмаячак. Алар үткән җирдә кеше сөякләре генә өелеп кала, көл-күмер генә кала!

Гали *(тыныч, киеренке)*. Улагчы! Синең кебек котны таратучыларны мин инде бер тапкыр очраткан идем. Ул чакта мин аларны чак-чак кына кылыч белән чабып ташламадым. Мин сиңа моннан соң беркайчан да андый куркыныч сүзләр сөйләмәскә киңәш итәм. *(Ураз бәккә, аксакалларга.)* Син, Ураз бәк! Сез, аксакаллар! Мине тыңлагыз — безгә хәзер үк сугышка әзерләнергә кирәк!

Ураз бәк. Ничек итеп, Гали? Йөрәгемә капты. Кулларым калтырый. Мин берни дә уйлый алмыйм, Гали.

[1] Болгар диңгезе — Каспий диңгезе.

Инэл кам *(явыз тантана белэн)*. Мин ни әйттем сиңа, Ураз бәк? Шул кирәк сиңа, шул! Аха-ха! Тамырың корысын, аха-ха!

**Барысы да сәерсенеп, котлары алынып, Инэл камга борылып карыйлар. Инэл кам, янап, кулларын бутап чыгып китә.**

Ураз бәк *(тәмам коты алынып)*. Сүзең хак, изге кам.

Гали. Күреп торам, сезнең кулларыгыз калтырый, йөрәкләрегез сикерә. Мин сиңа, Ураз бәк, элегрәк тә сугышка әзерләнергә, башка ырулар белән, Болгар белән берләшергә кирәк дип караган идем. Ул чагында син мине тыңламадың.

Ураз бәк. Гали углан, мин сине тыңлыйм! Мин сиңа буйсынам!

Гали *(күтәренкелек белән)*. Ураз бәк! Кыпчаклар! Болгарлар! Моннан соң кыпчаклар белән болгарлар үзара дус-тату булырбыз, дип теләсә нинди дошманга каршы бергәләп сугышырбыз, дип ант эчик!

Ураз бәк. Ант эчик!

**Кулларына касәләр, турсыклар тотып, хезмәтчеләр керә. Һәркемгә кымыз агызып бирәләр. Һәркем үзенең кымызын беркадәр эчә дә, күршесенә, ягъни болгар — кыпчакка, кыпчак болгарга бирә. Галигә яхшы киемнәр кидерәләр.**

Барысы да: Ант! Ант!

Гали. Антыбызны кыпчак йоласы буенча, кылыч белән беркетеп куйыйк. *(Кылыч йөзен үбә.)* Биргән антымны бозсам, бу күк керсен, кызыл чыксын!

Ураз бәк *(кылыч йөзен үбә)*. Биргән антымны бозсам, бу күк керсен, кызыл чыксын!

Гали. Инде барыгыз да минем сүзләрне тыңлагыз. Мин, Гали углан, илгә килгән яу куркынычы алдында бөтен эшне үз кулыма алам. Сез — аксакаллар, син, Ураз бәк, сез — болгар илчеләре, каршы түгелме?

Барысы да: Түгел! Түгел!

Гали. Алайса, тыңлагыз... Ураз бәк! Мине озатып куярга тиешле мең кешелек чирүдән тыш, корал тота алган барлык ирләреңне минем карамакка бирәсең.

Ураз бәк. Бирәм, Гали углан! Нәрсә кирәк — барын да бирәм. Менә, бер мең алтынны да бирәм! *(Акча янчыкларын Гали алдына ташлый.)*

Гали. Көч сорап, берләшергә өндәп, күрше ыруларга хәзер үк кешеләр җибәрәсең.

Ураз бәк. Җибәрәм, Гали углан!

Гали. Коралны ирләрдән башка бөтен ыру халкына, терлек-туарларын куалап, киез өйләрен арбаларга төяп, тиз арада төньякка — Болгар ягына күченергә боерасың.

Ураз бәк. Боерам, Гали углан!

Гали. Ныгытылган шәһәрләрдә, авылларда алар болгар туганнары янында сыену урыны табарлар. Яу үткәнче качып калу өчен Болгарда урманнар, тау-ташлар житәрлек. *(Ярмышка.)* Син, Ярмыш, юлдашларың белән хәзер үк Бүләр ягына юл тотасың. Сәүдәгәр Тукаш та сезнең белән бергә китәр.

Ярмыш. Миңа шундый боерык кына кирәк тә!

Гали. Мин сезгә өстәмә сакчы көч бирермен.

Тукаш. Менә монысы дөрес булыр, Гали углан!

Гали. Мин үзем, Ураз бәк белән берлектә, кул астындагы барлык көчне бергә туплап, дошманның юлына аркылы төшәчәкмен. Идел буенда берәр уңайлы урында яшеренеп, без аңа тозак корырбыз. Шунда без аларны тар-мар итәрбез! Ярмыш! Ханга, Актайга, сезне монда җибәргән башка кешеләргә минем теләкне ирештер: Болгар йортның бусага төбенә килеп җиткән явыз дошманны җиңәргә кирәк, дип уйласалар, миңа булышка иң яхшы чирүләрен җибәрсеннәр. Бу эшкә агам Хаҗи бәк каршы килергә мөмкин. Бу кара көннәрдә, элеккеләрне онытып, мин аңа дуслык, туганлык кулы сузам. Әгәр Хаҗи бәк гаскәр бирүгә каршы килмәсә, мин аны үземнән өстен санап, Болгар тәхетенә варислыктан баш тартачакмын!

Ярмыш. Син әйткәннәрнең барысын да түкми-чәчми житкерербез, Гали углан.

Илчеләр:

— Тыныч бул, теләгең үтәлер, Гали углан!

— Болгар сине ташламас, Гали углан!

Чәчәк *(чак-чак кына күңелсезләнеп)*. Болай булгач, безнең туй бозылды инде, Гали.

Гали *(Чәчәкне юатып, иркәләп)*. Чәчәгем — сылуым! Туйны без җиңүдән соң ясарбыз, менә диган иттереп ясарбыз! Хәзер сиңа, Бурлы ыруының барлык хатын-кызлары, бала-чагалары белән Болгар ягына китәргә туры киләчәк. Җиңүдән соң без синең белән Бүләрдә, хан урдасының Олы капуы янында очрашырбыз. Мине шунда көтеп торырсың.

Чәчәк. Мин ул капуның кайда икәнлеген дә белмим ич, Гали!

Гали. Мин сиңа белгән кешеләр бирер

мен, сылуым. *(Куенынан язма китап чыгара, Чәчәккә бирә.)* Оныта язганмын! Менә бу минем кыйссам. Мин аны язып бетердем. Син аны сакла... бик нык сакла! Мин алай-болай булып... үлеп калсам...

Чәчәк. Уеңа да китермә!

Гали. Яңадан күрешә алмасак, бу китапны атама — Болгар ханына тапшыр.

Чәчәк. Мин аны саклармын, Гали. Күз карасы кебек саклармын! *(Кочаклашалар.)*

**Пәрдә төшә**

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

### Беренче күренеш.

**Ханбалык. Хаҗи бәк сарае. Бай җиһазлы иркен бүлмә.**

**Бүлмә уртасында мәрмәр фонтан, кечкенә бассейн. Бассейнның як-ягында озынча утыргычлар. Түрдә — калку урын. Яхшы келәмнәр, җәнлек тиреләре. Ат, үгез сурәтләре төшерелгән тукымалар. Зур чүлмәкләрдә гөлләр. Стенадагы чөйләргә, болан мөгезләренә сугыш кораллары элеп куелган.**

**Сәхнә ачылганда, Энҗе бикә, тәрәзәгә капланып, тышкы якны күзәтә. Янында ике хезмәтче хатын. Шулай ук тәрәзәгә капланганнар. Урам яктан туктаусыз шау-шу, күңелле гөрелдек ишетелеп тора.**

**Бераздан борчылган, үртәлгән кыяфәттә Хаҗи бәк килеп керә. Өстендә җиңелчә өй киеме: ефәк халат, ефәк ыштан, билендә гади билбау, аягында — каюлы йомшак итек. Башы яланбаш.**

Хаҗи бәк. Кайтып та җиткәннәрмени, бикә?

**Хатын-кызлар кинәт артларына борылып карыйлар. Барысы да көләч. Хаҗи бәкне күрү белән, йөзләре сүрелеп кала. Хезмәтче хатыннар шыпырт кына чыгып китәләр.**

Энҗе бикә *(аңламыйча).* Кемнәр кайтып җиткән, Хаҗи?

Хаҗи бәк. Син соң кемне күзәтәсең, бикә?

Энҗе бикә. Урам тулы халык. Барысы да олы капка ягына ашыгалар.

Хаҗи бәк. Синең да аларга ияресең килә, ахрысы?

Энҗе бикә. Кайчагында килә, кайчагында минем дә, өстемдәге бай киемнәремне салып ташлап, каралар сыман киндер, тире киемнәргә киенеп, базарда, халык арасында... Чирмешән буйларында йөрисем килә!

Хаҗи бәк! Теләсәң, син бүген үк, хәзер үк китә аласың... җиңүчеләрне каршыларга!

Энҗе бикә. Ник, җиңүчеләрне каршылау миңа тыелганмыни, Хаҗи?

Хаҗи бәк. Алай дип әйтсәм, телем корысын, бикә!

Энҗе бикә. Шулай да синең шулай дип әйтәсең килә, Хаҗи!

Хаҗи бәк. Юк, минем бары: Галине көтәсеңме, Энҗе бикә, дип әйтәсем генә килә.

Энҗе бикә *(үзгәреп).* Мин тагын сезне татулаштыгыз, дип уйлаган идем.

Хаҗи бәк. Без татулаштык. Ләкин татулашу шатлыгыннан минем йокым качты, җиңү шатлыгыннан йөземне кара кайгы басты.

Энҗе бикә. Нишләп аны әлегрәк әйтмәдең? Тәрәзәдән карамаган булыр идем.

Хаҗи бәк *(кискен, тупас).* Мин синең атаң — Карт Бүрене көтәм. Бу тирәдә күренмәдеме ул?

Энҗе бикә. Ул синең сарык тиресе ябынган яшь бүре икәнлегеңне сизенгәндер дә килмәскә булгандыр.

**Күгеш керә.**

Күгеш. Актай килде. Сине сорый, бәк.

Хаҗи бәк. Монда керсен. *(Энҗе бикәгә.)* Ул әле берни сизенмәгән, бикә. Ул мине һаман да сарык дип уйлый!

**Күгеш чыга. Энҗе бикә дә чыгып китмәкче була.**

Энҗе бикә. Сезнең үзара чәйнәшүегезне карап торсам, эчем поша башлый.

Хаҗи бәк. Чыкма. Сиңа күңелсез булмасын өчен, бу юлы без өчәүләшеп чәйнәшербез.

**Ашыгып, Актай керә.**

Актай. Исәнмесез, кияү, кызым! Бөтен ханбалык кырмыска оясыдай мыж килеп тора. Барча кеше урамда: төзәнгәннәр, ясанганнар. Капкаларга байраклар элгән-

нәр. Җиңүчеләрне сыйларга әле анда, әле монда казаннар асканнар. Олы туй бүген, балалар! Болгар шәһәрендә мондый куанычны гомеремдә күргәнем юк. Сезнең... ник йөзегез чытык?

Энҗе бикә. Исәнме, әти.

Хаҗи бәк. Исәнме, бабакай. Без әле генә синең кызың белән сугыштык. Яңакка берне шундый иттереп кундырды — күземнән утлар күренде! Үзенә дә берне тондырмакчы булган идем, син килеп кердең.

Актай. Синең, кияү, җиңү көннәрең алда икән әле!

Хаҗи бәк. Минем җиңелгәнем дә юк, бабакай.

Актай. Синең миндә йомышың бар бугай, кияү?

Хаҗи бәк. Йомышым түгел, сүзем бар, бабакай!

Актай *(түрдәге йомшак урынга аякларын бөкләп утыра, дога кыла)*. Болай булгач, дога кылып алыйк, балалар. Зур сөйләшү алдыннан китап дога кылырга куша.

Хаҗи бәк *(көлеп)*. Доганы зур сөйләшүдән соң кылу тагын да яхшырак була торган иде, бабакай. Синең кебек мин качышлы уйнамаячакмын. Бүген мин сиңа турысын ярып салачакмын, бабакай!

Актай. Мин сине кыек яра дип уйламыйм да, кияү.

Хаҗи бәк. Мин зур эшләр кырмакчы булам, бабакай. «Эш кыра» башлаганчы, шулай да синең белән киңәшмәкче булдым. Билгеле, мин синнән башка да «кыра» алган булыр идем. Ни өчен дигәндә, ханбалыктагы чирү минем яклы. Ташкирмәдә, Тубылгытауда, Суарда, Иске Болгарда — якын тирәдәге барлык шәһәрләрдәге кораллы көчләр шулай ук минем яклы. Болгар аксөякләренең күбесе минем яклы. Шулай да, бабакай, синең белән киңәшмичә, мин әлегә кыл да кыймылдата алмыйм. Теләсәк тә, теләмәсәк тә, безнең кендек бергә ябышкан.

Актай. Син, кияү, миңа берекккән кендегеңне тартып алмакчы буласың, ахрысы. Ләкин, авыртыр, дип куркып, миннән киңәш сорамакчысың. Синеке авырткач, минеке дә авыртмас микәнни?

Хаҗи бәк. Син минем сүзләремне ялгыш аңлыйсың, бабакай. Бүгенге көндә мин, кендектән бигрәк, баш турында кайгыртам. Бер казанга ике тәкә башы сыймаганын беләсеңдер. Ә без — өч тәкә башы.

Актай. Тәкә башы, кияү, бер генә. Ул да булса — син!

Хаҗи бәк *(көлемсерәп)*. Син, бабакай, Карт Бүре, һаман тешле күренәсең. Шулай да син юкка хәйләләп маташасың. Бүген булмаса, иртәгә үләргә тиешле атам — карт тәкә башын санга тыкмаганда, ике баш кала. Ике баш! Я ул, я мин!



*«Кол Гали» спектакленнән бер күренеш.*

Энҗе бикә. Ни сөйлисең, Хаҗи?! Гали синең өлешкә керергә уйламый да!

Хаҗи бәк. Анысы дөрес — Галинең уйларын син миннән яхшырак беләсең.

Энҗе бикә. Юк, Хаҗи бәк, аның уйларын син дә яхшы беләсең! Ул безгә ап-ачык итеп белдерде: мин агамны үземнән өстен саныйм, тәхеттән баш тартам, диде. Галинең сүзләренә ышанганга күрә дә син бернинди каршылыксыз аңа утыз меңлек чиру бирдең. Әллә шулай түгел димәкче буласың?

Хаҗи бәк. Шулай, бикә, барысы да шулай. Алай гына да түгел, әнә ул — Гали углан — мин җибәргән утыз мең болгар белән, биш-алты мең кыпчак белән явыз дошманны җиңеп, ханбалыкка кайтып килә. Бөтен халык Олы капкага Галине каршыларга ашыга. Гали үзе ханбалыкка кайткач шәп итеп туй ясамакчы, ди, Ураз бәкнең кызы Чәчәккә өйләнмәкче, ди.

Энҗе бикә. Нинди Ураз бәк ул тагын?

Хаҗи бәк *(мыскыл белән).* Нинди Чәчәк ул тагын, диген.

Энҗе бикә *(үртәлеп).* Син бүген кире ягың белән торгансың, Хаҗи бәк!

Хаҗи бәк. Минем уңай ягым белән торганым да юк, Энҗе бикә.

Энҗе бикә *(үпкәләп, хәтере калып чыгып китмәкче була).* Миннән башка гына талашыгыз.

Актай. Ашыкма, кызым. Бүген монда Болгар язмышы гына түгел, безнең язмыш та хәл кылына. Син, кияү, турыдан ярыла торган сүзеңне әйтеп бетермәдең.

Хаҗи бәк. Мин аның бераз өлешен әйттем. Гали исән чакта бу дөньяда миңа тынгы булмаячак, бабакай. Мин кем генә булсам да — ханмы, варисмы анда — кайдадыр якында гына Гали барлыгын белә торып, беркайчан да күңел тынычлыгы тапмаячакмын. Мин сездән бер нәрсә дә яшермим: мин аннан көнләшәм, мин аннан куркам! Мин аның яхшылыгыннан, батырлыгыннан куркам, аның бөеклегеннән куркам! Бертуктаусыз ул минем канымны агулый, күңелемне ярсыта! Гомер буе шулай газапланып яшәргәме?

Актай. Синең газапланып яшәвеңә Галидән бигрәк син үзең гаепле түгелме, кияү?

Хаҗи бәк *(кискен).* Юк-бар сүзләреңне куеп тор, бабакай! Мин Галине юк итәргә тиешмен — менә шул минем туры сүзем.

Актай. Миннән ни сорала?

Хаҗи бәк. Киңәш.



*«Кол Гали» спектакленнән бер күренеш.*

Актай. Минем киңәшнең сиңа инде кирәге калмаган. Шулай да мин сиңа үз фикеремне әйтеп карыйм, кияү. Бу куркыныч, хәтәр көннәрдә күңел газапларыңны бер читкә куеп, ил кайгысын кайгыртсаң, яхшы булмас микән? Бер җиңелү белән генә магулларны кире чигенерләр, дип әйтеп булмый. Яу куркынычы бетмәгән. Мондый чакта Галине юк итү бик зур акылсызлык булачак. Галидән файдалана белергә кирәк. Аның кебек булдыклы, нык куллы ирләр хәзер бу дөньяда бик аз калды. Сиңа ничек тә тәхетне, Болгарны саклау турында уйларга кирәк. Тәхетне яулавы җиңел булыр, саклап кала алырсыңмы, юкмы — анысын бер хода белә.

Хаҗи бәк. Анысын мин дә беләм, бабакай.

Актай. Шулай булгач?

Хаҗи бәк. Мин синнән бары шуны гына сорамакчымын: Галине ничек юк итәргә?..

Энҗе бикә. Хаҗи, син чынлап та?!..

Хаҗи бәк *(тупас).* Чынлап та, бикә. Юри генә сөйләнәдер бу, дип ялгыша күрмәгез. Мин инде кайбер эшләр эшләдем дә. Чыңгызга каршы көрәштә ярдәм сорап, мин урысларга илче җибәрдем. Анннары мин, бабакай, җиңүчеләргә шәһәр капкаларын ачмаска боердым.

Актай. Шулай укмыни?!

Хаҗи бәк. Шулай ук, бабакай! Мин ханбалыкка Гали яклы кыпчакларның керен тулуын теләмим.

Актай. Менә монысы ялгыш. Кыпчак — синең кан-кардәшең, кияү!

Хажи бәк *(тыңламыйча).* Аннары мин, бабакай, хан сараен камап алырга боердым. Инде камап та алганнардыр.

Энҗе бикә *(Актайга сыенып).* Әти! Бу ни бу!? Безне дә.

Актай *(киеренке).* Тыныч бул, кызым. Ул әле үз сараен камап алырга боерык бирмәгәндер.

Хажи бәк *(көлемсерәп).* Шулай, бабакай, син уйлаганча, булдыклы, нык куллы ирләр Болгарда бөтенләй үк бетеп житмәгәннәр әле.

Актай. Син хаклы, кияү. Ләкин мин ник кирәк сиңа?

Хажи бәк. Безнең кендекләр бергә ябышкан дип, мин сиңа тиккә генә әйтмәдем, бабакай. Тәхеткә утыргач, миңа синең акылың, хәйләкәрлегең, осталыгың кирәк булачак. Әйт миңа турысын гына: син кем яклы — минем яклымы, әллә?..

Актай *(киеренке тынлыктан соң).* Барысы да ачыкланды дисәм, бер нәрсә калган икән. Тәхеткә утыргач, Тәүгилде тарханны кая куярсың?

Хажи бәк *(үртәлеп).* Тәхет тирәсендә аңа урын булмаячак.

Энҗе бикә *(сөенеп).* Әти!

Актай *(йомшап, куаныч белән).* Мин, кияү, синең атаң белән утыз елга якын бер табактан ашадым. Утыз ел эчендә мин бер генә тапкыр да аның теләгенә каршы килмәдем, бер генә тапкыр да аңа ялгыш киңәш бирмәдем, бер генә тапкыр да хыянәт итмәдем. Минем тырышлык аркасында изге Болгар илендә һәрвакыт тынычлык, иминлек булды. Эшне белеп башкаруым нәтиҗәсендә Болгарның байлыгы, көче артты, җире-суы киңәйде. Соңгы елларда хан бик картайды, акылы зәгыйфьләнде...

Хажи бәк. Бабакай, сузма!

Актай. Кияү... Хажи бәк, мин синең яклы! *(Хаҗи бәкнең аяк астына егыла, итеген үбә.)*

Энҗе бикә *(хурланып).* Әти! Тор!

Актай *(тора, Хаҗи бәкнең кулын үбә).* Шаулама, кызым. Үз кияvемнең кай жирен үпсәм дә, үпкәләмәс. Аягы астында ятсам да, язык булмас. Тик табаны астында гына ятмаска!

**Хажи бәк үз-үзеннән канәгать кыяфәттә кеткелдәп тора. Актай үпкәләгән баланы иркәләгәндәй, кызы Энҗе бикәне иркәли. Барысы да шат. Хажи бәк белән Энҗе бикә чыга.**

Актай *(ялгыз).* Карап карарбыз, иң ахырда кем кемнең аяк астында ятар бит әле!

## Икенче күренеш.

**Кирмән, ягъни хәрби лагерь. Зур, иркен чатыр. Уртада учак. Учак янындарак — багана. Баганага калканнар, ук-җәя ише кораллар эленгән. Түрдә калку урын. Анда яралы Ураз бәк ята. Сәхнә ачылганда, Гали, тирән уйга чумып, әрле-бирле йөренеп тора.**

Ураз бәк *(хәлсез. Үзалдына сөйләнә).* Олы җиңүне күрдем, олы туйны күрә алмадым. Инде күрмәм дә. Өметем киселде. Хәлем бетә бара, күз алларым караңгылана.

Гали *(йөрүеннән туктап).* Имче чакыртыйммы?

Ураз бәк. Мине инде имче генә терелтә алмас. Озакламый мин тәңре катына китәм. Сизеп ятам — күп калмады. Үзе өчен борчыла икән, дип уйлый күрмә...

Гали. Чәчәк турында да борчылма. Мин аны ташламам, кыерсытмам. Мин исән чакта аңа берникди кыенлык килмәс.

Ураз бәк. Мин сиңа ышанам, Гали. Ләкин синең үз хәлең яман.

Гали. Алай ук яман түгел. Безнең хәл озакламый ачыкланырга тиеш. Болгарда бер Хажи бәк кенә түгел, Болгарда әле хан бар, Актай бар. Гаскәр бар, халык бар! Мин атама, Актайга яшерен кешеләр җибәрдем. Алар тиздән кайтып җитәрләр дип уйлыйм. Кем кертми безне ханбалыкка — Хажи бәк кенәме, әллә атам дамы? Безгә менә шуны белергә кирәк.

Ураз бәк. Беләсе юк. Барысы да билгеле. Хажи бәктә — көч. Ул сине ханбалыкка якын да җибәрмәячәк. Таярга кирәк моннан исән чагында, Гали! Китик далага. Магул качты, дала үзебезгә калды. Алып кайт син мине үз даламә — мин шундук аякка басармын. *(Башын калкыта, торып утырмакчы була.)* Гали! Тыңла сүземне — кайтыйк далага!

Гали. Сине дала тарта — мине ханбалык тарта.

Ураз бәк *(яңадан торып утырмакчы була)*. Гали! Кил әле, тыңлале!

Гали *(Ураз бәк алдына тезләнә)*. Бәк... бабам, син яралы, сиңа борчылырга ярамый.

Ураз бәк. Син шулай да тыңла. Аннары уйлап кара.

Гали. Ярар, уйлап карармын.

Ураз бәк. Мин үлгәч... юк, далага кайту белән үк! — син минем урынга калырсың. Бәк булып! Ыру башы булып! Күз алдыңа китер — кыпчак даласы иксезчиксез! Анда утыз-кырык ыру. Берләштер шуларны! Бер йодрыкка тупла, Кыпчак-йорт яса! Син булдырырсың аны, Гали! Ул чагында... Хажи бәк тә... Чыңгыз хан да... О-у, ул чагында!

Гали *(уйчан)*. Уең изге, Ураз бәк. Шулай да бераз көтик инде, көтик! Кыпчак даласына китү беркайчан да соң түгел. Көтик, бабам: ачыклансын, барысын да тыныч юл белән хәл итик. Без әле керербез ханбалыкка, ясарбыз олы туйны!

Ураз бәк *(түшенке)*. Менә монысына инде ышанмыйм, Гали. Чәчәкне табып китерергә дигән кешеләрең дә кайтып житмәде.

Гали. Аларын да көтик. Чәчәк әле безнең нинди көлке хәлгә таруыбызны белми дәдер.

Ураз бәк *(башын калкыта, үртәлеп)*. Көлке хәл дисеңме? Аяныч хәл, кызганыч хәл, Гали! Монда, үз илеңә кайткач, сиңа әллә ни булды. Балалар сыман жебеп төштең дип әйтимме... уяулыгыңны югалттыңмы...

Гали. Дөрес, миңа чынлап тә әллә нәрсә булды. Күңелем йомшарды. Берниндә усаллык турында уйлыйсым килми. Мин хәтта Хажи бәкнең мәкеренә дә ышанмыйм. Боларның барысы да кемнеңдер ялгышыдыр кебек кенә. Алар шулай безнең тиз кайтып житүебезне абайламый калганнардыр да, капкаларны ачарга боерык булмаганлыктан, безне тоткарларга мәжбүрләрдер сыман. Кайгырма, бабам! Менә тиздән каерылып капкалар ачылыр, байраклар күтәрелер, бөтен ханбалык, шау-гөр килеп, безне каршыларга чыгар!

Ураз бәк. Ах, башым авырта! Кайтыйк далага! Тыңла сүземне, Гали!

Сакчы керә.

Сакчы. Ханбалыктан илчеләр килде.

Гали *(чиксез куанып)*. Илчеләр! Яшибез, бабам, яшибез, Ураз бәк!

## Өченче күренеш.

**Караңгы. Уртада беленер-беленмәс кенә учак яна. Югарыда чатырның түгәрәк төннегеннән йолдызлар күренә. Гали ялгыз.**

Гали *(үз алдына сөйләнә)*.

Тышта төн. Тавышлар тынган.
Канат жәйгән йокы һәр якка.
Тик мин генә уяу, байгыш сыман.
Йокы качты миннән еракка!

*(Югарыга карый.)* Кыпчак даласында да шундый ук төн иде, күктә йолдызлар яна иде. Монда да шундый ук төн, шундый ук йолдызлар. *(Йөренә.)* Юк, монда йолдызлар яктырак яна, Гали, монда йолдызлар якынрак. Берсе бүген жиргә төшкән. Төшкән дә үзе синең янга килгән. Кая соң әле ул, күренми? *(Карана. Ярым караңгыда Энҗе бикә күренә. Өстендә озын кием, башында — бөркәнчек.)* Әнә йолдыз! Шашма, йөрәгем!

## Дүртенче күренеш

**Энҗе бикә ялгыз.**

Энҗе бикә. Никтер эчем поша, күңелем шомлана. Мин ут белән су арасында. Үзем куркам, аякларым һаман монда тарта. Тәңрем-аллам, изге юлдаш бул! Кая килеп кердем соң мин — ожмахкамы, әллә тәмугкамы? *(Нәрсәгәдер абынып китә, җиңелчә генә кычкырып җибәрә.)* Ай!

## Бишенче күренеш

**Гали һәм Энҗе бикә.**

Гали *(ашыгып Энҗе бикәгә таба атлый)*. Энҗе, синме?

Энҗе бикә. Гали!

**Кочаклашалар.**

Гали. Энҗем-йолдызым!

Энҗе бикә. Гали, бәгърем! Син — исән!

Гали. Без тагын бергә!

Энҗе бикә. Я тәңрем, нинди куаныч! Син — исән! Син бөтенләй үзгәрмәгәнсең, Гали.

Гали. Син дә. Элеккечә синнән татлы ис килә. Тавышың да шул ук... күзләрең, чәчләрең...

Энҗе бикә. Юк, син үзгәргәнсең: элеккедән бераз гына кырысрак, усалрак... чибәррәк!

Гали. Анысы дөрес түгел. Мин — ямьсез. Хаҗи бәк менә чибәр!

Энҗе бикә *(каушап)*. Ник?.. Нигә... Юк, юк, әйтмә аны, исемен дә телгә алма!

Гали. Кичер, уйламыйча әйтелде. Минем дә аны телгә аласым килми. Ләкин онытып та булмый.



*«Кол Гали»* *спектакленнән бер күренеш.*

Энҗе бикә. Онытыйк без аны, Гали?

Гали *(тынычсызланып йөрен<br>ә башлый)*.

Исемен әйтү белән туганымның,
Нидер сынды, нидер ватылды...

*(Энҗе бикә каршында туктап кала. Беркадәр читләшү, кырыслану белән.)* Онытыйк дисеңме? Аны оныткач, сине дә... синең Энҗе бикә булуыңны да онытыргамы?

Энҗе бикә. Алай... әйтмә миңа, Гали!

Гали *(яңадан йөрен<br>ә башлый)*. Ярар, әйтмәм. Онытырбыз. Шулай да ничек дип әйтергә соң сиңа? Кем дип эндәшергә? Тегендә, читтә, иң авыр, иң кыен чакларымда мин сине уйлап юандым. Йөрәк ярсуымны басар өчен озын төннәремдә мин кыйсса язып уздырдым. Шунда мин сине тиңсез Зөләйха итеп сурәтләдем.

Энҗе бикә. Бәгърем! Бөтен Болгарда син — иң атаклы шагыйрь.

Гали *(тыңламыйча)*. Әлегәчә мин сине шул гүзәл Зөләйха итеп күз алдына китердем. Минем өчен Зөләйха да, Энҗе дә бер кеше булып тоелды.

Энҗе бикә. Гали, син әллә ничек аңлаешсыз итеп сөйли башладың.

Гали *(читләшеп)*. Юк, инде аңлаешлы кебек. Кинәт күз алларым яктырып китте. Барысы да аңлашылды хәзер!

Энҗе бикә. Гали, сөйләшмә алай!

Гали *(тукталып. Кызу-кайнар)*. Зөләйханы Энҗе белән бутап, мин бик каты ялгышканмын. Зөләйха — башка! Зөләйха — саф, тугрылыклы.

Энҗе бикә *(үпкәләп)*. Минем нинди дер Зөләйха буласым да килми. Минем бары Энҗе генә буласым килә.

Гали. Син инде Энҗе генә дә була алмыйсың! Син — бикә, ишетәсеңме, Энҗе бикә! Ха-ха! Хаҗи бәк... хатыны... *(Йөзен каплый, үкси.)*

Энҗе бикә *(юатмакчы була)*. Гали, бәгърем! Синең өчен мин һәрвакыт — Энҗе!

Гали *(башын калкыта. Тыныч, салкын)*. Ник килдең монда?

Энҗе бикә. Синең янга мин... илче булып килдем, Гали.

Гали. Сөйләп кара. Ник кертмиләр безне ханбалыкка?

Энҗе бикә. Агаң кертми. Кыпчаклардан курка. Керсәләр, таларга, көчләргә тотынырлар, ди.

Гали. Кыпчаклар миңа буйсына. Мин берникди талауга, көчләүгә юл куймаячакмын. Беләме шуны Хаҗи бәк?

Энҗе бикә *(яңадан ягымлы, серле итеп)*. Гали! Шулай ук син мине... әз генә булса да яратмыйсыңмыни?

**Гали эндәшми, йөрен<br>ә башлый.**

Гали *(туктый)*. Син — илче. Сүзеңне сөйләп бетер, Энҗе.

Э н ж е б и к ә. Мин сине... коткарырга килдем, Гали!

Г а л и. Кемнән, нәрсәдән?

Э н ж е б и к ә. Үлемнән.

Г а л и. Үлемнән? Нинди үлемнән?

Э н ж е б и к ә. Хажи бәк сине юк итмәкче була.

Г а л и *(кызу-кызу йөренә)*. Ул мине бер тапкыр юк итмәкче булды инде. Ул чакта минем нибарысы ун-унбиш кешем бар иде. Хәзер минем кырык меңгә якын чиреүем бар. Юк итеп карасын ул мине!

Э н ж е б и к ә. Сиңа хәзер үк нидер эшләргә кирәк, Гали!

Г а л и. Әйтеп кара, нишләргә икән?

Э н ж е б и к ә. Хажи бәк өлгергәнче, аның үзен юк итәргә кирәк. Теләсәң, хәзер үк, таң атканчы ханбалыкка бәреп керә аласың. Мин капка каравылын сатып алдым — алар минем яклы. Тәхеткә юл ачык. Йоклап кала күрмә, Гали!

Г а л и. Димәк, син миңа тәхет ачкычы алып килдең?

Э н ж е б и к ә. Мин синең белән, Гали!

Г а л и *(авыр, киеренке)*. Мин ханның, Болгарның җирен-суын, иминлеген саклап, юлбасарларга, илбасарларга каршы яу чаптым. Мин ханның, Болгарның җирен-суын арттыру өчен чит халыклар белән сугыштым. Ләкин мин беркайчан да болгарларны болгарларга каршы алып бармадым. Агамның, атамның, меңләгән болгар туганнарымның канлы мәетләре аша тәхеткә утырсам, исән калганнар — мин үтерткән болгарларның ата-аналары, туганнары — бөтен ил халкы миңа нинди күз белән карар?

Э н ж е б и к ә. Намус, вөҗдан дигәндә, син һәрвакыт талымчан булдың. Хәзер сайланып, тылымлап торыр чак түгел. Я син,— я ул! Миңа, тәхеткә син кирәк, Гали, син!

Г а л и. Канга буялачак тәхеттән мин баш тартам, Энҗе бикә!

**Тынлык.**

Э н ж е б и к ә *(Галигә бик якын килә, усал пышылдап)*. Син чынлап та миннән... Энҗедән баш тартасыңмыни?!

Г а л и. Мин бары Зөләйхадан гына... *(Сүзен әйтеп бетерә алмый — Энҗе бикә итәк астыннан хәнҗәрен чыгара, кадый.)*

Э н ж е б и к ә. Тәхет тә, Энҗе дә агаңа булыр! Хуш, шагыйрь! *(Ашыгып чыгып китә.)*

Г а л и. А-а! Хыянәт! *(Егыла.)*

**Йөгереп сакчылар керә. Гали янына киләләр.**

С а к ч ы л а р:

— Кая, кем кычкырды?

— Ни булды?

— Гали! Галине үтергәннәр!

— Тотыгыз, тот! Монда теге бөркәнчекле хатын гына булды.

**Сакчыларның берсе ашыгып чыгып китә, икесе Гали янында кала.**

Г а л и *(хәлсез)*. Кирәкми. Инде соң. Тимәгез аңа... Чәчәк... кыйссам... Кайда син?.. *(Үлә.)*

## Соңгы күренеш

**Әкренләп таң ата бара. Анда-санда янгын утлары күренә. Ыңгырашкан тавышлар ишетелә. Бу — яудан соңгы Бүләр. Җимерелгән йортлар, манаралар. Янган, кара күмергә әйләнгән агач калдыклары. Мәетләр, киселгән кул-аяклар. Сынган сөңгеләр, ватылган калканнар. Еракта куккә ашкан кара төтен — анда һаман нидер яна. Авыр, кайгылы музыка.**

**Агач-таш арасыннан Шәмсетдин килеп чыга. Ярым ялангач. Өтәләнгән. Чәчләре тузгыган, битен сакал-мыек баскан. Әледән-әле артына карый, як-ягына карана, абынасөртенә, каядыр ашыга. Туктый, утыра, бер башы янган ниндидер бүрәнәгә сөялеп хәл җыя.**

Ш ә м с е т д и н *(ерактагы янгыннарга карап)*. Дөмекте ханбалык. Дөмекте Болгар. Актайлар, ханнар, Энҗе бикәләр — барысы да дөмекте. Тәңрегә тиң Чыңгыз ханның изге кулы монда да килеп җитте. Ха-ха, беттеме башыгыз! Мин — исән! *(Башын тотып карый.)* Баш исән, Шәмсетдин, баш! Ха-ха, мин тагын качтым! *(Күзгалып китә, икенче яктан килеп чыккан Чәчәкка барып бәрелә яза, туктый.)* А! Син кем? *(Кача башлый, егыла.)*

**Чәчәкнең йөзендә чиксез кайгы. Култык астына нидер төреп тоткан. Иелеп-иелеп мәетләрнең йөзен карап йөри. Үлекләр арасыннан кемнедер эзли, үз алдына: «Юк, түгел», кебек сүзләр әйтеп куя. Шәмсетдинне күреп, кире чигенә.**

Ч ә ч ә к. Син... тере кеше түгелме соң?

Ш ә м с е т д и н. Юк, юк, мин тере кеше түгел! *(Кача башлый.)*

Ч ә ч ә к *(Шәмсетдингә якын килә, йөзенә карый).* Юк, син түгел.

Ш ә м с е т д и н. Юк, юк, мин түгел! Сиңа кем кирәк? Син үзең кем?

Ч ә ч ә к. Күрәсең ич, бер тол хатын.

Ш ә м с е т д и н *(качарга азаплана).* Юк, юк, мин ир түгел! Мин — Шәмсетдин. Мин — галим. *(Чәчәкнең култык астындагы төргәкне күреп ала.)* Бу ни? Икмәкме? Бир монда! *(Тартып алмакчы була.)*

Ч ә ч ә к. Бу — китап.

Ш ә м с е т д и н. Китап! Ха-ха, китап! Утка як, чүплеккә ташла! Болгар бетте, китап бетте. Кирәге юк, бетсен, дөмексен!

Ч ә ч ә к *(Шәмсетдиннең кулыннан тотып ала).* Син, галим, укый белмисеңе? Өйрәт мине укырга!

Ш ә м с е т д и н *(Чәчәктән ычкынмакчы була).* Юк, юк, мин укый белмим. Кит моннан, кит!

Ч ә ч ә к *(Шәмсетдинне ычкындыра үз алдына сөйләнә).* Бичара... җир корты... тирес корты. *(Үз юлы белән китә, мәетләрнең йөзләренә карый. Үтеп китешли Шәмсетдингә.)* Курыкма, тимәм. Миңа синең ише тере мәетләр кирәкми, миңа батыр үләләр кирәк.

Ш ә м с е т д и н. Батыр үләләр кирәк дисеңме? Ха-ха, батыр үләләр! Туктале, бу минем баш микән соң? *(Башын тотып карый.)* А-а! Әллә кем башы бу! А-а! *(Җиргә ятып үрле-кырлы килә, шуышып, каядыр китеп бара.)* Юк, юк, тоталмассыз! Мин качарга өйрәнгән инде...

Ч ә ч ә к *(китабын күз алдына китерә, ача, актара, караштыра).* Бөек кыйсса, мәңгелек истәлек. Мин сакларммын, Гали, синең китабыңны. Мин өйрәнермен, мин укырмын, Кол Гали, синең Йосыф атлы батыр ир белән Зөләйха атлы гүзәл кыз турындагы тиңсез җыруыңны!

**Пәрдә төшә**

*1972 ел. Казан*

**Хатип Госман,**
филология фәннәре докторы, профессор

# ЕРАК ЧЫГАНАКЛАР

Шагыйрьнең иҗаты турында хөкем йөртер өчен, иң элек аның иҗтимагый-эстетик идеалларын белергә, бу идеалларга ирешүдә әдәбияттан, сәнгатьтән ничек файдаланырга уйлавын күз алдына китерергә кирәк. Бу хактагы уй-фикерләрен шагыйрь, гадәттә, мәкаләләрендә, хатларында яки әдәбият-сәнгать турында махсус язылган китапларында әйтеп бирә. Әмма Кол Галидән безгә хат та, сәнгать турында махсус язылган хезмәтләр дә килеп җитмәгән. Мондый очракларда шагыйрьнең иҗтимагый карашлары нинди булганын, әдәбият-сәнгать һәм иҗат мәсьәләләрендә нинди юл тотканын аның безгә килеп җиткән әсәрләреннән чыгып ачыкларга мөмкин. Кол Галидән исә безгә тик «Кыйссаи Йосыф» әсәре генә килеп җиткән.

Чын сәнгать әсәре, кайсы гына заманда язылса да, аның үзәгендә җәмгыять белән шәхес арасында булган бәйләнеш һәм мөнәсәбәтләр яктыртыла. Бу мөнәсәбәтләр, үз нәүбәтендә, шул замандагы җәмгыятьтә нинди сыйныф хакимлек иткән дә, нинди сыйныфлар аңа буйсынулы, мәҗбүриятле ителгән булуына бәйләнгән. Кол Гали заманы — халык массалары өстеннән феодаллар хакимлек иткән рәхимсез заман. Монда хезмәт иясе булган шәхесләрнең үз араларында булган мөгамәлә һәм мөнәсәбәтләре — теләктәшлек рухында, гуманистик мәгънә белән сугарылган; әмма хезмәт ияләре белән феодаллар, аларның да иң дәве булган патша арасындагы мөнәсәбәт һәм мөгамәләләр сыйнфый антагонизм, дошманлык, нәфрәт белән сугарылган. Феодалларга хас ерткычлык, явызлык, халыкка нәфрәт күзе белән карау сыйфатлары, патша шәхесендә бергә җыйналып, әзрәта рәхимсез власть көченә әверелгән. Ләкин халык массалары патша сыйфатларында бөтен бер эксплуататор сыйныфның хас сыйфатлары бербөтенгә оешып гәүдәләнә дип уйламаганнар. Хәтта бик намуслы акыл ияләре, укымышлылар, галимнәр дә бу сыйфатлар патшаның үз табигатеннән, тәрбиясе җитмәүдән, гыйльме-белеме булмаудан килә дип санаганнар. Шушыннан инде явыз патша урынында тәрбиясе белән халыкка хуш килерлек кешелекле, укымышлы һәм гадел ниятле патша утырса, ил-көн, бөтен халык бәхетле заманнарга барып чыгар иде дип өметләнгәннәр. Шулай, урта гасырларда халык хыялында мәгърифәтле һәм кешелекле гадел хөкемдар идеалы туган. Бу идеал үткән заманнарда, әдәби образ рәвешенә кертелеп, Көнчыгышның һәм Көнбатышның күп кенә язучылары тарафыннан тасвир итеп үтелгән. Кол Гали — шундый язучыларның берсе.

Ул заманда Көнчыгышта патшалар турында төрле легендалар сөйләнгән һәм язылган. Шулардан берсе — Ибраһим Әдһәм турында. Ул 776—783 елларда Бәлх шәһәрендә патшалык иткән. Ләкин, башка кешеләр хезмәте белән табылган хәзинә исәбенә яшәү — явызлык дигән нәтиҗәгә килеп, бер көн патшалыгыннан, тәхетеннән ваз кичкән; дәүләтнең хәзинә сарайларын ачтырган, алтын-көмеш һәм затлы әйберләрне халыкка тараттырган, үзе дәрвишлеккә чыгып киткән; калган гомерен төрле илләрдә физик эшләр башкарып кичергән.

Бу — феодаллар заманындагы иҗтимагый явызлыкка бер протест күренеше, ләкин пассив протест күренеше булган. Бөтен бер илнең бар-булган дәүләтен таратып ташлауда анархистик шаукымны чамалау кыен түгел.

Кол Гали бу юл белән китмәгән. Аңарда дәүләтчелек идеясе — тотрыклы, нигезле идея. Аңарда булган дәүләтне җимереп ташлау түгел, бәлки аңа, патша итеп, мәгъ-

рифәтле һәм кешелекле хөкемдар куюь, патша белән халык арасында гадел мөнәсәбәтләр урнаштыру идеясе алга сөрелгән. Дөрес, бу үзе — чынлыкта тормышка ашмый торган утопик идея, дәүләтнең сыйнфый табигатен аңламаудан килгән ният. Шулай да монда, бу утопиядә, хыял төсендә булса да, халык массаларының өметләре гәүдәләнгән. Шагыйрь җәмгыять белән шәхес арасындагы мөнәсәбәтләрне әсәрдә зур күләмгә күчереп, патша белән халык арасындагы мөнәсәбәтләр рәвешендә яктырткан. Үзеннән-үзе билгеле, мәсьәләне болай зур күләмдә алгач, тасвир ителә торган шәхеснең дә халыкка тиң килерлек олы сыйфатлары булу кирәк, аның халык кичергән авыр хәлләрне үз башыннан кичереп, зур тормыш тәҗрибәсе алган кеше булуы шарт. Әсәрдә боларга бербөтенлек сыйфаты бирер өчен катлаулы вакыйгалардан, коллизияләрдән торган сюжет кирәк. Мондый очракта борынгы язучылар, гадәттә, әзер сюжетлардан файдаланганнар, дөресрәге, үз әсәрләренең нигезе итеп, легендаларда эшләнгән, әдәбиятта тегеләйме-болаймы гамәлгә кергән әзер сюжетларны алганнар, ләкин аларны үз эстетик максатларына ярашлы итеп үзгәртеп, яңартып төзегәннәр. Кол Гали дә шулай эшләгән.

«Кыйссаи Йосыф»ның сюжеты хакында сүз чыкканда, гадәттә, аны автор «Коръән»нән алган, диләр. Бу аңлатма төгәл түгел. Йосыф турындагы легенда сюжеты кыска вакыт эчендә генә тумаган. Аның аерым өлешләре төрле заманнарда төрле халыклар тарафыннан иҗат ителгән. Мәсәлән, борынгы грек драматургы Еврипидның (б. э. кадәр 480—406 елларда яшәгән) «Ипполит» исемле трагедиясендә яшь Федра, үги улы Ипполитка гыйшкы кабынып, ире югында аңа мәхәббәтен белдерә, егетне атасына хыянәт итәргә өнди. Ипполит Федра таләбен кискен рәвештә кире кага. Моңардан чиксез гарьләнгән Федра, үч итеп, атасы югында ул мине көчләргә теләде дип үги улына яла яга. Вакыйга Ипполитның һәлак булуы белән тәмамлана. Бу мотив буенча соңрак борынгы Рим драматургы Сенека (б. э. кадәр 4.— б. э. буенча 65 елларда яшәгән) «Федра» исемле әсәрен иҗат итә. Мең ярым ел үткәч, француз драматургы Жан Расин (1639—1699) шул ук мотив нигезендә һәм шул ук исемдә драма иҗат итә. Ниһаять, 1919 елда латыш шагыйре Ян Райнис (1865—1929) «Йосыф һәм аның туганнары» исемле әсәрен бастырып чыгара.

Йосыф турындагы легенданың нигезе Еврипидка кадәр үк туган булырга мөмкин. Ул, төрле заманнарда төрле халыкларда туган төрле риваятьләрне үзенә җыя-җыя килешли, Еврипид файдаланган легенданы да үзенә кушып алып киткән булуы ихтимал. Безнең эра башлангач, әлеге сюжет Якын һәм Урта Көнчыгыш илләрендә таралган, дини китапларга, шул исәптән «Коръән»гә дә килеп кергән. Аңа мөселман илләренең төрле әдипләре мөрәҗәгать иткәннәр. Кол Гали аңардан киң колачлы дөньяви поэма иҗат итү өчен файдаланган. Шагыйрьнең төп максаты мәгърифәтле һәм кешелекле хөкемдар идеалын ачып салу булган. Шушы максатка хезмәт иттерер өчен ул сюжетның байтак өлешләрен яңартып эшләгән. Ул, күренә ки, мәгърифәтле һәм кешелекле хөкемдар, бер яктан, төрле катлаулардан торган ил халкының һәр катлавы тормышын яхшы белергә, икенче яктан, үзенең рухи-әхлак сыйфатлары белән камил шәхес булырга тиеш дип исәпләгән, шушы ике якның берлеге аңа дәүләт эшләрен гадел юлдан алып барырга юл ачар дип санаган. Шул яктан караганда, сюжетның үзара органик төстә үрелгән ике линиясе күренә: беренчесе — Йосыфның тормыш һәм эшчәнлек мәктәбе линиясе: аның өстен катлаулар гаиләсендә туып, сабыйлык елларын шунда уздыруы, ягъни бу катламның тормыш, әхлак нормалары турында мөһим тойгы-хисләр, төшенчәләр алып китүе, аннары кол булып кулдан-кулга сатылып йөрүе, коллар хәленең үз хәленә әверелүе, хыянәт-ялган, ялалар аркасында төрмәләр тоткыны язмышына дучар булуы; килəчəкне алдан күрү зирәклеге һәм моны аның халык язмышы белән бәйләве, халыкны ачлык һәлакәтеннән коткару чараларын күрүе, ниһаять, дәүләт башлыгы булып әверелүе. Икенче линия Зөләйха белән бәйләнгән. Монда Йосыфның күбрәк рухи-әхлак, намус, сабырлык кебек шәхси кешелек сыйфатлары ачыла һәм сынала.

Ахыр килеп, Йосыф патша була: «Утыз яшьлек егет башына таҗ киде, тәхеткә утырды, үзе чибәр, йөзе кояштай балкый, акылы камил, зур гыйлем һәм хикмәт иясе, конфликтларга кереп чуалган кешеләр, акыл сорап аңа киләләр; ул өстен катлаудanмы, гади халыктанмы,— барысына да дөрес, гадел хөкем чыгара; һичкем аның сүзеннән чыкмый...»

Әсәрдән шагыйрьнең сәнгатькә, шигърияткә карашларын да ачыклап була. Ул үз заманы тормышындагы ялган, хыянәт, гадел кешеләрне җәберләү кебек явызлыкларны фаш итеп, кеше өчен хакыйкать, бәхет һәм матурлык эзли; явызлыкны фаш итүдә сәнгатьне көчле чара итеп ала. Бу фикерне аңлатыр өчен, чагыштыру ясарга кирәк. В. Шекспирның «Гамлет» (1604) әсәрендә Гамлетка атасының өрәге, мине абыең белән аниең, хыянәтчел төстә, колагыма агу салып үтерделәр дә елан чагып үтерде дигән ялган хәбәр тараттылар, дип белдерә. Соңыннан Гамлет: «Өрәк әйткән чынмы? Әллә чын түгелме?» — дип газаплана. Ул сарайга килгән күчмә актерлардан файдаланырга уйлый. Ишетүенчә, уен барганда, тамашачылар арасында утырган җинаятьче сәхнәдә барган вакыйгалар тәэсирендә намусы уянып, сикереп торырга һәм бөтен халык алдында үзенең яшерен гаебен әйтеп салырга мөмкин икән... Актерлар белән сөйләшеп, ул уйналачак әсәрнең вакыйгалары арасында атасын үтерү эпизодын керттерә. Уен барганда алгы сафта Гамлетның абыйсы белән анисе утыра. Әлеге эпизод уйналып үтүгә, Гамлетның абыйсы (хәзер ул — король), яраланган ерткыч кебек акырып, сикереп тора да, бөтен залны тәшвишкә салып, шашынып залдан чыгып китә. Шушының белән Шекспир сәнгать кеше күңеленең иң тирән, караңгы почмагында яткан серләренә дә барып җитә ала һәм аларны ачып сала дигән идеяне раслый.

«Кыйссаи Йосыф»та да мондый эпизод бар.

Ачлык елны Йосыфның абыйлары, икмәк алыр өчен, Мисырга киләләр. Икмәкне өләшүче — Йосыф. Ул абыйларын таный, тегеләр моны — юк. Ул алар белән сөйләшүен дә тәрҗемәче аша гына алып бара. Йосыф шул арада сарай һәм шул сарайда кунак залы төзетә. Ул залның стеналарын матур эшләнгән рәсемнәр белән бизәтә, рәсемнәрдә исә абыйларының Йосыфны ничек коллыкка сатып җибәрү эпизодлары күрсәтелә. Йосыф абыйларын залга чакыра, тегеләр рәсемнәрдә үз гаепләре ачып салынуын күргәч, коелып төшәләр. Йосыф сый тәкъдим итә, тегеләр ашамыйлар...

Бу эпизод «Кыйссаи Йосыф»та Шекспирдан 400 ел элек язылган. Ләкин ике шагыйрьнең сәнгать турындагы карашлары бер.

Сәнгать кодрәте, идея буларак, гуманизм, матурлык, нәфислек формаларында гәүдәләнә. Тасвирлау осталыгы, тасвирлау матурлыгы да шул исәпкә керә. Әсәрен башлаганда ук шагыйрь «Акылым тулы, телем татлы булсын иде»,— ди, шигъри юллары укучыга «гөл-рәйхан аңкышлары булып ирешүен» тели, сүзләренең энҗе-мәрҗән булып тезелүенә омтыла, аларның укучыга рухи ләззәт китерүен максат итә.

Зөләйха линиясе Йосыфның, шәхес буларак, рухи әхлак сыйфатларын сынау өчен алынган, дигән идек. Ләкин бу — мәсьәләнең бер ягы гына әле. Югыйсә әсәрдә Зөләйха образы — үзенә мөстәкыйль, бөтен образ. Аның Көнбатыш Европа әдәбиятларындагы тарихи юлын алсак, Еврипидның үзеннән үк башлап, драматурглар бу образ ярдәмендә замандаш хатын-кызларының үзенчәлекле холык-фигыль, психологиясен, гомумән, кешелек хасиятләрен ачарга омтылганнар.

Кол Галидә шунысы бик мөһим: Зөләйханы ул һәртөрле шәригать, патриархаль гадәт-йола чылбырларыннан ычкындырып җибәреп тасвирлаган. Ул — матурлык һәм акыл иясе, хис кешесе. Тыелгысыз хисләренең ихтыярына бирелеп китеп, кирәкмәс хәтәр адымнар да ясап куя ул. Ләкин Зөләйха шунысы белән ягымлы — күңелендә яшерен зәһәре юк, ул — кинә тотучан түгел. Аның мәхәббәт хисе чын, кайнар, алыштыргысыз, гаепле адымнарын да ул шушы хис ихтыярына бирелеп китү аркасында ясый. Шуңа күрә укучы аны кичерә.

Матурлыкның үз диалектикасы бар. Йосыфта матурлыкны сөю тойгысы бик көчле. Хәтта ул матурлыкны иҗат иттерә — матур сарайлар төзетә. Әмма аның иң зур матурлыгы — кешеләрне яратуында, хәтәр хәлләрдә кешеләргә, халыкка ярдәмчел булуында. Ул, әлбәттә, Зөләйханы да ярата, ләкин серен ачмый. Аңарда, Зөләйхадан аермалы буларак, идеал ачыклыгы белән ихтыяр көче бергә килгән. Идеалы — ачлык кырып салачак халыкларны коткарып калу, гадел хөкем иясе булырга омтылу. Аның калган барлык теләк һәм ниятләре шул идеалга буйсындырылган. Ул — көчле акыл, намус иясе генә түгел, көчле ихтыяр иясе дә. Идеал һәм ихтыяр көче аның барлык сыйфатларын бер бөтенгә җыеп алган. Зөләйхада мөстәкыйль сайлап алган иҗтимагый идеал күренми. Ләкин ул зур идеалга ия булган геройның юлдашы булырга ашкына. Шушы хәл аның тормышын да мәгънәле итә, матур итә.

«Кыйссаи Йосыф» әсәрен шушы яклардан якын килеп өйрәнәсе бар әле.

**Нил Юзиев,**
филология фәннәре докторы

# «КЫЙССАЛАРДАН, ХИКМӘТЛӘРДӘН КҮРЕКЛӘРӘГЕ...»

Китапларның да язмышы була, ди халык мәкале. Бу хикмәтле сүзнең дөреслеген дөнья әдәбиятыннан күп мисаллар китереп расларга мөмкин булыр иде. Тарихның эченәрәк юл тоткан саен, борынгыга таба юнәлгән саен, әлеге мәкальнең эчтәлегенә туры килгән әсәрләр — язмышлы китаплар ешрак күзгә ташлана. Моның, әлбәттә, җитди сәбәпләре бар. Үткән заманнарда китапларның басма түгел, ә кулдан күчереп йөртелүләре аларның нөсхәләрен һәм таралу мәйданын бик нык чикләгән. Еш булып торган һәртөрле сугышлар, янгыннар кульязма китапларны аяусыз сынаулар астында калдырган. Аларның бик азы гына, үз башларыннан күп язмышлар кичереп, бүгенге көнгә килеп ирешә алган.

Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы — әнә шундый олы тарихлы, бәхетле язмышлы китапларның берсе дип саналырга хаклы. Урта гасырлар төрки әдәбиятының кыйммәтле әдәби җәүһәре буларак танылган, Болгар чоры татар язма әдәбиятының башлангычы — «елга башы» саналган бу әсәрнең язылуына быел 750 ел тулды. Соңгы җөмләне «яшәвенә 750 ел» дип тә тулыландырасы килә. Чөнки әлеге шигъри кыйсса язылуы белән генә түгел, ә халыкта танылуы, даими яшәве белән дә гыйбрәтле. Шушы уңайдан шагыйрь С. Хәкимнең дүрт юллык бер шигыре хәтергә төшә:

> **Шагыйрь белән халык йөрәген мин**
> **Охшатамын ике чакмага:**
> **Очрашсалар бергә — очкын оча,**
> **Җырга күчә, илдә саклана.**

Әлеге юллар «Кыйссаи Йосыф»ны күздә тотып язылмаса да, эчтәлеге белән аңа да туры килеп тора: «Кыйссаи Йосыф» та бит «җырга күчкән, илдә сакланган» әнә шундый мәшһүр әсәр. Ул чын мәгънәсендә шагыйрь йөрәге белән халык йөрәге бергә очрашкан халык китабы. «Кыйссаи Йосыф» кебек әсәрләр хикмәтле фикергә, ялкынлы хискә әверелеп, яшәүләрен һәм көрәшүләрен дәвам иткәннәр. Татар халкында гасырлар дәвамында шул кадәр популяр булып килгән, рухи дөньясына һәм әдәби традицияләренә тирән үтеп кергән, шигырь-җыр-дастаннарына, сурәтле чагыштыруларына күчкән башка бер китапны табуы, Йосыфның гыйбрәтле язмышын, әтисе һәм туганнары белән аерылу-кавышуларын, Зөләйханың дәртле мәхәббәтен белмәгән-ишетмәгән укучыны очратуы кыен.

«Кыйссаи Йосыф»ның төрле чорларда Идел-Урал төбәгендә күчерелгән кульязма нөсхәләре әлешчә Казан, Ленинград, Баку, Уфа, Берлин, Дрезден кебек шәһәрләрнең китапханәләрендә, архивларында сакланып калган. XVIII гасырның укымышлы галиме һәм шагыйре Утыз Имәнинең 1839 елны поэманың җыелма-тәнкыйди текстын бастырып чыгаруы әсәрнең гомере тагы да озынаюга, халыкта популярлыгы үсүгә,

текстның тотрыклы саклануына сәбәпче булган. Әмма, китап булып күп тапкырлар басылуына карамастан, аның кульъязма рәвешендә яшәве дә тукталмый, дәвам итә. Халык әлеге кульъязмаларны кадерләп саклый, күп укудан искереп тузса — яңа нөсхәләрен булдыра. Әсәрнең кульъязма рәвешендә яшәве XX гасыргача дәвам иткән — археографик экспедицияләр хәзер дә XIII гасыр шагыйре поэмасының яңадан-яңа нөсхәләрен таба торалар. Хәзер бу мәшһүр әсәрнең 150 дән артык нөсхәсе билгеле. Мәҗлесләрдә, кич утырыpга җыелган вакытларда поэманы уку-тыңлау көнкүрештә тирән тамыр җибәргән халыкчан бер йолага әверелгән. Гадел патша даулап яуга чыкканда да халык «тыңламага татлы» бу борынгы дастанны үзе белән алган. Пугачев хәрәкәтенә катнашучылардан конфискацияләп алынган кульъязмалар исемлегендә «Кыйссаи Йосыф» әсәренең теркәлүе дә моңа бер мисал була ала. Шунысы символик мәгънәгә ия: патша түрәләре архивына килеп эләккән бу кульъязма китап нинди юллар белән юкка чыккан. Бергә эләккән«Кисекбаш китабы» да, башкалары да урыннарында сакланган, ә менә «Кыйссаи Йосыф»ның исемлектәге исеме генә калган — үзеннән җилләр искән. Әйтерсең лә, халык гадел патша турындагы хыялын күңелендә саклаганы кебек, гадел һәм тугры хөкемдар Йосыф турындагы китабын да дошманнары кулына тапшырасы килмәгән, киләсе дауларга күтәрелү өчен үзе белән алган.

Кыйссаның халыкта әнә шундый үтә популяр булуын, бик тә кадерле саналуын әчтәлегенең дөнья әдәбиятындагы традицион сюжетка — Йосыф һәм Зөләйха вакыйгаларына корылуы, төп героеның изге кеше, пәйгамбәр булуы һәм аңа Коръәндә махсус сүрә багышлануы белән генә аңлатып булмый. Изгеләр турында язылган күп әсәрләр эзсез югалган бит, ә монысы сакланган! Пәйгамбәрләр һәм дин өчен көрәшкән баһадирлар турында күп китаплар иҗат ителгән, әмма берсе дә «Кыйссаи Йосыф» дәрәҗәсенә күтәрелә алмаган.

Дини-мифологик образларга һәм сюжетларга таяну урта гасырлардагы әдәбиятның, сәнгатьнең табигый бер сурәтле фикерләү рәвеше булган. Әдипләр, рәссамнар үз халыклары кабул иткән дини тәгълимат мохитендә, стихиясендә яшәгәннәр, иҗат иткәннәр. Кол Гали дә, үз чорының улы буларак, шул дәвердә үз дәүләтендә рәсми рәвештә кабул ителгән ислам дине кануннары белән яхшы таныш булган. Әсәрнең эчтәлегеннән хәтта шагыйрьнең дин белеме өлкәсендә шул чорның бик тә укымышлы әһелләреннән икәнлеге беленә. Гадел патша һәм гадел җәмгыять, кешеләрнең үзара әхлакый мөнәсәбәтләрендәге сафлык (ата — ул, туганнар, ир — хатын), яхшылык һәм явызлык көрәше кебек әдәбияттагы мәңгелек темаларны шагыйрь дини образлар белән бәйле кыйсса эченә төреп бирә.

Кол Гали әсәренең популярлыгы һәм яшәүчәнлеге исә аның урта гасырчылык феодаль идеологиясен, дин схоластикасын җиңә алган гуманистик эчтәлекле фикерләве белән, үз чоры өчен әһәмиятле булган җитди әхлакый-фәлсәфи, социаль-иҗтимагый мәсьәләләрне кыю күтәрүе һәм аларны югары сәнгать дәрәҗәсендә новаторларча чишә алуы белән бәйле.

Кол Галине халык легендаларында, тарихи язмаларда (Таҗетдин Ялчыголның «Тәварихе Болгария» әсәре һ. б.) Идел буендагы Болгар дәүләте җирлегенә бәйләп аңлаталар, Биләрдә үлгән дип күрсәтәләр. Шагыйрь мирасын Идел буе җирле культурасы белән бәйләнештә карау аның тарихи әһәмиятен аеруча күтәрә.

«Кыйссаи Йосыф» — дөнья әдәбиятындагы традицион сюжетка корылса да, күп яклары буенча новатор әсәр. Шагыйрьнең иң олы миссиясе, минемчә, моңа кадәр авыз иҗаты әсәрләре хәзинәсе белән яшәп килгән Идел буе татар халкының әдәби иҗатын яңа юлдан, яңа эстетик принциплар белән үстереп китүендә, язма әдәбиятның халык тарафыннан үзенеке дип кабул ителгән беренче әдәби әсәрен иҗат итүендә. Гомумән — беренче әдәби әсәр дип кистереп әйтү мөмкин түгел — Кол Галидән алдарак чорда да, ул яшәгән дәвердә дә әдәби язма әсәрләрнең язылуы, тууы бик тә ихтимал. Шул дәверләрдән сакланып калган тарихи чыганакларда Болгар дәүләтендә Ягкуб ибне Ногман, Әбел-гала Хәмид бине Идрис әл-Болгари, Бөрһанетдин Ибраһим ибне Йосыф әл-Болгари исемле мәшһүр галимнәрнең яшәве һәм аларның тарихи-фәнни китаплар язуы теркәлеп калган. Ул чордагы галимнәрнең универсаль булуларын, төрле өлкәдә иҗат итүләрен искә алсак, шушы ук галимнәрнең әдәби әсәр язуларын да фараз итәргә мөмкин. Әмма тарих аларны саклый алмаган, безгә

тик үзенеке итеп кабул иткәнен, иң талантлысын, «кыйссалардан, хикмәтләрдән күркәмрәген», хикмәт сөйләү куәте көчлерәген, «күкрәгендә кешеләргә карата ярдәм итү, шәфкатьлелек шәме» яктырак янганын гына китереп җиткергән.

«Кыйссаи Йосыф» татар халкының XIII гасырда Болгар дәүләте җирлегендә үзгә бер тарихи дәверен, интеллектуаль-рухи күтәрелешен сәнгать чаралары белән гомумиләштерде, ул халыкның яңа эстетик югарылыкка күтәрелүен бөтенләй яңа типтагы әсәр белән беркетеп калдырды. «Кыйсса»ның эчтәлегенә дөнья әдәбиятындагы мәгълүм сюжетны алуы белән Кол Гали сүз сәнгатенең яшәешен тар этник чикләреннән арындыра һәм дөнья әдәбиятының гомуми чылбырына тоташтыра. Бу тәҗрибәнең шул чор болгар-татар культурасы өчен яңа һәм кыю адым булуын билгеләп үтү белән бергә, шагыйрь алдына гаять катлаулы иҗат мәсьәләләре китереп куюын да искәртәсе килә. Чөнки чит сюжетка, чит геройларга нигезләнгән әсәрнең халык өчен дә чит, ят булып чыгу куркынычы шагыйрьне һәрчак сагалап тора. Андый сюжетны халыкка якынайту өчен Кол Гали үз халкының иҗатына — аның эпос, әкият, дастан, хикмәт үрнәкләренә таяна, халыкның үз сурәтле фикерләү мөмкинлекләрен (вакыйгаларны мавыктыргыч итеп оештыру, геройларны җаннары ачылырдай ситуацияләрдә күрсәтү һ. б.) эшкә җигә, халыкның образлы телен һәм шигъри үлчәм калыбын оста файдалана. Шушындый синтез — үз халкының әдәби хәзинәсен башка халыкларның рухи байлыгы белән даһиларча куша алу нәтиҗәсендә яңа эстетик югарылыктагы әсәр туа. Бу югарылык инде әсәрнең билгеле бер иҗатчысы ачыклана башлауда да күренә. «Кыйссаи Йосыф» — бу инде коллектив иҗат җимеше түгел, ә аерым шагыйрь иҗаты. Шушы үзгә хасият әсәрнең бөтен тукымасында, эчтәлегендә, телендә — тулаем сурәтле фикерләвендә ачык сизелеп тора.

«Кыйссаи Йосыф» әсәренең авторы турында хәзерге әдәбият фәнендә мәгълүматлар бик тә аз. Беркадәр мәгълүмат легендалар рәвешендә сакланып калган.

Иң ышанычлы һәм бәхәссез чыганак — шагыйрьнең үзе турында әсәрдә үзе әйтеп-беркетеп калдырган сүзләре:

**... Боны дөзән зәгыйфь бәндә — аты Гали...**
**... Рәхмәт кыйлгыл, рәхим кыйл Кол Галия...**

Бу юллардан шагыйрьнең исеме Гали яки Кол Гали булуы ачык. Күрәсең, халыкта, үз тирәлегендә аны «Гали» дип атаганнар, ә әдәби тәхәллүсен (кушаматын) шул чорның әдәби этикетына буйсынып үзе «Кол Гали» дип сайлагандыр. Фәнни кулланышта да хәзер аның шушы икенче исеме ныграк урнашты. Кол Гали үзен текстта «бән зәгыйфь», «мәхзүн» (кайгылы-моңлы), «мәзнип» (гөнаһлы) дип атый, үзенең «фәһме иксек кемсә» («акылы ким кеше») булмаганлыгын билгеләп үтә. Үзе турында турыдан-туры әйткәннәре нигездә шушылар белән чикләнә дә. Шул чор әдәбиятына нисбәтән караганда, шагыйрь турындагы мәгълүматларның бик тә саран булуы гаҗәп түгел. Бу — урта гасыр әдәбиятларына хас гомуми үзенчәлек белән бәйле. Мәгълүм булганча, ул дәверләрдә әдипләр үз шәхесләрен ачу белән мавыкмаганнар, үз тормышлары турында сөйләүне кирәк һәм тиеш дип санамаганнар. Әдәбиятның максатын алар тормыш-дөнья хәлләре турында хикмәт сөйләүдә, әхлак тәрбияләүне күздә тотып үгет-киңәш бирүдә күргәннәр. Кол Гали үзе дә максатын:

**Аңласаңыз һәзар төрле пәнде, хикмәт,**
**Бу зәгыйфь назым әчрә дөзде имди [1], —**

дип язып үткән, төп игътибарын әсәрендәге «меңәр төрле киңәш, хикмәт»ләрне ачуга, аңлатуга юнәлткән. Әсәрнең кереш өлешендә олуг иясенә (аллага) мөрәҗәгать иткәндә дә ул аңардан күңелен нурга күмүне, кодрәт белән үткен акыл бирүен, күңелендә фикер-акыл балкышын тудыруын сорый.

Әсәрнең хикмәтле сүз әйтү нигезендә корылуы — поэманың бер хасияте. Шул нигездә шагыйрь үзе дә хәким шагыйрь буларак ачыла. Әмма шунысы да бар: шагыйрь әсәренең төп кыйммәтен аның хикмәтле булуында күрсә дә, хикмәтлелек ха-

[1] Һәзар — мең. Пәнде — киңәш, үгет.

лык авыз иҗатындагыча гыйбрәтле сүз әйтү, фикер-сүз культы белән генә чикләнми. Шагыйрь бирелә хикмәтлелекне кешенең рухи дөньясын, хисен-дәртен, кичерешен ачу белән дә, мәхәббәт культы белән дә кушып җибәрә. Шушы берләшү исә әсәрнең эстетик тәэсир итү ягын гаять көчәйтә.

Кол Гали үзе турындагы белешмә бирүгә шул дәвернең башка шагыйрьләре кебек үк үтә саранлык күрсәтсә дә, талантлы әдип буларак үзенең индивидуальлеген ачудан читләшә алмаган. Әсәр эчендәге «мең төрле киңәш, хикмәтләр»не җентекләп уку барышында шагыйрьнең үзе әйткәнгә караганда да тулырак, бөтенрәк, мәһабәтрәк образы туа. Әйтик, ул үзен «акылы ким түгел» дип кенә бәяләсә, укучы аны шул чорның акыллы галим-укымышлысы, хикмәт иясе буларак күз алдына китерә. Шагыйрьнең үзен «зәгыйфь бәндә» дип атавы да әсәрдәге киңәш-үгет-хикмәтләр фонында яңа төсмерләр белән байый. Ул үзен алла каршында гына зәгыйфь һәм гөнаһлы дип саный икән, ә шул чорның иҗтимагый-социаль тормышында ул гаять көчле рухлы, батыр җанлы, куркусыз шагыйрь. Хөкемдарның гаделлеге һәм аның халык мәнфәгате белән бәйләнешен күрсәтүдә шагыйрьнең кыюлыгы аеруча күзгә ташлана.

Урта гасырлар колбиләүчелек җәмгыятенең кешелексез табигатен Кол Галинең реалистик чынлыгы белән күз алдына бастыруында да (коллар базары, Йосыфның әнисе үлгәч, Йагкубның имезүче хатын яллавы, ә бу хатынның үз улын тартып алып сатып җибәрүе һ. б. күренешләр) шагыйрьнең «зәгыйфьлеге» түгел, ә үткен күзлелеге, ни өчен күңеле моңлы-сагышлы булуы һәм үзен «мәхзүн» дип атавы ачыла. Башкалар гаме, гарип-гидайлар сагышы белән яшәгәнгә ул моңлы, дөньяда еш кына явызлык өстен чыкканга ул сагышлы. Шагыйрьнең йөрәге әнә шул кешеләр арасындагы явызлыкларны, җәмгыятьтәге гаделсезлекләрне күреп иңри, борчыла, яна.

Әсәрдән шагыйрьнең тагын башка сыйфатлары да: аның үз чорының эрудицияле, белемле-культуралы, киң карашлы әдибе булуы, дөньяга карашында шул чорның официаль идеологиясенә — ислам диненә таянуы ачыла. Кол Гали әсәренең сюжеты турында үзе үк: «Кыйссалардан, хикмәтләрдән күреклерәге, ... дыңламага датлырагы»,— дип яза, үзенең гарәп һәм фарсы телендәге чыганаклардан файдалануын билгеләп үтә.

Соңгы елларда Кол Галинең әлеге «кыйссалардан, хикмәтләрдән күреклерәге» дип гомуми рәвештә генә әйтеп узган фикерен конкрет тикшеренүләрдә ачкан житди хезмәтләр дөньяга килде. Без беренче чиратта Җ. Алмаз, Г. Таһирҗанов, Ф. Фасеев, Н. Хисамовларның кыйссаның сюжет чыганакларын ачыклауга һәм шагыйрьнең сәнгатьчә осталыгын, яңалыгын билгеләүгә багышланган нәтиҗәле эшчәнлекләрен күз алдында тотабыз. Шушы юнәлештәге фәнни тикшеренүләрнең шагыйрь дөньясын, әсәрнең идея-проблематикасын тагы да тирәнрәк ачарга ярдәм итүенә шик юк. Әсәрнең төрле аспектларын һәм катламнарын өйрәнүдә комплекслылыкка һәм системалылыкка йөз тотуның әһәмияте дә басым ясап үтәсе килә.

«Кыйссаи Йосыф» китабы гасырдан артык инде галимнәрнең тикшерү объекты булып килә. Аңа татар әдәбиятчылары гына түгел, төрки Көнчыгышны өйрәнүче белгечләр дә игътибар итәләр, төрле яклап өйрәнәләр. Фәнни хезмәтләр белән танышкач, алардагы төрле юнәлешләр, тенденцияләр дә ачыклана. Берәүләр, әйтик, әсәрнең гомум төрки ядкаре булуына төп игътибарларын юнәлтәләр, икенчеләр исә конкрет җирлек белән бәйләнүне алгы планга күчерәләр. Әсәрнең телен тикшерүче кайбер галимнәр аның төп әһәмиятен һәм кыйммәтен тел үзенчәлекләрендә күрәләр. Шул нигездә әсәрнең сәнгатьчә кыйммәте, сюжетның яңалыгы күләгәдәрәк кала. Үткәндәге хезмәтләрдә әсәрнең проблематикасы, сюжеты турында сүз барганда исә еш кына поэманың күп проблемалы, шуңа нисбәтән күп катламлы булуы искә алынмый килә. Сюжеттагы аерым катламнарның әһәмияте күпертелүе, икенчеләренеке кечерәйтелүе кайбер хезмәтләрдә хәзер дә очрап куя. Әдәбиятчыларның һәм философларның әсәр проблематикасын аңлатудагы аерымлыклары аеруча күзгә ташлана. Һәр ике өлкәдәге галимнәр дә әсәрнең идея проблематикасы катлаулы һәм каршылыклы булуын, дөньяви мәсьәләләрнең дини-әхлакый фикерләр һәм сурәтләр белән үрелеп баруын таныйлар. Әмма аерым очракларда акцентларны алыштырыбрак куюбелән дә очрашырга туры килә. Филолог галимнәрнең соңгы еллардагы «Кыйссаи Йосыф»ка багышланган хезмәтләрендә авторның дөньяви мәсьәләләрне алгы планга

чыгаруы, гуманистик идеяләрне калку итеп куюы ассызыклана. Кайбер философлар исә әсәрнең идея эчтәлеген башкачарак аңлаталар. З. Ишмөхәммәтов, мәсәлән, поэманың төп идеясен «алла белән рухи кушылу өчен, теге дөньядагы рәхәт тормыш өчен җирдәге шатлык-ләззәтләрдән, җир мәхәббәтеннән суфыйларча баш тарту»да күрә, поэманы да «мистик суфыйчылыкка хас мәхәббәт лирикасының үрнәге» итеп саный [1]. Әсәрнең төп идеясен шушы рәвешчә аңлату белән һич тә килешәсе килми: чөнки моңа әсәрнең бөтен тәзелеше, андагы образлар системасы, вакыйгалар хәрәкәте каршы килә. Х. Госман хаклы язганча, Зөләйха образында шагыйрь мистиканы түгел, ә «кешенең үзендәге барлык рухи көчләрен дөрләтеп, тулы тормыш белән яшәүгә омтылуын тасвирлый» [2].

Мистик суфыйчылык юнәлешенең рәсми дингә — ислам догмаларына каршы туган хәрәкәт икәнлеген белгән хәлдә, аны XIII гасыр башы әсәреннән эзләү соңрак дәверләрдә ачык рәвеш алган күренешне ясалма тесте Кол Галигә күчерү булып аңлашылмасмы? Мин XIII гасыр башында дини оппозиция туу мөмкинлеген шик астына алырга теләмим. Ул дәвердә дә андый агымнар булгандыр. Әсәрнең кереш өлешендә авторның ислам динендәге сөнниләр юнәлешен оештырган Сабит углы Ногманны (Әбу Хәнифәне) мактап телгә алуы шагыйрьнең шушы юнәлеш тарафдары икәнлеген раслый. Әмма төп сюжетта дини оппозиция ачык күзгә ташланып тормый. һәм ул әсәрнең төп рухын билгеләми. Бу әсәр, барыннан да элек, дини-мистик чалымнары белән түгел, ә эчтәлегенең дөньяви яңгырашка ия булуы белән, гуманистик фикерләренең тирәнлеге белән үзенчәлекле. «Кыйссаи Йосыф»та дини караш белән дөньяви карашның аерылып, каршылыкка керүе әһәмиятле. Бер яктан, шагыйрь, әлбәттә, ислам дине нормаларына таяна. Икенче яктан, ул «теге дөнья» җәннәте төзү уе белән түгел, ә җирдәге гаделсезлекләрне, кешеләр арасындагы һәртөрле явызлыкларны тезгенләү уе белән, бу дөньяны яхшырту, төзәтү хыялы белән, гадел җәмгыять, сугышларсыз яши торган тыныч тормыш булдыру өмете белән яши, җирдәге ялкынлы мәхәббәтне зурлый. Бу инде мистикага сыеша торган караш түгел. Шундый гуманистик рухы белән ул, әйтик, XIII—XIV гасыр әсәрләре дип саналган «Кисекбаш китабы», «Авык кыйссасы» кебек әсәрләрдән дә нык кына аерылып тора. Шушы яклары аны дини-мистик әдәбияттан аерып куя, яңа рухлы итеп күрсәтә, дөнья әдәбиятындагы Ренессанс исеме белән билгеле булган гомуми прогрессив агымга, аның төрки дөньясындагы дулкыннарына тоташтыра.

Урта гасырларда дөнья әдәбиятының һәм сәнгатенең тигез генә үсмичә, аеруча зур сәнгатьчә югарылыкка ирешкән аерым чорлары турында галимнәр күптән инде язып киләләр. Әдәбият-сәнгатьнең шундый яңару, чәчәк ату дәверен төрле илләрдә төрле термин белән атап йөртәләр. һиндларда ул — «бхакти», фарсыларда — «классик дәвер», төрекләрдә — «алтын гасыр», итальяннарда — «чинквеченто», французларда — «ренессанс», немецларда «реформация» дип атала һәм ул төрле чорларда (X—XV гасырлар) кузәтелә. Галимнәр бу күренешнең асылында гомуми, уртак тенденцияләр ята дип саныйлар һәм аны Ренессанс (Яңарыш) термины белән атыйлар. Көнчыгышта мондый рухи күтәрелеш Көнбатышка караганда иртәрәк туа. Әл-Фараби, Әл-Бируни, Ибне Сина, Омар Хәйям, Сәгъди, Фирдәуси, Җәми, Низами, Нәваи кебек атаклы шәхесләрнең исемнәрен санап үтү дә Шәрыкта әлеге гомуми күренешнең күп илләрдә киң яңгыраш табуы турында сөйли.

Ф. Энгельс дөнья культурасы тарихындагы Ренессанс этабын шәһәрләр үсешенең нәтиҗәсенә бәйләп аңлата. Мәсьәләгә шушы нигездә якын килү халыклар, илләр тормышында урта гасырда туган бөек үзгәрешләрне дөрес аңларга һәм аңлатырга ярдәм итә. Утрак тормышка күчү, шәһәрләр тууы, җәмгыятьтә хезмәт бүленешенең тагы да тирәнәюе — әдәбиятта һәм сәнгатьтә кискен үзгәрешләр тууына, рухи тормышның яңа сыйфатлар белән баюына, дини идеология белән бәйләнештә-каршылыкта дөньяви башлангычның һәм демократик-гуманистик агымның көчәюенә сәбәпче була. «Кыйссаи Йосыф» китабының да гомуми гуманистик яңгырашы һәм аның зарурилыгы шушы нигездә аңлаешлы булып ачылып китә. Болгар дәүләтендә шәһәр культурасының

---

[1] Ишмухаметов З. Социальная роль и эволюция ислама в Татарии. Казань, 1979, 87 б.
[2] Госман Х. Татар поэзиясе.— Китапта: Татар поэзиясе антологиясе. Казан, 1956, 5 б.

үсүе, сәүдә аша дөньядагы күп халыклар белән аралашуның ифрат та көчле булуы яңа, прогрессив фикерләүгә юл ачкан, культура өлкәсендәге бөек казанышлар белән танышырга һәм алардан файдаланырга мөмкинлек биргән. Әлеге нигездә Идел буендагы Болгарда да яңа культура — шәһәрчә фикерләүгә нигезләнгән культура формалаша башлый. Шушы гомуми дулкын Кол Гали шәхесен һәм талантын, аның дөньяга карашын чарлый, «Кыйссаи Йосыф» әсәрен дөньяга китерә. Әмма Болгарда яңа башланган шушы Ренессанс тибындагы үсеш-үзгәрешне монгол яуларының һөҗүме туктата, яңарыш процессын нык сүрелдерә.

Кол Галинең үзен дә легендаларда монгол яулары Биләрне алганда һәлак булган дип аңлаталар. Әмма бу дәһшәтле яуларда шәһәр янса да, шагыйрьнең гуманистик фикерләр белән тулы китабы янмаган, юкка чыкмаган. Шәһәр культурасы җирлегендәге демократик-гуманистик традицияләрне алга таба Мөхәмәдьяр, Хәрәзми, Котб, Сәйф Сараи кебек шагыйрьләр дәвам итеп киткән.

Кол Гали үзенең әлеге мәшһүр әсәрен шундый сүзләр белән тәмамлый:

**Бу арада бу китапны тәмам кылдым —**
**Нәфәганә вә някөм кыла имди.**

Соңгы юлның мәгънәсе: «Безгә һәм сезгә файдалы булсын». Автор, бәлки, «безгә һәм сезгә» дигәннән үз чоры укучыларын, аның төрле этник төркемнәрен күздә тоткандыр. Тарихның күп агымсуларын кичкән әсәрдә инде хәзер бу гыйбарә киңрәк мәгънәдә яңгырый: әйтерсең лә, шагыйрь «сезгә» дип киләчәк буын укучыларына да эндәшә. Ничәмә-ничә буын инде «Йосыф китабы»н (халыкта аны шулай дип атау бар) иң кадерле, хикмәтле китаплардан санап килә, үзенә шуннан рухи азык һәм эстетик ләззәтләнү таба, тормыш сорауларына җаваплар эзли. Шагыйрь йөрәге белән халык йөрәге тормышның, көнкүрешнең иҗтимагый-социаль яшәешнең җитди мәсьәләләренә җаваплар эзләгәндә тоташып киткәнгә дә «Кыйссаи Йосыф» озын гомерле һәм күп буыннарга файдалы булып, «тормыш китабы»на әверелеп яши. Мондый язмыш сирәк әдипләргә — олы талантларга гына эләгә. Кол Гали — исеме тарихта җуелмаслык булып уелып калган әнә шундый якты талант иясе.

Нурмөхәммәт Хисамов,
филология фәннәре кандидаты

# «КЫЙССАИ ЙОСЫФ» ПОЭМАСЫНЫҢ ИДЕЯ ПРОБЛЕМАТИКАСЫ ҺӘМ СӘНГАТЬЧӘ ЭШЛӘНЕШЕ

Төрки культура тарихында җуелмас эз калдырган Кол Гали поэмасы татар әдәбияты үсешендә аерым урын тота. Бүгенге көнгә аны югалтмыйимгәтми татар халкы китереп җиткергән. Әсәрнең йөз илледән артык кульъязмасы татарлар арасыннан табып алыну күп нәрсә сөйли. Иҗат ителгән чорында ук аның болгар укучысы кулында булуына җитди дәлилләр бар.

Әсәрдә җырланган идеяләр һәм мотивлар татар халкының катлаулы тарихи язмышына аваздаш яңгыраган, алгы планга куеп тасвирланган ата — угыл мәхәббәте һәм халыкчан рухта хәл ителгән егет — кыз тугрылыгы аңа һәрвакыт иҗтимагый-әхлакый өлге булып торган. Әсәрнең поэтикасындагы эпик башлангыч та халык рухияте ихтыяҗларын канәгатьләндергән. Шунлыктан «Кыйссаи Йосыф» поэмасы хакында татар халкының милли эпосы буларак кыю рәвештә сүз алып барырга мөмкин. Халык китапларына хас булганча, «Йосыф китабы» әле дә үзенең эстетик кыйммәтен саклый.

Әлегә кадәр төрки әдәбиятларда Йосыф—Зөләйха сюжетына язылган башка әсәрләр схемасын механик рәвештә Кол Гали поэмасына да күчереп, аның тематик нигезен егет — кыз мәхәббәте рәвешендә билгеләү хөкем сөрде. Хәлбуки Е. Э. Бертельс ук Фирдәүси поэмасы кебек җитди версияләрдә мәхәббәт сызыгы сюжетның ярдәмче элементы гына дигән фикерне әйткән иде. Соңрак ул Дурбәк поэмасына карата да шуны язды[1].

Кол Гали әсәренең исеме үк аның Йосыф хакында икәнлеген күрсәтеп тора. Сюжет нигезендә ата — угыл мәхәббәте, Йосыфның Йагкубка тугрылыгы ята. Герой язмышындагы иң зур фаҗига да аның атасыннан аерылуына бәйле.

Шагыйрь әсәрнең үзәгенә хөкемдар һәм халык бәхете проблемасын куя. Калган барлык мәсьәләләр иҗти[гма]гый, әхлакый, эстетик планда шушы үзәк тирәсенә туплана.

Проблема герой образы а[ша] хәл ителә. Хөкемдар шәхесе нинди булырга тиеш? Шагыйрь, шул сорауга җавап бирү өчен, каһарманны бала чагыннан алып төрле сынауларга куеп карый, шулар аша аның кешелек сыйфатларын ача.

Кол Гали әсәрендә Йосыфның хәлиткеч сыйфаты итеп т у г р ы л ы к тасвирлана. Сюжетның Көнбатыш версияләрендә герой даимән «Гүзәл Йосыф» дип аталса, «Кыйссаи Йосыф»та ул — «Йосыф Сыйддыйк», ягъни Тугры Йосыф.

Тугрылык дигәндә шагыйрь, барыннан да элек, атага тугрылыкны күздә тота. Бу мотив каһарманның төш юратуыннан башланып, атасы белән яңа күрешүенә чаклы үстерелә. Әсәрдәге төрле шартларда аның бу сыйфаты антка, бурычка тугрылык, акыр чик, туган халкына, аның гореф-гадәтенә тугрылык рәвешен ала.

---

[1] Бертельс Е. Э. Абу-л-Касим Фирдоуси и его творчество. Л.-М., 1935, 61 б. Узбекский поэт Дурбек и его поэма о Иосифе Прекрасном.— Альманах Дар. Ташкент, 1944, 171 б.

Йосыф язмышындагы иң кискен очрак — Зөләйха васвасәсенә бирешми калу да «Кыйссаи Йосыф»та атага тугрылыкны сынау төсен ала. Зөләйханың сүзләреннән эреп, елмаеп куйгач та, Йосыфны хата эшләрдән кисәтеп, күз алдына атасы Йагкуб килеп баса, һәм егет үзендә яңадан ныклык таба. Атасының истәлеге һәрвакыт аның вөҗданы сагында тора. Сюжетка төрки шагыйрь алып килгән шундый яңа нюанслар әсәргә үзенчәлекле яңгыраш бирә.

Тугрылык идеясе — «Кыйссаи Йосыф» поэмасының лейтмотивы. Бу әхлак сыйфаты кешенең бәхеткә ирешүе өчен төп шарт икәнне шагыйрь Зөләйха язмышы белән раслый. Әсәрнең героинясы, кырык ел тугрылык саклап, сабыр итүе нәтиҗәсендә Йосыфка тиң һәм лаек була.

«Кыйссаи Йосыф» — борынгы төрки поэзиянең беренче сюжетлы әсәре. Аның сәнгатьчә эшләнешендәге үзенчәлекләр шушы хакыйкатькә бәйле. Әле сюжетлы әсәр коруда төрки әдәбиятның мөстәкыйль казанышлары булмаганлыктан, шагыйрь фольклор тәҗрибәсенә таяна. Образларны эшләү, сюжет борылышларын кору, стилистик ялгамнарны тәэмин итүдә ул тылсымлы әкият һәм каһарманлык эпосы тәҗрибәсеннән файдалана. Аның сәнгатьчә фикерләве дә нигездә эпик поэтика кысаларында бара, эпик идеаллаштыру кануннарына буйсына.

Мәсәлән, Йосыфны уңай герой итеп күтәргән төп сыйфатлар — тугрылык һәм зирәклек. Ә инде матурлыгы — аның тумыштан бирелгән һәм дөньякүләм данын тотып торган үзенчәлеге. Мисырда аны кабат сату вакытында базар хәбәрчеләре ун сыйфатыннан берсе итеп батырлыгын да телгә алалар:

> Алтынчы: камулардан бик куәтләү —
> Кырык ирдән куәти артык имди.[1]

Вакыйгалар барышында Йосыфка көч-куәт күрсәтү бөтенләй кирәк тә булмый. Әмма шагыйрь төрки укучының каһарман дастаннар традициясендә тәрбияләнүен истән чыгармый: ә аларда геройның беренче сыйфаты — ул батырлык. Эпик идеаллаштыруның иң мөһим күрсәткечләреннән тылсымлы көчкә ия булу санала. Бу — каһарманның өстенлеген тәэмин итү өчен кирәк. Мәсәлән, Кодес (Иерусалим) бәге, Йосыфны алып калу өчен, кәрван артыннан үнике меңле гаскәр белән куа чыккач, каһарманның бер күз карашыннан өч көнлек йокыга тала.

Йагкуб образында да эпослардагы зирәк аксакал гәүдәләнә. Бу, барыннан да элек, аның фикер йөртүендә, сөйләмендә чагыла. Үгет бирәме ул, кисәтәме, үз-үзен тынычландырамы — һәр очракта аның сүзләре мәгънәле, гыйбрәтле.

Зирәк аксакалның үлемен тасвирлаганда, дәдә Коркыт турындагы эпик легендаларга һәм угыз-кыпчак дастаннарына хас мотивлар килеп керә. Йосыф сюжетына Кол Галидән элек иҗат ителгән әсәрләрдә Йагкубның тере көе үзенә кабер казучыларга юлыгуы тасвирланмый. Бары «Әнисел-мөридин»дә[2] генә аның мәетен бабалары күмелгән мәгарәгә алып килүләре һәм шартлы сүзләр белән эндәшкәч, мәгарә ишеге ачылып, табутны эчкә кертүләре языла.

«Кыйссаи Йосыф» та исә Йагкуб, туган җиренә кайтып барышлый, кабер казучы фәрештәләргә тап була. Кабернең эчен күрергә дип тереләй кереп китә һәм шунда җан бирә. Бу дәдә Коркытның, үлемнән качып йөргәндә, дөньяның дүрт тарафында да үзенә кабер казучыларга туры килүе хакындагы легендаларны хәтерләтә. Себер татарларыннан язып алынган «Ак Кубәк» дастаны да каһарманның атка атланган көе кабергә кереп китүе һәм шунда күмелүе белән тәмамлана. Ак Кубәкнең кабер казучылар белән сөйләшүе гаҗәп дәрәҗәдә Йагкубның фәрештәләр белән әңгәмәсенә охшаган.

Күп санлы шушындый детальләр Кол Гали поэмасына төрки колорит бирә һәм сюжетның төрки җирлектәге үзенчәлекле сәнгатьчә яшәешен тәэмин итә. Зөләйха,

---

[1] Камулардан — барысыннан да. Кыйссаи Йосыф. Казан университеты табгханәсе, 1839, 57 бит. Гарәп хәрефендә. Алга таба чыганакның бит саннары гына күрсәтелә.


[2] Әнисел-мөридин вә шәмсел-мәҗалис (иярченнәрнең дусты һәм мәҗлесләрнең кояшы) — фарсы телендәге прозаик әсәр. Көнчыгышны өйрәнүчеләр аны XI гасыр һират галиме Абдулла Әнсарига нисбәт итәләр.

мәсәлән, Йосыфның чәчен уникә толымга үрә. Йосыф сюжетының Кол Галигә кадәрге чыганакларында бу деталь бөтенләй юк, һәм ул булырга мөмкин дә түгел. Чөнки, затлы нәсел күрсәткече буларак, ирләрнең толым йөртүе — борынгы төркиләргә, соңрак башлыча кыпчакларга хас күренеш. Шунысы кызык: соңрак Рабгузиның «Кыйссасел-әнбия»сында Йосыф толымлы итеп сурәтләнә. Мәсьәләнең тагын шул ягы игътибарга лаек: Йосыф сюжетының турыдан-туры Кол Галигә таянып барлыкка килгән угыз вариантларының берсендә дә толымга бәйләнешле деталь юк. Бу өлкәдә Кол Гали кыпчак мохитына якынрак тора.

Зөләйха образының нигезендә дә эпик башлангыч ята. Кол Гали бу образга мөһим социаль-әхлакый вазифа йөкли, шунлыктан аның иҗат ихтыяры монда аеруча көчле сизелә.

Мәгълүм булганча, Тәүрат белән Коръәннән башлап, сюжетның барлык җитди чыганакларында Мисыр газизенең[1] хатыны (Асенат, Мутенемет, аңа «Зөләйха» исемен башлап Фирдәүси бирә) бары Йосыфка бәла-каза китерүче тискәре образ буларак гәүдәләнә. Аны уңай образ итеп иң әүвәл Фирдәүси эшли. Хәлбуки бөек фарсы шагыйрендә дә образ каршылыклы кала. Беренчедән, ул үзе, ир хатыны була торып, Йосыф каршында коточкыч әдәпсезлек күрсәтә. Икенчедән, Йосыфның, инде аңа өйләнгәндә, кәнизәктән ике баласы туган була. Фирдәүси поэмасында Зөләйха «кыйбты хатын» дип бирелә. Ягъни ул — Мисырда туып үскән кеше. «Әнисел-мөридин»дә китерелгән бер риваять буенча, Зөләйха — башка ил патшасының кызы. Йосыфка төштә күреп гашыйк булуы һәм сөеклесе артыннан бүтән патшалыкка китүе белән, дастаннар традициясендә тәрбияләнгән төрки шагыйрь куңеленә ул хуш килә. Көнчыгыш поэзиясе тарихында беренче буларак, Кол Гали сюжетның мәхәббәт сызыгын гыйшык дастаннары схемасына кора. Төштә күргән Йосыфы өчен Мисырга килгәч, Зөләйханың «әрсезлек» күрсәтүе һәм әхлакый, һәм психологик яктан аклана. Шул рәвешле, Кол Гали образны эчке каршылыктан тәмам азат итә.

Икенчедән, Зөләйха — Йосыфның бердәнбере. Шагыйрь бу фикерне ассызыклап әйтә. Әсәрнең каһарманнары мисалында мәхәббәт һәм гаилә мәсьәләсен хәл итеп,




*Поэма кулъязмасының бер нөсхәсе*

[1] Кол Галига кадәрге чыганакларда фиргавен вәзире. «Кыйссаи Йосыф»та «газиз» патша мәгънәсендә килә.

ул үз чоры Көнчыгышындагы күп хатынлылыкка каршы чыга, Йагкуб гаиләсе өстенә килгән бәла-казалар, кардәшләрнең ата мәхәббәтен бүлешә алмыйча ызгышулары — барысы да күп хатынлылык бәласе, дигән фикерне үткәрә. Поэзиядә Йосыф сюжетын эшкәртү тарихында Кол Гали бу яктан беренче юл яручы була.

Мондый тәвәккәл идеяләрне күтәреп чыгу өчен, нинди дер тарихи-иҗтимагый шартлар янсә, шуңа өстәп, эстетик факторлар этәргеч бирергә тиеш. Бу очракта этәргечнең берсе төрки фольклор булса, икенчесе — мөселман Көнчыгышы әдәбиятында гуманизмның чәчәк атуы. Шагыйрьгә бер яктан моногамияне яклаучы халык поэзиясе тәэсир итсә, икенче яктан Көнчыгыш әдәбиятын яңа баскычка күтәргән Низами иҗаты йогынты ясый. Шушы ике чыганакны искә алганда гына, «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә куелган мәсьәләләрнең хәл ителеш үзенчәлеген аңларга мөмкин. Кол Гали иҗатының гомуми әһәмияте төрки поэзияне Низаминың идея-эстетик казанышларын үзләштерүгә тәмам якынайтудан гыйбарәт. «Кыйссаи Йосыф»та Низами


بسم الله الرحمن الرحيم

*«Кыйссаи Йосыф» поэмасының Дрезден нөсхәсеннән бер үрнәк.*

әсәрләрендәге детальләрне дә аермачык күрсәтеп була. Мәсәлән, Зөләйха сараеның эче сандал агачыннан бизәлү Низаминың «Җиде гүзәл» поэмасындагы Бәһрам шаһның Рум патшасы кызына салдырган сараен искә төшерә.

Зөләйха сарае тулаем да автор фантазиясенең байлыгына дәлил. Сарай күренешләрен тасвирлаганда Кол Гали шактый мөстәкыйль эш иткән. Барыннан да элек, шагыйрьнең төрки укучы каршында үтә әдәп саклавы күзгә ташлана. Фирдәүсидә Зөләйха Йосыфны тәхеттә ялангач утырып каршылый, һәм Йосыф, күзен кая гына төбәсә дә, көзгеләрдә аның чагылышын күрә. «Әнисел-мөридин»дә дә (Кол Гали сюжетын нигездә шул чыганакка таянып эшли) эротик мотивлар ярылып ята. «Кыйссаи Йосыф» авторы Йосыф һәм Зөләйха сурәтләреннән тыш, үсемлек, кош-корт һәм хайван сурәтләренә киң урын бирә. Алтын агачларга кунган кошлар, ул агачлар янында иярле алтын ат, көмеш үгез сурәтләре борынгы төркиләрнең ышануларына һәм мәҗүсилек чоры сәнгатенә барып тоташа. Бизәлештәге үзәк мотивларга төрки дастаннардагы нәсел агачы тасвиры күчерелгәнлеген күрү читен түгел. Казан татарларының чигү сәнгатендә нәсел агачының ике ягына утыртып ясалган алтын янсә көмеш кош сурәт-

ләрен соңгы чорларга кадәр күзәтергә мөмкин... Кыскасы, һәр урында деталь һәм эпизодны эшкәрткәндә, әсәргә җирле колорит бирү өчен, шагыйрь эпик фольклорга мөрәҗәгать иткән.

Кол Гали әсәрендәге үзәк проблема да халыкчан хәл ителә. Хөкемдар һәм халык проблемасы башлангыч тестә сюжетның барлык эшкәртелмәләрендә куела. Әмма аңа халыкчан яңгыраш биргән беренче автор — Кол Гали. Аңа кадәрге чыганакларның берсендә дә Йосыф чын мәгънәсендәге хөкемдар түгел. Тәуратта һәм Коръәндә тәфсир һәм «Кыйссасел-әнбия»ларда Йосыф Мисыр патшасының вәзире дәрәҗәсенә ирешә. Фирдәүсидә аның күтәрелүе берничә баскыч үтә. Башта ул фиргавеннең якыны була, аннары, үзе үләр алдыннан, фиргавен тәхетне аңа васыять итә. «Әнисел-мөридин»дә Мисыр мәлиге үзенең төшен юраган Йосыфка тәхет һәм таҗ тәкъдим иткәч, каһарман патша булудан баш тарта.

Бары «Кыйссаи Йосыф»та гына каһарман, төшне юраугa ук, патша була. Шагыйрь биредә тылсымлы әкиятләр схемасына таяна.

Йосыфның идарәсен шагыйрь байга да, ярлыга да тигез караучы «идеаль» итеп тасвирлый. Бу — асылда Йосыф Баласагунидан башлап, татар әдәбиятында мәгърифәтчеләргәчә дәвам иткән прогрессив-демократик, әмма хыялый-утопик идея. Кол Гали аңа гаять үзенчәлекле төсмер бирә: ул, илдәге идарә гадел булсын өчен, хөкемдар түбәннән, халык эченнән күтәрелергә тиеш дип саный. Бу идея татар мәкалендәге «карадан чыккан хан яхшы» дигән фикергә аваздаш. Шагыйрьнең шушы мәсьәләгә аерым игътибар итүе аны өстәмә мисаллар белән ныгытуыннан күренә. (Мондый алым — Кол Галинең иң яраткан сәнгатьчә тасвир ысулы. Аны без шартлы рәвештә «кабат раслау» дип атыйбыз.)

Гадел идарә өчен хөкемдарның түбәннән күтәрелү зарурлыгын шагыйрь вәзир эпизоды белән кабат раслый. Йосыф тәхеткә утыргач, аның вәзире мәсьәләсе килеп баса. Каһарман сәйранга чыкканда, беренче очраган кешене үзенең вәзире итәргә була һәм шулай эшли дә. Ул үтә йолкыш, кыяфәтсез, фәкыйрь бер кешегә юлыгып, шуны вәзир итә. Вәзир исә Йосыфка лаек акыллы һәм гадел булып чыга. Бу эпизод башлап Кол Галидә очрый. Мәсьәләнең хәл ителешендәге әкиятчәлек беренче очраган кешене сайлап алуда чагыла. Мондый мотивны байның үзенә ялчы сайлавы, яки берәр гозерен үтәүдә ярдәмен өмтләнеп, беренче очраган кешене сыйга чакыру хакындагы бик күп татар әкиятләрендә күрергә мөмкин. Әсәрнең проблематик контекстында мондый детальләрнең эчке логикасы бар, шунлыктан алар сәнгатьчә хакыйкать буларак ышандыралар.

«Кыйссаи Йосыф» поэмасы үзенә кадәрге әдәбият үсеше нәтиҗәсендә барлыкка килеп, үзеннән соңгы төрки әдәбият үсешенә дә йогынты ясаган әсәр. Шунлыктан, аның эчтәлеге нинди чыганакларга таянуын һәм аның сәнгатьчә йөзен барлыкка китергән эстетик факторларны ачу әдәбият тарихында традицияләр формалашу һәм аларның үсешен күз алдына китерү нисбәтеннән дә әһәмиятле.

Гасырлар буе эшкәртелеп камиллаштерелгән сюжетка төрки авторның үзеннән яңалыклар өстәве нинди юллар белән барган соң?

Геройларны иҗат итү, сюжет төеннәрен иҗади оештыру, яңа эпизод һәм детальләр кертүнең аерым мисалларын инде өлешчә карап үттек һәм шагыйрьнең башлыча эпос һәм тылсымлы әкият традицияләренә таянуын күрдек. Сәнгатьчәлек мәсьәләләрен хәл итүдә фольклорның башка жанрлары да шагыйрь өчен мөһим чыганак булган.

Мәсәлән, ата белән угыл арасындагы хәбәрләшүнең үтә драматик моментларын шагыйрь үзенчә хәл итә. Менә күзгә иң бәрелеп торган Кәнган гарәбе эпизоды. Аның Мисырга килешли зиндандагы Йосыф белән сөйләшүе «Әнисел-мөридин»дә үк бар Йосыф сәүдәгәрдән туган җире һәм атасы турында сораша, кайткач, сәлам тапшыруын үтенә. Бу сөйләшү анда ачыктан-ачык, берникди тел яшерүсез эшләнә.

Кол Гали үзенең каһарманын гарәп сәүдәгәре каршында серле зат итеп калдыра. Шагыйрь социаль психологияне һәм момент үзенчәлеген нечкә тоемлап эш итә. Йосыф үз каршында тукталган узгынчыга сорауларын табышмакка төреп бирә:

> Йосыф әйдер: «Кәнгандән килүрмусән,
> Анда бер каба йегач белүрмусән,

Чүрәсендә[1] ботаклари белүрмусән,
Ул ботаклар ун икимү тәмам имди!»

Теге дә төшеп калганнардан түгел — табышмакны тиз аңлап ала:

Гарәб әйдер: «Аңладым бу сүзеңни,
Белдем, фәһем әйләдем бу разыңни,
Вә ләкин дыңлыйурмән бу сүзеңни,
Бу эш ичрә нә хикмәт вар»,— диүр имди.
Каба йегач дидекең Йагкуб дорыр,
Ун бер угли хезмәтендә хазир дорыр,
Ун икенчи Йосыф адлу гаиб[2] дорыр,

Хакыйкатьдә ани корд йиди[3] имди».

Бу аңлашудагы «каба йегач» метафорасы игътибарга лаек. Ул «биек агач» дигәнне аңлата. Нәсел агачы мотивы төрки эпосларда даими күренеш булып йөри. Кол Гали шушы традициягә таяна.

Табышмаклы аңлашу исә гомумән борынгы дәверләрдә яшерен телнең актив кулланылуын чагылдыра. Дастаннарда, әкиятләрдә, никахлашу һәм туй йолаларында яшерен тел, ягъни метафорик аңлашу, зур урын тоткан. «Патша, вәзир һәм тегермәнче» дигән татар әкияте тулысынча шуңа корылган.

Элгәреге чыганакларда сюжеттагы роле пассив булган персонажларны җанландыру өчен, шагыйрь гаять оригиналь алым куллана. Мәсәлән, Йосыфның бер анадан туган кардәше Ибнейәминнең рухи һәм әхлакый дөньясын ул балаларының исемнәрендә чагылдыра.

Мәгълүм ки, төрки халыкларда балага исем кушканда, ата-ананың изге теләкләре, бала язмышын алдан юрап кую янсә аны бәла-казадан саклау нияте чагылыш таба. Ибнейәмин балаларының исемлегендә дә шушы хәлне күрәбез. Бу деталь Кол Галигә кадәрге чыганаклардан беренче тапкыр «Әнисел-мөридин»дә очрый. Анда Йосыфның энесе җиде улы, өч кызы барлыгын, ә исемнәренең «Йосыф, Бүре һәм Кан» булуын әйтә. Чыганакта, шул рәвешчә, өч исем генә аерым атала.

«Әнисел-мөридин»дә Йосыф энесеннән мондый исемнәр куюның сәбәбен сорагач, тегесе: «Аларны чакырганда, сине искә төшерәм»,— дип җавап бирә. Төрки шагыйрь бу детальнең сәнгатьчә мөмкинлекләрен абайлап ала һәм, аны тулыландырып, персонажның бөтен бер әхлак кодексын ачыг бирә. Балаларның санын ул сюжет нигезендәге символик санга туры китереп, унике итә, «Әнисел-мөридин»дәге ике исемне генә ала: Корт (Бүре) һәм Кан. «Йосыф» исеме — аның өчен бердәнбер, һәм ул үзенең кабатланмас кыйммәтен сакларга тиеш. Персонажның олы улына ул «Диңгез» исемен куша. Бу, әлбәттә, «Угызнамә» традициясеннән килә: «Угыз — каганның алты улыннан берсе шулай аталган. Идел буенда угыз ыруларының таралган булуы һәм аларның шактые татар халкы составына да кергәнлеге тарихи, археологик, тел һәм топономик мәгълүматлардан билгеле.

Ибнейәмин балаларының исемлеген шагыйрь шулай тезә: Диңгез, Корт[4], Койу, Кан, Гар, Дар, Гүр, Арыслан, Моздур, Гариб, Кайгу, Кол. Чыганагы белән төрки булмаган сюжеттагы исемнәрнең төрки булуы кызык: шагыйрь әсәргә һәрьяклап җирле колорит бирергә, аны үз халкының тел, әдәбият, фольклор стихиясенә якынайтырга тырыша. Тулаем исә исемлек шактый ямансу әчтәлекле.

Шагыйрь исемнәрнең мәгънәсен ачуның үзенчәлекле композицион алымын эшләгән. Строфаның һәр юлы бер исемгә карый, нәүбәттәге строфа исә шуның эчке мотивын бәян итә. Мәсәлән, беренче дүрт исемгә бәйләп, Ибнейәмин болай ди:

Диңгезләр катында чук агладым,
Тагдагый кортлара чук ант вирдем.

[1] Чүрәсендә — тышында, тирәсендә.
[2] Гаиб — юкка чыккан.
[3] Корд йиди — бүре ашады.
[4] Дрезден нөсхәсе, 56 а. Корт — бүре. Гар — тау куышы. Дар — тарлавык. Моздур — ялчы. Гариб — юлчы, иленнән аерылган.

Канли күңләкени тутуб чук йалвардым,
Чук койулар ичена бакдим имди [1].

Шушындый шәрехләүче строфаларда персонажның рухи дөньясы үтә эмоциональ булып гәүдәләнә. Ул үзенең агасын гомер буе эзләгән, балаларына да Йосыф истәлеген яңартучы итеп кенә караган романтик шәхес булып күз алдына баса. Шагыйрь бу образда тылсымлы әкияттәгә агаларын эзләү юлында зур газаплар кичерүче кече энекәш мотивын гәүдәләндергән. («Ак бүре», «Унберенче Әхмәт» кебек татар әкиятләрен искә төшерегез).

Ибнейәминнең иҗтимагый-әхлакый дөньясы бигрәк тә соңгы өч исемне шәрехләүче строфада ачык чагыла.

Кол (лари) күричәк хуш дотар идим,
Гарибләри күричәк сурар идим,
Кайгулари күричәк аглар идим
Һәм коллара миһербан үлдум имди.

Шул рәвешчә, колларга мәрхәмәт күрсәтүдә шагыйрь персонажны Йосыфка тиң итеп тасвирлый. Монда да аның яраткан алымы — «кабат раслау» чагыла.

Эпик башлангыч поэманың стилендә дә өстенлек итә. «Кыйссаи Йосыф»ны шул сюжетка язылган барлык әсәрләр арасында аерып торган мөһим үзенчәлек — ул сөйләмнең диалогка корылуы. «Йагкуб әйдәр», «Йосыф әйдер», «Зөләйха әйдер» кебек композицион-стилистик ялгамнар, һичшиксез, төрки халыклар фольклорындагы әйтелешләргә һәм дастан поэтикасына барып тоташа.

Диалог шагыйрьгә сөйләмне мәгълүм дәрәҗәдә индивидуальләштерергә мөмкинлек биргән. Дөрес, урта гасыр әдәбиятында аңлы бер сәнгатьчә күренеш буларак индивидуальләштерү бөтенләй диярлек очрамый. Бу — чорның гомуми үзенчәлегеннән килеп чыга: сәнгатьнең, фикерләүнең һәр өлкәсендә гомумилеккә омтылу, күренешләрне шартлы символларда чагылдыру, индивидуаль сыйфатлардан бигрәк уртаклыкка, гомумилеккә игътибар итү урта гасыр эстетикасының йөзен билгели. Менә шушы шартлар эчендә Кол Гали персонажларны икегә — уңайга һәм тискәрегә аера. Геройларның уңай булуына беренче шарт итеп, ул зирәклекне куя. Табигый ки, андый персонажларның теле дә афористик. Афоризмнар башлыча Йосыф сөйләменә хас.

Үз-үзен тотышындагы акыллылык һәм афористик тел каһарманның рәнҗетүчеләре каршында өстенлеген, вакыйгалардан югары була белүен күрсәтә. Мәсәлән, үзен коллыкка саткан агалары турында ул сәүдәгәргә: «һәр кеши үз лайыкын эшләр имди»,— дип җавап бирә. Сәүдәгәрнең әле хатыны төзәтергә соң түгел дигәненә каршы: «Кәчән күз кирү кәлмәз»,— ди.

Тискәре персонажларның телендә гомум әһәмиятле мәгънәгә, гомумиләштерүче көчкә ия бер генә сүз дә юк. Менә алар ничек җиңел уйлыйлар (17 бит):

...Йосыфи атамыздан деләйәлүм,
Алуб илтүб бер дөрлү эш әйләйәлүм,
Йә үлдерәлүм, йә йыракга сата(лу)м имди.
Атамыз кашында без калалум,
Һәмишә сәүеклү без улалум...
Без мөхтәрәм, без мөкәррәм улалум имди.

Персонажлар сөйләмен оештырудагы нечкә төсмерләрдә шагыйрьнең осталарча эш итүе күренә.

Мәгълүм булганча, Йосыфның явыз агалары арасында бер Йаһуданең күңеле йомшара, һәм ул энесен яклап, туганнарына үгет бирә. Аның үгете чыганактан-чыганакка шулай үзгәреп килә. Мәсәлән, Коръәндә ул ике генә сүз әйтә: «Йосыфны үтермәгез!» Табари Тәфсирендә үтерүгә гомумкешелек әхлагы күзлегеннән бәя бирелә, гыйбарә күп сүзле нәсыйхәт рәвешен ала: «Йосыфны үтермәгез — чөнки кеше үтерү —

---

[1] Дрезден нөсхәсе, 56 бит.

ул олы гөнаһ»[1]. Фирдәүси поэмасында үгетнең гуманистик мәгънәсе таррак эгоистик төс ала: «Минем энемнең канын түгәргә ярыймы соң?!»


«Әнисел-мөридин»дә бу төсмерләр бергә туплана һәм бер-берсен тулыландырып килә. «Йосыфны үтермәгез — ул гаепсез! Гаепсезгә түгелгән кан җәзасыз калмас... Үз кардәшеңне үтерү ярый торган эш түгел!..» (46 бит).

Кол Гали гыйбарәне афористик рәвешкә кертә (13 бит):

**Карендәш карендәшне һич үлдермәз...**
**Оҗмах вәреб тамуг утыйн сатун алмаң!**

Үтерүне гаепләү идеясе монда гомумкешелеккә хас мәгънә алган.

Поэмадагы афористик юллар һәр очракта хис каршында акыл өстенлеген дәлилләп киләләр. Уңай геройлардан Зөләйха белән Ибнейәмин сөйләмендә генә мәкальләр очрамый, чөнки алар икесе дә — хис кешеләре. Шагыйрь кешелекле мәхәббәт һәм турылык хисен олылаңса да, акылны бар нәрсәдән өстен куя. Ул Йосыф образында акылны гәүдәләндерсә, Зөләйха образында хисне чагылдыра.




*«Кыссаи Йосыф»ны көйләп башкару үрнәкләре. Саимә Шәраповадан язып алынды. (1891 елда туган.) Апас районы Борнаш авылы.*




*Зәйнәпбану Мәхмутовадан язып алынды. (1918 елда туган.) Чүпрәле районы Мунчәли авылы.*

[1] Табариэ Кәбир тәрҗемәси. Җилд әүвәл. Чыйбарли таш, 1290 (һиҗри), 83 б.


Йосыф сюжеты дөнья әдәбиятында бер язмышның күп төрле катлаулы күренешләреннән, әле бәхет-рәхәт дөньясыннан газапка ташлану, әле яңа җәмгыятьнең игътибар үзәгенә калкып чыгуыннан торган үзенчәлекле сюжет хисаплана. Аның шушы хасиятен философ, хикмәт иясе буларак сизәмләгән сәнгатькәр шуңа тиң тасвир ысулын да сайлый белгән.

Кол Гали — Йосыф сюжетының үзенчәлеген үтә нечкә тойган авторлардан. Герой язмышындагы кискен күчешләрне билгеләгәндә, сюжет борылышындагы яңа этапны башлау һәм теркәү өчен, ул каршылыклары ягыннан чик төшенчәләрне куллана.

Кардәшләре коллыкка саткач, Йосыф үзенең халәтенә шулай ачына:

**Атам бәни икени үзә күтәрер иди,**
**Уйкум кәлсә, йастук үзә йаткырур иди,**
**Уйгансам, төрлүк тәгам йидерер иди,**
**Ул нигъмәтдән бу михнәтә дөшдим имди.**

Шушы контраст тасвир каһарман язмышының күп төрле борылышларына карата кулланыла.



*Поэма кульязмасының бер нөсхәсе*

Поэманың сәнгатьчә эчтәлегендә шагыйрьнең үз образы аерым игътибарга лаек. Аны әсәрнең лирик керешеннән һәм хәтимәсеннән (эпилогыннан) шәйләп була. Керештән укучылар каршында зур иҗат җаваплылыгы тоючы шагыйрьнең илһамлы образы килеп баса, хәтимәдә үзенең поэзия алдындагы олы бурычын башкарып чыгудан тирән канәгатьләнү кичерүче, мәгърур һәм тыйнак сәнгатькәр зат гәүдәләнә. Ул үз хезмәтенең мәгънәсе турында уйлана, аның әһәмиятен яңа бер күздән кичереп чыга һәм җуелмас кыйммәтенә иманын ныгыта. Бу өлешләрнең фәлсәфи стиле әсәр каһарманнарыннан Йагкубның зирәк һәм затлы фикерләү рәвешенә аваздаш булса, шагыйрьнең үз-үзенә ныклы ышанычы Йосыфның тәвәккәл характерын хәтерләтә. Әмма шулай да шагыйрьнең фикерләү стиле, тормыш, язмыш һәм әхлак турындагы хөкемнәре Йагкубка якынрак тора. Ул гомумән вакыйгаларга баласы язмышы өчен гадәттән тыш җаваплы ата педагогик һәм фәлсәфи мөнәсәбәте зур күзләгеннән бәя бирә. Аның мәсьәләгә тормыш тәҗрибәсе туплаган шактый олы яшьтәге кешене күз алдына китерә. Димәк, каһарманнарында шагыйрь үзе гуманистик идеалын чагылдырган, аларны үзенә охшатып иҗат иткән.

Шул рәвешле, Кол Гали үзенең эрудициясе һәм талант көче нәтиҗәсендә гаять җаваплы һәм читен иҗади бурычны хәл кылган: инде Шәрык дөньясында күптән өешып утырган сюжетка яңа тормыш көче биргән, оригинальлек дәрәҗәсе югары булган әсәр барлыкка китергән, халыкара сюжетны төрки колоритлы милли әдәби күренешкә әверелдергән.

# Фатих Хөсни

# БЕРӘҮ КИЛӘ, БЕРӘҮ КИТӘ...

КЕЧКЕНӘ ПОВЕСТЬ

*Татарстанның халык артисты Фоат Таһировка багышлыйм.*

## I



Сугышка мин башыннан ук барып кердем дип әйтә алмыйм, яшь җитмәү дә булгандыр, башка сәбәпләре дә юк түгел иде. Әнием сырхау, шуның өстенә матурлыгыннан, уен-көлкеле булуыннан башым әйләнеп, яшьлек тилелеге белән Зөһрә атлы кызга өйләнгән идем. Без Зөһрә белән бик аз һәм бик тату яшәдек. Ләкин шундук бу татулыкның бер күләгәле ягы да ачыла башлады. Зөһрәдә тумыштан килгән йөрәк авыруы булган икән, врачлар аңарга балага узу, узган сурәттә дә бала табу бик куен, хәтта фаҗига белән бетү ихтималын әйтеп куркыттылар. Шулай да, табигый, без икебез дә балабыз булуын бик тели идек. Шулай сузыла килеп, сугышның икенче елы да җитте, ул арада халык теләндә: «Быел икенче фронт ачылачак, ул ачылгач, фашистны ике яктан чытырдатып кысып, кабыргаларын сындырачаклар икән!» дигән хәбәр дә йөри башлады. Ул да түгел, мобилизацияләү яше килеп җитеп, бер көнне миңа да военкоматка чакырып повестка китерделәр. Сугыш, әлбәттә, уен түгел, моны Зөһрә дә, мин үзем дә белә идем. Иртәгә китәсе дигән төнне без бөтен икеләнүләрне, кисәтүләрне оныттык...

Мин сугышка Сталинград фронтына, аның азаккы көннәрендә генә килеп кушылдым. Сталинград фронты фельдмаршал Паулюсны тез чүктерү, аның армияләрен, гаскәри берләшмәләрен чолгап алу, әсир итү белән тәгәлләнгәч, безнең гаскәрләрне, шул җөмләдән безнең танкка каршы ата торган бүлекчәбезне дә көньяк фронтына күчерделәр. Бугазга бугаз килеп сугышулар монда да булгалап торды. Немец безнең игелекле көньяк туфрагыбызга дагалы итеген ничек тә тирәнгәрәк батырып калырга тырыша, ә безнекеләрнең бурыч шулай ук ачык: фашистның дагалы итеге баскан туфракта шундук гарасат кузгатырга, аңарга утырып ял итәргә дә ирек бирмәскә!

Сугыш турында күп язылды, әле дә языла тора, киләчәктә дә язылыр һәм сөйләнер, минем бурыч сугыш турында язу яки сөйләү түгел, минем бурыч — Зөһрәм, минем сөекемле һәм гомерлек ярым Зөһрәм турында язу. Аның үзсүзлелеге аркасында бичараның үзенә дә, безнең якыннарыбызга да, сугыштан аяксыз кайтып егылган мин — гарип солдатка да тау чаклы борчулар, бәхетсезлекләр яуды. Моны мин

Зөһрәмә рәнҗүдән әйтмим, моны мин Зөһрәнең тормыш яратуына, шул тормышта ничек тә үзенең эзен калдырырга үҗәтләрчә ябышып ятуына сокланудан әйтәм.

Сугыш турында язмыйм дисәм дә, шулай да кайда һәм ничек аяксыз калуымны, кыска гына итеп булса да, әйтми уза алмыйм. Табигать бирәүгә дә артык аяк бирмәгән, иң элек мина ярчыкларыннан тетелгән һәм соңыннан, шул тетелүнең финалы буларак, гангренадан череп баручы аякны сүзсез генә онытып китү гөнаһ булыр.

Көннәрдән бер көнне безне 547 нче артполк составында десантчылар итеп Керчь ярым атавына ташладылар. Немец соңгы форпостларыннан берсе итеп бу җирне бик ныгыткан икән. Дөнья мәхшәре кузгалды анда. Дингез һәм коры җир, сугыш әсбаплары һәм тәрәзә рамнары, төтен һәм миңгерәгән балыклар бергә буталып, һаваны тетрәтеп торды. Шул гарасатта миңа, курчак театры артистына, күпме кирәк соң. Сызгырышып очкан мина ярчыклары минем аякны да онытмаганнар.

Һәм китте, китте шуннан... Ничек киткәнен мин үзем белмим! Ни булганын Тбилиси госпиталендә, наркоздан айный төшеп, күземне ачкач кына белдем. Димәк, алай икән: аяклы артистлар күп иде бу дөньяда, хәзер менә аяксыз бер артист та өстәлде булып чыга.

Үлем белән яшәү арасында кысылып, әле дөньядан кичкәндәй онытылып, әле яшисе килүдән кабат кабынып, госпитальдән госпитальгә күчә-күчә кайтканчы байтак вакыт узган...

Култык таякларында өйгә кайтып төшкәндә өйдәгеләр мине ярым сискәнү, ярым шатлык белән каршыладылар. Ләкин каршылаучылар арасында минем Зөһрәм юк иде.

Аптыраулы авыр минутлар узганнан соң гына миңа Зөһрәнең бала тудыру йортында авыр хәлдә ятканлыгын аңлаттылар. Димәк, врачлар сүзен тыңламаган икән!

Сүзгә дә, үпкәгә дә урын калмады. Эшнең ничек торганлыгы баланы карыннан ярып алу һәм нәтиҗәдә аның авыр хәлдә калуы турында янындагы табибы әйткәч кенә аңлашылды. Дөресен әйткәндә, төшенергә соң иде инде. Кинәт Зөһрәнең хәлсез иреннәре хәрәкәткә килде:

— Миннән сиңа соңгы бүләк... бала кала. Какма, сукма, кешедән дә кактырма.

Җанымның миңа ишеттерә алган иң соңгы сүзе — боерыгы менә шул булды. Дөресен әйткәндә, сүзләр белән түгел, авыр, борчулы күз карашларыбыз белән сөйләштек.

Бугазыма авыр төен килеп тыгылганга әйтмичә сузып килгәнмен, хәзер дә менә шул төен аша әйтәм: Зөһрәм юк, ул булмагач, өйдә дә бушлык иде. Өстәвенә ипи карточка белән генә бирелә, хәер, бусы ил белән килгән бәла. Ягарга утын юк. Барыбызны да иң нык борчыганы — Зөһрәдән калган бала. Аны ничек исән-сау алып калырга да, ничек аякка бастырырга? Дөрес, медицина бу очракта безгә ярдәмгә килде, бераз исәймичә баланы бирeп җибәрергә ашыкмадылар.

Баланы алыр көн җитте. Киттек әни белән.

— Менә ул сезнең гүзәл кызыгыз, күрегез,— диде врач, баланың башын-күзен биләүсәләрдән чак кына бушата төшеп.

— Шушымыни инде Зөһрәмнең миңа бүләк итеп калдырганы?— Минем сүзләремне тегеләй дә, болай да аңларга мөмкин булгандыр, врач, баладан бигрәк минем белән кызыксынгандай, такт белән генә менә тагын мондый сүзләр дә өстәде:

— Нишләмәк кирәк, солдат, язмыштан узмыш юк, ди безнең халык.

— Миңа да шул сүзләрне кабатларга кала инде алайса,— минем күңелгә зәһәрле усал сүзләр дә килгән иде югыйсә. Тыелып калдым.

Нигә үтеңне гөнаһсыз кешеләр өстенә сытарга? Телемне ничек кирәк алай әйләндереп әйткәнем шул булды:

— Шулай да, иптәш врач, ничек үстерәбез инде бу кеше валчыгын? Нәрсә ашатып, дигән сүзем?

— Ул ягын без карарбыз. Без аның өчен, аның әтисе кебек үк, җаваплы. Баланы үзегезгә алгач, сөт кухнясыннан стерилизованный сөт алырсыз. Көн дә килеп алырсыз, ник дисәң, бер көнлеке икенче көнгә ярамый.

Үтә дә ачык итеп әйтте врач бу сүзләрне, монда шикләнергә яки икенче төрле уйларга урын калмады. Димәк, шулай: Зөһрәм миңа бүләк итеп чүпрәккә төрелгән шушы баланы һәм аны исән-сау үстерү өчен гаять зур һәм гаять катлаулы җаваплылык та калдырган. Күз сирпеп бер генә карадым һәм шундук таныдым: Зөһрә валчыгы ул, өлешчә минем дә валчыгым. Димәк, аны күтәрү, аны үстерү, аны кеше итеп аякка бастыру безнең изге бурыч!

## II

Шәһәрнең бер читеннән икенче читенә сөт ташулар китте. Әле әни, әле апа чаба, әле үзем титаклыйм. Баштарак бала бераз исәйгән кебек тә күренә башлаган иде. Ләкин бу озакка бармады, тиздән сабыебызның эче китә башлады, ашаганы йокмый, китә чүпрәк юуулар... Озак та үтмәстән, безнең карап торган күз нурыбыз уртак хафабызга әйләнде.

Әни үзенә өстәмә мәшәкать эзләп тапты: без чыгып торган арада, күрше карчыгын алып кереп, өшкертергә, төчкертергә тотына. Ай-һай ла, бу дөньяның чәбәләнеп беткән мәшәкатьләрен, борчуларын хәлсез карчыкның сулышы белән генә очырып җибәрергә мөмкин булса? Аптырагач, бер көнне безнең беребез белән дә киңәш итмичә, баланы күтәреп, үзе больницага киткән. Аны-моны уйлап тормаган, күңеленә җыелганны чыгарган да түккән.

— Сез биргән казна сөтен эчми, эчсә дә аш булып ятмый, ашаганы астында. Әтисе шул Гитлер төртенмешкә каршы сугышып аяксыз калган инвалид. Әнисен үзегез беләсез, сезнең кулдан китте. Инде шул фронтовик баласын, әнисез дә калган гөнаһсыз нарасыйның бөтенләйгә күзләрен йомганын кул кушырып көтеп торыйкмы. Юктыр андый закон, булмаска тиеш андый закон.

Бала күтәреп килгән олы яшьтәге хатынның гаҗизлек белән әйткән бу сүзләрен ишетми калмаганнар, әлбәттә. Әнинең күңелен табар өчен генә булса кирәк, укалы кәгазьгә төрелгән бер порошокны тоттырганнар да, көйләп-җайлап җибәргәннәр:

— Бар, әбекәй, кайта тор бүгенгә... Бик борчылса, әнә шул порошокны җылымса суда изеп, бал кашыгы белән генә авызына каптырыгыз. Без монда үзара киңәшләшеп, бәлки, берәр чарасын табарбыз, рас казна сөте ярамый дип барасыз икән.

Киңәшләре шул булган. Карап торган бер донорлары бар икән. Ниләр генә булмый бу дөньяда!.. Донор дигәннәре Мәдинә атлы яшь хатын булып чыкты. Сөтен калдырып китә икән иртәләрен. Соңга таба бу эш өчен аз-маз акча да эшләргә мөмкин икәнлекне белеп алгач (ул авыр елларда акча кемнең кесәсен тишсен), көнгә икешәр мәртәбә килеп йөри башлаган. Аның сөтен минем Хатирәгә җибәрәләр (без бу исемне аңарга әнисе хатирәсе итеп кушкан идек). Бар бит игелекле кешеләр. Фронтовик баласы, әнисез дә калган нарасый дип, карт әнинең тилмереп әйткәненә дә колак салганнар, күрәсең.

Могҗиза юк дип бара хәзерге халык, бигрәк тә күп китап күреп, башын акыл белән тутырган кешеләр әйтә. Ә менә мин әйтәм, мог-

жиза бар ул. Ник дисәң, мин үзем күрдем ул могҗизаны, үз күзем белән күрдем. И шул күрмәгән-белмәгән хатынның аерым савытка салып минем әнигә тоттырып җибәргән сөтен ашата башлауга, китте минем кызның эше ходка. Эч китүе туктады, бала чүпрәге юу кимеде, бала елаган тавыш шулай ук кимеде. Әни мескен, куанып бетә алмый. «Бар бит ходаның игелекле кешеләре!» дип, күрмәгән-белмәгән кешегә дога кылудан бушый алмый. Әйтми үтеп булмый торган тагын бер файда килеп чыкты — күршебездәге өшкерә-төшкерә торган карчыктан суынды. «Аның ул хәлсез сулышы белән бала өстенә төкерүеннән ни файда? Аптыраганнан гына чакырдым инде», ди. Үзем төсле әни дә юктан гына да очынып китүчән. Бала табу йортындагы, сөт кухнясындагы докторларга, барлык ак халатлы кешеләргә куанычын сөйләү белән генә туктап калмаган бу.

— Күрсәтегез миңа шул изге җанны. Минем нарасый ятимемә шифалы сөтен бирә торган изгелекле кешене,— дип, сагызланырга тотынган. Ниһаять, ирешкән дә булса кирәк ул үз дигәненә. Бер көнне кайтып, тиктомалдан миңа аны мактарга тотынды:

— Мәдинә атлы икән, бахыр. Болай карап торырга әллә нәрсәсе дә юк, ике аяклы, ике куллы кеше. Безнеңише җир бәндәсе. Ә йөзендә изге нур уйный. Карап торып әйтер сүземне онытттым, телем көрмәкләнде.

— Әти-әниең нинди кешеләр соң, бәбкәм. Авылданмы? Әллә шушы ук Казаныбызданмы,— дим. Аптырагач, әйтер сүземне әйтә алмагач, кесәмдә өч сум акчам бар иде, шуны чыгарып бирдем. «Сәдака булыр», мин әйтәм.

— Мин сәдакага калган кеше түгел, әбекәй, үземнең көчем, үземнең эшем бар,— дип оятлы итте.

Әнә шундый беркатлы кеше инде ул минем әни. Хатирәне дә бик ярата иде. Сөтне ничек тә суытмаска тырышып күкрәгенә кысып алып кайта. Апа белән икесе алмашлап бара-кайта йөрделәр дә, бер көнне бу минем үземне җибәрде. Шифалы күкрәк сөте белән баланы күзгә күренердәй тернәкләндергән адәм баласын үз күзләрең белән күрү сиңа да хәрам түгелдер, гомер-бакый болай дуадак кебек йөрмәссең, бар әле бер үзең. Кичә сөйләшеп кайттым, сөтен китерешли ул шунда, коридор башында көтәргә булды.

## III

Әнинең үз тегермәне ярган ярма инде, кая ул көтү, киресенчә, мин аны үзем көтеп алдым. Култык таякларымны бик алай күргәзмәгә тезеп куймыйча, әлбәттә. Яшермим, минем Хатирәмә күкрәк сөте белән алай тереклек биргән кешене, өстәвенә әни дә кайта-кайта мактый торгач, минем үземнең дә күрәсем килә иде. Шулай да, әйтер идем, без алай очынып күрешмәдек. Килеп, ишек катындагы үрмә чыбык диванда сәгать, сәгать ярымнар утыргач кына миңа аны няня күрсәтте.

— Менә шушыдыр ул, әгәр син әйтә торган кеше булса,— диде. Мин, барыннан да элек артымдагы култык таякларымны күрсәтмәскә тырышып, тизрәк торып бастым. Бу беренче хәрәкәтем ярыйсы гына тиз һәм килешле чыкты.

— Күреп торам, сез Фатыймәттәй җибәргән кеше,— диде каршымда басып торучы яшь, мөлаем тавышлы ханым. Аның сизелер-сизелмәс кенә аптырабрак калганлыгы беленә, шул халәтен яшерер өчен булса кирәк, ул кинәт ясалма кыюлык белән өстәде.— Фатыймәттәйнең өзелеп сөйли торган бердәнбер улы, күптән түгел генә кайткан фронтовик солдат сез булсагыз кирәк.

— Так точно! — дидем, солдатларча коры гына итеп. Беренче караштан ук үземнең йомшак ягымны сиздерәсем килми, бу яшь ханым белән әдәплерәк сөйләшергә дә дәртем кузгалып тора иде.

— Сезгә, инвалид кешегә, килеп йөрү авырдыр. Фатыйматтәй килә алмаса... авырып китеп килә алмаса дигән сүзем, бәлки... мин үзем дә вакыт табармын.— Ул өзек-төтек әйтте бу сүзләрне, күренеп тора: беренче очраган ир кеше алдында аның бик чишеләсе дә килми иде булса кирәк.

Сүзне озакка сузмас өчен ул үзе тотып килгән сумкага иелде, аннан кат-кат мамыкка уралган озынча шешә тартып чыгарды, шешәле сөт йомшак кына тавыш биреп куйды.

— Кайтканчы суына төшсә, Фатыйматтәйне өйрәтеп торасы юк, рәтен белә,— диде аннары.— Сүзне сузмыйк, сезнең тизрәк кайтып җитүегез хәерле. Сөткә артык суынырга бирмичә...

Монда бүтәнчә аңлатма бирүнең кирәге юк, «тизрәк юлыңда бул, иптәш фронтовик, минем бүтән әйтердәй сүзем юк!» дигән мәгънәне аңлата иде бу. Ә минем күңелдә, җәннәттән сөрелгән адәм баласында, бүтән сүзләр дә туып тора иде, каһәр. Култык таякларымны таба алмаган атлы селкенгәләп, ә чын дөресендә, аларны бу мөлаем, аз сүзле хатынга ничек тә күрсәтмәскәрәк тырышып мәтәшкән арада ул инде китеп барган иде.

Юл буе төрлесен уйлап кайттым, изүемә кыстырылган сөт шешәсе, әлбәттә, суынган булгандыр. Күңелем миңгерәткеч каршылыклар белән тулган иде. Беренчедән, яшерә алмыйм, тартынкырак узган берничә минутлык сөйләшү ул яшь ханым турында миндә җылы тәэсир калдырды. Икенчедән, шулай ук яшермичә әйтәм, күңелемне эчпошыргыч сорау тырный: нишләп әле ул ханым сөтен читләргә өләшә? Аның үз баласы кайда?

Кайттым да әнигә ташландым:

— Син мине бүтән андый эш белән йөртмә. Әнә Алма апа, әнә кечти апа бар, аларның аягын бик җәллисең икән, үзеңнең дә укчаң төшеп калмас, только минем бүтән барасым юк.

— Мәдинәнең үзен күрдеңме соң син?— дип, гаҗәпләнеп сүземне бүлдерде әни.— Юкса минем белән сөйләшкәндә бик тә ягымлы күренә иде ул бала. Әллә бүтән берәрсе туры килеп, каты бәрелдеме?

— Күрдем, үзен күрдем,— дидем мин әнигә.— Нигә кирәк миңа аны күрү? Бирәсе сөтләрен биреп җибәрсеннәр дә и шуның белән вәссәлам. Кешедән үзеңне җәлләтеп торганчы.

— Укаң коелган икән, бер дә харап!— дип, авызымны томаларга маташты әни үз чиратында.— Кеше белән сөйләшми яшәрсең инде, бар. Гомер буе дуадак каз булып яшәрсең. Култык таякларыңны кочаклап ятарсың ятканда. Шул Мәдинә дигән адәм фәрештәсе белән дә сөйләшер сүз тапмагач.

Бу соңгы сүзләре белән әни мине тагын да миңгерәйтте, сүзенең төбенә тора-тора гына төшенеп җиттем: әни, беркатлы карчык, мине чын-чынлап безгә сөтен бирүче сеңелкәш белән якынайтырга уйлый иде булса кирәк. Нәрсә әйтим: дивана дисәң — дивана түгел, акыллы дисәң, башка сыймаслыкны башына китерә.

## IV

Бер ара Мәдинәбезне бөтенләй югалттык. Югыйсә, сүз куешканча вакытында да барабыз. Я әни бара, я үзем. Сөт кухнясы тирәсендә көтеп, сорашкалап та карыйбыз, ләкин юк безнең сабыебызны ризыкландыручы игелекле Мәдинәбез.

Соңыннан билгеле булды: бөтенесе өчен минем күпне белергә теләүче әни гаепле икән. Бу урында бер мәсьәләне ачыклап китү кирәк. Сөт кухнясыннан кайту юлы бергә туры килеп, әни шул араны гел үз файдасына сузмакчы булган. Сүз иярә сүз чыгып, Мәдинәдән төпченергә тотынган. Янәсе, кайдан ул? Нинди кеше баласы? Әти-әниләре саулармы? Хәзергесе көндә Мәдинә кем белән тора? Бу соңгы сорау Мәдинәне берьюлы чыгырыннан чыгарган.

— Минем кем белән, ничек торуым сезгә кагылмый, Фатыймәттәй,— дигән ул, моңарчы һич сиздермәгән кызулык белән кабынып китеп.— Алай бик төпченүчән булсагыз, мин сөтемне кая куярга урын табармын. Үзең дә белеп тор, инвалид улыңа да әйт: минем хәлем белән артык кызыксынучыларны яратмыйм.

Шулай дигән дә, чатка җиткәнне дә көтмичә, җимерек коймалы бер ишегалдына борылып кереп тә киткән. Ничек кенә булмасын, безнең бәләкәй Хатирәбез яратып эчә торган сөттән аерылды, янадан гомуми кухня сөтенә калды. Мәдинә сөтеннән аерылу белән безнең сабыебыз күзгә күренеп чирли башлады. Кыскасы, эшне ничек тә төзәтергә кирәк иде.

— Эшнең бозылуы синнән, әни,— дидем мин.— Үзең бозгансың, үзең төзәт. Бар, Мәдинәне ничек тә үзең табып сөйләш. Хата миндә булган, бөтенесен дә үз өстемә алам, бары тик безнең гөнаһсыз ятимебезне игелекле сөтеңнән генә мәхрүм итмә, диген. Кирәк булса, аягына егыл. Хатирә хакына егыл.

Мәдинәне күрә алмыйча, шул тирәдә озак кына буталып йөргән әни. Шул арада сүзне ничек, кайдан башларга дип, мин өйрәтеп җибәргән «әлифба»сын да төшереп калдырган булса кирәк. Дипломатия мәктәпләре үтмәгән, коры телле, перәмедән туп-туры әни сүзне болай башлаган:

— Син, Мәдинәкәй җаным, ач итмә ятимебезне. Синең сөтеңнән аерылгач, тагы торыксыз калды оланыбыз.

Мәдинә бер сүз дә эндәшмичә карап торды, ди әни. Бичара беркатлы бәндә, әни турында әйтәм шулай дип, бу эндәшми торуны (тегесе беркадәр өметләндерә торган итеп, көлемсерәп тә торгандыр бәлкем) әни үз файдасына юрап булса кирәк, тагын да чишелебрәк киткән:

— Син, Мәдинәкәй җаным, бер караштан ук ошадың безгә. «Безгә» дигәнем — миңа дигән сүзем. Хәер, «безгә» дип Фәрдием исеменнән әйтсәм дә бер дә харам түгел. Гомергә болай култык таягына калмас, яшь тән төзәлер, аягына бер басар әле, алла боерган булса. Бер эзенә төшсә, акылсыз бала түгел минем Фәрдием. Әлегә, бу минем сүз, Фәрдием дә минем сүздән чыкмый.

Кыскасы, балага сөт кайгыртып киткән кеше, көтмәгәндә баланың әтисе, ягъни минем турыда кайгыртучы яучы карчыкка әйләнә язган.

Башсыз түгел Мәдинә дә. Кызмаган, кутәрелеп бәрелмәгән. Гадәтенчә, сүзсез көлемсерәп торуы белән бер мәл уздырган да әйткән аннары:

— Син, Фатыймәттәй, йомшарып килгәнсең бу юлы. Барыннан да бигрәк, минем үткәнем турында төпченмәвең миңа ошады. Минем үткәнем кызыклы түгел. Һәм мин аның белән кызыксынырга бераүгә дә рөхсәт итмим. Шулай килешсәк, Хатирәне сөтсез итмәбез, шат.

Башка сүз кирәкми дә әнигә. Артык сүз ычкындырмагаем дип, үзе дә шүрләгән булса кирәк, башы күккә тиярдәй шатланып, кайтып киткән шул сүзләрдән соң. Ләкин аннан соң да байтак көннәр үтте, безнең сабыебыз Мәдинә апасыннан имләшкән сөтен күрмәде.

— Кирәкле-кирәксез сүз әйтеп, син хәтерен калдырмадыңмы, әни? Син бит ни... турыданрак очасың вакыты белән.

— Шулай инде, без каткан телләр сөйләшә дә белмибездер. Кая ул безгә сез яшьләр артыннан куып житәргә,— дип, ризасызлык белдерә әни, ләкин — үз урынында зирәклеге житәрлек иде — сүзне артык үстермәде. Баланың борчылуын тыныч кына күзәгә алмыйча, үзем сөт кухнясына юл алдым. Сөт кухнясының регистратурасыннан, Мәдинәнең координатларын алып, эзләп киттем. Бер генә яклы Заря урамындагы сугышка хәтле салынган өйләрнең берсендә, аскы каттагы кечерәк бүлмәне биләп яшәп азапланган була икән. Өй җиһазларының бик алай шәптән булмавына карап, бу ялгыз ханымның тормыш итү дәрәҗәсен чамаларга мөмкин иде.

## V

Искәртмәстән генә килеп керүдән мин бер уңайсызлансам, үзенең бик гади ситсы күлмәктән, шәрә балтырларын ялтыратып, яланаяклап идән юып йөрүеннән Мәдинә үзенә бер аптырады. Без күпмедер вакыт сүзсез калдык. Шулай да Мәдинәне югалып калды димәс идем мин.

— Менә шулай инде мин, кичке сменага барасы көнне төшкә чаклы диярлек йокы симертәм,— дип сүз башлады ул, үзеннән-үзе мыскыл иткән тон белән.— Җылап утыра торган балам юк, сөйрәп торгызыр иде, инәй еракта — Башкириядә.

Сүзнең болай җиңелчә-шук тонда башлануы үзе генә дә минем кулаякны чишеп җибәрергә, яшь хуҗабикә белән иркенрәк сөйләшергә, сорашырга мөмкинлек бирде.

— Алайга китсә, белергә рөхсәт итегез, алдында утырган бу сабыйны кем дип белик? — Мин стенадагы бала рәсеменә ымладым.

— Ашыкмагыз, барысын да үз вакыты белән белерсез,— дип өзеп салды Мәдинә. Һәм эшен дәвам иткән хәлдә, түбәндәге белешмәләрне тезеп китте:

— ...Мин Казанга әллә ни байлык белән килеп төшмәдем. Алып килгәнем карынымда, аны үзем генә белә идем. Әти-әнисенең бәддогасына юлыккан, үз авылында туганнары күзенә чалынып йөрмәскә кушылган кыз баланың бүтән нинди байлыгы булсын. Рәхмәт, Казан мине рәхимле кабул итте. Эш эзли торгач, завод тулай торагына техничка булып урнаштым. Тырышлыгымны күреп, күңелләре йомшады булса кирәк, менә шушы кысан бүлмәне бирделәр. Кыскасы, минем артымда әллә ни мактанырдай эшләр юк.— Мәдинә кинәт житдиләнеп китте. Артык сүз куертуга юл куймастан, ул шундук мине иң нык кызыксындырган сүзне әйтте: — Әгәр сезнең ул сабыегызга минем сөтем бик ошый икән, сатулашып тормабыз, шулай ук сез инвалидны да тинтерәтеп йөртмәбез, сөтне мин көнгә ике мәртәбә сезгә үзем илтермен. Иртәнге сменага барасы көнне иртүк — смена алдыннан. Кичке смена көнендә сменадан кайтышлый. Әгәр шулай килешсәк, миңа адресыгызны калдырыгыз.

Мин куанып адресымны калдырдым. Чыгып барышлый, ишек тоткасына килеп тотынгач, Мәдинә үзе минем юлыма аркылы төште. Ул түбәнгә караган, бик моңлы һәм юаш күренде бу минутта.

— Ә сез, иптәш фронтовик, ник кызыксынасыз минем баштан үткән хәлләр белән?

Мәдинә тоташ табышмакка әйләнгән иде бу минутта. Ул кыска арада, ишек бусагасы төбендә генә нәрсә дә булса әйтергә дә өлгерә алмадым.

— Ул турыда как-нибудь башка вакытта,— дидем.

Нинди җавап булды бу? Мәдинә моны ничек кабул итте? Ул турыда уйлап тормадым. Зөһрәмнең вакытсыз үлеменнән соң, хатын-кыз белән сөйләшүне онытып бетерә язган идем инде.

## VI

Шушы очрашудан соң бер иртәне ул үзе безгә килеп керде.

— Болай таң тишегеннән йөрүем өчен гаепләмәгез,— диде ул, миннән түгел, әнидән гафу үтенгәндәй.— Сменага барышлый сугылдым.

Сөт белән тулы колбасын әнигә калдырып, минем якка таба әйләнеп тә карамыйча, китеп барды. Кайтышлый тагын кереп, савытын алып киткән.

Шул рәвешчә, рәттән берничә көн килә-китә йөрде бу. Кыска вакытка гына сугыла, һәр керүендә ашыга, сөйләшсә, әни белән генә берничә авыз сүз алыша, мин күзенә чалынсам да, баш кагып исәнләшүдән узмый. Балага сөтен китерүе өчен, әлбәттә, рәхмәт. Ләкин баш селкеп исәнләшүдән артык узмавы белән бераз хәтеремне калдыра иде. Дөресен әйтим, теге көнне, искәрмәстән мин барып кергәч, ситсы күлмәктән генә, яланаяк килеш идән юып йөргән җиреннән бераз аптырабрак калса да, үзен югалтмыйча, минем белән уйный-көлә сөйләшүе, бигрәк тә игътибарсызлыгым өчен миңа җиңелчә генә берничә сүз ташлавы хәтердә утырып калган иде. Җитмәсә тагын бер көнне сүз юктан әни дә кыстыра куйды:

— Ул ятим баланы әйтәм, үзенә рәтләп сүз катар кешесе юк, безнең сабыйны кайгырта, рәхмәт төшкере.

Бу да, әлбәттә, колак яныннан гына узмагандыр, ләкин эчемнән генә сизә йөрим: күңелем тартыла ул «рәхмәт төшкере»гә. Ләкин ничек, кайчан, кайсы яктан килеп сүз башларга? Әни алдында башлый торган сүз түгел, хәер, кыска вакытка килә-китә йөргән җиде ят кешегә күңелдә генә йөргән зур сүзне ничек башламак кирәк. «Тукта, аяклар бер мәл рәткә килсен, вакыты җитәр, тел ачылыр әле», дип, үземне юата киләм. Көлке бер яктан. Әйтерсең, аяк белән башлыйсы сүзне.

Шулай ничек сүз башларга форсат эзләп йөргән иртәләрнең берсендә, Мәдинә безгә ашыгыч кына кереп чыккан арада әни, дуамал кубып, миңа әйтә куймасынмы:

— Бар, Фәрдеттин, өйдән чыгып тор әле син бераз гына, хатын-кызның үзара нинди сүзе булмас.

Әнинең боерган тонда мине өйдән кууыннан миңгерәп калгандай булдым. Бактың исә, бөтенесе Мәдинә сеңелкәш кушуы буенча эшләнгән икән. Юкка гына килә-китә йөрмәгән ул. Мине өйдән куып чыгарганнар да болар, Мәдинә Хатирә сабыйга турыдан-туры күкрәген каптырып, суыртып карарга булган.

Һәм китте... китте шуннан... Балабыз күзгә күренеп тернәкләнә башлады. Әни дә Мәдинәне гел мактап торгач (үземнең күңел купшыганны әйтәсе дә юк), кибеттән бер пар каюлы башмак алып, тәвәккәлләп Мәдинәгә киттем. Кереп, бүлмәсенең бусагасын атлау белән бөтенесен оныттым. Ник дисәң, бик матур киенеп куйган бу. Чәч толымнарын үреп җилкәсенә салган, үзе яланбаш, бераз сөрмә дә тарткандай күренә, кыскасы, безнең Рамазан күрше әйтмешли, сусыз кашык белән суырып йотарлык.

— Сине таякларыңны ташлавың белән котларга кирәк иң элек,— дип, сүз башлады Мәдинә. — Алып килгән бүләгең өчен дә рәхмәт.

Күреп торам, кухня тирәсендә бөтерелеп, ни дә булса әзерләргә маташа.

— Карагыз әле, Мәдинә, мәшәкатьләнмәгез, мин ашап килдем.

— Ач килгәнсез дип әйтергә җыенмыйм. — Ул кухня яктан җавап кайтарды. — Бүләк алып килгән кешене бер стакан чәй дә эчерми җибәрү бер дә килешмәс.

Бу очракта миңа да җавапсыз калу килешмәгән булыр иде.

— Бүләк дип көлмәгез инде, — дидем мин. — Минем эш әнинең поручениесен үтәү. Сиңа дип ул алып кайткан, мин алып кына килдем Дөресен әйткәндә...

Мин дөресен әйтергә өлгерми калдым, Мәдинә кухня яктан поднос-ка куеп, бер стакаан куе чәй, омлет һәм юка гына киселгән икмәк китереп куйды.

— Менә хәзер әйтәбез дөресен,— дип, бүленеп калган сүзгә ишарәләде ул, каршыма килеп утырды.

## VII

...— Мин Башкортстандагы татар авылларының берсендә туып үскәнмен,— дип башлады Мәдинә, артык сузмыйча. — Кече яшьтән башкорт, татар җырлары колагыма керә торды, мәгәр үзем кеше алдында авыз күтәреп җырлаганымны хәтерләмим. Көйне бозармын, адәм көлкесенә калырмын дип шүрли идем. Аның саен башкорт, татар көйләре, моң минем күңелгә ныграк сеңә бара иде. Кече яшьтән җыя килгән бар байлыгым әнә шул. Бераз үсә төшкәч, моңа Фәрит дигән күрше малае өстәлде. Әйтмәс идем матур малай дип. Кара тутлы ябык кына бер малай шунда. Кечерәк чагында бит очында аз гына сипкеле дә бар иде шикелле, ә мин диванага барыннан да элек әнә шул сипкеле ошый иде. Ни хикмәттер, тора-бара миңа ошый торган ул сипкелләре юкка чыкты. Әле дә исемдә, мин аңарга «сипкелләреңне кая куйдың?» дип, бәйләнергә тотындым. Ул авызын ерып көлә, «сиңа күрсәтәсем килмәде, саттым мин аларны» дип, шаярта иде. Тагы шуны да әйтергә кирәк, без Фәрит белән бер мәктәптә — үз авылыбызның җидееллык мәктәбендә укый идек. Бер-беребездән көлә-көлә, бер-беребезне мыскыл итешә-итешә, бер-беребезне гел тутыра, үстерә килгәнбез. Җитте бер заман, без, үзебез дә сизмәстән, бер-беребезне яратыша ук башлаганбыз. Фәрит өйдәгеләрен шыр елатып, үз теләге белән Ватан сугышына китешли:

— Син мине көт, Мәдинә... Көтәрсең бит, Мәдинә? — диде, күзләрен мөлдерәтеп, миңа туп-туры карап торды.

Мин нәрсә дип әйтергә дә белмичә аптырап калдым. Минем дә күзләремдә мөлдерәмә яшь иде. Ахрысы, мәхәббәт дигәннәре шул булгандыр. Аннан соң Фәрит үзенә табарак тартып китерде дә бит очымнан үбеп алды. Шул булды беренче үбешүебез.

Соңгысы да шул, дип әйтер идем, соңгысы бераз тегеләйрәк килеп чыкты. Кыскасы шул: китте хатлар язышу, китте әдәби китаплардан йогып калган матур сүзләр, шигырь юллары... Миннән китә яшь аралаш язылган озын-озын хатлар, Фәриттән килә кыска-кыска «өчпочмаклар»... Аның шул кыска «өчпочмаклары»ннан куанычым куенума сыймый, «Фронт бит ул, кайда анда чәчәкләп-чуклап торыр вакыт... Шул «өчпочмаклары» өчен дә зур рәхмәт, ходай хәвеф-хәтәрдән сакласын» дим, үземне тынычландырырга тырышам. Ә сагышым, ә сагышым, татар көйләрендәге моң кебек аның саен эчкәрәк сеңә бара, эчкә сеңә бара иде.

Шулай узды көннәр, шулай узды айлар. Җанашымның китүенә ике ел да нәкъ унбиш көн узды дигәндә... Сез көлмәгез, мин ул көннәрне, ул айларны хәтеремә уеп санап бардым... Фәритемнән хат бөтенләй килмәс булды. И, шул чактагы януым-көюем, бер ходай белә дә, үзем беләм. Артык алгысынучан шул мин, кем белә, бәлки, артык нык яратудан да булгандыр, кешегә чәчеп йөри торган сүз түгел.

Шулай да бөтенләй канатларны салындырырлык нигез булмаган икән. Фәритем каты яраланган булган, госпитальгә салганнар, анда байтак яткан, ә мин, дуамал җан, әллә ниләргә юрап бетердем. — Игъ-

тибар белән миңа карап алды да: — Бик суздым түгелме? Ялыксагыз, әйтегез, туктармын,— диде ул.

— Сөйләгез, сөйлә. Хәзергә бик әздән барасыз.

Мәдинә болай үзе бик җитди булса да, вакыты-вакыты белән юктан гына да юмор кыстырып куя. Бу урында да минем «әздән барасыз» дигән сүзләремнән кыек мәгънә чыгарды булса кирәк, авыз чите белән генә көлемсерәп әйтә куйды:

— Шулай «әздән» бара-бара булды инде барысы да.

— Бәлки соңыннан стенадагы бала рәсеменә күчәрбез. Бу урында мин сезнең аеруча туры сүзле булуыгызны көтәм. Шул авылдашыгыз Фәрит белән уртак җимешегездер әле?

— Әйе, госпитальдән соң ул ялга кайткан иде,— диде Мәдинә һәм кызарынып аска карады.

— Ә сезнең ул балагыз кайда?

— Менә шул инде иң авырткан урыным. Фәритнең фронтта геройларча һәлак булуы турында хәбәр килеп төшкәч, баланы мин, аның язмышы белән артык кызыксынмаска кулдан язу биреп, больницада калдырдым. Яшьлек тилелеге дә булгандыр, әти-әниләрнең каргыштиргәш астында өйдән куып чыгарулары да өнсез калдыргандыр, кыскасы, бер дә гафу итәрлек хәл түгел, мәрхәмәтсезлек, күңел катканлыктан килеп чыккан эш. Соңыннан мин моны төзәтергә тырышып йөреп карасам да, бернәрсә дә чыкмады. Миңа үзем калдырган язуны гына күрсәттеләр. Булганы шулай. Калганын боргаламыйча гына сез әйтегез: минем бүтән нинди чарам бар?

Инде миңа аңлатып булмаслык батыр уй килде:

— Әгәр, әйтик, чараны икәү бергә эзләп карасак? — дидем мин тәвәккәлләп. — «Чара» дигәнем, бала дигәнем. Синең баланны...

Бу, әлбәттә, кинәт кабынып, артык чамасыз әйтелгән кыюлык булгандыр, әмма мин тәвәккәлләргә булган идем инде.

## VIII

Әнинең безне Мәдинә белән кушарга теләп алып барган өндәү-димләү эшләре дә, әлбәттә, эзсез калмагандыр. Бигрәк тә минем Мәдинәгә аның югалган баласын эзләшергә чын ихластан сүз бирүләрем бичара хатынның күңелен йомшартты булса кирәк; барыннан да элек безнең үз арабызда бер-беребезгә тартылу хисе көчәйгәннән-көчәя барды.

Белмим, мин мәхәббәт турында күп укыган кеше түгел, шулай да бөтенләй үк шыр ялангач та булмаганмындыр, шигырь китаплары укырга ярата идем. Ләкин бер китапта да мәхәббәт ялкыны ничек дөрләп киткәнен укыганым юк иде. Ә менә бу очракта башланды. Уртак бер фикергә килгәннән соң, артык сузмыйча, без кушылырга булдык. «Кушылырга» дигәнем — Мәдинәне туп-туры үзебезгә алып килергә.

Туй кыңгыраулары уйнатып тора торган вакыт түгел. Шулай итеп, әнинең фатихасын алып (ул бу фатихага әллә кайчан әзер иде инде!) һәм кичтән Мәдинәне әзер торырга кисәтеп куеп, иртәләрнең берсендә такси алып Мәдинәгә киттек. Мәдинә әзер, хәер, аның артык җыйнарлык әйберләре дә юк иде.

— Менә килеп тә җиттек, Мәдинә,— дидем мин капылт кына. — Минем Хатирәм анда әни таптыра бит, әй.

Без кайтып җиткәнче киенешеп-ясанышып апалар да килгән, кешеләккә кия торган күлмәге өстеннән ак алъяпкыч япкан әни кухня белән түр як арасында тыз-быз чаба, өй тәмле ис белән тулган. Тик бу ыгы-зыгының төп сәбәпчесе Хатирә генә бер читтәрәк тынып калган. Безнең шук Хатирәбез бу минутларда танылмаслык басынкы иде. Ләкин

аның бу халәте озакка бармады, Мәдинәнең сөенечле тавыш белән «Кайда соң минем Хатирә кызым, нишләп мин аны күрмим!» — дип чыңлап бер тавыш бирүе җитә калды кызга.

— Инде мин сине җибәрмим, инде син бездә каласың, китә башласаң, минем дә тәпием бар, артыңнан чабам,— дип, сакау лыкылдап барыбызны да шаккатырды.

Менә шулай узды безнең өйгә яшь килен төшерү.

## IX

Шулай итеп безнең Хатирәбез әниле, әниебез киленле, мин үзем кәләшле булдым. Өебезгә яңа ямь өстәлде, без бәхетле идек. Ләкин бу тыштан караганда гына шулай күренә иде булса кирәк. Мин моны Мәдинәнең үзен тотышыннан да, әни өйдә юк чакта сиздерергә тырышып әйткән кинаяле сүзләреннән дә сизенеп йөри идем. Килде бер очрак, уйламаганда килде дә мине берьюлы тотрыксыз калдырды. Мәдинә безгә теге алдында утырып төшкән ир бала рәсемен дә кыстыра килгән һәм, күзгә бик ташланмастай итеп, шкаф артына куйган.

— Бу бәләкәй кунак нишләп шкаф артына кысылган? — дип куйдым мин, аны-моны уйламастан. — Давай без аны нәкъ синдәгечә итеп стенага урнаштырыйк.

— Оныттың дамыни, Фәрди? — Ул күзләрен авыр гына күтәреп сынаулы бер караш ташлады. — Син бит миңа үз баламны, югалган баламны табышырга вәгъдә иткән идең.

Сүзгә урын калмады, Мәдинәнең миңа ташлаган үпкә сүзләре артык җитди, минем хәтердән чыгарган вәгъдәм шулай ук җитди иде. Ул кинаяне искә төшерүе белән генә узмады, төннәрнең берсендә, йокының иң тәмле вакытында уянып, Мәдинәмнең кешегә ишеттермәскә тырышып кына елап-сыктап ятуыннан сискәнеп киттем.

— Ни булды? Яман төш күрдеңме әллә? — дип, иркәмне кочып алдым.

— Төшем түгел, өнем куркытты. Балам искә төште.

Чынлап торып кузгалырга вакыт җитте; иртәгесен үк без, Мәдинә белән аның администрациясенә барып, мәсьәләне кабыргасы белән куйдык.

— Без югалган баланы эзләргә чыгабыз, моның өчен Мәдинәне ике-өч көнгә эшеннән бушатып тору кирәк.

Үтенечне Мәдинә үзе курка-ояла гына әйткән булса, бәлки колак яныннан гына да уздырган булырлар иде. Миндә чын солдат каны кузгалган иде инде, сүзем кискен чыкты, безгә каршы килә алмадылар. Мажаралы бу сәяхәтне без туп-туры роддомнан башладык. Мәдинәнең администрациясе белән сөйләшкәндә сүзне кискен башлау нәтиҗә биргәч, мин бу урында да шуны кулланып карадым. Хәтта тәвәккәллеккә барып: «Бала минеке, мин фронтта каты яраланып, госпитальдән озак вакыт хәбәр алмаганлыктан, Мәдинә чарасыздан баланы калдырырга мәҗбүр булган»,— дип очынып алдым. Ләкин бу урында очынуым нәтиҗә бирмәде. Мәдинә калдырган язу минем очынуларга караганда көчлерәк булып чыкты. Безгә баланың кайда икәнлеген әйтмәделәр. Шулай да, сорашкалый торгач, әлбәттә, чама белән эзенә төшә башладык. Кулыбызга берничә адрес килеп керде. Беренчесе кайдадыр шәһәр читендәрәк тар гына тыкрыкта яңы белән салынган ике катлы өйнең беренче каты булып чыкты. Хуҗасызлык өйгә керү юлыннан, баскычлардан ук күренеп тора иде монда.

— Сез дә шул Габделәхәт үксезне эзләп килүчеләрмени? — дип, кулын билендәге алъяпкычына сөртә-сөртә безне урта яшьләрендәге

бер хатын каршы алды. — Ярыйсы гына исәеп киләдер иде улыбыз, бәхетсезлеккә каршы, юк кына чирдән әтиебез үлеп китте. Ялгыз башыма ятим бала үстерү авырга киләчәкне кайгыртып, картымның туганнан-туган кардәше Зарифҗан кучер ярдәмгә килде. Көтеп-көтеп тә, Зәйнәп җиңгәгездән булмады, үстерерлек хәлебез бар, бирегез ятимегезне безгә. Ким-хур итмәбез,— дип зинһарлап сорагач, озак уйлап тормадым, тәвәккәлләп бирдем дә җибәрдем. Аларның адресы... карагыз әле, бөтенләй таркалып калдым бит. Өйгә кереп утырыгыз әле.

Ханым чак кына бөтерелгәләп алды, аптырабрак сузды:

— Күл башымы, су башымы, бар бит әле шундый бер урам...

— Бар, апа, бар ул адрес безнең кулыбызда.

Шул адрес буенча без китәргә ашыктык. Ләкин «Күл башы» безнә ачык чырай белән каршыламады.

— Бар бездә андый малай, ике елдан бирле бар,— дип, тәксе генә эндәште ир урталарындагы кеше. — Тыңлыйк, ни йомышыгыз төште ул малайга?

Беренче сүзләреннән үк эшнең җиңел булмаячагы сизелеп тора иде. Абзыйның тырпаеп эндәшүе мине дә кузгатты. Сүз җитдидән китте.

— Ике ел үстереп тәмам кеше иткән баланы ансат кына белмәгән-күрмәгән кешегә биреп җибәр имеш.

— Әгәр ул күрмәгән кеше дигәнегез баланың атасы булса? — Миңа да эреп торырга вакыт калмаган иде монда.

Миңа Мәдинә дә өстәде. Кыскасы, безнең уйнап йөрмәгәнебезне, мин каты җәрәхәтләнеп госпитальдә хәбәрсез озак ятканда Мәдинәнең сабыйны роддомда калдырып чыгарга мәҗбүр булганлыгын аңлатып әйткәч, абзыйның берәз йомшаганлыгы күренде. Алар ирле-хатынлы бер-берсенә моңсу гына карашып торганнан соң (хатыны елап ук җибәрде!), аптыраудан нишләргә белмәгән баланы безнең кулга китереп тоттырырга мәҗбүр булдылар. Әлбәттә, җиңел аерылышу булмады бу, әмма бүтәнчә мөмкин түгел иде.

## X

Балалар бераз тартынып торганнан соң татуланып, бер-берсенә ияләшеп киттеләр. Малай «з» авазын ачык кына чыгара алмый, шунлыктан сөйләве чак кына сакаурак, хәер, бу кимчелеге аны һич төшерми, безгә якынайта гына иде.

Малай хәзер өйдәгеләр өчен улыбыз Әхәткә әйләнгән, аны тулы исеме белән әйтсә бары тик әбиләре Фатыйматтәй генә әйтә. Башкаларның да исемне кыскартып әйтүләрен өнәми.

— Телегез калыр ие баланың исемен тутырып әйтсәгез,— дип, сукранып куя. Титулларны да саташтырмый башладык: мин — әти, Мәдинә — әни, Хатирә белән Әхәт безнең балаларыбыз булып калды. Тик Хатирә өчен әбиебез генә икенче ягы белән ачылды түгел микән? Элек ул кызый өчен турыдан-туры «әби» генә иде, хәзер аның әбисе әтисенең әнисе булганы өчен әби икән. Өйдә дә, күрше-тирәдә дә икенче әни булганлыгы турында телгә керткән кеше юк, гомергә болай яшереп саклый алмаслар, телгә керер. Озак көттермәде, һич уйламаганда Әхәт сиздереп тә куйды. Нәрсәдәндер сүз чыгып, мин Мәдинәгә тәксе эндәшкәнмен, хатыным моны авыргарак алып:

— Син, Фәрди дус, әтәч булып та кычкыра беләсең икән,— дип шаяртып куйды.

Өч яшьлек Әхәт — җирдән өч карыш калыккан малай — шуңа игътибар иткән булган:

— И, анда безнең атка утырып йөри торган эти энигә болай гына әйтми иде.— Ул, андагыларны мондагылар белән бутарга ярамаганлыгын сизгән кебек тотлыгып, сакауланыбрак калды, шулай да әйтә башлаганын төгәлләп чыкты: — Бервакыт исереп кайтып, энигә шул кадәр кычкырды... Аннары урындык алып өстенә атты.

Мәдинә малайны тиз генә кулыннан алды да почмак якка, уенчыклары янына илтергә ашыкты. Соңыннан без бер-беребезгә карашып алдык: «Ә, шулай икән әле! Бик үк түгәрәк тә түгел икән. Бездән башка тагын дөньяда атка утырып йөри торган эти дә бар икән»,— дигән мәгънә чагылып калды безнең бу карашып алуыбызда. Бер үк вакытта без сабыйны урындык белән бәрешә торган дөньядан үз вакытында алып китә алганыбыз өчен шатланып та куйдык. Кыскасы, хәзер безнең өйдә бөтенесе дә үз урынына утырды. Хатирә өчен дә әни бер генә, Мәдинә әни генә бар иде. Әгәр кызыбыз кайчан да булса үзенең чын әнисен белеп алса да, моннан гына әллә ни үзгәрмәячәк. Дөнья шулай ул: берәү килә, берәү китә, тормыш дәвам итә — каршылыклары, борчу-шатлыклары, җырлары һәм күз яшьләре белән...

## Нури Арсланов

### Йөрәгеннән алдым

Орфей, Орфей! Аның җырларына
Агым сулар туктап тынганнар,
Ул кагылса лира кылларына —
Сандугачлар сәҗдә кылганнар...

Җырда булган аның бөтен көче,
Сәнгатендә булган тылсымы,
Давылларны авызлыклар өчен
Тик лирасы илткән җырчыны.

Ишетәм сыман Орфей
тавышларын,
Яңгырашы чыңлый сазымда:
Һәлакәте кушыла алысларның
Бәхет җырлыйм дигән чагымда...

«Алтын руно» өчен әнә җирдә
Изге ирләр көрәш күтәрде:
Язон батыр баткан кара тиргә,—
Аргонавтлар килеп җитәрме?!.

Җиһан тетри өреккән ат кебек,
Колыннарын талый бүреләр...

Илләр поскан ояларга кереп,
Шик таратып өннәр йөриләр.

Сугыш яный безгә уңда, сулда,
Бар дикъкатен ала сак ирнең:
Бер кулында лира, бер кулында
Кылыч хәзер солдат-шагыйрьнең.

Булыр иде яшәү ансат-шома
Хәтеремне әгәр алдасам:
Гаҗәпмени, халкым, язмышыңа
Мин ваемсыз карый алмасам!

Үзең шагыйрь дигән исем бирдең,
Ул җиңел дә җилдәй, авыр да:
— Чәчәкләре җирнең сиңа,—
диден,—
Күтәр,— диден,— иңгә тавын да!

Кичерәм сыман Орфей
язмышларын:
Иминлеккә — һәр ни кылганым!
Лирамны да илгә багышладым,
Йөрәгеннән алдым кылларын.

*1982—1983*

### Төрле уйлар

Кыл яхшылык, рияланма — кыл да оныт,
Җуйма кадерен — искә алма торып-торып.

Кылыйм дисә, яманлыкка һәркем оста,
Яманлыкның уе озын, буе кыска:

Уе озын... ләкин күпме үрләмәсен,
Ай-йолдызга ташлый алмый күләгәсен.

Егет булсаң егып була җаһилләрне,—
Үрнәк итсәң Алишләрне, Җәлилләрне...

Ирләр көрәш мәйданында батыр кала,
Ә мескеннәр хәрәмләшә — аяк чала.

Тасма телнең озын ул сүз дилбегәсе:
Хуҗасына бар дан сөйләп, бил бөгәсе.

Бәхет — андый түбәннәрдән булсаң ерак,
Кыска гомерең үткәрмәсәң «хәер сорап».

Гаҗәп түгел тел төбендә төпченсәләр,—
Хөсетлекне «уяулыкка» күчерсәләр.

Вак-төякнең бар сыйфаты хөсетлектә,
Андыйга хас койрык болгар көчеклек тә.

Андый белә, тел озайтмый иясенә:
Исәп тота күпме сөяк тиясенә.

Торган саен йөзен ача кайбер дуслар,
Тел «остара», күтәрелгән саен тостлар:

Сугышларга теләп киткәнлегем дә хак,
Бирәү шуның өчен диде миңа: «Ахмак!»

«Без патриот!» дип түш каккан якыныма
Исем китте — икейөзле «акыллыга».

Миңа нәрсә, миңа горурлыгым — байлык!
Шәрап тотсам да, хисләрем булды айнык.

Сугышта да, тынычта да тугры калдым:
Ике яклап ветеран дип исем алдым.

Шуннан артык нәрсә кирәк карт солдатка,
Я, кем тагын да ни әйтер шушы хакта?

Ни әйтсә дә, ис китәрлек дөнья бит ул:
Галибкә[1] дә, гарипкә дә оя бит ул!

Син дә, Нури, фани дөнья улысың бер,
Уйларыңны һәр дәм изгелеккә дүндер.

*1981—1982.*

## Ике оям

Казаннардан чыгып китәм
Казакъ араларына,
Мин шул кадәр гашыйк икән
Сәйран далаларыма:

Кайтыр идем Казаныма —
Далам, казагым кала.
Китәр идем казагыма —
Йортым — Казаным кала.

Идел яры итәр идем
Алатау кыяларын...
Бер үземә ике илем —
Үстергән ояларым.

Бик ерак тик аралары,
Ә күңел ерак түгел:
Даладамы, каладамы —
Мин килгән кунак түгел.

[1] Галиб — җиңүче.




*Тавил Хаҗиәхмәтов рәсеме*

Казакъ иле — ак биләвем,
Казан иле — аталык [1].
Шуңа үтте гомерләрем
«Чалаказакъ»[2] аталып.

Кушаматны дуслар бирде,
Болай, шаярып кына,
Кеше үз булмый бит инде
Урталай ярып кына.

Мин бөтен килешмен, бармын!
Күңелне булмый ясап:
Татарым белән — татармын,
Казагым белән — казакъ.

*1982*

## Сөйләп уйлыйм[3]

Хискә һибә кылдым бөтен көчне,
Кергән чаклар булды утларга...
Инде тәмам сабый бала төсле,
Җик күрмәгез мине юк-барга.

Күңел барлык киртәләрне бозды,—
Шуңа язмыш җыера кашларын.
Уйлап сөйли торган чаклар узды,
Хәзер сөйләп уйлый башладым.

«Гаеп итсәң — бар да гаеп» инде,
Ул турыда сөйлә-сөйләмә:
Тигәнәктәй сырган итәгемне —
«Гаепләрем» һаман сөйрәлә.

Акыл, әхлак-әдәпләрдән арынып
Калып булмас ахры тынычлап:
Йөгем авыр, я егылырмын абынып,
Төямәскә иде дыңгычлап...

«Тиленеке турыдан»,— ди картлар,—
Кинаяне инде ташладым,
Узды уйлап сөйли торган чаклар,
Хәзер сөйләп уйлый башладым.

*1982*

## Сарман сагышы

*Сарманда миңа сандык бүләк иттеләр.*

Сарманнарның сары сандык
Күтәреп килгәннәре:
Сандык тулы сагыш салып
Сагынсын дигәннәрме?..

Сандык сырлый икән Сарман,
Тоткалары алтыннан.
Инде Сарманнарга барсам,
Калмас идем артыннан.

Сарман якларына тартып,
Сарыла сагышларым.
Өздерә гармун, уятып
Кыңгырау тавышларын...

И бер җигеп җилдералсаң
Шул Сарман байталларын!
Инде Сарманнарга барсам —
Тиз генә кайталмамын...

*1982*

---

[1] Борынгыда ил белән тугры хөкем итсен дип, хакимнәр балаларын аталыкларга биреп, гади шартларда тәрбияләгәннәр.
[2] Чалаказакъ — ярым казакъ, кан аралаш мәгънәсендә.
[3] Сөйләп уйлау — думать вслух — балаларга хас халәт.

## Кама буенда

Камады Кама буенда
КамАЗлылар — яшь кызлар:
Ваем юк алар уенда,
Хәрәкәтчән, тыз-бызлар.

Тик берсе сабыр арада,—
Сөеп йөргән чагымы?..
Шул кадәр тутырып карады —
Татлы моңнар чагылды.

Алтын сары яфраклардан
Таҗ кидерде башыма:
Дөп-дөп килә, Нури, саклан,
Йөрәк никтер ашыга.

«Ак чәчләргә бу сары төс
Шул кадәр килешә!»— ди.
Ә акыл әйтә: «Нури, т-с-с,
Сиздермә-бирешмә», ди.

Яшерен-батырын юк эчемдә,—
Җән-акылсыз юана!
Шуңа юаткан өчен дә
Куанам мин — дивана.

*1982*

## Көз көткәндә

Килим микән, килмим микән, дип көз килде,
Бер килмәде — төрлеләнеп ул йөз килде:
Бер кыш булды ак сакаллы, бер яз булды,—
Хәтерләтеп көлеп торган нечкә билне.

Миңа, вакытын белеп килсә, көзем дә шәп,—
Саргайган, сагышлы, моңлы йөзлем дә шәп,
Һәр нәрсәнең яме, иркәм, үз төсендә:
Кырыкларга кыланмасаң — үзең дә шәп!

*1982*

## Миләш

Кардан бүрек киеп,
Тәлгәшләрен иеп,
Миләш өшеп тора.
Яфраклары күптән
Инде коелып беткән,
Ә ул пешеп тора.

Горурлана миләш:
«Без бит һаман да яшь,
Күр,— дип, безнең хәлне,
Кызыл без һәр даим,
Бәс каплаган саен,
Туңган саен тәмле!»

Миләш үзенчә хак.
Ышанмасаң, я, кап,
Тәмен татып кара.
Бөтен дөнья тулы
Яшәү горурлыгы,—
Хәят шулай бара!

*1982*

## Байкал күл

*Бу җыр Себер якларында җырлана иде. Көе белән кушымталары хәтердә сакланган. Ә куплетларын элекке сюжет нигезендә яңадан язарга туры килде.*

Автор.

Балыкчылар икәнсез лә,
Каекларда китәмсез:
Исәнлектә күрешалмасак,
Инде ни хәл итәрбез...
Байкал күл комлыйкән [1].
Башым нигә моңлыйкән?..

Күл төбендә ташлы таулар,
Ишкәкләр сынмас микән?
Яулык болгап калган ярлар
Безне юксынмас микән?..
Байкал күл камышлы.
Башым нигә сагышлы?..

Исән-сау кайтсын үзләре,
Кайтмасын хәбәрләре:
Упкынлы Байкал күзләре,
Күп хәвеф-хәтәрләре...
Байкал күл таш кына.
Башым нигә ашкына?!.

Ишеттек язмыш көлгәнен,
Тетрәтеп тау-ташларны,
Әрәм булган егетләрнең
Шунда газиз башлары...
Байкал күл балыклы.
Тапканнар буш каекны...

*1981*

## Тал бөгелә

Тал бөгелә, тал бөгелә,
Җилнең уйнавын кара!—
Уйна, шаян, сылу белән,
Тузган чәчләрен тара.

Бер тара, бер тузгыткала,
Җилфердәт күлмәкләрен,
Сурәтләп күрсәт бер ара
Калкытып күкрәкләрен.

Койган сындай бара чибәр,—
Карап күзләр чагыла...
Сөлектәй тартылган билләр
Шат җилләр кочагында.

Бу — Хәйям җамы хәяттан,
Бу — бәхет үзе бара!—
Екмакчы була аяктан,
Җилнең уйнавын кара...

*1982*

## Юану

Берәү авырып ята, үлем көтеп,
Тынгы бирми бер уй аңында:
Уйлый байгош күпме гомер итеп,
Нинди рәхәт күрүе хакында.

«И ташыдым михнәт капчыкларын,
Исәпләсәң — Идел буарлык!
Инде тәмам арып-талчыкканмын,
Хәл калмаган дөнья куарлык...

Китүме бу яшәү кызыгы күрми?
Болай булырын кемнәр уйлаган!
Җәннәтләре исемә дә керми,—
Бер өмет юк теге дөньядан...»

Шунда кинәт... зөфаф кичәләрен
Хәтерли дә алчак бу бәндә,
Авызын ерып әйтә: «Бичәләрем!
Үкенмәслек икән үлсәм дә!»

*1982*

[1] «Комлы икән», «моңлы икән» сүзләре шулай кушылып «и» авазы йотылып җырлана.

## Мәхәббәт турында

Мәхәббәт азатлык түгел —
Күп аның богаулары;
Үзенә кол итә күңел
Мөкиббән булганнарны.

Күңел колы булып мин дә
Яшәдем... үкенмимен.
Азатлык булмаса, нигә?
Бәхетем булды минем!

Алиһәләр юмарт иде.
Зарланмыйм кичәгемә:
Ни сорасам, шуны бирде,
Нәүмиз итмичә генә.

Богауда, татлы газапта
Мәҗнүннәрчә яшәдем.
Кемгә хаҗәт мондый чакта
Узганың, киләчәгең!

*1983*

## Газраилне күрдем

Күптән түгел Газраилне күрдем,
Җан алырга дисәң, ул комар:
— Тормышыңнан бизепме,— ди,— килдең?
Котылгы бар, дөньяң булса тар.

Һәр кем шулай, вакыты җиткән икән,
Үземә генә килсен туп-туры.
Ә ветеран булса, кабул итәм
Чиратсыз,— ди,— каһәр суккыры,—

Повесткасыз килгәч, бардыр әле
Берәр сере, сөйлә, ни йомыш?
Кергәч чыгармаучан мин бәндәне...
— Әйе, сиңа керү — куркыныч!

Тик, белеп тор, мин бит сугышларда
Үлем белән уйнап йөргән зат!—
Үзем эчтән уйлыйм: синең алда
Юкка гына тормый карт солдат;

Салып карыйм әле димен кармак,
Син салганчы элмәк бугазга:
Разведкага килдем, бәлки алдап
Булмас микән диеп беразга.

*1983*

## Гаделсезлек

Миңа
Бөек сугыш ветераны диләр,—
Кенәгәм бар — дөрес.
Мактаулы эш ветераны диләр,—
Медалем бар, көмеш.
Ә мәхәббәт ветераны диген,
Я кенәгә, я бер медаль биргән
Булмасын ди имеш!
Бу нинди эш?!

*1982*

## Фәүзия Бәйрәмова

# БОЛЫН

ПОВЕСТЬ



Мин, үземне белгәннән бирле, күңелемдә сурәтләнгән бер күренеш белән саташам. Миңа бик авыр мизгелләрдә, бар дөнья, кинәт тынып, телсез-өнсез булып кала да, мин тагы үземә — күңелемдәге шул ак томаннар дөньясына китәм. Башта мин ул дөньяга кыяр-кыймас кына килеп керәм. Ул — чәчәк исләреннән оеп яткан җәйге бер болын. Көн үзе бик якты да кебек, ә шулай да болын өстен әллә нинди шомлы болытлар каплап киткән. Җиле дә бар кебек. Мин анысын йөгерә башлагач кына тоям. Мин гел шулай, болынга кыяр-кыймас кына килеп керәм дә аннан әкрен генә йөгерә башлыйм. Каршы искән җил минем озын кара чәчләремне кирегә куа, алар, мин атлаган саен, бер очып китәрдәй булып күккә күтәреләләр, бер нәүмизләнеп, хәлсезләнеп, минем муеныма, җилкәләремә уралалар. Ә мин һаман йөгерәм дә йөгерәм... Үзем чәчәкләр арасыннан йөгерәм, үзем бөтен җаным-тәнем белән өстән шомлы болытларның түбәнгә агылуларын, миңа таба якынлашуларын сизәм. Кулларым өметләнеп алга сузылган, миңа һаман арырак, болынның әнә теге башындарак, миңа таба да кемдер шулай йөгереп киләдер кебек тоела. Мин инде арыйм, хәлем бетә, ләкин туктый да алмыйм, тукталсам, теге авыр соры болытлар куып җитәрләр дә... Куып җитәрләр дә... Ә каршыда һаман берәү дә юк... Болын искиткеч зур да, чәчәкле дә, матур да, шомлы да... Ә мин һаман бер ялгызым йөгерәм. Кая соң ул, кочагын җәеп, минем каршыма йөгерергә тиешле кеше?! Килеп капланыр идем шуның көчле кулларына, качар идем шул шыксыз салкын болытлардан...

Мин инде шушы ялгыз йөгерүемнән мәңге туктала алмаячагымны аңлаган хәлдә, котылгысыз рәвештә һаман текә яр буена якынлашам. Ләкин мин нигәдер курыкмыйм, мин инде бик арыган, миңа инде барыбер. Шул якты да, шомлы да гомер болынымнан йөгереп килгәнем хәлендә, мин инде упкын читенә үк барып җитәм. Ә аста ап-ак томан, минем аягым астыннан ук ап-ак томан башлана. Мин, кап-кара чәчләремә урала-урала, шул ап-ак томан эченә ташланам. Арып, хәлсезләнеп, гаҗизләнеп... тынычланып. Һәм үзем дә ап-ак томанга әйләнәм. Ап-ак томанга...

Мин, үземне белгәннән бирле, әнә шул күренеш белән саташам. Ләкин мин, чәчләрен җилдә туздырып, болын буйлап йөгереп килүче бу ялгыз кызга берничек тә ярдәм итә алмыйм. Упкын читенә барып җиткәч, туктата да алмыйм. Күзләремне йомам да, үзем дә аның бе-

лән ап-ак томан эченә ташланам. Шулай итеп мин, вакытлыча гына булса да, өстемә ябырылып килгән усал болытлардан качам, үз-үземә качам, үземә китәм... Миңа нидер әйтәләр, аңлаталар, мыскыллап көләләр, ә мин барыбер ишетмим, мин бит инде ак томаннар арасында хәзер...

Аннан, җүләр диләр дә, китеп баралар. Ә мин бит җүләр түгел, түгел, мин бары тик аларга охшамаган гына. Ә нигә кеше кешегә охшарга тиеш соң әле? Әгәр мин дә аларга охшаган булсам, минем болыным буенча кем шулай йөгерер иде икән соң? Әллә барыбыз да шул болыннан йөгерер идекме икән? Бөтен кеше берьюлы йөгерә-йөгерә дә, барысы да берьюлы төпсез упкынга оча. Тавыш-тынсыз, сырхау-газапларсыз гына... барысы да... юкка чыга... Юк, алай яхшы булмас иде. Алай булмасын. Ул бит минем генә болын, ул — мин генә очасы упкын, ул — минем генә дөньям...

Мин шәһәрдә туып-үстем. Ләкин һәр җәй мине авылга, әбиләремә кайтаралар иде. Ул кайтуларны мин әкият дөньясы кебек итеп көтеп ала идем. Шәһәрнең кырыс режимыннан соң, кыш буенча мәктәп белән үзем яшәгән йорт арасыннан башка дөнья күрмәгән бер кыз бала өчен авыл ул могҗиза иде! Ул әкият иде. Ул моң иде.

Мин, авылга кайтуыма, аякларымнан кыйммәтле шәһәр туфлиләрен салып ташлыйм да, болынга йөгерәм. Беркемнән курыкмыйча, оялмыйча, әдәп-кагыйдәләрнең дөньяда барлыгын да онытып, тилереп, кыргыйланып, мин болынга йөгерәм. Андагы чәчәкләр минем билемә җиталәр, алардан таралган әллә нинди тәмле исләр минем елыйсымны китерәләр. Шунда ук меңтөрле бөҗәк мыж килә, болын өстендә әллә нинди кошлар сайрый! Мин инде, бу кадәр дә могҗиза, матурлыкка түзә алмыйча, күзләремне йомам да, болын чәчәкләре өстенә авам. Бармакларым салкын җир белән очрашкач, сискәнеп китәм. Кара инде, болында җир җәй көнендә дә салкын була икән бит, куе үлән арасына кояш нуры төшеп җитми микәнни? Ә барыбер рәхәт. Өстә — җылы кояш, аста — салкынча, дымлы җир. Чәчәкләр, нелеп-нелеп, минем битләремнән, күзләремнән үбеп алалар, муенымны кытыклыйлар. Мин аларны өзмим — өзгәч, алар шунда ук шиңәләр, ямьсезләнәләр. Мин аларны беркайчан да өзмәячәкмен, мин аларны карарга һәркөн саен бирегә йөгереп киләчәкмен. Җәй бит әле башлана гына, мин әле аның бәтәренә дә ышанмыйм. Миңа гел шулай җәй булыр кебек, гел шулай болын булыр, чәчәкләр булыр кебек.

Ә бер көнне бирегә йөгереп килгәч, мин чәчәкләремне тапмадым. Болыным да үзгәреп, боегып калган. Чәчәкләр бер рәт булып җиргә ауганнар, төпләре шыксызланып тырпаешып торалар. Инде ялан тәпи бу болында йөрерлек тә түгел иде. Аякларым авыртуданмы, болынымның, җанымның шулай рәхимсез талануыннан әрнепме, мин елый-елый печән чабучы ирләр янына йөгерәм.

— Нигә тиясез сез ул чәчәкләргә?! — дип кычкырам мин килә-килешкә.

— Бу нинди бала тагы? — дип сорый ирләрнең ямьсез кыяфәтлесе.

— Ә... Шәһәр кызы ахры. Авыл баласы мондый уттай эш өстендә чәчәк эзләп йөрмәс.

— Нигә тиясез сез ул чәчәкләргә?! — дип сорыйм мин кабат үземә салкын гына карап торган кешеләрдән.

— Ә син аны, сеңелем, бар инде, әбиеңнән кайтып сора... Ирләр шунда, җыен эшлексез, үлән таптап.

Мин аның соңгы сүзләрен тыңлап та тормыйм. Аякларымның әрнеп үтереп сызлауларына да карамастан, чабылган болын буйлап авыл ягына йөгерәм.

— Әби! Нигә ул чәчәкләргә тияләр? Нигә болынны ямьсезлиләр алар?!

— Ә... Ул ни бит, балам, чабалар инде аны. Бүген печәнгә төшteләр шул.

— Ә нигә чабалар?! Алар бит әле шундый матурлар иде!

— Соң, вакыты җиткәч, чәчәкләрне дә чабалар инде, балам. Чәчәк дип, үлән бит инде ул. Кышка малларны ач тотып булмый бит.

— Чәчәкләрне дә малларга ашаталармы?

— Әйе, сыерыбыз менә шуны ашар да сиңа күп итеп сөт бирер, каймак бирер.

— Кирәкми миңа андый сөт! Кирәкми миңа андый каймак! Сез барыгыз да усаллар! Мин сезне яратмыйм!

Мин тагы, тузан туздырып, авыл буенча йөгереп узам. Кая барасымны үзем дә белмим, хәзер инде барып капланырга болын да юк. Минем кайгымны аңларлык кеше дә юк. Барысы да ду килеп утынпечән әзерли. Аларга бу кыңгырау чәчәкләре — печән, менә бу ак каенкаем, мескен каенкаем — утын. Алар миңа да бер җүләргә караган кебек кенә карыйлар. Мин бит сизеп торам! «Шәһәр кызы кайткан икән!» — дип аркамнан шапылдатып сөюләрен дә яратмыйм. «Шәһәр балалары бигрәк матур булып үсәләр инде»,— дигәннәренә дә ышанмыйм. Чөнки мин китүгә, икенчесе әйтеп куя аның: «Эшләп үсмәгәнгә шулай ул,— ди.—Ап-ак булып, буйга сузаеп, йом-йомшак булып үсәләр иркәләнеп»,— ди. Мине, шәһәрдә үскәч, татарча аңламый дип беләләр инде. Мин татарча аңлыйм, мин менә аларның үзләрен генә аңламыйм. Аларның матурлыкка шулай битараф булуларын, табигатьтәге һәр нәрсәне файдалы-файдасызга бүлеп кенә кабул итүләрен аңлый алмыйм. Алар гомер буе эшлиләр дә эшлиләр, дөньяга сокланырга аларның вакытлары да юк.

Әбием мине ачулангалый башлады. «Кешеләргә алай кара көеп йөрмә,— ди.— Авыл халкы кыланган кешене яратмый ул»,— ди. Ә мин кыланмыйм. Һәм аларны яратмыйм да.

Икенче җәйдә мин инде болынның чабылачагын алдан ук белә идем. Өченче җәйдә мин инде аның чабылырга тиеш икәнен аңладым. Калган җәйләрдә мин инде беркайчан да тилереп-кыргыйланып ул болынга йөгермәдем. Барсам да тыныч кына, ял итәргә генә бара идем. Тик беркайчан да, беркайчан да мин үзем ул чәчәкләрне өзмәдем! Минем балачак хыялларымны шулай үткен чалгы белән бер селтәнүдә юк итә алсалар да, матурлыкка табынган җанымны сындыра алмадылар. Мин ул чәчәкләрне беркайчан да өзмәдем...

Минем дөнья хәзер икегә аерылды: аның берсе — озын салкын кыш, шәһәр тормышы, икенчесе — җәй, авыл, болын. Әгәр җәйләрен авылга кайтмасам, мин акылымнан шашар идем. Җәйләрен эссе асфальт урамнарда бәрелеп-сугылып йөргән яшьтәшләремне кызганам. Аларның балачаклары бөтенләй юктыр кебек. Балачакка дип бирелгән еллар бар, ә балачаклары — юк. Аларның әле бәлки беркайчан да яланаяклап җиргә басып караганнары да юктыр. Кара урманда адашып калганнары да юктыр. (Ә мин адашам — һәр җәй саен урманда бер адашмыйча калмыйм. Иң кызыгы — шул. Үзе куркыныч, үзе рәхәт. Ә соңыннан табылуы рәхәт!)

Әбием әйтә, сине хәзер җәйләрен авылга кайтарырга да куркыныч, ди. Башта болын дип йөрәгемә төштең, хәзер урман дип саташасың, ди. Болынны бигрәк иртә чабалар шул, әле җәйнең яртысы да җитмәгән була, болынны инде чабып та ташлыйлар. Чапканнан соң, мин анда бармыйм инде, бер-ике көн нәүмизләнеп, күңелсезләнеп йөрим дә бакча башыннан гына урманга чыгып йөгерәм...

Безнең шәһәр янында да урманнар бар. Ләкин мондагы урманнар — бөтенләй икенче. Анда куак төбе саен чүп-чар, шешә ватыклары аунап

ята, яланаяк җиргә басарга да куркыныч. Ә мондагы урманнарда ул абагаларның куелыклары, ул җирдән килгән баш әйләндергеч исләр. Ә агачлар гел гөжләп торалар кебек. Болын җәй уртасында үзгәрә, ямьсезләнә, урман исә мине гел менә шулай шаулап-гөжләп каршы ала, озатып кала.

Минем бүген адашасым килә. Кичә болынны чаптылар, җил белән болын ягыннан кипкән печән исе килә. Мин, үлгән чәчәкләр исе, дим. Әби ачулана. Синнән чыгар инде ни чыкмаса, ди. Кешеләргә бу ис ошый, ә мине ул буа. Минем кычкырасым, елыйсым, аларга тупас сүзләр әйтәсем килә, мин, кырт борылам да авылдан чыгып йөгерәм. Бу юлы инде болынга түгел, урманга таба йөгерәм. Ул да авылдан ерак түгел, кыр аша гына бераз барасы-барасы да, аннан урман башлана.

Болынны чапкан көн — минем урманда адашу көнем. Ул көнне мин авылга кайтмыйм, урманда кунам. Авыл халкы инде минем адашасымны белә, «Теге Рәйханның җүләр кызы (Рәйхан минем әнием була инде) тагы адашкан икән. Буе үскән, акылы — юк. Булса да булыр икән шулкадәрле тулыксыз бала»,— дип сөйләшәләр. Шуңа күрә минем авылда да иптәшләрем юк. Минем яшьтәш кызларым баш күтәрми печән-утын әзерлиләр, кичләрен су буена чыгып, җырлый-җырлый әйлән-бәйлән уйныйлар. Аннан ду килеп, бер-берсе каршына очып килә-килә, тыпырдап бии башлыйлар. Миңа бу да күңелле түгел. Аларның җырлый-җырлый җитәкләшеп йөрүләреннән минем башым әйләнә башлый. Мин ул такмакларның сүзләрен дә аңламыйм. Кыш буе дөнья классикларының шедеврлары белән шыплап тутырылган башым бу такмакларны кабул итә алмый. Әнием, нинди заманча, оригинальный әнием, хәтта ул да, яшьләрнең кичке уен җырларын ишетсә, күз алдында үзгәреп, моңсуланып, кечерәеп кала. Су буеннан ишетелгән ул җырларны әнием ярты төнгә хәтле капка баганасына сөялеп тыңлап тора ала. Өйдә әбием дә йокламый. Аһ та ух килә, и гомерләр ди, гел без яшь чактагы кебек җырлыйлар бит, ди. Ә минем нигәдер Есенин шигырьләре исемә төшә, яки үземне Толстой геройлары урынына куеп карыйм, барысына да ышанам, табынам, тик такмаклардагы сүзләргә — юк. Әбием шәһәрне гаепли, баланың моңы юк, ди. Авылга кайтып, үз иптәшләре белән сөйләшә алырлык та теле юк, ди. Йөри аннан соң ялгыз күккүк кебек әле болынга барып чәчәкләр белән сөйләшеп, әле урманнарга чыгып китеп адашып, ди. Их, әби, әби! Телдәмени хикмәт. Безнең бит җаннарыбыз төрле алар белән. Менә берсе генә килсен иде шуларның минем янымa, кызыксынсын иде чәчәкләрнең җаны белән, минем җаным белән. Ә алар киләләр дә, бу джинсыйны кайдан алдың? диләр. Шәһәрдә хәзер нәрсә модный, диләр. Егетләр белән үбешкәнең бармы әле? диләр. Мин җавап бирмәгәч, әй, кыланчык, әллә кем булган, шәһәр кызы булдым дигәч тә, дип, миннән кычкырып көлеп, китеп баралар...

Мин бу авылда да я[illegible]-ялгыз.

Минем бүген адашасым килә. Мин инде кайсы якка барганымны да белмим. Миңа барыбер. Менә шулай йөри торгач, барыбер урман кырыена килеп чыгасымны беләм бит мин. Мондагы урманнар да кечкенә бит. Аларның кеше аягы басмаган урыннары юктыр инде. Әнә бит күпме сукмак, ат, машина, көпчәк эзе. Ә мин аларның берсеннән дә бармыйм. Чәчләремне куаклардан йолкыта-йолкыта, битләремне тырнатып-канатып, кеше йөрмәгән җирләрдән үҗәтләнеп үземә юл салам. Тырналган урыннарым сулкылдап сызлый, чыбык тартелеп, күзләремнән туктаусыз яшь ага, мин аның сыен кыргыйлана, ярсый барам.

— Әй син!

Кайсы куак шулай эндәште миңа? Мин инде чытырманлыкта басып торам, яшь каплаган күзләрем берни күрми...

— Сиңа әйтәм! Нишләп чәбәләнәсең анда баядан бирле?

Чуалып күземә төшкән чәчләремне бер селтәнү белән артка алып ташлыйм, атылып куаклар арасыннан чыгам. Каршымда — бер малай. Авыл малаена охшаган.
— Тропинка салам.
— Нәрсәгә кирәк ул сиңа тропинка? Менә бит сукмак янында гына.
— Булса ни! Ул бит — синең сукмак. Ә минем — үземнеке.
— Урманда һәркем үзенә юл салмый инде. Әллә җүләрме соң син?
— Әйе шул, җүләр, җүләр! Ә сиңа барыбер түгелмени?
— Түгел шул. Син бит анда куакларны сындырасың. Әнә күпме чәчәкне таптагансың инде.
Урманда кинәт бөтен кошлар берьюлы сайрый башлады. Минем каршымда басып торган авыл малае да әллә нишләп үзгәреп, җанланып киткән кебек булды. Кап-кара чәчле, кап-кара күзле минем яшьләрдәге бер малай. Без инде әйтәсен әйтеп бетереп, гаҗәпләнеп, аптырашып, бер-беребезгә карап торабыз.
— Син әллә... адаштыңмы соң?
Минем гомеремдә беренче тапкыр кемгәдер зарланасым, аннан соң юату сүзләре ишетәсем килеп китте. Әбием, минем киреләнгәнне күреп, сер бирәсең килми инде, ди иде. Менә минем хәзер сер бирәсем килеп китте.
— Әйе шул, адаштым шул мин.
— Кайсы авылныкы соң син?
— Мин авылныкы түгел, шәһәрнеке.
— Ә... Әйтәм аны сукмаксыз җирдә сукмак салып йөрисең... Кайсы авылга кайттың?
— Күллегә.
— Ә... Бездән ерак түгел ул. Син инде йөри-йөри безнең авыл турына ук килеп чыккансың...
Без аның белән инде безгә кадәр дә кемнәрдер йөргән урман юлыннан барабыз. Кара, кеше салган сукмактан баруы да рәхәт икән. Бигрәк тә, янында сөйләшергә иптәш булганда.
— Исемең ничек синең?
— Алсу... Ә синең?
— Алмаз.
— Икебезнең дә «А»га башлана икән...
Тагы бер тын сүзсез генә барабыз. Икебез дә яланаяк. Мин беренче тапкыр ялангач аякларымнан оялып куйдым. Аннан кофтамның ертылган урыннарыннан оялдым. Битемдәге тырналган эзләрдән, чәчләремә ябышкан пәрәвез җепләреннән оялдым.
— Син ничәнче класста укыйсың?
— Җиделә.
— Мин дә җиделә...
Без авылга тиз кайтып җиттек. Кара, безнең авыл урманга бигрәк тә якын икән. Алмаз авылга кереп тормады. Мин, рәхмәт, дидем бугай, ул... бүген кич белән уенга чыгасыңмы? дип сорап куйды.
— Уен?.. Күңелле түгел бит анда.
Ул бер сүз дә әйтмәде. Мин дә. Аннан, ул инде шактый киткәч, мин кыр ягына карап кычкырдым:
— Мин чыгам бүген уенга, чыгам...
Ул борылып кул болгады. Аннан, кая басарга белмәгән яшь колыннар кебек, икебез ике якка торып йөгердек. Мин рәхәтләнеп, көлә-көлә йөгердем. Атылып өйгә кайтып кердем. Ишек төбендә бөкрәеп нидер эшләп яткан әбиемне дә бәреп ега язганмын. Әнием дә кайткан икән... Икесе дә гаҗәпләнеп миңа карап торалар. Мин көлә-көлә түр якка уздым. Куак-ботаклардан кыйналган тәнемне, әллә нәрсәсенә котырынып киткән җанымны караватка аттым. Ә теге якта әби белән әни сөйләшәләр. Бөтен сүзләре дә миңа ишетелеп тора...

— Бу балага нәрсә булган тагы? — Монысы әби. Хәвефле, борчулы тавыш.

— Печәнгә төшәләр, дип телеграмма суктың бит. Тагы урманга китеп адашыр дип курыктым.— Монысы әни. Аны әби чакыртып кайтарткан икән...

— Елның елында адаша торган иде. Баштарак бөтен авыл эзләргә чыга иде. Быел нәрсә булгандыр. Көнендә үк кайтып житте.

— Соң, бик әйбәт булган кайтса.

— Әйбәтен әйбәт тә. Әллә нәрсә эшләгән бит. Гомер болай очынганы юк иде.

Алар теге якта көйләп кенә һаман нәрсәдер сөйләшәләр. Өйдә салкынча, рәхәт. Күнелдә әллә нинди сәер тойгы — гел иртәгә бәйрәм булыр кебек. Ничә еллар буе үҗәтләнеп, кыргыйланып бәргәләнгән жаным кинәт кенә тынычланды да калды. Тәнем шундый жиңел, ул әллә нинди зәңгәрсу-ал яктылыкта тирбәлә. Яктылыкта тирбәлә...

Кичен мин ашыга-ашыга уенга жыена башладым. Джинсымны салып, бер матур гына күлмәк киясем килеп китте. Әби бөтенләй куркуга төште:

— Кызым, әллә жарың бармы соң синең? — ди ул кулларыма кагылып.

— Нигә, әбием? Ю-юк... Нигә алай әйтәсең?

— Уенга куып та чыгарып булмый иде бит үзеңне элек. Күлмәк кимәгәнеңә дә инде кайчаннан.

— И, әбием! Син бит әйтәсең, что мин кыз кеше. Ә кыз кеше күлмәктән дә йөрергә тиеш иногда.

Әби көлә. Аңа кушылып әни дә көлә. Мин дә көләм. Аннан әби әйтеп куя: «Кызым, сине бүген урманнан алыштырып кайтармаганнардыр бит?» — ди. «Безнең кызмы соң бу?» — дигән булып, сөякчел куллары белән чәчләремнән сыйпап куя.

— Адашмаска булдың инде, кызым, ә? — Әни инде гел шулай үзенчә төрттереп алырга ярата.

— Мин бәлки адашкан да булыр идем. Мине таптылар, адаша башлаганда ук.

— Шулаймыни?! Кем тапты соң сине?

— Алмаз.

— Кайсы Алмаз икән ул тагы? Кем баласы икән ул?

— Күрше авылныкы.

— Ә... булыр, булыр... Куркытмадымы соң үзеңне... Кем дисең әле?

— Алмазмы? Что син, әбием, беләсеңме, ул нинди яхшы малай?!

Әби белән әни мәгънәле генә карашып алалар. Әбинең күзләре моңлы, әнинең — сынаучан. Карашлары минем аша үтә. Мин дөрләп яна башлыйм, аннан утлы очкын булып кабынам да урамга атылам.

Кичке уен буласы урынга иң беренче мин барып життем. Яшьләр бирегә уенга соң чыгалар — көтүләр кайтып, бөтен йорт эшләре эшләнеп беткәч кенә су буена жыелыша башлыйлар. Анда да әле төрле-төрле төркемнәргә бүленеп; олыраклар бер урында биниләр, ә икенче бер такыр жирдә минем яшьтәгеләр ду килә, тагы да кечерәкләр, инде күптән ятып йокларга вакыт булса да, су буен бетереп чабышып йөриләр.

Мин уенга катнашмыйм. Мине чакырмыйлар да. Тик бүген минем якка сәерсенеп карап-карап кына алалар. Нигә икән? Бер үземә басып торырга уңайсыз, жиргә утырыйм дисәм... джинсы булмагач, утырып та булмый икән бит. Ә... кызлар шуңа карыйдыр инде миңа гажәпләнеп, күлмәк кигәнгәдер...

Мин Алмазны табармын микән соң бу караңгыда? Танырмынмы икән? Шулай уйлавым булды, күз алдымда аның йөз чалымнары пәйда булды. Кара чәчләре тәлгәш-тәлгәш булып ап-ак маңгаена төшкән, каш-

лары да сызып куйган кебек матурлар, каралар... Ә күзләре... күзләре бераз моңсурак иде бугай. Миңа гына шулай тоелдымы икән?

Бер урында таптана-таптана күпме генә көтсәм дә, Алмаз күренмәде. Уен ничек кисәк башланса, шулай кисәк кенә бетеп тә куйды. Бер заман су буенда беркем дә калмады. Әрәмә буеннан гына кемнеңдер чырык-чырык көлгәне ишетелә. Төнге авыл буйлап кайсыдыр дөпелдәп йөгереп уза. Саташып кына гармун кычкырып куя да... тына. Бөтен дөнья тып-тын булып кала. Шул тынлыкта, үз аяк тавышларымнан үзем үк оялып, мин дә кайтырга кузгалам. Бер-ике капка төбендә пырхылдашып минем арттан көлеп калдылар шикелле. Караңгыда аклы күлмәгем чекрәеп торадыр инде. Моннан соң күлмәк киямме соң мин?! Алмаз дип... При чем монда Алмаз? Мин вообще аның өчен киенмәдем. Бик кирәге бар иде ул бер авыл малаеның!

Инде үземнең бу халәтем өчен оялу үтә, аның урынына кирелек килә, кирелекне әйдәкли-әйдәкли, горурлык килә...

Мин икенче көнне тагы чыгам уенга. Үзем көне буе чыкмыйм дип киреләнеп йөрдем, ә кич җитүгә, чалбарымны кидем дә тагы шул якка чыгып йөгердем. Рәхәт чалбар кигәч... Хет утыр, хет тәгәрә чирәм өстендә. Мин, читкәрәк барып утырдым да, эч пошканнан, олырак кызларның әйлән-бәйлән уйнап җырлауларын тыңлый башладым. Алар әллә нинди озын, моңлы көй җырлыйлар да, аннан такмаклап бии башлыйлар.

Бишмәтеңдә алты төймә,
Нигә төймәләмисең?
Аралар да ерак түгел,
Нигә килгәләмисең?

Абау, нәрсә турында җырлыйлар алар? Бик тә аңлашыла бит бу җыр, мәгънәсез дә түгел. Ну, бишмәтен белмим инде, ә «аралар да ерак түгел, нигә килгәләмисең?» дигәне... Ә Алмаз нигә килми икән? Аларның да авыллары әнә генә бит, болын аша гына. Әнә утлары да җем-җем итеп күренеп тора. Тонык кына булып, эт өргәне дә ишетелә бугай. Ә кызлар җырлыйлар да җырлыйлар. Мин башымны тезләремә салып, күрше авыл ягына карап, аларның җырларын тыңлыйм.

Исемнәре Нәфисә,
Шул яклардан җилләр иссә,
Бәгырьләремне кисә.

Минем әле бу кадәр дә матур җырларны беркайчан да ишеткәнем юк иде. Нигәдер, гел минем хакта җырлыйлардыр кебек. Минем Алмаз турында уйлаганымны белеп шулай җырлыйлардыр кебек. Алмаз исеме, аның сурәте янына җыр сүзе килеп өстәлде, аннан, күз яшьләрем төсле булып, моң инде. Минем болынлы, урманлы, кыргый дөньяма, шул моңга, җырга ияреп, икенче берәү килеп керде. Мин аның турында хәзер чәчәкләргә караганда да күбрәк уйлый идем инде...

Алмаз өченче көнне дә килмәде. Мин инде кичке уеннарга чыкмый башладым. Капланам да ятам, капланам да ятам. Әби уфылдап йөри, йөри, өйгә бер керә, бер чыга. Дәшми. Сорашмый. Әни булса, әллә кайчан теңкәмә тияр иде инде. Белмичә тәки туктамас иде. Ә минем нигәдер аңа берни дә сөйлисем килми. Әбигә сөйлисем килә, ә әнигә — юк... Әнигә нәрсә сөйлим мин, ул «әйе» белән «юк»ны гына белә бит. Машина кебек. Әйтсә, өзеп әйтә. Аның өчен урталык юк. Мин беренче класста укыганда, безнең бөтен кызлар бию түгәрәгенә йөриләр иде. Мин дә йөгереп өни янына кайттым. «Әни, мин дә йөрим әле биюгә»,— дидем. Әнинең сүзе бер генә булды. «Юк!» «Нигә — юк? Барысы да йөри бит?!» «Син барыбер биюче булмаячаксың. Юкка вакыт әрәм итмә». «Минем бисем килә!» «Син быелдан чит телләр өйрәнә башлаячак-

сың». «Минем бисем килә!!!» «Аннан шахмат түгәрәгенә йөрерсең. Хәзер акыл заманы. Хис, бию заманы түгел».

Шулай итеп ничә кышым, кар тауларында ауный-тәгәри чана шуып үтәсе кышларым, хәрефләп-иҗекләп чит телләрдә «кыш», «кар» сүзләрен өйрәнү белән үттеләр дә киттеләр. Ятлый-ятлый, елый-елый шахмат уйнарга өйрәндем. Мин кар яуганын да, буран котырганын да тәрәзәдән генә карап үстем...

Әнигә бернәрсә сөйләп булмый. Мин, үскән саен, аннан ерагая гына барам ахры... Иптәш кызларым да юк. Ә кем беләндер сөйләшәсе килә. Менә өй уртасында япа-ялгыз басып торам инде. Юк, бөтен авылында берүзем. Бөтен дөньясында... бер ялгызымдыр мин бүген.

— Кызым, бик уйланма һаман шулай... Башыңа сугар бит, башыңа...

Әбием икән. Ишек янагына сөялгән дә, тилмереп миңа карап тора. Үзе шундый бәләкәй, шундый якын.

— Нәрсә сугар, әбием?

— Уең сугар, балам, уең... Болын, урман дип саташып йөрүләрең яхшырак булган икән әле...

Әллә әбием елый инде? Йөгереп барып, аның ябык гәүдәсен кочаклап алам. Әбием минем янымда бөтенләй кечкенә генә булып кала. Аны кызгануымнан йөрәгем өзелеп төшкәндәй була. Бала гәүдәле, юка, ап-ак әбиемне юатасы урында, үзем мышык-мышык елый башлыйм. Озак елыйм мин, ә әбием мине сүзсез генә юата, аркамнан сөя, чәчләремне сыйпап куя. Мин аның саен үксебрәк елыйм. Аннан... кинәт тынычланып, яктырып, җиңеләеп калам.

— Әби, ә нигә Алмаз килми икән?

— Кайсы Алмаз ул, кызым?

— Соң теге көнне, урманда адашканда мине тапкан малай. Ул әнә теге авылныкы. Болынның теге ягында гына.

— Ә... Сарылы малае... Кем баласы икән соң ул, кызым? Үзебезнең авыл яшьләренең дә исемнәрен белмим инде мин хәзер. Шул, ата-аналарына охшатып төсмерләсәм генә инде.

Әби, алъяпкыч итәген бөтерә-бөтерә, көйләп кенә сөйли дә сөйли. Ә миңа барыбер рәхәт... Әле ярый дөньяда әбиләр бар. Менә шулай үз алдына, моңлы гына көйләп утыра белүче бәләкәй әбиләребез бар...

Урманда Алмаз минем әллә күземә генә күренде-ме икән соң? Адашкан, адашырга теләгән җанга гына шулай кеше булып тоелдымы икән? Җен булмагандыр бит инде? Алай дисәң, безнең кыр юлы буйлап бергә кайтуыбыз? Соргылт тузанда янәшә калган аяк эзләребез? Аннан аның болын ягына таба йөгереп китеп баруы? Ә авыллары әнә генә бит инде, болын аша гына. Әллә, берәр сәбәп табып, барып кайтыйммы икән авылларына? Кибеткә дигән булыпмы шунда...

Ләкин миңа Сарылы авылы кибетенә барып кайтырга туры килмәде...

— Алмазыңның кайгысы зур икән әле, балакаем,— дип, әби минем бөтен планнарымны челпәрәмә китереп ташлады.— Атасы үлгән икән балакайның. Биш ятим белән утырып калды инде Хәтимә. Ходай чыдамлыклар бирсен үзенә... Бүген инде өчесен уздыралар икән...

Өчесе... Биш ятим... Атасы үлгән... Моңа кадәр мин бөтенләй белмәгән нәрсәләр. Һәм бу сүзләр, өрәкләр кебек, һаман Алмаз тирәсендә бөтереләләр. Монда инде урман да юк. Монда инде болын да юк... Юк, болын бар, шул болын белән ике арада упкын да бар. Ул упкын һаман җәелгәннән җәелә бара, ул инде болын өлешенә дә керә, мин инде болын аша йөгереп кенә Алмазлар авылына да барып килә алмыйм. Ул упкын ап-ак томан эчендә, аның упкын икәнен дә без генә

беләбездер әле. Ике ягында — икебез... Башта — болын аша, аннан — упкын аша...

Быел көз иртә килде. Печәннәрне чак киптереп өлгерделәр, коеп яңгырява башлады. Шуннан инде бер дә туктамады. Әллә миңа гына туктамаган кебек тоелдымы? Болын өстендә бигрәк тә утырып ява кебек. Сарылы авылы күренми дә. Ике арадагы елга тулып агадыр инде. Әни әйтә: «Болын яңадан чабарлык булыр инде болай булгач»,— ди. Әбием әйтә: «Әгәр тамырында черемәсә,— ди.— Бик коя бит, кояш җылысы юк»,— ди. Болынны елына ике тапкыр чабалар микәнни? Салкын күзләргә каршы курыкмыйча тернәкләнеп чыккан үлән-чәчәкләрне тагы чабалар микәнни? Матурлыкны, өметне, хыялны гел шулай чабып-кисеп торалар микәнни?! Шул болынны күпсенделәр инде табигатьтән. Әле чалгылар белән яныйлар, әле упкыннар белән кискәлиләр. Ничек түзә икән моңа болын, ничек түзә икән?!!

Мине быел авылдан да иртә алып киттеләр. Үзем дә, башка еллардагы кебек, китмим дип чат ябышып ятмадым. Авыр иде миңа һаман томан аша аргы ярга карап торуы. Атка утырып, коеп яуган яңгыр астында авылны чыктык, коеп яуган яңгыр астында кыр юлы буйлап бардык. Монда инде Алмаз белән минем эзләр юк, иртә килгән яңгырлар аларны юып, балчык, тузан белән бутап, ике авыл арасындагы елга-упкынга илтеп тә ташлагандыр инде.

Урманга кергәч тә күтәрелеп карамадым. Җәй көне минем белән сугышып яткан куаклар үземне танырлар да инде яфраклары коела барган шәрә ботаклары белән йөземә сугарлар кебек тоелды. Мин сискәнеп киттем. Нәрсәдә гаеплиләр соң мине бу җандай нечкә талчыбыклар? «Качасың, качасың»,— дип гөжлиләр түгелме соң алар?! «Дустыңа кайгы килгәндә качасың бит, кызыкай!» — дип мәсхәрәләп көләләр түгелме алар?!

— Туктатыгыз атны!

Әни зәһәрләнеп миңа карый, ат тотучы абзыйның дилбегәсен тартып ала да ярсый-ярсый атны кыйный башлый. Арбадагы сумка-төенчекләр үрле-кырлы сикерешә; юлдагы яңгыр суы биткә, күзгә чәчри, шул мизгелдән файдаланып, юл читендәге куаклар, үрелеп-үрелеп, чәчне йолкып алалар. Һәм мин сикереп төшәм дә кирегә йөгерәм. Артымнан беркөм кумаса да, җүләрләнеп, үз тыныма үзем буылып, йөгерәм дә йөгерәм. Яңгыр суы туфлиләрем эченә кереп җәфалый. Мин, туфлиләремне салып ташлап, яланаяк йөгерә башлыйм. Үзебезнең авылда да туктап тормыйм, болыным аша очып кына узам... Менә елга. Ике авыл арасындагы елга. Минем күңелемә упкын булып шом салган елга. Яңгыр суларыннан ул тагы да күтәрелгән, кара-кучкыл булып, дәһшәтләнеп, актарылып ага. Шул дуамал агымы белән ике арадагы тар гына агач күперне дә алып киткән... Ә авыллары әнә, күренеп кенә тора. Миңа — ундүрт яшь... Мин кире чигенә алмыйм. Мин бүген шушы упкын каршында куркып артка чигенсәм, гомер юлым гел чигенүләрдән генә торачак! Әйләнгеч юллар эзләүдән торачак!! Башкалар салган сукмаклардан шуышып барудан торачак! Нинди мескен киләчәк!! Юк, бу киләчәккә риза булганчы, мин үзем теләп кайнап торган упкынга сикерәм. Мин аны йөзеп чыгарга тиеш. Чөнки миңа — ундүрт яшь.

Йөзеп чыктым мин ул елганы. Йөзеп чыгу теләгем шулкадәр көчле иде, мин ничек елганы кичүемне дә, каршы яктагы тайгак ярга ничек үрмәләп менүемне дә сизми калдым. Юеш киемнәрем тәнемә ябышкан, ялангач аяк-кулларыма, тез башларыма яр пычрагы сыланган. Шул кыяфәттә мин авылга йөгереп килеп кердем. Бу авылда минем беренче тапкыр булуым. Алмазларның кайда торганнарын белмим. Кешеләрдән сорыйм. Кайсы Алмаз, диләр.

— Аталары үлгән,— дим.

Бер йортка төртеп күрсәтәләр. Батыраеп, туп-туры шунда таба китәм. Капка төпләренә килеп җиткәч кенә, котым чыгып, туктап калам. Нәрсә дип әйтәм инде мин анда кергәч? Әллә кире торып йөгерим микән? Ишегалдында кемнәрдер сөйләшәләр. Алмаз тавышы да бар! Тагын бер тапкыр упкынга сикергән кебек, капканы этеп җибәрәм. Теге якка атлап керергә хәлем юк. Алмазны күрәм. Ул да мине күрде ахры. Күтәргән утыннарын берәм-берәм җиргә куя башлады. Аның янындагы бала-чага да, шым булып, барысы да бер булып, миңа текәлделәр. Лапас астыннан карлыккан тавыш ишетелде:

— Нигә кертмисез берегез дә? Якты көздә ташып бетерергә кирәк тизрәк.

Бала-чага бер Алмазга, бер лапас астына карый. Аннан тагы тасраешып миңа текәләләр.

— Нәрсә булды сезгә анда, ә? И-и, төшәсез бәгырьләремә!..

Лапас астыннан таза гына гәүдәле бер апа чыга. Алмазның әнисе шушыдыр инде, Хәтимә ападыр бу. Ул да, чыга-чыгышка шаккатып, бер мәл миңа карап торды.

— Нәрсә кирәк сиңа, бала?

— Мин... Алмаз янына килгән идем.

Алмазның кечкенә сеңелләре, ял итәргә җай чыкканына сөенеп, шыбыр-шыбыр әниләре янына җыелдылар. Әмма Хәтимә апаның игътибары аларда түгел, миндә иде.

— Кайсы авыл кызы соң син, бала? Бер дә күргән-белгәнгә охшамагансың.

— Мин Күлле авылына кайттым. Казаннан.

— Ә... Ә безнең Алмазны кайдан беләсең соң?

— Урманда очраткан идем. Теге... теге... әтиегез үлгән көнне. Ул мине авылга кадәр озатып куйган иде.

Апага әллә нәрсә булды. Күзләре бер кысылды, бер зурайды, ул үз тирәсенә чүмәшкән бала-чаганы этеп җибәрде һәм Алмаз каршына килеп басты.

— Син... Атаң үлеп ятканда... Синең аркада үлде бит ул... Шушы шәһәр нәмәрсәсе белән... Әз генә иртәрәк кайтсаң да үлми иде бит атаң...

Апа акырды да акырды. Ишегалды тулы бала-чага, зәһәрләнеп, каш астыннан мине күзәтте, беркем бер сүз әйтә алмады. Алмаз да берни эндәшмәде. Ул, башын иеп, анасы кизәнеп-кизәнеп куйган саен, сискәнеп муенын җыерды, пычкы чүбе белән буталган пычрак җирдә таптанды. Ә ямьсез сүзләр очтылар да очтылар. Минем мондый сүзләрне беркайчан да ишеткәнем юк иде әле. Сүзләр артыннан утын пүләннәре оча башлады. Балалар, пырхылдашып, куркышып, кайсы лапас астына, кайсы баз, мунча артына качышып беттеләр. Алмаз гына урыныннан кузгалмады. Бер чи утын пүләне Алмазның аягына ук килеп тиде, таеп китеп, ул юеш җиргә егылды. Аннан, башын куллары белән каплады да, мышык-мышык елый башлады.

Мин каттым да калдым. Ни аягымны, ни кулымны кыймылдата алмыйм. Мин, беренче тапкыр, үсмер ир-баланың чарасыз булып, йөзен дөньядан яшереп үксеп елаганын күрәм. Аны һәм үземне кызганудан, рәхимсезлектән, хаксызлыктан минем үземнең дә кычкырып елыйсым килә. Ләкин мин елый да алмый идем! Утын пүләне аңа түгел, миңа тигән булса икән шул чакта.

— Бар, утырма монда җан көйдереп.— Әнисе Алмазга аяк очы белән тибеп узды, Алмаз, сикереп торып, бакча ягына таба йөгерде. Ул миңа күтәрелеп карарга да оялды ахры...

— Нәрсә басып каттың анда? Бар, бар, юлыңда бул. Синең кайгыңмыни бездә хәзер.— Ярсуы басылган ана инде хәзер үзе еларга җитешкән иде.— Биш бала белән утырып калдык бит менә. Өелешеп уты-

рып калдык... Син атаң-анаңа бер баладыр анда. Бетте Алмазның вәемсыз чаклары. Ата канаты астында яшәгән чаклары. Үзенә җигелеп тартырга хәзер. Бу ыбыр-чыбыр кызларда өмет юк. Алмазда инде бар ышаныч, Алмазда.

Үзе эле генә улын тотып кыйнады, үзе, бар ышаныч шуңарда, ди. Нәрсәгә кыйнады инде ул аны, нәрсәгә шундый әшәке сүзләр белән ачуланды? Урманда мине очраткан өченме?..

— Әле син һаман торасыңмыни терәлеп? Синең кайгылармыни бездә хәзер?.. Кая таралып бетте соң балалары да? Бу чи утын белән ничек кермәк кирәк кышларына да? И-и, бар икән күрәселәр...

Ул үзе сөйли, үзе көйли, үзе елый да бугай. Ул инде минем якка карамый да иде. Давыл узганын сизеп, качкан җирләреннән әкрен-әкрен генә кызлар да чыга башладылар. Алмаз гына күренмәде. Ул мин монда торганда чыкмас инде. Аякларымны пычрак җирдән кубарып алдым да, мин алардан чыгып киттем. Мин инде килгәндәге кебек йөгерә алмый идем. Мин хәтта юньләп атлый да алмый идем бугай. Мин, аякларымны көчкә сөйрәп, урамның нәкъ уртасыннан, пычракның нәкъ уртасыннан көч-хәл белән бардым да бардым. Бөтен тәнемне куырып алып, әллә кайдан салкын җил исә башлады. Ул юеш киемнәремне әле калтыранган тәнемә китереп сылады, әле изүемнән кереп, җилкән итеп кабартты. Мин шул хәтле арыган идем, шул хәтле тетрәнгән идем, менә шушы пычрак җиргә егыласым, эзләп табып алганчы, шунда бөгәрләнеп ятасым килде. Ләкин кем эзләсен мине? Әни китте инде ул бүген Казанга, аның кире борыла торган гадәте юк. Әбием бернәрсә дә белми, ул бит мине дә әни белән китте дип уйлый. Алмаз... Ә нигә мине Алмаз эзләргә тиеш әле? Аның үз кайгысы да баштан ашкан бит әнә. Эзләмәячәкләр, кызый, син егылма, бар да бар инде. Менә син бүген беренче тапкыр үз язмышыңны үзең хәл итәсең — егылыргамы сиңа, эзләп тапканнарын көтеп ятаргамы, әллә, үрмәләп булса да, алга барыргамы? Йөгереп тә булмый ичмасам, әзрәк җылыныр идем.

Менә елгага да килеп җиттем. Я хода! Мин моны ничек кичәрмен икән инде? Су кырыена барырга да куркам, актарылып, күбекләнеп агуын күрүгә үк тәнем чымырдап китте. Ә яңгыр һаман ява да ява. Елгадагы су да күзгә күренеп күтәрелә кебек. Менә хәзер инде үрмәләп тә барып булмый. Бу тирәдә күпер-фәлән барын да белмим. Ә безнең авыл, әнә, күренеп кенә тора. Мин хәтта үзебезнең йортны да күрәм кебек, ап-ак моржасын күрәм, өй эчендә әкрен генә кыштырдап йөрүче әбиемне күрәм. Юк, мин берни дә күрмим, мин инде елыйм, үзебезнең авыл ягына карап үкерә-үкерә елыйм. Кайвакытта тавышым үземә килеп ишетелә. Мин, тагы да өметсезләнеп, тагы да кызганычрак итеп еларга тотынам.

Яр буенда шулай күпме үкереп йөрер идем икән, яңгыр шавы аша кайсыныңдыр эндәшкәнен ишетәм.

— Син елама инде һаман... Тукта инде...

Алмаз бит бу! Ничек тапкан ул мине?!

Мин йөгереп яр өстенә менәм, ә үзем нигәдер Алмазга якын килергә куркам. Ул да минем янга килергә кыймый ахры. Мин телемә беренче килгән сорауны бирәм:

— Аягың бик авыртмадымы, Алмаз?

— Юк... Ялгыш кына таеп егылдым бит мин.

Тагын тик торабыз. Ялангач аякларыбыз белән яр балчыгын таптыйбыз. Тагы мин сүз башлыйм.

— Әтиең ничек үлде соң синең?

— Ул... ул... мин урманнан озак кайтмыйча торгач... мотоциклга утырып... Мине эзләргә барышы булган... Борылышта машина бәрдереп киткән...

— Үлгәнме?

— Сразы. Мин кайтканда шунда ята иде әле.

Мин, котым чыгып, шул мизгелне күз алдыма китерәм. Менә Алмаз, миннән аерылып, болын ягына йөгерә. Ул кичен безнең авылга уенга киләчәк. Кичкә кадәр инде күп калмады. Менә ул, өйләренә кайтып, киемнәрен генә алмаштырыр да... Авыллары инде күренеп тора. Ул ике арадагы чабылган болын буйлап йөгерә, күпернең (ул вакытта әле күпер китмәгән була) тар такталарын ике-өч кенә сикереп уза... Авылларына җитәрәк, олы юлга чыга торган борылышта, кара болыт кебек халык төркеме җыелып торганын күрә. Һәр адымы белән нинди зур кайгыга якынлашканын сизмичә, ул шул якка китә. Аны күреп, төркем тирәсендә чуалган берничә малай каршына йөгерәләр, берсеннән-берсе уздырып, «яңалык» җиткерергә ашыгалар.

— Синең атаңны машина бәрдереп киткән!

— Матаегызны челпәрәмә китергән!

— Матай нәрсә монда! Атасын да бетергән бит инде Алмазның.

— Сине эзләргә барышы булган бит аның.

Алмаз инде йөгерми, аны малайлар этеп диярлек алып баралар. Төркемдәге халык аңа шундук икегә ярылып юл бирә. Елый-елый шешенеп беткән әнкәсе, ап-ак кәфен кебек басып торган малае өстенә ташлана.

— Әниең... гел шулай кыйныймы сине?

— Юк инде... Нишләп кыйнасын. Әни әйбәт безнең. Кайгысына гына түзә алмый ул. Әлек ул гел көлеп кенә йөри иде әле.

Алмазның әнисен елмайган хәлдә күз алдына китерә алмыйм. Чәчләре яулык астыннан бүселеп чыккан, иреннәре зәһәрләнеп кысылган, таза гәүдәсе ярсудан дер-дер килә... Кулында чи утын агачы. Менә ул аны Алмазга тотып ата, Алмаз, җайсыз гына сикереп куя да, арты белән юеш җиргә барып төшә... Юк, мин аның әнисен елмайган хәлдә күз алдына китерә алмыйм.

— Әле... ничек кача алдың соң?

— Бакча башыннан чыгып йөгердем. Бүген тими инде ул. Соңыннан җәлли инде ул үзе дә...

Яңгыр һаман ява да ява. Елга һаман шулай котырынып, киреләнеп ага.

— Теге якка ничек чыгарбыз инде, Алмаз?

— Бераз арырак олы күпер бар. Син аны белмисеңмени?

— Юк.

— Килгәндә кайдан чыктың соң?

— Менә шушыннан.

— Монда басманың киткәненә әллә кайчан бит инде.

— Мин йөзеп чыктым.

Алмаз гаҗәпләнеп миңа карый. Ул мине белмәгәнгә шулай карый. Ә мине кем белә соң? Мине беркем дә белми. Кире диләр, җүләр диләр, хыялый диләр, кылана диләр. Ә мин менә шушылай, тилерә-тилерә, үҗәтләнә-үҗәтләнә, әле беркем дә, хәтта Алмаз да, хәтта үзем дә белмәгән дөньяга кереп барам. Суларга сикерә-сикерә, урманнарда адаша-адаша, болыннарда тәгәрәп елый-елый.

— Әйдә алайса, шул күперне эзләп барабыз.

— Монда гына ул. Әйдә, йөгердек. Сиңа суыктыр.

Без, яңгыр тамчыларын куа-куа, күпергә таба йөгерәбез. Бу күпер киң икән, аннан җитәкләшеп тә чыгып була икән. Аны яңгыр сулары гына алып китә алмыйдыр шул.

Алмазга болын ягына чыгып тормаска кушам. Ул менә шушы күпердә генә калсын. Болын ягына мин үзем генә чыгам. Мин хәзер юлны беләм инде.

— Киләсе җәйгә дә кайтасыңмы, Алсу?

— Мин җәй саен кайтам...
— Кайчанрак кайтасың?
— Болын әле чабылмаган була...

Яңгыр җиле, су җиле, минем соңгы сүзләремне эләктереп ала да, ике арадагы күпер өстендә әйләндерә. Аннан, өзек-өзек булып, үз сүзләрем үземне куып җитә: «Болын... әле... чабылмаган... була... чабылмаган... чабылмаган...»

Ләкин, икенче җәйдә дә, өченчесендә дә мин авылга кайта алмадым. Теге вакытта авылдан киткәндәге җүләрлекләрем, кыланышларым әнинең күңелен таш иткән иде. Шуның өстенә айлар буе үпкәм шешеп больницада ятулар да өстәлгән иде. Әни, үзенә хас үҗәтлек, ныклык белән: «Җитте! — диде.— Авыл сине боза,' кыргыйландыра, тәмам кулдан ычкындың,— диде.— Кеше арасында үз-үзеңне тота белмисең, элементар әдәп кагыйдәләрен үтәмисең. Син — җиткән кыз. Кеше алдында миңа синең өчен оят»,— диде.

Әнигә шактый кызарырга туры килә шул минем өчен. Мин кыш көне дә өйдә яланаяк йөрим. Әни янына еш кына телевидениедән (ул шунда режиссер булып эшли) дуслары килә. Алар югары культура, дөнья әдәбияты турында бик матур гына, зур дәрәҗәдә генә сөйләшеп утырганда... үз бүлмәмнән яланаяклап мин килеп чыгам. Әни кызара: «Гафу,— ди. Аннан әдәп белән генә миңа кисәтү ясап ала.— Җиткән кызга яланаяк йөрү килешми, кызым».

Кунаклар, сөйкемле генә елмаеп, миңа карап торалар. Аларның карашында мине кызгану да (кара инде, хәзерге заманда нинди кыргый бала!), шул ук вакытта миңа кызыгу да бар. Әллә аларның үзләренең яланаяк йөриселәре килмиме?! Бик килә! Оялалар гына алар! Бар хыялларын, теләкләрен аяк астына салып, әнә шул кадак үкчәле туфлиләренә бәйләп куйганнар. Ха-ха-ха! Мин, туфли үкчәсенә бәйләнгән хыялларны күз алдына китерәм дә, тыела алмыйча көлә башлыйм. Әни бу юлы янымнан үтеп барышлый гына татарча пышылдай: «Җитteme синa, юкмы, тиле нәрсә?!» Җитте, җитте! Миңа шул гына кирәк иде. Миңа сезнең үзегез булып уйнавыгыз кирәк иде. Гафу!

Зал яктан тагы матур гына, гөлдерәп кенә сөйләшә башлыйлар. Бу юлы сүз музыка турында бара. Алар, берсен-берсе әдәпле генә бүлдереп, «берничә сүз әйтергә рөхсәт итегез?» диган булып, музыка дөньясындагы экстра-яңалыкларны сөйләргә ашыгалар... «Сез беләсезме әле, Англиядә дискокампанияләрне шулерлыкта гаепләп, бик зур скандал чыккан». «Пугачева быел Казанга килүдән баш тарткан. Тамашачы ужасный бит бездә...» «Америкада төсле музыканың корсактагы балага тәэсирен өйрәнәләр икән. Бәлки бездә дә кызыксына башларга кирәктер?»

О, нәрсә генә белми,ниләр турында гына «хыялланмый» алар. Аннан музыка турында бу коры сөйләшү туйдыргач, сүздән көйгә күчәселәре килепме, пианино янына мине чакыралар. Әни: «Музыка мәктәбен отличнога тәмамлады»,— дип әйтеп куярга да онытмый.

Мин, яланаяклап, (принципиально кимим!), пианино янына килеп утырам. Аларга карамыйча гына, нәрсә уйныйм дим.

— О, Шопен!
— Бетховен!
— Штраус!

Ә мин тотам да... ә мин тотам да «Тәфтиләү»не уйный башлыйм. Нечкә бармакларым арасыннан үзәкләрне өзәрлек моңлы авазлар агылып чыгалар да, кадерле кунакларның гаҗәпләнгән салкын йөзләренә бәрелеп, аяк астына сибеләләр. Аннан, таш белән бастырып куйган

җанлы чишмә тибеше сыман, яңа моң, яңа авазлар сулкылдый башлый. Алар, бу бүлмәләрнең тарлыгыннан, бу кешеләрнең битарафлыгыннан качарга теләгәндәй, калын тәрәзә пыялаларына килеп капланалар, аларда тоткарланып, бераз зыңгылдап торалар да ачык форточкадан урамга, ак кар дөньясына ташланалар. Буран тавышы, җил тавышы белән кушылып, зур шәһәрне уята да сискәндерә дә алмыйча, салкын кыш кочагында калып җан бирәләр.

«Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңелем кошы...» Үзем уйныйм, үзем елыйм. Күз алдыма бәләкәй генә, ябык кына әбием килеп баса. Ничек сагындым мин аны! Ап-ак чәчле, ап-ак җанлы әбием! Минем авылга кайтасым килә! Минем әбием янына кайтасым килә. Узган җәйдә дә кайтармадылар, ике мәктәптә берьюлы имтихан бирәсең бар дип, әни кайтармас өчен мең төрле сәбәп тапты. Тугызны бетергән елда, бер генә айга дип, үзе белән Кырымга алып китте дә җәй буе шунда яттым. Мин ул тоташ диңгезгә, ул сап-сары, комлы пляжларга карый алмас хәлгә килдем. Минем күңелемә яңгыр кирәк иде, минем аякларыма бу ком түгел, яңгырдан юешләнгән урман юлы, чабылган булса да — болын, адаштырмаса да, урман кирәк иде! Ә ул мине җәй буе диңгез комына бәйләп тотты.

Үзем пианинода уйныйм, үземнең күз алдымда барысы бергә бутала — диңгезе, урманы, болыны...

— Бала арыган. Быел укуы бик каты шул.— Әни мине җайлап кына үз бүлмәмә кертеп җибәрә дә ишекне ябып куя. Буе биш адым, аркылысы дүрт адымлы бүлмәдә бер ялгызым калам. Бүлмәнең бер тәрәзәсе бар. Каршыдагы йортның соры стенасына чыга. Мин аның һәр кирпечен беләм инде. Башта ул ак төстә булган, хәзер инде ямьсезләнгән, сорыланган, кирпечләре ашалып-ашалып кергән урыннары да бар. Бу стена артында да кешеләр яшидер бәлки. Әнә шул стена каршында бәлки менә хәзер минем кебек үк бер кыз басып торадыр. Аның тәрәзәсеннән ни күренә икән? Әнә теге йортның стенасыдыр. Шулай дәвам итәдер, шәһәр беткәнче. Стена аша, стена аша, стена аша...

Быел инде унны бетерәм. Әни, чит телләр институтына керерсең, ди. Ул өйдә еш кына минем белән инглиз, француз телләрендә сөйләшә. Аннан русчага күчәбез, аннан тагы французчага, инглизчәгә. Минем кайвакытта туктыйсым, татарча гына: «Әни, арыдым бит!» диясем килә. Ләкин кая ул! Әни аның саен ныграк котырачак, текст ятлатып, тәрҗемә иттереп төне буе утыртачак. Кайвакытта минем бер телдә дә сөйләшәсем килми. Бер телдә дә! Телсез кешеләрдән көнләшә башлыйм. Бер генә көнгә, бер генә атнага булса да, телсез булып торасым килә. Ә вакыт төрле телләрдә, төрле әйтелешләрдә һаман минем аңымны даулый, аннан һаман әкренләп урманнарымны, болыннарымны кысрыклап чыгара бара. Алар урынына сүзләр, сүзләр, сүзләр генә кала.

Тәрәзәгә карасам, соры стенага килеп төртеләм, ишеккә барсам, кыланып көлгән, һаваланып сөйләшкән авазлар юлымны буа. Буйга — биш адым, аркылыга — дүрт адым... Аһ, чыгып йөгерер идем хәзер шушы тар зинданнан, дөньяның иркен җирләренә, иксез-чиксез җирләренә. Ап-ак кар дөньясына. Ул болыннар кыш көне, кар астында нинди булалар икән? Ә урман? Җәйләрем куак-чытырманлыклары белән сугышып үткән серле урман? Ә Алмаз?..

Алмаз бер якыная, бер ерагая... Бер якыная, бер ерагая... Карашында үпкә дә бар, көтү дә... Мин аңа, киләсе җәйгә кайтырмын, дигән идем бит. Ул җәй дә үтте, икенчесе дә... Ә бу җәйдә авылга кайтуларында бөтенләй дә уйлап булмый. Башта унны бетергәнгә имтиханнар тотасы бар, аннан институт. Институтка керсәң, җәйләрен тагы авыл кайгысы булмас. Хыялымдагы авыл, чәчәкле болын-урманнар һаман ерагая, алар белән бергә Алмаз да ерагая... Мин аны куып җи-

теп, туктатырга ашыгам, ә ул һаман шул урманнарга керә дә адаша, керә дә адаша. Карашында рәнҗеш, рәнҗеш...

«Хәзерге заманда мәхәббәткә бернәрсә дә комачау итми»,— дисәләр, ышанмагыз! Мин үземдә, белемем арта барган саен, хиснең, хыялның, мәхәббәтнең һаман арткарак чигенгәнен тоям. Инде минем тилерергә вакытым юк, инде мин әкиятләрдәге пәри малайларына ышанмыйм, инде мин үземнең җир малае — Алмаздан да һаман ерагая барганымны тоям. Тоям — туктата алмыйм. Вакыт, үзенең ярсу вакыйгалары, исбатланган һәм исбатланасы мәсьәләләре, кагыйдәләре, телләре белән минем аңыма ябырыла. Мин, бөек бер акыл иясе булам дип йөргән, шуларның барысын да зиһенемә сеңдерә барган заман баласы. Вакыт каршында үземне мескен, изелгән бер нокта итеп кенә тоя башлыйм. Миндә хәзер җансыз чәчәкләргә җанлы итеп карау түгел, җанлы кешеләргә җансыз итеп карау үзенчәлеге үсә бара кебек. Мин дә — автомат, алар да — автомат. Җыябыз, җыябыз да ул белемне, шуңа таянып, болыннарны юк итәбез, матурлыкны, җанны юк итәбез. Алар урынына ясалма болыннар, ясалма җаннар уйлап табабыз.

Хәзер мин төштә генә үзем балачакта күргән нәрсәләр белән юанам. Минем төшләремдә гел авыл була, мин гел яшел болын буйлап йөгерәм, һәр иртәдә мине, күпер уртасына басып, Алмаз озатып кала... Бу шул чаклы гади, шул чаклы самими төшләр була, иртә белән уянгач, миңа бу кырыс чынбарлык дөньясына кайту куркыныч төсле тоела башлый.

Ә үзем мин «биш»кә генә укыйм. Ун ел инде, «биш»кә генә укыйм. Акылым теоремалар, физик күренешләр, тарихи вакыйгалар белән шыплап тулган. Башымның кайсы гына өлешенә кул тидерсәң дә, аннан тарихи шәхесләр, молекулалар, квадратлар, өчпочмаклар сикереп төшәрләр кебек. Шуларның авырлыгыннан башым зыңлап тора. Алар өстенә инглиз, француз телләре... Музыка... Тап-тар бүлмә, буе — биш адым, аркылысы дүрт адым...

Мин инде бу буразнадан чыга алмыйм. Минем аннан инде чыгасым да килми. Чөнки аннан чыксам, мин адашырмын кебек, күпләр адашкан төсле, я кибет тирәсенә, я төнге маҗараларга барып чыгармын сыман...

Миңа уналты яшь. Мин үземдә зирәк аксакаллар акылы сизәм. Ә хис — юк. Бәлки киресенчә кирәктер минем яшьтә? Бәлки җүләрләнеп, берәрсенә гашыйк булыргадыр? Әнә бит безнең класста кызлар бер-берсе белән сугышуга хәтле барып җитәләр малайлар өчен. Хәзер малайлар өчен кызлар сугыша бит. Әле малайлары нинди диген? Бер фикерсез дистрофиклар. Алар өчен сугышырлык та түгел. Миңа аларның берсе дә ошамый. Мине дә беркем яратмый. Кичәләрдә биергә дә чакырмыйлар. Үземә ишетелерлек итеп: «Круглая отличница»,— диләр, артымда: «Круглая дура»,— дип хихылдашалар. Ә миңа барыбер. Миңа шулкадәр барыбер — мин, аларны яратмаган кебек, аларга нәфрәтләнә дә алмыйм. Минем җаным, чабылган чәчәкләрне кызганып еларлык нечкә, үкереп аккан суларга сикерә алырлык көчле җаным — бу салкын дөньядан, бу кешеләрдән мең кат стена артында, мең кат стена артында! Аның аша санаулы кешеләр генә керә ала минем җаныма. Шуларның берсе — Алмаз. Мин аны җаныма бикләдем дә, шуннан чыгара да алмыйм, калдырырга да көчем җитмәс кебек. Бәлки ул анда калырга үзе үк теләмәс. Ул хәзер моннан ике ел элек күргән малай түгелдер инде, аның үз күңеле бардыр, ул күңелнең үз тәртипләре, үз аллалары бардыр. Кагылып карарга иде шул күңелгә, күрергә иде инде ничә еллар төшләремдә үземне җитәкләп йөргән Сарылы егетен. Салып ташларга иде аң-зиһен кабыгын, сизелер-сизелмәс сулкылдап яткан хисләрне ычкындырырга иде бәйдән... Тугарылсыннар иде, йөгерсеннәр иде,

җуләрләнсеннәр иде... Күгәргәнче, катып бозга әйләнгәнче, тилереп калсыннар иде.

Хәзер мин чыгам да...

Юк, мин башта киенәм. Нык итеп, җылы итеп. Хәзер мин чыгам да...

— Кая барасың, Аллочка? — Әни матур гына итеп, француз телендә миннән сорап куя.

— Мин киттем, әни. Авылга.

— Син нәрсә?! Кыш уртасында — авылга?! Ике аягыңның берсен дә атламыйсың.

Боларын инде әни татарча гына кычкыра. Мине ачуланганда ул, үзе дә сизмәстән, гел татарчага күчә. Кунакларның күбесе, татарча белмәсәләр дә, әнинең кычкыруыннан нәрсәдер сизенәләр (кычкыру — кайсы телдә дә кычкырудыр инде ул), сораулы карашларын миңа төбәгәннәр.

— Мин авылга кайтам. Син кычкырма да, борчылма да.

Әни минем киреләкне белә. Мин әле озак кына уйлап йөри алам, бер карарга килә алмый интегәм, инде бер карарга килдемме — бетте. Мине берни тота алмый. Иң мөһиме — мин үз-үземне тота алмыйм. Мин, тарттырып, кысып тоткан нерв җепләрен ычкындырып җибәрәм дә, үзем дигәнчә барам да барам... барам да барам... Барып бәрелгәнче.

— Юлга акчаң бармы соң хет?

— Бар.

— Ниләр күрер инде синең белән бу башларым? Ни теләсәң, шуны кыланасың бит. Әле хәзердән шулай, тора-бара нәрсә булыр?

Ул, зарлана-зарлана, мине ишеккә кадәр озата бара. Мин, тар бүлмәмнән, ясалма әдәплелекләрдән, ясалма елмаюлардан, ясалма тормыштан котылуыма мең сөенеп, ак кар дөньясына катнашып эрим, юкка чыгам, очам, бөтереләм, бөтереләм... Тәрәзәдән әнинең борчылырга тырышып кырысланган матур йөзе күренеп ала. Борчылмыйсың бит син, әнием, борчылмыйсың! Без бит синең белән икебез ике дөньяда яшибез, икебез ике юлдан йөгерәбез. Син, замананнан калышмаска теләп, оригинальный булырга тырышып, һаман танылган кешеләр тирәсендә мәж киләсең, әдәбият-сәнгать өлкәсендә барган бәхәсләрдә үз фикереңбелән ялтырыйсың. Ә яныңда гына бәргәләнгән мине — үз кызыңны — мең юл чатында басып торып та, үз юлын таба алмыйча адашып йөргән кызыңны күрмисең. Минем дөньям синең өчен бикле. Ул сезнең барыгыз өчен дә бикле! Аңа санаулы гына кешеләр керә ала. Һәм ул кешеләрне мин үзем сайлап алам! Үзем, үзем, үзем!!!

Район үзәгенә кадәр башта автобус белән кайттым, анда кайтканда ук үзебезнең Күлле авылы кешеләре белән таныштым. Дөресрәге, алар мине үзләре эзләп таптылар. Күллегә кайтуымны белгәч, кемгә дә кемгә дип бер гаҗәпләнсәләр, Рәйханә әбиләргә кайтам дигәч, икенче тапкыр аптырашта калдылар... «Кыш көне түгел, җәйләрен дә Рәйханә әбиләргә хәзер беркем кайтмый бит»,— дип, ярты юлга кадәр шушы хакта сүз куерттылар. Таныйлар микән алар мине — чабылган болын чәчәкләрен кызганып елаган, һәр җәйне урманнарга барып, адаша торган бер җүләр кызны? Мөгаен, төсмерләгәннәрдер инде. Әдәп йөзеннән генә төпченмиләрдер. Монысы өчен дә рәхмәт аларга.

Аларның очравы минем өчен бик җайлы булып чыкты. Район үзәгенә килеп җитүгә, мине дә үзләре белән ияртеп, алар авыл башына таба ашыктылар. Мин, биткә бәреп яуган кардан башымны күтәрә алмыйча, аларга ышыкланыбрак, артларыннан калмыйча бардым да бардым. Ул арада кичке караңгылык уртасыннан, ялт итеп, көчле ут яктысы сузылды. Кар бөртекләре сөенешеп, шушы көч каршында сихерләнгәндәй, ду килеп биешә башладылар. Агайлар, апайлар да шатланышып, трактор, трактор килә, дип шаулаштылар. Кайсы кулындагы төенчеген, кайсы биәләен салып, якынлашып килүче шул ут каршында болгады.

Трактор безнең турыга житте дә моторын сүндерми генә туктап калды. Апайлар-агайлар кабина тирәсен сырып алдылар, кайберләре сумкабиштәрен трактор чанасына ыргыта ук башлады. Аннан үзләре дә төялешү ягын карадылар. Мин дә алар тирәсенә елыштым...

— Син, сеңелем, кабинага керерсең. Өстендә дә бик юка, өшүең бар бу салкында.

Кабинага икән — кабинага. Әллә нинди дерелдәп торган тимерләргә абына-сөртенә, кабинага кереп тә утырам. Кара, монда нинди жылы икән. Бераз караңгырак кына караңгысын. Ә барыбер рәхәт. Менә трактор кузгалып та китте бугай. Әкрен генә калтырап без тылсымлы корабта йөзәбез кебек... Менә ул кораб безнең болыныбызга килеп туктый, үзе шунда ук жәй икән, тирә-якта ап-ак кар түгел, ап-ак чәчәкләр шулай жемелдәшә икән. Мин шул чәчәкләр арасыннан йөгерәм. Әллә каян гына Алмаз да килеп чыга, ул да миңа кушылып йөгерә башлый, аннан кинәт кенә миннән аерыла да, үз авылларына таба китеп бара. Мин аны туктатырга телим, бар көчемә: «Алмаз, Алмаз!» — дип кычкырам. Ул, әллә нинди ят, өлкән тавыш белән, «Нәрсә кирәк сезгә?» — ди. Мин тагы нидер әйтмәкче булам, башым шап итеп ниндидер каты әйбергә килеп бәрелә дә... сискәнеп уянып китәм.

— Тотынып утырырга кирәк, апасы.

Әле мин һаман төш күрәммени? Нигә төштәге тавыш миңа эндәшә?

— Сез мине каян беләсез?

«Мин — сезне? Юк, мин сезне белмим. Мин сезне күрмим дә бит бу караңгыда.»

— Исемем белән дәшкәч, әллә беләсезме дигән идем.

— ... Төштә бит ул... Ул — икенче кеше. Сез дә Алмазмыни?

— Әйе.

— Күлленекеме?

— Юк, Сарылыныкы мин. Күлле аша үтеп кенә йөрим.

Әллә трактор дерелди, әллә минем йөрәгем. Әллә башым бәрелеп уяндым мин, әллә һаман төш күрәм. Тик күзләремне ачарга куркам. Нигәдер, куркам.

— Нигә сезнең биредә шулай караңгы?

— Хәзер яктыртабыз аны, апасы.

Ходаем, ник әйттем. Хәзер бит күзне ачасы була, ачасы да...

Ул нәрсәләрнедер шатыр-шотыр китереп бора, күземне, зиһенемне, үткәннәремне ярып, кыш уртасында, трактор кабинасында ут кабына. Керфекләрем башта сискәнеп бер-берләренә ныграк сыеналар, аннан, озак йомылып торуга түзә алмыйча, әкрен генә ачылалар.

Трактор руле артында, өстенә жылы сырма кигән, бит-куллары әллә салкын жилдән, әллә трактор маеннан ялтырап каралган, кырысланган, олыгайган Алмаз утыра. Ул да мине таныды ахрысы, трактор кинәт кыр уртасында дөп итеп туктап калды. Без икебез дә мондый очрашуны көтмәгән идек, без икебез дә аңа әзер түгел идек. Без ничә еллар буе бер-беребезнең хыялларында, төшләрендә генә яшәдек, менә без хәзер янәшә генә, инде барысы да чын, табигый иде, ләкин артык табигый, артык чын иде. Без янәшә дә идек, ләкин бер-беребездән сүзләр дә, хәрәкәтләр дә барып житә алмаслык дәрәжәдә ерак та идек...

Чанадагылар кабина түбәсен төя башладылар. Тракторның моторы да сүнгән икән, ул, салкын кышкы төндә, кыр уртасында, сүнгән моторы белән, япа-ялгыз каралып, кызганыч хәлдә, ярдәмчесез хәлдә туктап калган иде. Алмаз нәрсәләрнедер боргалады, шырпы сызып карады, аннан, кабина ишеген ачып, төн караңгылыгына сикерде. Урамнан шундук салкын жил бәреп керде, ир-атларның борчулы авазлары ишетелде. Мин урынымнан кузгалмадым. Кузгалып та нишли ала идем инде мин?

Мин беренче тапкыр үземне көчсез итеп, фикерсез итеп, киреаксез итеп тойдым.

Ир-атлар трактор тирәсендә озак кайнаштылар. Әле берсе, әле икенчесе кабинага кереп кабызып та карадылар. Аннан кар-буран эченнән Алмаз үзе килеп керде. Нәрсәләргәдер җан көче белән бастымы, нәрсәләрнедер җан көче белән бордымы — трактор башта яман итеп, үзәк өзгеч итеп кычкыртып җибәрде, аннан бер-ике тапкыр шулай сулкылдап куйды да, тыныч кына гүләргә тотынды. Кабина тирәсендә таптанган ир-ат шыбырдашып яңадан арбага төялде. Трактор тагы әкрен генә кузгалып китте...

Без башка берни дә сөйләшмәдек. Без икебез дә сөйләшергә курка идек бугай. Ул мине әбиләр каршында төшереп калдырды, башкалар да шушында коелыштылар. Алар төшеп бетүгә, ул тракторын тагы ачы итеп бер кычкыртып алды да, Сарылы ягына таба кузгалып китте...

Менә шулай итеп мин, үз гомеремдә беренче тапкыр, кыш уртасында авылга кайтып төштем. Әбиемнең, мине күргәч, өне калмады. Башта ул берниңди хәл дә булмаганына ышанмады, ышангач, минем тиктомалдан шулай кайтып төшүемә ышана алмады. Аннары минем мин булуыма ышанмады! Ялгыз бәләкәй әбием минем! Ничек арыгансың син көтә-көтә. Көтеп-көтеп тә саргайганда кайтмагач, инде менә хәзер, көтмәгәндә, төн уртасында, кыш уртасында кайтып кергәч, син инде ышана да алмыйсың. Бу мин, синең оныгың! Әле үз-үзен тапмаган, ләкин һичшиксез табачак, әле үз юлын белмәгән, ләкин һичшиксез беләчәк киребеткән оныгың!

Ә авыл! Ә болын! Ә урман?!

Я хода! Мин шушы яшемә кадәр бу кышкы матурлыкны күрмичә ничек яши алдым икән?! Ә хәзер тотмагыз мине, туңасың бит дип тә, өшерсең дип тә әйтмәгез. Әбием, алайса бир миңа киез итекләреңне, бир үзең бәйләгән җылы мамык бияләйләреңне, бир бабамнан калган теге иске туныңны! Мин хәзер кырларга китәм, урман, болыныма китәм! Ки-и-тә-м!!!

Тун чабуларыма урала-урала, юлсыз җирдә юл салып билдән карга бата-чума, баткан саен, очарга талпынган кош кебек, кулларымны җилпеп көлә-көлә, ап-ак кар булып, болын ягына таба тәгәрим. Ә болын һаман юк та юк. Минем үзен эзләгәнне сизенеп, болыным һаман ераккарак кача, мине һаман ераккарак ымсындыра кебек. Карда әвәләнә-әвәләнә, ниндидер чыбыклар янына килеп чыктым. Башта мин аларны әллә юри шулай утыртып чыктылармы икән дип уйлаган идем, бер-икесен тартып карап та чыкмагач, аларның шушында тамырланып үсүләрен аңладым. Соң, бу бит... бу әрәмә бит! Болын буендагы әрәмә. Аның әнә теге кырыенда әле яшьләр уен уйныйлар иде. Әле менә бу тирәдә бөрлегәнлек тә булырга тиеш. Мин, болынга төшкәч, ничә тапкыр кереп ашап чыкканым бар ул тәмле җиләкләрне. Әрәмә хәзер кар астында калган, шуңа күрә аны танып та булмый икән. Димәк, минем болыным да шушында була бит инде! Димәк, мин аның өстеннән шулай бата-бата йөзеп узганмын!..

Бөтен болын ап-ак кар астында. Тигез түгел, әллә нинди дулкын-дулкын булып яткан кар каплап киткән болынны. Җил уйнавы шундый хәлгә кертеп калдыргандыр инде аны. Үзе турында истәлек калдыру өчен. Ә тегесе, ап-ак күңелен ачкан да, җил малаена тулы ирек биргән — ни теләсәң, шуны яз. Ә җил дулкын-дулкын, дулкын-дулкын... Аның ак күңеленә кагылудан бер тетрәп китеп, дулкынланып елагандыр, бер бу күңелнең артык салкынлыгын, артык аклыгын, артык серлелеген, тиң түгеллеген тоеп, үкереп күкләргә ашкандыр. Аннары тагы төшкәндер ул болынына, җәйге көннәрнең кайнарлыгын, кичләренең наз тулы аулаклыгын исенә төшерергә тырышып, әрәмә куакларын

да шаһитлыкка чакырып, өздереп-өздереп сызгыргандыр. Барыбер уятырмын, барыбер бу салкын матурлыкны буйсындырырмын дип өметләнеп, кыш буе болын өстендә бөтерелгәндер. Ләкин болынга уяныр өчен иң якты кояш кирәклеген, иң шашкан, иң ташулы яз кирәклеген ул аңларга теләмәгәндер, беркатлы җил малае!

Ике арадагы елгадан соң болын бетә. Болын безнең якта гына. Елганың теге ягында бераз көтүлек җирләре, аннан Сарылы авылы башлана. Анда — Алмаз. Әле теге вакытта ул басып калган күпер дә моннан ерак түгелдер. Аны да кар күмде микән? Әллә барып карыйм микән? Юк, бармыйм, хыялымда ул, котырып аккан су өстендә, ике як ярны тоташтырып торган бердәнбер ныклы урын булып торып калсын. Шулай калсын. Хыялымда гына булса да, кар күммәсен аны, җимерелмәсен... Хыялымда гына булса да...

Ә нигә мин кичә Алмаз белән берни дә сөйләшә алмадым? Ничә еллар буе идеаллаштырып, табынып, беркем белән алмаштырмыйча төшләремдә яшереп яшәттем дә, үзе белән очрашкач, куркып, күзләремне йомдым. Тагы шул хыял дөньясына, төш дөньясына, төшләремдәге Алмаз янына кайтасым килде. Алар икесе ике кеше иде. Әллә миңа гына шулай тоелдымы? Миңа Алмазны күрмичә, аның белән аңлашмыйча, кире шәһәргә китәргә ярамый. Ул соры стеналар дөньясында төшләремдәге Алмаз да булмаса, бу бушлыкны ни тутырыр, яшьлек дигән чәчәкле болында мин кемнәрнең тезләренә башымны салырмын, кем минем яшьле күзләремне иелеп үбәр дә, кем мине, кулларына күтәреп, дөньядагы иң матур, иң изге сүзләрне әйтеп, алласы урынына күреп, миңа табыныр? Кем?!

Кич. Җил малае аркамнан этә. «Бар кайт инде, ди, калдыр инде мине болыным белән ялгыз гына»,— ди. Нигәдер, туңып китәм. Әллә куркам да инде? Әнә авыл ягында сүрән генә утлар җемелдәшә. Әбием борчыладыр инде. Аһ, әбием, күпме уй-хәсрәт өстимдер мин синең чал башкайларыңа! Дөньяда иң-иң яхшы, иң-иң изге кешем!..

Итек асларымны шыкыр-шыкыр китереп, тун табуыма ябышып каткан кар-буранны өстерәп, җылы, якты өйгә кайтып егылам. Әбием, йомшак кына әрли-әрли, минем шакыраеп каткан киез итекләремне салдыра, аякларыма тизрәк мич башыннан алып җылы, йомшак, ап-ак йон оекбашлар кидерә. Авыр тунымны салдырып, җилкәмә мамык шәлен сала, кулларымны, битләремне каз мае белән уа. Башта мин авыртудан, аннан җаныма иңгән рәхәтлектән, үземне шулкадәр яратып, кызганып, җанын ярып бирерлек булып яшәүче кеше барлыгын тоюдан, шуның рәхәтлегеннән елыйм. Нигә әнием дә мине шулай итеп яратмый икән? Аның бит мине иркәләү, назлау түгел, сөйләшеп утырырга да вакыты юк. Кайтасың — записка, китәсең — записка. Без аның белән уч төбе кадәр кәгазь аша гына аңлашабыз: «Мин киттем. Нәрсә булса да аша». «Мин бүген соң кайтам. Мине көтмә, йокла». Ә кемне көтим мин, аны да көтмәгәч, кем белән сөйләшим мин, аның белән дә сөйләшмәгәч?

Ә әбием миңа бер дә аңа охшамаган бит. Аның әнисе бит инде югыйсә. «Бик иртә кулдан китте шул,— ди әби әнинең холкын сизеп, уфтанып.— Бер үзе шәһәргә чыгып китте, ундүрт яшеннән. Бәрелде, сугылды — авылга барыбер кайтмады, тирес арасында черисем юк, диде. Ырды-ерды, тәки үзенекен итте. Укырына да керде, эшнең дә яхшысына урнашты, тик миңа ирдән генә уңмады, тыныша алмадылар атаң белән. Синең яшь тә тулмаган иде, аерылыштылар. Гел берүзенә булды шул тормыш, гел берүзенә. Шуңа күрәдер, холкы да үзгәрде, тоткан җирендә сындыра инде, бер дә икеләнүне белми, уйлануны белми. Кечкенә чагында йомшак кына бер бала иде бит югыйсә...»

Миңа шул тоткан җирендә сындыра торган әнием мине дә сындырды

бугай инде. Яки сындырырга җыенамы? Мин бит агач түгел, мин — кеше, минем мең сорауга җавап эзләп тыпырчына торган тере җаным бар, минем әллә нинди, кешедә юк борчуларым бар. Ә шуларны уртаклашыр кешем — юк...

Әбием бүген әллә нинди тәмле бәлешләр, өчпочмаклар пешергән. Өстәлдә зур самавыр чыжлап утыра. Өйдә шундый җылы, рәхәт. Әбинең ризыклары шундый тәмле. Бер дә кулинарныйда пешкән пирогларга охшамаган. Әби аларны, мин кайтканчы дип, тастымалларга төреп, эссесен дә суытмый саклаган. Әби белән кара-каршы утырып чәй эчәбез. Мин, әби белән сөйләшә-сөйләшә, яртылаш кар күмгән тәрәзәгә күз салып алам. Һәм... кулымнан чынаягым төшеп китә яза. Әби дә минем куркып, агарынып киткәнемне сизә, күз кырые белән генә тәрәзәгә карап ала.

— Әби, анда кемдер йөри кебек,— дим мин, яңадан ул якка карарга куркып.

— Песи-мазардыр, кызым. Я эт-фәләндер.

Тәрәзәдән читкәрәк китеп утырам. Һаман кемдер шыгыр-шыгыр итеп йөргән кебек. Әллә бүреме икән? Монда кыш көне бүреләр капка төбенә хәтле килә дип сөйлиләр.

— Әби, әллә бүреме икән?

— Быел күренмиләр әле бүреләр. Булса да, тәрәзәдән кереп, тотып ашамаслар. Бүре үзе курка хәзер кешедән.

Ул арада кемдер шык-шык итеп ишек кага башлады. Әби, өстенә иске бишмәтен элде дә, күрше-фәләндер дип, өйалдына чыгып китте. Бераздан әби йөткерenә-йөткерenә кире керде.

— Кызым, сине сорыйлар анда.

Мин аптырап киттем. Мине?! Мине бит монда беркем дә белми. Аннан, мин караңгы өйалдына чыгарга да куркам әле... Әйдә дә әйдә, дип, әбигә ялына башладым. Әбием әллә нәрсәсенә киреләнде дә куйды (анда да минем холык бар шул), бар, бар, кешене көттереп торма, дип, җилкәмә үзенең бишмәтен салып, мине өйалдына чыгарып җибәрде.

Өйалдында караңгы иде, дөбердәп, әллә нәрсәләргә килеп бәрелдем, капшана-капшана өйалды ишеген ачып җибәрдем. Ап-ак кар яктысында, йорт стенасына сөялебрәк басып торган Алмазны күргәч, әллә курыктым, әллә сөендем... Мин аны көткән дә, көтмәгән дә идем. Без танышлар да, ятлар да идек. Ләкин аны монда, ишек төбендә дә тотып булмый иде, бу әдәпсезлек булыр иде. Мин аны өйгә чакырдым. Ләкин Алмазның анда керәсе килмәде, мин башка сөйләшер сүз таба алмадым. Җиңелчә генә киенеп чыкканлыктан, туңа да башладым.

— Миңа суык. Өйгә керергә кирәк.

— Әзрәк торыйк инде. Бар, җылырак киенеп чык.

Ләкин минем монда торасым да, җылырак киенеп чыгасым да килми. Минем тизрәк җылы өйгә, әбием янына керәсем килә.

— Әйдә, үзең безгә кер. Әбием бик тәмле бәлеш пешергән.

— Бәлеш өйдә дә бар ул анисы. Әни бүген көне буе мич янында кайнашты.

Әни диюгә, зиһенемне сызып, коеп яуган яңгырлы көн, пычрак ишегалды, чәчләре бөселеп чыккан, авызлары кыйшайган таза бер хатын, утын пүләннәре арасында башын тотып елап утырган яшүсмер малай күз алдыннан йөгереп узды. Мин күтәрелеп Алмазга карадым, теге вакытта әйтә алмаган юату хисе, яклашу теләге күңелемә килеп төялде; мин Алмазны кулыннан җитәкләдем дә, тиз генә караңгы өйалды аша узып, өйгә, әбием янына алып кердем.

— Кунак кызы килгәнне егетләр дә сизгәннәр икән, кыз күзләргә килгәннәр икән.— Әбием кет-кет көлә, үзе яшәреп киткән, эчендәге әллә нинди сөенечләре нур булып йөзен балкыта.

— Әби, Алмаз бит бу.
— Кайсы Алмаз икән соң, балам?
— Сарылыныкы ул. Теге вакытта әтисен машина бәрдергән Алмаз.
Үтергән дип әйтергә телем бармады. Әби дә җитдиләнеп китте. «Әй, балакай!» — дия-дия, шап-шоп итеп аркасыннан сөеп, Алмазны чәй янына утыртты, аннан, минем турыда да онытып, җентекләп аның өй хәлләрен сораштыра башлады.
— Анаң ничек соң? Кыз туганнарың?
— Әни мәктәптә җыештыручы булып эшли. Сеңелкәшләр барысы да укыйлар.
— Үзең эшлисеңме, укыйсыңмы соң?
— Эшлим инде мин, әби. Бер әнигә генә авыр бит.
— Шулай булмый ни, балам, шулай булмый ни... Кайда эшлисең соң?
— Тракторчы мин.
— Һөнәрең бик пачутлы икән. Яшь кенә булсаң да, анаңа терәк бит әле менә.
— Армиягә киткәнче булса да, эшли торыйм дидем инде.
— Эштән кеше үлми, балам. Син хәзер өйдә глауный хәзәин бит анда. Синдә — өйнең тоткасы...

Әбием, үз җаена, мedeр-мedeр сөйләнә-сөйләнә, өстәл өстендә күренгән ипи валчыкларын чүпләп җыя башлады, бөртеген дә калдырмый җыеп бетергәч, уч төбенә алып, аларны тешсез авызына озатты. Ул бервакытта да өстәлдәге ризык валчыгын сыпырып чүп чиләгенә илтеп салмый, тастымал астында башланмаган түгәрәк ипиләре өелеп торса да, ул өстәл өстендәге валчыкларны чүпләп каба. Минем бәләкәй әбием моны шулкадәр якты бер тынычлык белән, тантана белән эшли, без тып-тын калып, борынгылар аллага табынгандай, аңа карап торабыз. Аннан әбием, җыерчыклар белән челтәрләнгән, үтә күренмәле булып юкарган кечкенә кулларын бит турына китерә дә, күзләрен йома төшеп, иреннәрен лепер-лепер китереп, озак кына итеп дога укый. Өстәленнән ризыгын өзмәгән өчен, кешеләрне рәхим-шәфкатеннән ташламаганы өчен, адәм балаларына моннан соң да яхшы ниятләрдә торуын теләп, үзенә генә билгеле булган алласына багышлап озак итеп дога кыла да, мин дә шуңа кушылам, дигән кебек, кулларын битләре өстеннән шудырып уза. Аннан дөньялардан ваз кичкәндәй, бер тын оеп кына, хәрәкәтсез генә утыра. Моңлы гына итеп, и дөньялар, дип әйтеп куя. Бу мизгелләрдә анда ике дөнья — серле дә, шомлы да, котылгысыз да булган теге дөнья, авыр да, якты да, кыска да булган бу дөнья очрашкан кебек. Алар бер мизгелдә шушы кечкенә генә карчыкның юка гәүдәсе аша үтәләр дә, моң булып, аның күзләрендә эленеп торалар, уфтану булып, тавышында калтыранып куялар...

Әбием, әкрен генә урыныннан кузгала да, каба-җебен алып, агач урындыкка килеп утыра. Орчыгын ипле генә итеп, зырылдатып кына бөтерә-бөтерә, башын бераз кыңгыр салып, гәүдәсен төз тотып, җеп эрләргә тотына. Аның орчыгына хәтле моңлы булып, әбиемнең җанын аңлагандай, чәчәкле алъяпкыч япкан тез өсләрендә үз җае белән генә бөтерелә дә бөтерелә. Кабадагы йон да бер дә бетмәс кебек, агач орчык та бөтерелүеннән һич туктамас кебек, әбием дә шушы каба артында мәңге җеп эрләп утырыр кебек...

Алмазга күңелсез ахры, ул, башын читкә борып, берничә тапкыр авызын ачып иснәнеп тә алды. Безнең арада һаман сүз ялганып китә алмый. Әллә нәрсәләр сөйләрмен, әллә нәрсәләр киңәшермен, аңа гына, бары аңа гына әле беркемгә дә әйтелмәгән сүзләремне әйтермен дип кайткан идем. Каршымда әллә нинди чит кеше утыра кебек. Алмаз да кебек, түгел дә. Исеме шул, күзләре, чәчләре дә элеккеге Алмазныкы

бугай әле, әмнә күңеле, уйлары, хыяллары — мин белгән Алмазныкы түгел кебек. Тукта, нинди син белгән Алмаз ул? Син аны ни дәрәҗәдә белә идең соң? Я, син аны ничә тапкыр күрдең? Ике. Берсе — урман юлында, икенчесе, яңгыр яуган көнне, су буенда. Калганын, идеалга әйләндереп, шушы кеше рәвешендә син үзең тудырдың. Үзең ничек күрергә телисең, күңелеңдә әнә шундый образ тудырдың. Тормыштагы үзең белгән бөтен яхшы сыйфатларны, гади кешеләрнең кулыннан килмәгән бөтен бөеклекләрне, фанатикларча инану белән, син шушы кеше тирәсенә җыйдың. Менә хәзер, кайтып үзе белән очрашкач, күңелеңдәге бөеклек җирдәге артык гадилек, артык гадәтилек белән уртак сүз таба алмагач, бер-берсен танымагач, диванның икебез ике башында тын гына утырабыз. Алмазның йокысы килә, туктаусыз иснәнә, ә минем уянасым, үз саташуларымнан, үз хыялларымнан уянасым килми. Ул минем төшләремдә җанлырак иде, ул минем хыялларымда җүләррәк иде, ул минем саташуларымда назлырак иде...

Агач орчык бөтерелә дә бөтерелә. Аның зырылдаган көенә Алмаз калгып-калгып куя. Урамда буран күтәрелә ахры, җил тәрәзә артында нәрсәнедер шакы-шокы китерә, аннан, көйли-көйли сузып, әллә нинди үкенечле тавыш белән, бик югары тональностьта сызгырып тора. Шул югарылыгында кисәк кенә өзелә дә, җаннарыгызны уята алмадым инде, дигән кебек, инде бастырылып кына, офтанып кына, әрнеп кенә сулкылдап ала.

Җил тавышы Алмазны бөтенләй баса. Ул, авырлык белән генә урыныннан кузгала да, камыр булган аякларын көч-хәл белән җыеп, ишеккә таба кузгала.

— Буран чыга ахры, мин кайтыйм инде,— ди беркемгә дә карамыйча гына.— Иртәгә иртүк станцага комбикормага да менәсе бар.

— Ярар, улым, ярар, үзең беләсеңдер.— Әби дә каба төбеннән кузгала. Оеп киткән аякларына ава-түнә басып, Алмазны ишеккә хәтле озата бара.— Тагы кил, улым. Алсуга да күңеллерәк булыр бергә-бергә.

Алмаз чыгып киткәч тә әбием берни сорашмый. Тик, үзалдына гына сөйләнгәндәй, миңа да ишетелерлек итеп, урын җәйгән арада һаман әйткәләп куя.

— Бик тә инсафлы бала күренә,— ди.— Хәтимәнең бер яктан бәхете булмаса, икенче яктан ходай бәхетне кызганмаган,— ди.— Малае бик җүнле күренә,— ди.

Үзе, каз мамыгыннан гына торган түшәк-ястыкларны күтәреп ала да, кат-кат итеп, мин ятасы караватны түши. Ул минем яраткан урынымны белә — олы якка, мич белән стена арасындагы караватка җәя урынны. Түшәк-ястыклар тау кадәр булып өелгәч, әбиемнең буе да җитми башлый, кардай ак җәймәне мамык тавы өстенә мин үзем җәям. Озын ак күлмәгемне киям дә, күзләремне йомып, йомшак урынга чумам. Әбием минем өстемә мамык юрганын яба, аннан шау чәчәкләр сибелгән чаршауны тарттырып куя да, нинди догалар укып чәч-башларымны сыпырып, утны сүндереп, үзе кече якка чыгып китә. Мин, көнчыгыш әкиятләрендәге хан кызлары кебек, биек, йомшак урында, чаршаулар арасында әллә нинди серле дөнья рәхәтлегендә калам. Бер ягымда — әле кичтән генә ягылган, әсселе дә суынып өлгермәгән ап-ак мич, икенче ягымда — сап-сары бүрәнә стена. Бу бүрәнәләрнең теге ягында — урам. Анда — салкын, анда — кыш. Анда — Алмаз.

Кайтып җитте микән инде Сарылыга? Куркынычтыр инде төнлә берүзенә. Болынны үтте микән инде? Елгага җитте микән? Иртәгә дә килер микән? Килсенме икән соң? Ә мин каян белим... Син күңелеңнән сора... Бүтән вакытта бит күңелең ни кушса, шуны гына эшли идең. Бүген дә төшкә керер микән Алмаз? Үзен күргәч, кермәс инде...

Күзләрем йомыла, йомыла... Җаным да... Аңа да ял кирәк икән бит. Шартлап өзелмәс өчен, җүләрләнеп, тәрәзәдән сикермәс өчен, кешеләр арасында яши алырлык көч табу өчен...

Икенче көнне көне буе буран котырды. Әбием белән бер көянтә-чиләк суга чак барып кайттык. Атлый барабыз, эзебезне буран сибереп күмә бара. Чайкалдыра-чайкалдыра, ярты суым түгелеп бетә язды, чайкалган суым боз булып чиләкләрем кырыена ката барды. Авырая-авырая, кайтып җиткәнче тәмам җилкәмне кисеп, һәр чиләк бер әр потлы булып тоела башлады. Чишмә ерак иде, тау астында ук иде. «Әби ничек алып кайта икән моннан көн дә суны?» — дип, әбиемне уйладым. Таягына таянып, бата-чума текә таудан иңенә көянтә-чиләк асып су ташуын күз алдына китердем. Без бит шәһәрдә суның нәрсә икәнен дә белмибез. Кранын борып җибәрәбез дә, япканчы ага да ага, ага да ага. Болай ташыйсы булса, кадерен белер идек без аның.

Әбием әйтә, бүген башка бармабыз инде, ди. Бу суны чәйгә генә тотарбыз, ди. Мал-туарга кар суы эретергә куйдык. Әбием, карт булса да, һаман сыер асрый әле. Печәнне сатып ала икән. «Курмы алырга акчаны анаң сала бит, бер дә белмисеңмени шуны?» — ди. Белми идем шул. Без бит әни белән күп нәрсәләр турында сөйләшмибез дә, киңәшмибез дә.

Малларга азыкны әби үзе салып керде. Рәтен дә белмисең, йөрмә, ди, мыскаллап кына тоткан печәнемне чәчеп, әрәм-шәрәм итеп бетерерсең, ди. Әбинең иске бишмәтенә ияреп, өйгә, суык белән бергә, кипкән печән исе, болын исе кереп тулды. Мин, йөгереп килеп, аның бишмәтенә ябышып калган үләннәрне җыйдым, чәч арасыннан бер кипкән чәчәк тә килеп чыкты әле. Мин шуларны иснәп, нишләргә белмәдем, аһылдадым, күзләремне йомдым... Әби рәхәтләнеп көлә. «Бәләкәй чагыңда, шул чәчәкләргә нигә тиясез дип елый идең,— ди.— Хәзер кызганмыйсың бугай инде, күр ничек рәхәтләнеп юанасың»,— ди.

Хәзер дә кызганам, әбием. Тик хәзер башка кызгану. Мин аларның чабылырга тиеш икәнлекләрен үземә күптән исбат иттем инде. Исбат итү генә түгел, шулай кирәк, шулай дөрес дип тә таптым. Күңелемнән мин аларга үзем хөкем чыгардым, җәзасын гамәлдә башкалар үтәде. Хәзер миңа хөкем чыгаручылар да, җәзалаучылар да кызганыч. Матурлыкны юк иткәндә әле һаман хиснең елый-елый көлүен акылларына сыйдыра алганнары өчен...

Әле яңа гына йокыдан торган кебек идем, инде кич тә җитте микәнни? Әллә урамда буран булганга, тәрәзәне кар көрте басып киткәнгә генә әбием утны яндырдымы? Без бүген пилмән пешерәбез. Әбием инде чоланнан оннарын кертеп куйды. Ул онны безнең кебек полиэтилен капчыкта йөртми, җилпуч дигән нәрсәгә салып алып кергән. Аннан шул онны матур итеп, үзенә күрә бер көе, җае белән генә или. Иләкне алып, кул арасында мин дә йөртеп караган идем, кулымнан төшә дә китә, төшә дә китә... «Бигрәк кулың эшкә ябышмый шул, кызым,— ди әбием, башын чайкап.— Анаң бер дә өйрәтмимени соң үзеңне?»

Соң, безнең өйдә мондый әйберләр юк бит! Җилпуч та юк, иләк тә юк, күп вакытта оны да булмый әле аның бездә. Чөнки без пирогларны, пилмәннәрне барысын да әзерне, кибеттән генә сатып алып кайтабыз. Өстәлнең икебез ике башында кулга китап тотып тын гына ашыйбыз да, икебез ике якка чыгып та йөгерәбез. Безнең вакыт юк бит, әби!

Әби моның белән риза түгел. Үзеңә ашарга да пешерә белмәгәч, нинди яхшы килен чыксын синнән, ди. Менә мин, бер ялгызым булсам да, атна саен таба ризыгы пешерәм, бер көнне дә итле шулпасыз калганым юк, ди. Мин шәһәрдә нәрсә ашаганымны да хәтерләмим, ашала-

дыр инде ул, ач йөрмисеңдер, ләкин нәрсә ашыйм, нәрсә яратам мин — әйтә алмыйм. Мөгаен, ни туры килсә — шунысыдыр.

Без инде пилмән ясыйбыз. Минем пилмәннәр ябышмыйча теңкәгә тияләр. Әби кулымнан тотып өйрәтә, эшләгәнең минем өчен булса, өйрәнгәнең үзең өчен булыр, ди. Син бит кеше кешесе буласы, ди.

Беренче тапкыр киләчәк турында, үземне хатын кеше итеп, аш-су тирәсендә йөрим итеп күз алдыма китереп карыйм. Миңа куркыныч булып китә. Мин бит бернәрсә дә эшли белмим! Мин чит телләрдә сөйләшә беләм, пианинода уйныйм, дөнья классикларының әсәрләре турында үз фикерем бар, ә йорттагы хатын-кыз урынына куеп карагач, мин үземнең йөз процентлы булдыксыз икәнемне сиздем. Пилмән дә ясый белмим, он да или белмим, җеп тә эрли белмим. (Аларын әни дә белми бугай әле аның.) Тагы нәрсәләр белмәгәнемне әле үзем дә белмим.

Әби мактый тагы үземне, әнә бит, тырышкач була, ничек матур чыга пилмәннәрең, ди. Болай гына әйтә инде, минем күңелем төшмәсенгә генә. Менә болары матур булган икән чыннан да. Өйрәнәм мин, әбием, өйрәнәм, өйрәт кенә!

Пилмән белән мәж килеп, кичне дә җиткердек. Инде кайтканыма ике көн, ник бер китап укыйм, ник бер телевизор карыйм дип әйтим. Казанда бит мин китапсыз, телевизорсыз бер минут тора алмыйм. Монда әбинең телевизоры бөтенләй юк та. Ә вакыт үтә барыбер, әле сизелми дә. Ә! Белдем! Эш эшләгәнгә сизелми икән бит ул вакыт. Адәм баласына, акылдан шашмас өчен, эш тә кирәк икән бит!

Минем үземне тагы берәр эштә сынап карыйсым килә, әбинең артыннан калмыйм, эш сорап тинтерәтәм. Әби әйтә, эшне аны сорап эшләмиләр, тавык чүпләп бетергесез безнең монда эш, ди. Ә мин бернәрсә дә күрмим. Бөтенесе тәртиптә кебек, бөтенесе инде эшләнгән. Ә әбием һаман кыймылдый, юка, җитез гәүдәсе бер яктан икенче якка очып кына йөри, куллары бер дә эшсез тормый. Я булмаса, иске бишмәтен киеп, абзар, чолан тирәсенә үк чыгып китә. Мине ияртми, өйдә генә утыр, әнә, башлаган оекбашым бар, шуны бәйли тор, ди. Мин, ул күрсәткән бәйләмне алып, кулымда әвәлим, бишинәсен саныйм, йомгагын тотып карыйм, аптырагач, иснәп тә карыйм (сарык исе килә), тик бәйли генә алмыйм. Аптырап, гаҗизләнеп, үртәлеп, тыштан әбиемнең кергәнен көтәм. Әбием керә, тик янымa килеп, оекбаш бәйләргә өйрәтергә ашыкмый.

— Синең янга, кызым, теге Сарылы малае килгән анда,— ди ул өстен чишенә-чишенә.— Өйгә кермәде. Үзеңне чакыра.

Юк! Чыкмыйм мин анда! Калсын хыялымда гына, калсын төшләремдә генә, тормышта ул андый түгел, чыкмыйм мин аның янына. Мин аның белән сөйләшергә сүз таба алмыйм, мин аның янында бөтенләй йомылып калам.

— Алай килешми, кызым. Шушы буранда интегеп килгән бит кеше. Бар, җылырак киен дә, чык.

Ә бәлки чыгаргадыр? Чыгарга да әйтергәдер? Син башка килмә инде, Алмаз, безнең балачак белән ике арада күпер юк, дияргәдер? Мин инде киенә башлыйм, әби миңа итекләрен бирә, ак мамык шәлен ябындыра, кызым, ерак китмә, озак торма, дип әйтергә дә өлгерә.

Буран улавын ишетермен дигән идем, шулкадәр дә тынлык тоеп, аптырап калдым. Буран туктаган икән бит! Төн дә җылынып, җепшеп киткән. Әллә мин җылы киенгәнгә генә шулаймы? Алмаз кая соң әле? Әллә, мин чыкмый икән дип уйлап, кайтып ук киткәнме?

Минем инде өйгә керәсем килми. Капка төбенә чыгыйм әле, тап-тар ишегалдында шулай сихри булганны, урамда нәрсәләр анда. Итекләрем белән кар көртен ера-ера, капкага таба китәм, капканы ачып, урам якка атлыйм дигәндә генә, кулларымнан кемдер эләктереп тә ала. Юк,

мин курыкмыйм, мин кычкырып та җибәрмим. Мин аның Алмаз икәнен беләм. Тик аның шулай, караңгыга яшеренеп, тәкәллефсез генә кулымнан тотып алуы мине өшетеп җибәрде. Мин кулымны ычкындырмакчы булам, тартылып карыйм, ләкин ул нык тоткан, минем көчсез генә тартылуымны гадәти хәл итеп кабул итә, күрәсең.

— Нигә син алай тотасың кулларымны?

— Алайса кереп китәсең бит син. Белгән инде кызларны.

— Юк... Мин кермим әле. Урамда бик матур бит.

Ул, гаҗәпләнеп, ышанмыйча миңа карый. Минем тыныч карашыма килеп бәрелә дә күзләрен аска төшерә. Куллары, оялып, әкрен генә минем кулларымны ычкындыра.

— Әйдә, авылны бер әйләнеп килик, Алмаз. Бигрәк матур бит.

— Ни... Юл юк бит. Көрт бөтен җирдә. Беркем йөрмәгән. Менә монда да чак ерып кердем әле.

— Болынга да барырлык түгелме?

— Ю-юк! Кая ул! Анда бөтенләй котырган буран. Әйтәм бит, үрмәләп диярлек килдем.

Күңелемнең әллә кайсы бите зыңгылдап куйды. Мин ул бик артында нәрсә барын үзем дә белми идем әле. Хатын-кызның башкаларга бирелачәк зур һәм кечкенә корбаннары яшеренгән ахры анда. Шуны тоя алу хисе яшеренгән.

Карашымның терелеп китүен Алмаз да сизде, ахры. Тагы да дәртләнеп сөйли башлады.

— Әйе, үрмәләп инде менә. Кичтән буран котыра, әни, кая барасын тагы төнгә каршы, ди. Кичә дә төн уртасында кайтып егылдың, ди. Безнең әни бәйләнә башласа...

Беләм... Хәтерлим... Яңгырлы көн... Тайгак ишегалды. Башын куллары белән каплап утырган малай. Елаудан, гарьләнүдән, оялудан ябык аркасы дер-дер килә.

Алмазның кулыннан җитәкләп алганмын икән. Кулы нинди зур, кытыршы, кайнар...

— Әниең һаман кыйныймы сине, Алмаз?

Кул, сагаеп, хәрәкәтсез кала.

— Нишләп кыйнасын ди ул мине, җүләр. Аның хәзер миңа буе да җитми инде.

Кулга тагы җан керә, сизелер-сизелмәс кенә дерелдәгән бармакларымны кысып-кысып куя.

— Нишләп син теге җәйдә кайтмадың? Мин җәй буе сезнең капка төбен сагаладым. Икенче җәйне дә кайтмадыгыз.

— Шулай килеп чыкты инде. Менә... хәзер кайттым бит.

— Тракторга утырганда, башта сине танымадым мин. Күллегә кайтучы берәр студенткадыр дип уйладым. Аннан... Син йокыга киттең дә... Минем исемне әйтеп кычкырдың. Шуңа йөрәкләрем жу итеп китте...

— Мин сине төштә күргән идем анда. Мин сине гел төштә күрәм. Менә ничә ел инде... Ә син... Бер дә күрмәденме?

Кул, уңайсызланып, тартылып куя.

— Юк шул. Безнең эше дә инде. Эт булып арыйсың. Кайда ятканыңны да белми йоклыйсың.

— Теге, ике арадагы күпер, торамы әле?

— Кайсын әйтәсең — зурысынмы, кечесенме?

— Син басып калганы...

— Анысы тора. Кечкенәсен ел саен яңгыр агызып алып китә. Ә зурысы тора. Анысы болай гына бирешми аның.

Сүз бар да кебек, юк та кебек. Ике арада күпер бар да кебек, юк та кебек. Бар — узганнарда икебез генә белгән вакыйгалар, икебезгә генә таныш истәлекләр бар. Тар бүлмәләрдә күңелемне тарлыктан кот-

карып калган, иң караңгы мизгелләрдә дә өметләндереп яктырткан төшләрем бар. Кыргый күңелемә сорамыйча килеп кергән, күпер уртасында мине озата калган (бу якка — аңа, ул якта миңа юл юк!), аннары кабат-кабат төшләремдә саташтырган, кабат-кабат төшләремдә саташтырган... Алмаз...

— Син мине көттеңме?

— Мин сине... Үзем көттем, үзем курыктым... Син безнең авыл кызларына охшамагансың. Син беркемгә дә охшамагансың.

— Мин кыргый...

— Юк, син кыргый түгел... Мин менә кыргый кебек күренәмдер синең янында. Бер авыл трактористы.

— Алай әйтмә... Син минем өчен — Алмаз... Алмаз...

Әллә ул мине үзенә тарта, әллә мин, үз хисләремнән үзем башым әйләнеп, үз төшләремә үзем ышанып, сихерләнгән кебек аңа тартылам. Ике арадагы бушлык юкка чыга, битләремне аның кайнар сулышы яндырып үтә, иреннәрем, аңнарын җуйгандай, аның килеп орынуын көтәләр. Кинәт, бар дөнья, безне тотып торган җир дә, салкын гына яктыртып торган ак кар да, урманнар, болыннар да, тар шәһәр бүлмәләре дә, барысы да берьюлы юкка чыгалар. Мин үзем дә эреп шулар арасында юкка чыгам. Күзләремне ачсам, якында гына аның күзләре, аларда сагыш та, соклану да, табу да, югалту да бар кебек. Аның озын керфекләре тетрәп йомылалар, иреннәре сүзсез генә тагы миңа табылар, миңа табыналар...

Күк! Мең йолдызың күрдеме бу төннең яктылыгын?!

Мең йолдыз! Сез күрдегезме җирдә дә бер йолдыз кабынганны? Аның исеме мәхәббәт икәнен, ул безнең мәхәббәт, безнең өчен бердәнбер булган, кешелек тарафыннан беренче мәхәббәт дигән сагышлы һәм якты исем бирелгән мәхәббәт кабынганын күрдеңме син, мең йолдызлы күк?! Миңа кадәр дә гашыйклар, бер-берләренә килеп орынгач, шулай аңнарын җуялар идеме? Миңа кадәр дә чит бер кеше каршында, дөньяда нәкъ син очрарга тиеш идең миңа, дип, әллә урынына күреп тезләнәләр идеме? Дөньяда миңа кадәр дә минем кебек сөя беләләр идеме, мең йолдызлы күк?! Син шуларның барысын да күреп торганда, ничек йолдызларыңа ут капмады, ничек син һаман шулай үзгәрешсез, тыныч кына кала алдың?!

— Әйдә, Алмаз, күктәге йолдызларны күзәтәбез. Берәрсенә ут капмадымы икән?

— Капса да, моннан күренмәс инде ул барыбер.

— Алайса, әйдә, җирне ятып тыңлыйк әле. Ут ташкыны күтәрелмиме икән астан? Тетрәмиме икән җир бу төндә?

— Кары бик калын бит, барыбер сизелмәс. Аннан, безнең бу якларда бик тыныч. Алай җир-мазар тетрәп интектерми.

Ә мин барыбер бәхетле! Икебез ике телдә сөйләшсәк тә. Бер дә сөйләшмәсәк тә. Ничә еллар буе мине буып, кыргыйландырып торган кире бер көч, аның иреннәре килеп кагылгач, әллә нинди садә якты бер моңга әйләнде дә калды. Миңа хәзер бөтен дөнья, бөтен кешеләр искиткеч әйбәтләр, яхшы күңелleләр булып тоела. Минем бөтен кешегә дә елмаясым, барысына да әллә нинди яхшылыклар эшлисем килә. Төнге урамны яңгыратып көлә-көлә, Алмазны ап-ак кар өстенә төртеп егам. Ул башта гаҗәпләнеп миңа карап тора да аннан үрелеп мине дә үз янына тартып аудара. Без, ап-ак кар булып, оеп утырган кечкенә өйләрне сискәндереп, бер-беребезгә сарылган хәлдә көлә-көлә кар дингезендә йөзәбез. Я хода! Дөньяда мондый төннәр дә, адәм баласында мондый халәт тә була ала икән! Миңа — уналты яшь. Минем, бәхетем каршына кочагымны җәеп, көлә-көлә йөгергән чагым. Вакыт! Узып китә күрмә мине алда, сөйли күрмә миңа сүрелгән мәхәббәтләр, аянычлы

язмышлар турында. Мин белергә тиеш түгел аларны! Уналты яшемдә булса да, мин мәхәббәткә, тормышка, кешеләргә ышанырга тиеш! Ышанырга тиеш...

Шәһәргә кайткач, әни мине таный алмый интегә. Булмә ишегеН шарт итеп ябып чыгып киткән җүләр кызың кайтып муеныңа сарылсын әле! Гомер булмаганны! Кайчаннан бирле елмаюның-көлүнең нәрсә икәнен белмәгән, кешегә күтәрелеп карап бер җылы сүз әйтә алмаган кыргый кызың көлә-көлә синең косметика каплаган битләреңнән үпсен әле! Гаҗәпләнерсең дә. Әни миңа нинди телдә эндәшергә дә белми. Минем кочуымнан, сарылуымнан котылган арада, татарча гына аһ-вах итәргә тотына.

— Нәрсә булды соң сиңа, кызым? Чирләп килмәгәнсеңдер бит авылдан?

Чирләп? Авылдан чирләп кһиләләрмени? Яктылыктан, сафлыктан, мәхәббәттән кеше чирли димени, әнием?!

Пианино янына йөгереп киләм дә, шашып-котырынып, Штраус вальсларын уйный башлыйм. Аннан Бетховенга, Чайковскийга күчәм, аннан бәгыремне сызып, күңелемне әллә нинди биеклекләргә күтәреп, татар көйләре агыла башлый. Тар бүлмәләргә сыя алмыйча, «Урман», «Болын», «Гөлҗамал»лар сулкылдыйлар. Көйнең кылдан нечкәреп җаннарда чыңлаган, өзеләм-өзеләм дип бәгыремдә бәргәләнгән бер мизгелендә мин түзә алмыйм, салкын пианино клавишларына капланам да үксеп елап җибәрәм. Бу — үзе бер көй. Бу — үзе бер моң. Бу — үзеңә килгән мәхәббәтне, бәхетне тоеп елау. Дөньяның бөеклеген танып, яктырып елау. Бу — сагыну.

Мин яшьлекнең үзендә, мин инде яшьлегемне сагынам. Мин инде кичәге көнемне, кичәге бәхетемне сагынам. Сине сагынам, Алмаз! Ләкин бу өметсез, билгесез, бер яклы сагыну түгел, минем сагынуым да якты, сагышым да шатлыклы.

Әни аптырап калган. Миңа кушылып еларга да, көләргә дә белми. Ул инде минем кирелекләремә, җүләрлекләремә өйрәнгән, мондый бәхетле җүләрлегемне генә күргәне булмаган. Бөтен нәрсәне дә аңлап, барысына да үз карашы булган әнием, уналты яшьлек кызының мәхәббәттән үксеп елавын аңлый алмый гаҗизләнә. Әллә аңлап та, бу мизгелнең шулай тиз килеп җитүенә, заманнан калышмый йөгерә торгач, заманның барыбер аны узып киткәненә, каршына буй җиткән кызын җитәкләп чыгып басуына хәйраннар калып, гаҗәпләнеп басып торадыр. Беренче тапкыр үзен ана ролендә, буй җиткән кызның анасы ролендә күреп, куркып калуыдыр...

Мәктәптә дә миндәге үзгәрешне сизеп алдылар. Мин барысына да елмайдым, барысына да ярдәмгә йөгердем. Миңа үземнең классташларымнан да яхшырак, якынрак, минем җанны аңлый алырлык кешеләр юктыр кебек тоела башлады. Ничек ун ел буена бергә укып, янәшәмдә нинди кешеләр булганын сизмәгәнмен соң мин? Аларны гел үземнән көләләрдер дип уйладым, алар белән үзем арасында һәрвакыт стена барлыгын тойдым. Алар әнә нинди гадиләр икән, нинди беркатлылар үзләре. Тыштан караганда, яннарына барырга куркыныч — барысы да әллә нинди салкыннар, бөекләр кебек. Ә якыннанрак белә, аралаша башлагач, мин аларның да җаннарында мең төрле борчу барын, кеч кенә генә шатлыктан да кабынып китәргә әзер торуларын, битарафлык кабыкларын да шаулап торган бу дөнья сытып-изеп китмәсен өчен генә кигәнлекләрен аңлый башладым. Алар барысы да кай яклары беләндер миңа охшаганнар. Алар барысы да яратырга, яхшылык эшләргә әзер торып та, салкын дөньяның мең төрле каршылыкларына килеп бәрелгәч, челпәрәмә ватылып, шул ватыкларга баса-баса кайсы үҗәтләнеп һаман алга баручы, кайсы өметсезләнеп артка таба шуышучы

билгесез җаннар иде. Әмма аларның яратасылары һәм яратыласылары кирә, бик кирә иде! Чистарынасы, табынасы һәм табындырасылары кирә иде...

Әгәр авылга кайтып килмәсәм, Алмаз белән аклык дөньясында җитәкләшеп йөгереп йөрмәсәм, мин ул ел ничек шулай сукыр булсам, иптәшләрем янынннан, аларның очкынланып, тетрәп торган тормышлары яныннан шулай берни күрми үтеп тә киткән булыр идем. Күләгә кебек, янгырсыз болыт кебек, сүзсез-моңсыз җыр кебек. Әле ярый авылга кайтканмын, әле ярый Алмазны тапканмын.

Алмазның беренче хаты мине күктән җиргә төшерде. Чөнки мин татарча укый белми идем. Хәрефләрен җыеп сүзләр ясасам да, аларның мәгънәләрен аңлый алмый идем мин. Хәрефләп җыя-җыя, иҗекләп укый-укый, алай да ахырына кадәр ерып чыктым. Ләкин мин көткән серлелек, мин көткән якынлык шул хәрефләрдә таралды да бетте. Ләкин җавап хаты язу укудан да авыррак булды. Монда инде мин бөтенләй чи надан идем. Сүзләрем мәгънәсез, язганым салкын килеп чыкты. Мин аптырадым, йөдәдем дә хатымны русча яздым да җибәрдем. Хатлар аша шулай сөйләшә башладык — ул татарча, мин — русча. Ул минем хатларны ничек укыгандыр, күңеленә ничек кабул иткәндер, миңа аның хатларын укуы көннән-көн кыенлаша башлады. Мин аларны аңлап укымый идем, үзем укырга, үзем күрергә теләгән нәрсәләрне күздә тотып укыйм да, шулардан чыгып җавап яза идем. Бер хатын, аптырагач, аңлый алмый йөдәгәч, әнигә күрсәтеп карарга булдым. Әнинең, хатка күз төшерү белән, чәчләре үрә торгандай булды. Бармаклары белән чеметеп тотып, хатның әле бер ягын, әле икенче ягын әйләндергәләде. Авыз кырыйлары салынып төште, тигез, шома маңгаенда беренче тапкыр җыерчыклар күрдем.

— Бу нинди хат? — диде ул салкын, кырыс тавыш белән.— Бу нинди пычрак хатлар килә тагы сиңа?

— Нишләп пычрак булсын ул, чиста бит.

— Син аның эчтәлеген кара, ахмак! Кемнән килә сиңа мондый хатлар!

— Нәрсә язган соң ул анда шул хәтле?

— Укый да белмәгәч, ни пычагыма дип хат алышасың син аның белән?

— Мин аның кайбер төшләрен аңлыйм. Кайбер сүзләрен генә...

— Моны син түгел, мин дә аңлап бетермим. Атаң белән аерылганнан бирле мондый сүзләр ишеткәнем юк иде. Нәрсә яза бит, авыл мокыты.

— Нигә син алай дип әйтәсең? Белми торып.

— Беләсе юк, менә тыңла, аңламасаң, тәрҗемә итәрмен... Так, менә бу төшен. «Син анда, шәһәр егетләре белән типтергәндә, монда, трактор маена батып йөрүче мине уйламыйсыңдыр да инде. Кызларны беләбез инде аны, үбешкәндә генә җаным-бәгырем. Син инде анда әллә кайчан башкаларга сырышкансыңдыр»...

Тукта, укыма, тәрҗемә дә итмә. Нәрсә укыйсың син?! Алмаз алай дип яза алмый. Аның сүзләре түгел бу!

— Кайдан таптың син бу трактористны?

Дәшмәгез! Бикле! Минем күңелемнең ишеге бикле! Шакымагыз аны җәрәхәт ясалганчы, тинтерәтмәгез мине үзем дә җавап бирә алмаган сораулар белән!

— Авылдандыр инде, кайдан булсын. Бик ашкынып кайтып киткән иден бит кышын авылга.

Мин җавап бирмим. Мин куркам, ул сүзләрнең нәкъ Алмазныкы булуыннан куркам. Күңелдә үзем тудырган образның барыбер юкка чыгасын, җимереләсен аңлаудан куркам. Барысыннан да качарга те-



*Тавил Хаҗиәхмәтов рәсеме.*

ләп, күзләремне йомам да, үз дөньяма китәм. Бу — чәчәкләр исеннән оеп яткан тын болын. Башта мин анда кыяр-кыймас кына килеп керәм, аннан әкрен генә йөгерә башлыйм. Каршы искән җил минем озын кара чәчләремне кирегә куа, алар, мин атлаган саен, бер очып китәрдәй булып күккә күтәреләләр, бер нәүмизләнеп, хәлсезләнеп, минем муеныма, җилкәләремә уралалар. Ә мин һаман йөгерәм дә йөгерәм... Үзем чәчәкләр арасыннан йөгерәм, үзем бөтен җаным-тәнем белән өстәге шомлы болытларның түбәнгә агылуларын, миңа таба якынлашуларын сизәм. Кулларым өметләнеп алга сузылган, миңа һаман арырак, болынның әнә теге башындарак, миңа таба да кемдер шулай йөгереп киләдер кебек тоела. Мин инде арыйм, хәлем бетә, ләкин туктый да алмыйм, туктасам, теге авыр соры болытлар куып җитәрләр дә... Куып җитәрләр дә... Ә каршыда һаман берәү дә юк... Болын искитеч зур да, чәчәкле дә, матур да, шомлы да... Ә мин һаман бер ялгызым йөгерәм! Кая соң ул кочагын җәеп, минем каршыма йөгерергә тиешле кеше?!! Килеп капланыр идем шуның көчле кулларына, качар идем шул шыксыз салкын болытлардан...

Алмаз белән һаман икебез ике телдә сөйләшәбез. Хатлар аша гына. Мин аны, кулларыннан җитәкләп, хыялымда гына булса да, кабат ак кар дөньясына алып кермәкче булам. Мең йолдызлы күкне шаһитлыкка чакырып, дөньяда мәхәббәт барлыгын, тик аның тупас уйлардан, саксыз кагылышлардан да сызылыплар гына бетәрлек бер халәткә әйләнергә мөмкинлеген кисәтергә тырышам. Өскә ябырылып килгән бу дөньяда, бу зур, ят дөньяда без бер-беребезне табышканбыз икән, салкын кышта очкын булып кабына алырлык хисләр уятканбыз икән, сүндермик инде без аны, Алмаз?! Мин куркам, ул очкын сүнсә, минем кешеләргә ышанычым да, тормышка, киләчәгемә өметем дә сүрелер кебек. Карап, ымсынып барырга шул очкын булмаса, адашырмын бит мин бу тормыш урманында, адашырмын!

Алмаз минем җәйгә авылга кайтуымны көтә. Ачыктан-ачык, күзгә-күз карап сөйләшәсе бар, ди. Бу хатлар аша гына, икебез ике телдә ым кагып сөйләшүләр туйдырды, ди.

Ә җәйгә! Ә җәйгә!.. Күпме экзаменнар! Унны бетерергә, аннан институтка керергә... Алмаз! Син, барысын да ташла да кайт авылга, дисең. Мине салкынлыкта, хиссезлектә гаеплисең. «Син инде барысын да оныткансың, кыш көне әйткән сүзләрең дә чын булмаган, син уйнагансың гына минем белән», дисең. Нигә алай әйтәсең, Алмаз?! Мин моңа хәтле бөтенләй белмәгән, ишетмәгән сүзләр әйтәсең, мин хатта аларны аңлый алмый бер интексәм, тормышта бөтенләй нәрсә икәнлекләренә төшенмичә йөдим. Минем хәзер бик җаваплы, бик авыр чагым, Алмаз! Аптыратмыйк, бүлгәләмик без бер-беребезне юк-бар шикләнүләр белән...

Күңелгә, нишләптер, бик авыр. Үзе яз көне, ә үзе, нигәдер, бик авыр. Кыш көне яктырак та, сафрак та кебек иде дөньяда. Башым — тубал. Анда теоремалар, формулалар, тарихи даталар сикерешә, әллә ничә телдә дөньяның, материянең мәңгелеге турында бәхәсләр кабына, аларның барысын күмеп, бөтен җиһанны тутырып, Бетховен музыкасы агыла башлый. Дөнья бер караңгылана, бер яктыра. Күңелем, бер очкынланып кабынып китә, бер чарасызланып, сүнеп кала.

Кыш миннән ераклашканнан-ераклаша, җәйгә дә керәсем килми, мин ул җәйдән куркам, мин үз-үземнән куркам, мин киләчәктән куркам. Мин дөнья уртасында тагы япа-ялгызым калам...

Җәен мин авылга кайта алмадым. Ярты җәем урта мәктәпне тәмамлаганга имтиханнар биреп үтсә, ярты җәем институт белән бәйләнгән

иде. Мин институтның чит телләр бүлегенә имтиханнар бирдем, мин анда керә алырыма шикләнми идем. Чит телләрдә инде мин туганнан бирле сөйләшәм, бу телләрдә мин бәхәсләшә алам, язма рәвештә аңлашам. Институтка керү дә минем өчен авыр проблема булмады.

Әни минем өчен бик шат. Алай ачылып сөйләшмәсә дә, соңгы вакытта мине нык күзәткәне, нервларының бик киеренке булуы сизелә. Ул минем өчен борчыла, берәр җүләрлек эшләп ташламасын тагы дип уйлыйдыр. Мин тыныч. Миндә ниндидер киеренке тынлык. Давыл алдыннан була торган тынлык кебек. Шомлы тынлык, битараф тынлык. Башымны күтәрми укыйм. Башымны күтәрсәм, кешеләрнең күз карашлары белән очрашырмын кебек. Мине басып торган дәһшәтле тынлыкка саксыз кагылырлар да, күңелемнең тагы ялгызлыкка, юлдашсызлыкка хөкем ителүен аңларлар. Аңларлар да, үз кинәшләре, үз чаралары белән бу бәргәләнгән җанга дәва эзли башларлар. Юк!!! Мин тагы битарафлык кабыгы киям. Минем җаным авыру, бу — ялгызлык авыруы, бу — кешесезлек авыруы.

Көзен Алмазны Армиягә алдылар. Бернинди очкынсыз, бернинди хиссез гадәти генә хатлар языштык. Әллә нәрсә иде бу — бер-беребездән көннән-көн ераклаша баруыбызны да тоябыз, икебез ике дөнья кешесе икәнлегебезне дә сизәбез, ә хатларны һаман язышабыз. Бу үткәннәр алдында, безне адаштыра язып калган урманнар, төшләрдә очраштырып сөендергән болыннар, мең йолдызлы күкне шаһит итеп чакырып беренче тапкыр үбешүләребез алдында — аклану идеме, кабынып китә алмаган очкынны бөтенләй үк сүндермәскә теләү генә идеме?..

Олы сөю көтеп тә, шул көтү халәтеннән үземнән-үзем куркып, артык гади һәм гадәти тормыштан кача-читләшә үз күңелемә бикләнеп, унсигезем дә үтте, унтугызым да, егермем дә... Мин җанымның уянмас борын йомыла баруын тоям, мин хисләремнең кабынмас борын сүнүгә дучар ителүләрен тетрәнеп, тыштан барысына да салкын, битараф, эчтән дөрләп яна-яна кичерәм. Минем яшьтәш кызларым инде ничә тапкыр гашыйк булдылар, инде кемнәргә алла итеп табынмадылар да кемнәрне канлы яшьләре белән каргый-каргый, яшьлекләре белән хушлаштылар. Ләкин алар барыбер миңа караганда бәхетлерәк иделәр. Алар яши иделәр, алар үзләре дә яна-яна, дөньяны да яндыра-яндыра яши иделәр!!! Мин — таш кыя! Мин — салкын стена. Гомерем буе үзем төзедем мин ул стенаны. Чынбарлык белән хыял арасында. Җаным белән тәнем арасында. Хәзер ул стенаны җимереп үзем дә чыга алмыйм, башкалар да аңа үтеп керә алмыйлар. Ә дәһшәтле тынлык һаман үсә, үсә бара...

Алмаз Армиядән кайткан җәйне без авылда очрашырга булдык. Минем инде болынымны да күптән күргәнем юк иде, сагынган идем мин шау чәчәктә утырган ул назлы болынкайны! Әле чабылганчы кайтып җитә алам бит мин аңа, дымлы җиренә капланып, җанымны ашаган, яндырган бу бетмәс ялкыннарны сүрелдерә алырмын бәлки анда? Анда бит әле Алмаз да бар — беренче мәхәббәт төсендә кабынырга тиеш булып та, һаман кабынып китә алмаган, һаман сүнәр-сүнмәс кенә очкынланган бер якты хис бар. Анда — минем тиле балачагым, анда — минем кыргый үсмерчагым, анда — минем сәер яшьлегем...

Әбием бик нык картайган. Әллә танымады да инде мине? Аның да карашлары инде әллә кайда, әллә кай дөньяларда. Юкка-барга сөенеп, инде өй арасында йөгереп тә йөрми, күбрәк кулына тәсбихен тотып, бер ноктага текәлеп утыра. Авыз эченнән генә һаман нидер укый, нидер укый... Мин, болынга барам дигәч, нишләптер уянып киткәндәй булды, йөзе буйлап күләгә узды, авырлык белән генә:

— Барып йөрмә инде син анда, кызым,— дип куйды.

— Әбием! Мин авылга кайтып, болынны күрмичә китәмме соң?

Мин болынга барып, балачагым белән очрашмыйча түзә аламмы? Шул хәтле арып килеп бу мизгелгә, көтеп арып, ялгызлыктан арып, билгесезлектән арып...

Әллә яланаяк кына чыгып йөгеримме икән? Көлмәсләрме икән? Сез көлмәгез инде миннән, кешеләр! Аңлагыз дип әйтмим, мине аңлау бөтенләй дә кирәк түгел. Адашып калдым мин сезнең арада. Менә сезнең һәрберегезнең үз сукмагы, үз максаты бар. Ә мин кая барып бәреләсемне дә белмим. Мин нигә баш күтәрми укыганымны, ул укыганымның нигә кирәк буласын да белим. Миңа барыбер. Мин әллә нинди саташулы йокы белән йоклыйм кебек. Ләкин мин уянырга да куркам, әле уянганчы ниндидер өмет бар кебек, әле бу төштә генә шулай бит, менә, уянырмын да, барысы да яхшы булыр, кызыклы булыр дип уйлыйсың. Әгәр уянып та ниндидер бушлыкка, юлдашсызлыкка барып төртелсәм?! Юк, мин уянырга куркам, уянырга куркам...

Ләкин... Кайда соң ул болын? Кайда болын буендагы куе әрәмәлек? Сискәнеп, авыл ягына борылып карыйм. Авыл үз урынында. Әнә мин әле генә яланаяк йөгереп узган урам. Әнә, каршыда, Сарылы авылы күренеп тора. Ә ике арадагы болын, мин кечкенәдән кайтып, аунап үскән болын, кайда соң ул?! Кайда соң кып-кызыл бөрлегәннәре белән янып, исерткеч исле колмакларына чорналып утырган әрәмәлек?! Аларның урыны буш, аларның урынында кантар-кантар кәсләре кайтарып ташланган кара җир генә актарылып ята... Болынны күптән түгел генә сукалап киткәннәр ахры, үлән-чәчәкләрнең мәңгегә өзелгән тамырлары, җәрәхәттән ачылган нерв җепселләре кебек, таралып, җиргә китәсе тармакларын күккә төбәп, җан биреп яталар. Кантар араларына әллә яңгыр суы, әллә җирнең күз яше җыелган. Юл да юк, сукмак та юк, болын да юк, әрәмәлек тә юк. Тоташ сукаланган да сукаланган. Тагы, котым чыгып, авыл ягына әйләнеп карыйм. Авыл тора. Күктә, берни булмагандай, тәгәри-тәгәри кояш көлә. Һава шундый чиста, зәңгәр. Авыл өстендә әнә беленер-беленмәс кенә рәшә тибрәнә. Ә бередә, мин басып торган җирдә — үлем тынлыгы. Меңләгән бөҗәк-кортлары, чикерткәләре гөжләп-җырлап, йөзләгән кошлары сайрап торган болын шулай тавыш-тынсыз гына, моңсу гына дөнья белән хушлаша. Мең еллык бәгырен тимер сукалар ертып үткәндә, иңрәдеме икән ичмасам?! Кемнең кулы барды икән мең еллык матурлыкны шулай бер селтәнүдә юкка чыгарырга?!

— Үзебезнең авылдан берәү дә риза булмады. — Әбием, әллә нинди моң белән, әллә бәет, әллә мөнәҗәт әйткәндәй, сөйли дә сөйли. — Пресидәтелнең аякларына тезләнеп ялвардылар, кагылма болынга, дип. Ай-васна карамады халыкның... Яңгырлар башлангач, болынга кереп булмас дип, печәнен чабып алуга, сукалатырга булган. Шулай дигәч, халык печәнен чабарга да төшмәде. Шулай итеп кенә алып калып булыр дип уйлаганнардыр инде, бахырлар. Булмады... Машина кертеп чаптырдылар да, печәнен җыеп алуга сукалатып та ташладылар. Үзебезнекеләр риза булмагач, Сарылыдан килеп сукаладылар... Теге елларда... синең арттан йөргән егет... Алмаз сукалап китте болыныбызны. Су эчәргә дип кергән иде, бирмәдем, суым юк, дидем. Йөзенә күтәрелеп карыйсым килмәде, йөзенә...

Ике арадагы күпер дөбердәп, җимерелеп, ишелеп төште. Аннан бөтерелә-бөтерелә, ярларга бәрелә-бәрелә, хатирәләре, төшләре, мең йолдызлы күкләре белән кайнап торган тормыш упкынына очты. Мин аны туктата алмадым...

Мин килеп кергәндә, Алмаз бер якта берүзе гырылдап йоклап ята иде. Артымнан ук кебек атылып әнисе килеп керде.

— Уята күрмә, йокласын,— диде ул, кабаланып, малаен ниндидер

афəттəн сакларга телəгəндəй җил-җил килеп.— Йокласын. Кичə көне буе Күлле болынын сукалады. Санын җыялмый, эт булып кайтып егылды. — Шунда гына мине яңа күргəндəй, гаҗəплəнеп карап тора башлады. — Бəрəч, син кем буласың соң? Бер дə күз күргəн кешегə охшамагансың.

— Мин сезнең авылныкы түгел.

— Шулайдыр шул, шулайдыр... Безнең Алмазны кайдан белəсең соң?

— Мин аны белмим. Мин аны белəм дип йөргəн идем. Белмим икəн...

— Менə тагы, иске авыздан яңа сүз... Белмəгəч, нигə кирəк соң ул сиңа?

— Əйе шул...

Мин, төштəге кебек салмак адымнар белəн, ишеккə таба китəм.

— Туктале дим... Соң, сорый килгəч, белмəгəн кешең түгелдер? Алмаз, Алмаз дим. Əнə сине сорап килгəннəр анда. Бу кадəр дə үлек йокысы белəн йокларсың икəн!

Диваннан ыңгырашып кына, авыр гəүдəсен чак сөйрəп, бер ир-ат күтəрелə. Озак йоклауданмы, башка сəбəпме — күз төплəре шешенеп беткəн, карашы сүрəн, йөзе караңгы. Чыннан да, мин бу кешене бөтенлəй белмим бит. Китəргə кирəк булган миңа моннан башта ук. Нишлəп килдем соң əле мин монда? Болын!!!

— Син сукаладыңмы болынны?

Алмаз, каш астыннан гына сөзеп, əллə нинди битарафлык, салкынлык белəн миңа карый. Кинəт аның күзлəреннəн ниндидер дулкыннар йөгереп үтə, йөзендə — гаҗəплəнү, сөенү, уңайсызлану.

— Алсу! Син бит бу, Алсу?!

— Ə... син буласыңмыни инде ул Алсу. — Таза апа да канатларын җилпи-җилпи минем янга килə. — Телендə гел син идең инде элегрəк. Ул урысча язган хатларың белəн баз өсте тулы.

— Əни!.. Бар син, чəеңне кара əле, əни. — Монысын Алмаз əйтə. Бу инде башын куллары белəн каплап, анасының типкəлəгəнен көтеп утыра торган малай түгел. Бу — бөтенлəй икенче кеше...

— Соң, ярар, ярар. Чəй эчеп китəрсең, кызым, чəй куя торам.

Без бүлмəдə икебез генə калабыз. Алмаз, кулларын җəеп, минем каршыма килə. Менə ул инде миңа бөтенлəй якын, менə шешенгəн йөзе миңа таба иелə, аракы катыш тəмəке исе йөземə килеп бəрелə.

— Болынны нигə сукаладың, Алмаз?!

— Син һаман шулай җүлəр икəнсең əле. — Алмаз, диванга ава да, кычкырып көлəргə тотына. — Вот, кешегə əйтсəң, кеше ышанмас, йөргəн кызың, ничə ел күрмəгəн йөргəн кызың, җаным, дип кочакка ташланасы урында, шул черегəн болыннан башласын əле сүзен.

Ул, башын артка ташлап, шаркылдап көлə дə көлə. Көлгəн саен, муенындагы төере ямьсез итеп сикереп-сикереп куя. Минем тизрəк чыгып йөгерəсем, бу карлыккан көлү тавышыннан, бу шешенгəн йөздəн, бу чит кеше янынннан качасым килə. Мин инде аның, кушалар икəн, болынны гына түгел, ярты дөньясын шулай актарып, сукалап чыгасына ышанам. Миңа хыялый үсмерчагым, алсу төшлəрем, беренче мəхəббəтем, шуңа шаһит булган мең йолдызлы күк каршында оят. Мин, артыма да борылып карамыйм, урамга чыгып йөгерəм. Мине аның шаркылдап көлгəн авазы куа килə, бер кырыйдан, еламсырап, кыргый үсмер чагым йөгерə. Бу тупас көлү инде бөтен болын өстенə, бөтен дөньяга җəелə. Ул инде минем җанымны да басып китмəкче була. Юк!.. Ишеклəр биклəнə, дөнья тынып, телсез-өнсез кала, елганың теге ягында үсмерчакның үрсəлəнеп сулкылдаганы ишетелə. Хəтта аңа да инде кайту

юлы юк. Ишекләр бикле... Хәтта хыялларга да, хәтта төшләргә дә. Хәтта үз-үземә дә. Тагы күпме сөйрәп йөрисе булыр икән бу җансыз тәнне... Арыдым бит мин, арыдым...

Бишенче курсны тәмамлаганда, миңе бер егет белән таныштырдылар. Әнинең дуслары тырыштылар. Әни үзе инде минем язмышым өчен артык борчылмый, без тыныч кына, ярсып кабынып китми генә яши идек инде. Әни әле шактый актив, бер дә кешедән калышырга теләми, бер дә картайган булып күренергә теләми иде. Мин генә бөтен нәрсәгә битараф, мин генә әллә яши, әллә юклый идем.

Башта мин ул егет белән бөтенләй кызыксынмадым. Килә, утыра, нидер сораша, мин нидер җавап бирәм. Барысы да өстән-өстән генә, барысы да төштәге кебек кенә. Җаным бикле. Миңа шулай җайлырак. Мин мең кат кабыкка уралган.

— Ә мин әнә теге йортта гына яшим...

«Теге соры стена артындамы? Шулай янәшә генәме? Ә синең тәрәзәләреңнән нәрсә күренә иде?»

— Әнә теге йортның соры стенасы.

— Синең аны кайбер вакытта төртеп җимерәсең килми идеме?

— Мин аны җимергәләп тә карадым. Астан ничә кирпечен чокып кердем мин аның...

Миңа кызык булып китә. Минем беркайчан да стена җимереп караганым булмады. Ә бу егет, әнә, җимереп карадым, ди.

— ...Әни, теге, безгә килгән егетнең исеме ничек иде аның?

— Ничә көн сөйләшеп утырып, исемен дә белмәдеңмени соң?

— Мин... кызыксынмадым да...

— Менә, кызыксынмыйсың да шул. Я алла, карт кыз булып утырып калырга ахры синең исәбең.

— Миңа барыбер.

— Хәзергә барыбер ул. Соңыннан бер дә барыбер булмас. Ничек үз-үзеңне ашаганыңны күрәм бит мин.

— Ә нишлик соң, әни?

Мин, бөренче тапкыр, нишлик соң, дип, киңәш сорыйм. Минем, беренче тапкыр, нидер эшлисем, нидер үзгәртәсем килә.

— Сөйләш менә шушы егет белән. Бик практичный кеше күренә.

Әни сөйли, ә минем күз алдыма ул егет түгел, һаман теге соры стена килеп баса. Мин инде кешеләрнең йөзләрен дә хәтеремдә калдыра алмыйм. Барысын да оныта барам кебек.

Ә ул онытмаган, ә ул көн саен килә минем яныма. Исеме дә бар икән — Гомәр. Инде институт тәмамлаган, зур заводларның берсендә баш инженер булып эшли икән. Әниләр, аның дус-ишләре аһ-уһ киләләр, менә дигән пар инде, ничек бер-берегезне күтәп ала белдегез, дип, безнең янда йөгерешеп йөриләр. Гомәр бик игътибарлы, бик төгәл, әдәпле кеше. Миңа аның кайгыртучанлыгы ошый. Миңа кайвакытта рәхәт тә булып китә аның янында — син тыныч кына, бәргәләнми, ярсымый гына яшисең, синең турыда кайгыртучы бар, сине үз ышыгына, үз канат астына алучы бар...

Әниләр инде туй турында сөйләшәләр. Барысын да Гомәр үзе башлап, үзе оештырып йөри. Миңа барыбер. Төштәге кебек кенә. Мин, әйтерсең лә, читтән генә күзәтеп торам... Кемгәдер туй күлмәге киертеп карыйлар, әнә, кемнедер, кулларыннан җитәкләп, загс баскычыннан алып менәләр. Әнә халык белән тулы туй мәҗлесе, барысы да, ду килеп, «Горько!» кычкыралар. Әнә ап-актан киенгән ап-ак бер кыз бала, әкрен генә торып баса да, янындагы егеткә карый. Егет, аны сак кына кочаклап ала да, иреннәренә нелә.

Шул чакта мин, сискәнеп, күзләремне ачам. Мин бит бу! Ә ул, миңа

таба иелгән дә, иреннәремнән үбә! Мин бит бу кешене бөтенләй белмим, мин бит барысын да төшемдә генә күрәм дип уйладым. Мин бит аны бөтенләй яратмыйм! Чыгарыгыз мине бирәдән. Минем туем түгел бу, түгел! Яратмыйм мин аны, яратмыйм, яратмыйм!

Әни кулларыма асылынып елый. Икенче ягыма ап-ак булып агарынган Гомәр килеп баса. Мине тынычландырмакчы була, «син арыгансың, Алсу!» дип, әкрен генә чәчләремнән сыйпый. Һәм мин ышанам! Үземнең бик нык арыганлыгыма ышанам, Гомәрнең Гомәр булуына ышанам, бу туйның да үз туем булуына ышанам. Ышанам да, Гомәрнең киң күкрәгенә капланып, үксеп-үксеп еларга тотынам. Елаган саен җиңеләя барам, җиңеләя барам... Егерме ике ел буена күңелдә утырган юшкын, туй кичемдәге күз яшьләреннән эреп, юкка чыга. Миңа җиңел булып кала. Мин, елап туйган сабый баладай, беренче тапкыр Гомәрнең кочагында арып йокыга китәм...

Мин Гомәргә иялэнергә тырышам. Гомер буе ялгыз бәргәләнү халәтеннән бик арыган идем инде мин. Минем дә кемгәдер сыенасым, иркәләнәсем, бик авыр вакытларда, алдына капланып елыйсым, кешеләр кебек бер рәхәтләнеп көләсем — яшисем килә иде!

Өйләре янәшә генә булса да, Гомәр бездә яшәп калды. Анда аның тагы ике энесе бар иде. Әнинең дә мине белмәгән-күрмәгән җиргә чыгарып җибәрәсе килмәде, ул һаман минем тынычланып, Гомәргә иялэнеп китә алуыма ышанмый иде ахрысы.

Мин дә, укуымны тәмамлап, зур гына бер оешмага тәрҗемәче булып урнаштым. Биредә дә Гомәр булышты, кемнәр беләндер алдан сөйләште, җайлады, һәм мин, иптәшләремнең күбесе авылларга укытырга китеп барганда, Казанда җайлы гына урнашып калдым. Мин моңа уңайсызланмадым, җаным да борчылмады. Мин бу хәлләрнең барысын да шулай тиешле итеп кенә кабул иттем. Мин инде күп нәрсәләргә, шулай тиеш, дип кенә карый башладым. Мин, югары белем алып, чит телләр буенча белгеч булып чыктыммы? Бу — шулай тиеш. Зур дәрәҗәле, акыллы бер егеттә кияүдәме? Бу да шулай тиеш. Ниһаять, танылган бер оешмада тәрҗемәче булып эшли башладым. Димәк, монысы да шулай тиеш.

Көн саен иртә белән Гомәр мине, машинасына утыртып, эшемә озатып куя. Кич белән килеп ала. Ял көннәрендә без, икәү генә, Идел буйларына, урманнарга чыгып китәбез. Гомәр минем һәр капризымны үти. Аңа минем белән бала-чагадай мәж килү ошый, ахрысы. Ул мине инде машина йөртергә дә өйрәтте. Мин, урман юлында үсеп утырган кыңгырау чәчәкләрен таптатып (кулда руль барында күренмиләр икән алар!), Гомәрне куркытып та, сөендереп тә, кыргыйланып көлә-көлә әллә кая ашкынам. Минем кулда хәзер вакыт машинасы! Минем кулда заман үзе! Төссез, бәйрәмсез, сөелүсез үткән яшьлегемә үч итеп, мин бүген ашкынып яшәп калырга телим. Чәчәкләрнең машина тәгәрмәче астында сытылып, пычранып калуларын мин күрмим! Машина тәрәзәсенә ялгыш килеп капланган күбәләкнең өстенә мин салкын су сиптертәм! Элек миңа карата дөньяның карашы барыбер иде, хәзер мин дөньяга барыбер дип карыйм. Мин үземнең җанымнан, нечкә күңелле чакларымнан, үзем дә белмәгән тарафка, ләкин минем өчен барыбер булган тарафка качам. Дөньяның мең төрле соравыннан, гаҗәпләнгән күкнең мең якты йолдызыннан, үземнең тетрәп торган мең төрле халәтемнән бер халәткә — тыныч битарафлык халәтенә оча идем ахры мин.

Мин Гомәргә, үзебезнең тырышып-тырышып, акыл белән төзегән тормышыбызга карата да артык тыныч, битараф була башладым. Безнең барысы да артык тыныч, артык гадәти иде! Безнең барысы да бар иде — һәм ниндидер коточкыч шомлылык, шул тук шомлы тынлык миннән, сезнең арада бернәрсә дә юк, дип, мыскыллап көлә кебек иде.

Мин, хатын-кызларга хас сиземләү, курку белән, бу ялтырап торган шома буш тормышыма ябышмакчы, бозны — ут дип, битарафлыкны — тынычлык дип, яшәргә тырышуымны яшәү дип исбат итмәкче булдым. Авылларга эшкә киткән группадаш кызлар очрашуларга үзләре кебек үк гади, үзләре кебек үк шаян ирләрен, нәкъ үзләренә охшаган түгәрәк битле балаларын җитәкләп килделәр. Мин соңгы елларда ул очрашуларга да бармас булдым. Мин хәзер инде алардан бик еракта, елавым да, көлүем дә барып җитә алмаслык бер чит-ят дөньяда идем. Бу хәтта минем үз дөньям да түгел иде. Бу салкынлык, бу битарафлык хәтта минем үз җанымны да басып алган, җаным өшеп йокыга киткән, инде аны уятырлык көч, инде аны тетрәндерерлек хис дөньяда бөтенләй дә булмас кебек...

Эшемнән мин юаныч та, бу халәтемнән котылу, онытылу мөмкинлеге дә таба алмадым. Мин чит телләрдә тутырылган техник документларны рус теленә тәрҗемә итә идем. Бу иҗади эш тә түгел иде, илһамланып, янып, борчылып башкарыла торган хезмәт тә түгел иде. Кайвакытларда миемнең бер почмагында, барысын да ташларга да, мәктәпкә укытырга китәргәме әллә, дигән фикер дә уянып куя иде. Ләкин мин болай эшләргә дә курка идем, гомер буе кешеләрдән читтә, үз дөньяма гына бикләнеп яшәү мине инде алардан бөтенләй айерган, берәр чарасын күрмәсәң, тиздән дөбердәп өстемә җимереләчәк бу шомлы тынлыкны үзгәртергә мин үземне әзерлексез, чарасыз итеп тойдым. Эшкә бардым, эштән кайттым... Тагы эшкә бардым, эштән кайттым... Шушы төссез, хыялсыз, буш түгәрәктә әйләндем тә әйләндем. Бу түгәрәкнең очкырые булмас кебек тоела башлады. Әле утыз яшемә дә җитмәс борын, мин инде арыган идем, минем, тормышымның алдыннан түгел, артыннан сөйрәлеп барырга да көчем, теләгем юк иде...

Башта бәхетеннән кая басарга белми йөргән әни, минем тагы үз дөньяма китә баруымны күреп, мине җиргә төшерергә, уятырга тырышып карады. Ул минем рухи ялгызлыгыма, бөтен дөнья шаулап, актарылып торганда, минем генә һаман шуңа кушылып актарыла, яна алмавыма гаҗиз булып, инде өметләрен дә өзеп, миңа дә беренче кат миңа ялварырга тотына:

— Нигә дөньялардан ваз кичеп йөрисең син, нигә?! — дип башлый ул сүзен. Әни, картайган саен, һаман үз теленә күчә бара. Французча, инглизчә түгел, русча да ул миңа хәзер сирәк эндәшә. Каршыма килеп утыра да татарча гына әрли дә әрли. Шундый вакытларында әбиемә дә охшап китә бераз. Өй тутырып хәзер дус-ишләрен дә җыеп утырмый. Һаман, аһ-вах килеп, минем артымнан тагылып йөри.

— Нигә күзләреңне бер ноктага текәп, кичләр буе ялгызың утырасың? Чык кеше янына, күңел ач. Нәрсәләр җитми сиңа, и бала?.. Кияүне дә тәмам биздереп бетерәсең бит үзеңнән.

Әйе, кичләрен мин хәзер ялгыз идем.

Баштарак әле без Гомәр белән дус-ишләр янына, мәҗлесләргә дә еш йөри идек. Миңа, моңа кадәр андый компанияләрдә булмаган кешегә, бу мәҗлесләр бик шау-шулы булып, бик ялыктыргыч булып тоелалар иде. Ә Гомәр? Гомәр андый мәҗлесләрнең күркенә әйләнә, бөтен кешене авызына каратып, үз тирәсендә җырлатып-биетеп, үзе дә егылганчы күңел ачып яши. Мине дә үзе белән җитәкләп йөртә, биетә, каршына бастырып җырлата, минем арыганымны, ялыкканымны уйларга да теләмичә, күп кичләрен әнә шулай уздырырга күнегеп китте.

Ләкин бер мәҗлестән соң мин Гомәргә ияреп йөрүдән баш тарттым.

Җәйге кичләрнең берсендә булды бу хәл. Гомәрнең ниндидер иптәше безне туган көн мәҗлесенә чакырды. Әллә нинди тыныч, моңсу кич иде. Күңелләрне иләсләндереп, Казанка ягыннан бакалар кычкырганы ишетелә. Нәкъ авылдагы кебек... Нәкъ әрәмә буендагы кебек. Әрәмәне

корыткач, бакалары кая китеп бетте икән? Әбием хатларында, болынга бәрәңге утыртып карадылар, тик үсеп китә алмый, тамырында чери, дип яза. Дым артык күп, ди, күз яше, моң артык күп бәрәңге өчен, ди... Гөл үсәсе урын иде шул ул, гөл...

Күптән авыл турында уйлаганым, болынны исемә төшергәнем юк иде. Кинәт миңа, үземнең бу канәгатьсезлегем, ясалма битарафлыгым авылга кайтып, бер болынны күрсәм, бетәр кебек тоела башлады. Сукаланган булса да, бәрәңге утыртылган булса да! Бу теләк миндә шулкадәр көчле иде, мин бүген кич буласы мәҗлес турында онытып, Гомәргә, авылга кайтыйк, дип ялына башладым. Менә хәзер үк, машинага утырабыз да, авылга кайтып китәбез! Мин бит синең белән күпме йөрдем ул җаным сөймәгән мәҗлесләреңә, син дә, бер тапкыр булса да, тыңла мине?!

Гомәр, минем бу теләгемне ишеткәч, шаркылдап көлә башлады. Аннан, кулларымнан өстерәп, инде барабан тавышларыннан гүләп торган ресторанга таба алып китте. Ләкин минем анда керәсем килми иде! Ясалма елмаюлар, начальниклары килеп кулымнан үпкәндә, шуңа шатланган кыяфәттә торулар, ярты төнгә кадәр сер бирмичә, кешедән калмыйча, аяктан егылганчы бәргәләнүләр — арыткан иде мине болар... Минем күңелем тормышның бу ритмын кабул итәргә теләми иде.

Кемнәрдер килеп кулларымнан үпте, кемнәрдер төче комплиментлар әйтеп узды, кайсыларыдыр биергә дә чакырдылар бугай. Ярымкараңгы залда тирләгән чит куллар калтыранып аркам буйлап шуыштылар, минем бу дөньяда булмавымны, исергән дип уйлап, кыюланып китеп, тыннары белән муен, күкрәк тирәләремне көйдерделәр... Ире хатынын, хатыны ирен күрмичә, музыка ритмына чайкалып, чит гәүдәләргә сыруштылар, тәннәре, хисләре белән инде ничәнче тапкыр бер-берләренә хыянәт иттеләр, шуның белән ләззәтләнделәр.

Мин кинәт үземнең зал уртасында ялгызым басып калганлыгымны тойдым. Юк, янымда Гомәр дә бар икән әле. Ул мине бирегә җитәкләп чыгарып куйган. Нишләп мин биредә басып торам соң әле? Тынып калган бу ят карашлар нәрсә көтә миннән?

Гомәрнең... — җырлый, — ...дигәнен ишетәм. Әнә ул елмаеп тагын кабатлый. «Хәзер минем хатын сезнең өчен җырлый... Люб-бой телдә!»

Кызмача зал аның бу сүзләренә аһ иткән була. Кайсы немецча, инглизчә, кайсылары, давай, үзебезчә, русча гына җибәр, дип кычкыралар. Мин өйдә Гомәр өчен шулай төрле телләрдә үзем уйнап җырлый идем. Ләкин мондый халык алдында...

Гомәр җиңелчә генә минем беләгемне кыса. Әйдә, янәсе, күрсәт әле бу деревняларга үзеңне! Ә мин һаман, төштә кебек, айный алмый басып торам. Зал инде тынычсызлана башлый. Минем һаман бер ноктага текәлеп басып торуымны күргәч, чыш-пыш килә башлыйлар.

— Исерек бит ул,— ди ун бармагына ун алтын балдак кигән бер хатын.

— Әллә соң... тегеләйрәкме бераз? Җитеп бетмиме? — Монысын, биегәндә мине кысып-кысып карап та, күзләремдә уяну, теләк чаткылары күрмәгән юан ир әйтә.

Мин һаман уртада басып торам. Карашлары белән барысы да миңа төртеп, көлеп узалар. Алар таралышалар бугай инде. Гомәр җилтерәтеп мине читкә алып китә.

— Слушай, кайда очасың син?! — ди.

— Мин... болында йөрим... Ул әле сукаланмаган да, ул әле шау чәчәктә утыра...

— Син нәрсә? Әллә мин күрмәгәндә эчеп куйдыңмы бераз?

— Әйе... Чык бөртекләрен тезләнеп эчтем... Салкын иделәр... Чиста иделәр...

Безнең янда басып торган хатыннар пырхылдашып көлешә башлый-лар. Иелеп, ирләренең колакларына нидер әйтәләр. Тегеләре әллә кыз-ганып, әллә кызыксынып, Гомәргә карыйлар. Мине инде биергә дә беркем чакырмый. Мин аларның барысы өчен дә сәер, җүләр бер хатын идем. Мин бу сәерлегем белән аларны өркетә, читләштерә идем ахры...

Гомәр юл буе миңа эндәшмәде... Казанка буенда шашып-шашып бакалар кычкыра... Йөрәгемне рәхәт оетып, елыйсыларымны китереп, мине тагы болын үзенә тарта, чакыра башлады... Гомәрдән ерагайган саен, аңа, андагы үз-үземә ныграк якыная барам. Үземнең Гомәр янә-шәсендә ничә еллар буе бары тик тырышуымны гына — яшәргә тыры-шуымны, яратырга тырышуымны аңлыйм. Әмма бу яшәү дә, ярату да түгел иде. Түгел иде!! Түгел иде!!!

Башта Гомәр сынды. Ул бу салкынлыкны, бу киеренкелекне күтәрә алмады — кичләрен өйгә бик соң кайта башлады. Бөтенләй кайтмый калган төннәре дә ешайды. Элеккегә кебек ул инде минем белән шаяр-мый иде, мин дә аның бу уйнауларыннан, бу ялтыравык тыныч тормы-шыннан туйган, арыган идем. Кайтмый калган кичләрендә дә эзләп ар-тыннан чыкмадым, ничек минем тормышыма сиздерми генә килеп кер-сә, шулай сиздерми генә китеп тә баруын аңладым, тойдым. Ләкин, тукта, дип әйтерлек көчем, кабын дип әйтерлек хисем юк иде. Бу ясал-ма ут иде, бу ясалма тормыш, ясалма мәхәббәт иде...

Ул кайвакытларда әле мине элекке кебек кочып алмакчы, ирennә-ремә орынмакчы була. Ләкин миндәге салкынлыкны, миндәге битараф-лыкны күрә дә, тешләрен кысып, йөзен читкә бора.

— Мин кайтмаганга да борчылмыйсың, яныңа ятмаганга да сүз әйтмисең, җаның юкмыни соң синең?! — ди ул ярсып, әллә салкын стенага, әллә миңа...

— Юк минем җаным... Күптән үлде инде...

— Нигә болай булды соң әле бу, Алсу?!

— Сиңа чыккан көннән... җаным үлгән иде минем. Мин... тырыштым гына... Иялөнергә тырыштым... Яшәргә тырыштым, яратырга тырыш-тым...

— Әмма син минем белән бәхетсез булмадың бит?!

— Бәхетле дә булмадым...

— Синең бар нәрсәң дә бар иде!

— Һәм... бер нәрсәм дә юк иде...

— Нәрсә кирәк соң сиңа, нәрсә?!

Ул, ярсып, урыныннан сикереп тора. Күзләрендәге боз сөңгеләре белән мине салкын стенага кадаклый.

— Нәрсә кирәк тагы сиңа? Ник дәшмисең? Рәхәтеңә, маеңа чыдый алмыйсыңмы?

— Миңа... мәхәббәт кирәк... Чабылмаган болын кирәк... Мин шул болын буйлап йөгерер идем... йөгерер идем... Ә анда — упкын... Төпсез упкын... Бары ак томанга гына уралган... Томан булганга гына белеп булмый аның упкын икәнен... Упкын ул, упкын...

— Әллә инде акылыннан шашкан? — Ул гаҗәпләнеп, шикләнеп, миңа карый.— Соң син... тере дурак икәнсең бит. Я хода?! Ничек яшә-дем мин синең белән җиде ел?!

Аннан мендәрләрен тиз-тиз генә җыештыра да, диванга барып ята. Ул инде шуннан, караңгыдан гына минем өскә әллә нинди куркыныч сүзләр яргыта... Сиңа психиатрга күренергә кирәк, ди, теләсәң, иртәгә үк үзем җитәкләп алып барам, ди. Мин туй көнендә үк бераз шиклән-гән идем инде, ди. Син «Горько!» кычкырып үбешкәндә дә аягүрә басып йоклый идең, күзеңдә нур юк иде, мәет күзләре кебек иде күзләрең, ди. Җиде ел дурак белән торганмын бит, ди дә, урыныннан сикереп торып, ваннага кереп китә. Җанымны әле кайнар су агызып пешерә, әле боз-

дай су белән калтырата. Өстемә, керле киемнәре белән бергә, соңгы сүзләрен ыргыта.

— Валлаһи, чирканам бит мин синнән хәзер. Кешегә әйтсәң, кеше ышанмас, җүләр хатын белән җиде ел тордым дигәнгә. Җүләрләр йортында бит синең урының! Җүләрләр йортында! Яшисең килсә, бар иртәгә үк врачка. Может, алып кала алырлар...

Үзе ашыга-ашыга өстенә киенә, үзе соңгы ташларын атып калырга тырыша. Утны яндырып, портфеленә нәрсәләрнедер җыештырып сала да, стенага сеңеп беткән бу үле гәүдәгә күтәрелеп тә карамыйча, өйдән чыгып китә...

Аның артыннан ук бүлмәгә ашыгып әни килеп керә. Ул, минем күзләрем йомык булгач, йоклый дип белә ахры, калтырый-калтырый мине уятырга ашыга.

— Кызым, тор әле, тор. Төн уртасында кияү чыгып китте бит!

Мин дәшмим. Минем күземне дә ачасым килми. Җанымны таптап чыгып киттеләр ни, тәнемне ни. Миңа инде барыбер. Минем уянмыйча, уянмыйча йоклыйсым килә...

— Нинди җан белән йоклап ятасың син, кызым?! — Әни минем янәшәмдәге буш урынга каплана да, үксеп елый башлый. — Сер бирмәскә тырышып, мин ирсез гомер иттем. Үзем генә белдем, үзем генә белдем хәлләремне! Инде син дә шул көннәргә калырсыңмы икәнни?! Уян, бар, чык кияү артыннан!

Нигә кагылалар миңа?! Нигә минем уянуымны таләп итеп, җаным өстендә чаң кагалар! Минем уянасым килми!! Мин уянырга куркам! Үземне көтеп торган ялгызлыктан, бушлыктан куркам. Киләчәктән куркам! Җибәрегез мине үткәннәремә! Җибәрегез хәтеремдә мәңге чабылмаган чәчәкле болыныма.

— Әни! Алып кайт мине авылга! Минем үземнең анда кайтып житәрлек хәлем юк инде.

Әни тавышсыз гына елый. Үзе әллә миңа, әллә артындагы соры стенага текәлгән, йөзендә бер хәрәкәт юк, ә яшьләре агалар да агалар...

— Әбиемне бик күрәсем килә... Алып кайт мине авылга.

Әни сулкылдап урынга ава.

— Әни, мин бер сүз дә әйтмәс идем анда. Болынга да йөгермәс идем, урманда да адашмас идем. Сүзеңне гел тыңлар идем. Әбием янында гына утырыр идем.

Әни елап шешенгән йөзен күтәрә. Әллә кайдан, тормыш төбеннән үк, тонык, ят тавыш ишетелә...

— Әбиең... үлде бит инде, балам... Үзең ни үле, ни тере йөри идең... Шуңа күрә әйтмәдем...

Әбием?!!

Агач орчык күз алдымда очынып бөтерелә-бөтерелә дә, тәгәрәп, идәнгә барып төшә. Бәгырьләрне зыңгылдатып, җир белән күкне тоташтырып торган соңгы кыл шартлап өзелә. Бөтен дөньяны, инде аралап чыга алмаслык итеп, ап-ак томан урап ала. Йөземне каплап, шул томан арасына ташланам. Каршы искән җил минем озын кара чәчләремне кирегә куа, алар, мин атлаган саен, бер очып китәрдәй булып күккә күтәреләләр, бер нәүмизләнеп, хәлсезләнеп, минем муеныма, җилкәләремә уралалар. Ә мин һаман йөгерәм дә йөгерәм... Үзем чәчәкләр арасыннан йөгерәм, үзем бөтен җаным-тәнем белән өстән шомлы болытларның түбән агылуларын, миңа таба якынлашуларын сизәм. Куллары өметләнеп алга сузылган, миңа һаман арырак, болынның әнә теге башындарак, миңа таба да кемдер шулай йөгереп киләдер кебек тоела. Мин инде арыйм, хәлем бетә, ләкин туктый да алмыйм, туктасам, теге авыр соры болытлар куып җитәрләр дә... Куып җитәрләр дә... Болын искиткеч зур да, чәчәкле дә, матур да, шомлы да... Ә мин һаман бер

ялгызым йөгерәм! Кая соң ул кочагын җәеп, минем каршыма йөгерергә тиешле кеше!!! Килеп капланыр идем шуның көчле кулларына, качар идем шул шыксыз салкын болытлардан...

Мин инде шушы ялгыз йөгерүемнән мәңге туктала алмаячагымны аңлаган хәлдә, котылгысыз рәвештә һаман текә яр буена якынлашам! Ләкин мин, нигәдер, курыкмыйм. Мин инде бик арыган, миңа инде барыбер. Инде упкын читенә килеп җитәм дигәндә, инде ап-ак томан арасына соңгы тапкыр ташланам дигәндә, кинәт яр буенда мин а н ы күрәм. Ул нәкъ минем юлым өстендә тора, упкын белән ике арага кыя булып баскан да, мине һәлакәттән саклап калырга теләгәндәй, кулларын як-якка җәеп җибәргән. Тик нигә миңа таба килми соң ул, томан арасында бер күренеп, бер юкка чыгып, нигә һаман бер урында басып тора?

Тыным бетеп, туктала да алмыйча, һаман упкын читенә якынлашам. А н ы да инде якыннанрак күрәм. Җилдә тузгып торган ап-ак чәчләр, акыллы, моңсу күзләр. Ул минем үзенә таба йөгереп килгәнемне күрә, ул инде мине болынның әнә теге башыннан ук күреп алгандыр — әнә бит, күзләрендә, йөзендә — гел көтүләрдән генә торган ап-ак арыганлык.

Минем аны әйләнеп узарлык көчем дә, теләгем дә юк. Гомер болынымнан ялгызым йөгереп килгәнем хәлендә, туктала алмый аның күкрәгенә килеп капланам. Без инде упкын читендә икәү басып торабыз. Үткәне, киләчәге, бүгенгесе бергә буталып, упкын читендә вакыт туктап кала...

— Уян!

Кемнәрдер миңа ялварып эндәшә.

— Уян!

Мин күзләремне ача алмыйм. Аларга ак томан сарылган. Тәнемне дә ап-ак томан баса. Минем инде бу томаннан араланып чыгар көчем дә юк. Әкрен-әкрен эрүемне, юкка чыгуымны тоям. Минем инде хәтта бер җирем дә авыртмый да, миңа инде барыбер...

Шулчак... О могҗиза! Керфекләремдә кемнеңдер кайнар бармакларын тоям. Аннан ул бармаклар әкрен генә минем битләрем буйлап шуып үтәләр, иреннәрем тирәсендә бераз тукталып торалар да... юкка чыгалар. Мин, сискәнеп, күзем ачам... Үземә таба иелгән ап-ак чәчле, ак халатлы бер ир-атны күрәм. Минем бит инде аны кайдадыр күргәнем бар иде. Упкын читендә!.. Упкын читендә күрдем бит мин аны! Чәчәк, болын исе дару исе больница исе белән бутала, ак халатлы кеше бер якыная, бер ерагая. Мин куркынып күзләремне йомам, ләкин зиһенем инде уянган, җаным, почмакка поскан кош баласыдай, бу ак халатлы кеше янында куркып дерелди, бәргәләнә иде.

— Күзләреңне йомма, зинһар... Бик озак ачмадың бит син аларны. Алсу, ишетәсеңме мине?

Ә ул мине каян белә икән? Әллә күзләремне ачып карыйммы икән үзенә? Мин, курка-курка гына, күзләремне ачам. Ап-ак чәч... Ап-ак халат. Арыган, сабыр йөз. Ә күзләре шундый моңлылар...

— Сез... кем буласыз?

— Мин синең дәвалаучы врачың. Мин синең күзләрең ачылуны бик озак көттем.

Врачың? Димәк, мин больницада?

— Минем бит бер җирем дә авыртмый. Нигә больницада соң мин?

— Син... бик озак йокладың... Сиңа уянырга кирәк иде.

Йөрәгемне жу иттереп, тәрәзәсе соры стенага чыга торган тар бүлмәм исемә төште. Битемә керле киемнәрен ташлап чыгып киткән ирем, буш урынга ятып елаган әнием күз алдыма килде. Шул дөнья күз алдыма килү белән, мин үземнең тагы бушлыкка очуымны тойдым. Уп-

кын төбенә бәрелеп, челпәрәмә киләм дигәндә генә, керфекләремдә тагы ул кешенең җанлы бармакларын сиздем. Алар җиңелчә генә дерелдиләр, минем җеп очында гына эленеп торган гомеремә җан өрергә теләгәндәй, керфекләремә нидер сөйлиләр, нидер сөйлиләр... Үзе дә миңа эндәшә ахры, мин инде аның тавышын таный да башладым...

— Сиңа уянырга кирәк, Алсу, уянырга.

— Минем уянасым килми... Мин уянырга куркам... Минем көчем юк... уянгач яшәрлек.

Җавап юк. Битләремнән иркәләп сыйпаган бармаклар да юкка чыга. Керфекләрем, куркышып, упкын читенә ябышалар... Аска очмас өчен... Ул кешегә тагы бер күтәрелеп карар өчен...

— Мин сезне башта... алла дип белдем. Сез ап-ак. Мин аллаларны сезнең кебек була дип уйлаган идем.

— Мин врач кына, Алсу, алла ук түгел. Син терелеп аякка бассаң, бәлки үземне алла итеп тә хис итеп куярмын. Минем сине уятасым килде... Мин сине уятырга тиеш идем...

Әллә кайдан, тавыш-тынсыз гына, әни килеп керә. Әнием түгел бит бу, әби! Әбием!! Мин, сикереп тормакчы булып, алга таба тартылам... Күз алдымда яшен утлары ялт-йолт килеп ала да, мин тагы урыныма егылам. Колагыма әниненме (әллә әбиненме?) еламсырап ялварган тавышы ишетелә...

«Зинһар, алып кала күрегез баланы»...

Алып кала күрегез... Алып кала күрегез... Ә мин тагы китеп барам... Башта, яланаяклап, атылып болынга килеп керәм. Сукаланган кара болын, кантарлары белән үкереп, минем өскә килә... Мин, тыным бетеп, урманга кереп адашам... Мине урманнан да куып чыгаралар... Ул да булмый, киемнәрем белән, актарылып, күбекләнеп аккан кап-кара суга ташланам... Бөтен җирем су... Әллә каян йөгереп Алмаз килеп чыга. Тракторына утыра да, мине куа башлый... Үзе шаркылдап көлә. Инде куып җитә, инде таптый дигәндә, Гомәр килеп чыга да, кулларымнан өстерәп, ялтырап торган боз өстенә алып кереп китә. Мине әйләндерә-әйләндерә дә, боз өстендә ялгызымны ташлап, көлә-көлә чыгып йөгерә.

Кинәт ак томаннар арасыннан у л килеп чыга. Мине җиңел генә күтәреп ала да, упкын төбеннән өскә алып чыга башлый. Үзе мин ишетерлек итеп кенә пышылдый.

— Син уянырга тиеш... уянырга тиеш...

Минем гомеремдә беренче тапкыр уянасым, уянасым да... үземне уятырга тырышкан кешене күрәсем, алдына тезләнеп, коткаруын үтенәсем килә. Ачам мин бу күзләремне, барыбер ачам! Мең кат ак томан басып китсә дә, мин аларны ачарга... мин... яшәргә тиеш!

Я алла! Әле ярый ул китмәгән. Минем ябыша-үрмәли упкын төбеннән менеп килүемне, ыңгыраша-саташа яшәргә теләп аваз салуымны ул ишеткән! Менә ул минем хәлсез кулларымны үз кулларына алды, минем үткәнемдәге барлык газаплы кичерешләремне дәшми-тынмый гына үзенә кабул итте...

— Син яшәргә тиеш, Алсу!

— Яшим мин, яшим! Тик сез генә... китмәгез. Алмагыз миннән кулыгызны. Мин үзем генә калырга куркам. Ул төпсез упкын мине тагы үзенә йотар да, мин инде аннан мәңге чыга алмам кебек...

Мин хәзер күзләремне йомарга куркам. Күзләремне йомсам — ул юкка чыгар кебек. Аның кулларын да җибәрмим. Җибәрмим...

Тагы әни (әллә әби?) тавышы...

— Кызым, Әхнәф абыең арыгандыр инде. Бераз ял итсен.

Бу больницага әнине ничек кертканнәр?

— И бала, бала... Больница түгел бит бу, үз бүлмәңдә ятасың бит син... Бирәмме соң мин сине больницага үзем исән вакытта...

Димәк, мин больницада түгел. Ә Әхнәф абый? Мин җүләр булмагач, ул кем була соң инде бирегә?

Әхнәф абый көлә...

— Мин синең дәвалаучы врачың булам,— ди. — Врачың.

Аллалар да көлә бит икән... Аңа ияреп, минем дә көләсем килә. Әллә нинди үзем дә белмәгән бәхеттән, сөенечтән елый-елый көләсем килә... Әни белән Әхнәф абый мине ике кулымнан тотып идәнгә бастыралар. Идән бераз чайкалып куя да, тынычлана... Утыз ел буе тар бүлмәмне яктырткан сыңар тәрәзә көлә-көлә миңа таба килә.

Ә тәрәзә каршындагы теге стена соры түгел икән бит! Аксыл төстә икән ул! Мин, борылып, бүлмәгә күз ташлыйм. Минем карашымнан стеналар артка таба чигенәләр, бүлмә киңәя, зурая, яктыра!

— Димәк, мине уятучы — сез?

— Мин.

— Ә мин сезне башта алла дип белдем. Сез ап-ак томан арасыннан килеп чыктыгыз... Үзегез дә ап-ак идегез...

— Оныт инде син аларны, Алсу. Бик күп уйларга тырышма алай.

— Мин бит авыру түгел!

— Мин бик шат. Кирәк булсам, тагы чакыртырсыз.

Мин, кирәк! дип кычкырып өлгерә алмыйм, ул ишек төбендә эреп юкка чыга. Бүлмә эче тагы караңгылана, ул чыкканны гына көтеп торган стеналар тагы минем өскә килә башлыйлар. Мин, кычкырып, ишеккә ташланам. Калтырап торган тәнем белән аңа килеп бәреләм. Башымны аның күкрәгенә яшерәм, кинәт бөтен тәнемнең нидер көткәндәй тынып, йомшарып, хәлсезләнеп калуын тоям. Һәм кинәт үзем килеп сарылган бу гәүдәнең алла да түгел, врач кына да түгел, ир-ат икәнлеген, бер кагылуы белән мине ничә еллар буе йоклаган йокымнан уята алырлык, китүе белән мине яңадан тилертә дә, юк итә дә алырлык кеше икәнлеген аңладым. Гомер буе эзләп, көтеп, килергә, нәкъ миңа килергә тиешле кеше икәнлеген аңладым. Авыру булып күкрәгенә башымны салсам, хатын-кыз булып күзләремне күтәрдем. Алардагы назны, алардагы сусау, көтүне ул да күрде, аркамда яткан кулы кинәт калтырап куйды, ул, ниндидер көчкә буйсынып, мине үзенә табарак тартты. Бу минем туганнан бирле көткән иң бәхетле мизгелем иде. Бу минем хатын-кыз буларак беренче ачылуым, ир-атка беренче тартылуым, беренче тапкыр уянуым иде...

Мин җирдән очып йөрдем!

Үземә очраган һәр кешедән, үзем баскан һәр таштан, хәтта үз-үземнән, үземнең үткәннәремнән тезләнеп гафу үтенәсем килде. Кешеләрдән — моңарчы аларны күрмәгәнем, битараф булганым өчен... Үз-үземнән — йокылы-уяулы үткән тоныкгомерем өчен. Үткәннәрем шулай — үз-үземнән ваз кичәрлек дәрәҗәдә өметсез, караңгы булмаса, бәлки мин бүгенге көннең кисәк кабынып киткән яктылыгын бәяли, аңа тартыла да алмас идем. Ә ул яктылык миңа ничек кирәк иде! Мин дә адәм баласы идем бит... Хатын-кыз идем... Минем инде гомерем, үзем аңа ничек битараф булсам, ул да миңа карата шулай салкын булып, төссез генә узып бара иде! Минем, утыз яшькә җитеп, акылдан шашарлык булып сөйгәнем бар, ә сөелгәнем юк иде. Мине әнә шул, күңел ялгызлыгы, бушлык акылдан шаштыра иде. Ничек кирәк булган икән миңа бу уяну! Дөньяның — дөнья икәнлеген, үземнең кеше булуымны тану өчен. Һәм шул дөньяда беренче тапкыр яктырып, чистарып, күкләргә ашып яну өчен!

Минем бу уянуым, бернигә дә карамый, өмет белән, ышаныч белән, әйтелмәгән наз, сөелмәгән җан белән үзенә каршы йөгерүем аны да гаҗәпләнеп туктап калырга, миңа инде авыру бер хатын итеп кенә түгел, хатын-кыз дип карарга мәҗбүр итте ахры. Ләкин ул тормышында

бу тукталышны көтмәгән иде, минем кебек, көтеп-көтеп арымаган иде. Мин моны аның иркәләп түгел, кызганып караган күзләреннән күрдем, мин аңнарымны җуеп табынганда да, салкын калган иреннәреннән тойдым... Ул, үзе дә сизмичә, мондый нәтиҗәне үзе дә көтмичә, мине гомерлек йокымнан уяткан да, хәзер инде үзе үк чарасыз булып, ялкын сарышкан таш стена хәлендә калган иде. Ялкын күпме генә бәргәләнмәсен, ташка ут капмаячак, каралып, бәгырендә эзе калса да, таш стенага ут капмаячак иде! Ялкын гына үз эссесеннән үзе көеп, хәлсезләнеп, бер-ике сулкылдар да, сүнеп, аның аяк астына егылыр... Без моны икебез дә бик яхшы аңлыйбыз, мин шомланып, ул арып, алҗып бу ялкынның соңгы тапкыр тилереп күкләргә атылуын, күкләргә атылуын да, анда да чит-ят булып, кабат иңрәп җиргә егылуын көтәбез. Бер җиргә егылгач, инде кабат тора алмасын, инде мәңге үрләп китә алмасын белгән тәкъдирдә дә... шуны көтәбез...

Мин инде моңсу көземә кереп барам кебек. Уянганыма үкенмим, сөюнең ни икәнен белмәсәм, бу ялгыз көземдә кемнәргә табыныр идем? Инде сүнәм, уянмыйм дип тынып барган бер мизгелемдә, дөрли-дөрли кабынып китүем, аны яндыра алмыйча, үзем генә булса да яна, сөя алуым — минем өчен бу да бәхет иде, минем өчен бу да яшәү иде. Тик ул гына югалмасын. Минем кебек үк тилереп ярата алмаса да, яратуымнан гына качмасын, минем кебек үк бәхетеннән күктә очып йөрмәсә дә, күкләрдән генә ваз кичмәсен. Бармакларының җылысы керфек очларымда саклана, иреннәрем аның салкын иреннәренә дә риза. Ап-ак чәчләре алдында, минсез узган ап-ак гомере алдында тезләнеп бер елар идем. Артык соңга калуым өчен, ул дөньяда яшәп тә, моңа кадәр аны белмәвем, уяна алмавым, эзләп табалмавым өчен... тезләнеп гафу үтенер идем...

Вакыт! Мин сине барыбер туктата алмадым. Сине туктатсам, мин аны да туктатыр идем... Чәчләренең күзгә күренеп агаруыннан, җанының моңсу гына сүнә(б)баруыннан туктатыр идем... Син нинди мәрхәмәтсез, вакыт! Адәм балаларына тыелгысыз хисләрне, ашкыну, мәхәббәтне әле үзләре дә кадерләрен белми торган чакларында өеп-өеп бирәсең дә, аларның бу бәһасыз байлыкны җил-давылга очыруларын сиздермә генә, көлеп кенә күзәтеп торасың. Инде адәм балалары бу җүләрлекләреннән бер акылларына килеп, уянып, гомер буе көттереп килгән мәхәббәтләре каршында таң калып торганда, син инде аларның чәчләрен агартып, хисләрен суытып, арытып, алҗытып өлгергән буласың. Мин синең бу шәфкатьсез көчеңә ышанам... Ышанам... Ләкин күралмыйм мин сине! Иртәрәк уянып, аны синең тырнакларыңнан тартып ала алмавым өчен... күралмыйм мин сине, вакыт!

Күкләр көлә... Вакытка барыбер — ул инде үзенекен эшләгән. Аллалар арыган — инде могҗизалар тудыра алмыйлар. Мин үзем эшлим ул могҗизаны! Мин аның янына үзем барам! Инде бөтен җаным тоташ бер әрнүгә әйләнгәч, инде бөтен тәнем, һәр күзәнәгем аның иркәләвен сагынып шашынган бер мизгелдә, мин кешеләрне дә күрми, стеналарны, дөньяны да күрми аның янына чыгып йөгерәм. Килеп җитеп өлгермәсәм, менә-менә ул юкка чыгар, минем бер ялгызлыгымны шушы олы дөнья уртасында калдырып, юкка чыгар кебек тоела. Мин, тыным бетеп, аның бүлмәсенә атылып керәм. Егылмас өчен, чытырдатып ишек тоткасына ябышам. Бераздан караңгылык тарала башлый, мин якында гына тагын аның ап-ак чәчләрен, арыган йөзен күрәм, ап-ак халатын күрәм.

— Сиңа начармы әллә, Алсу?

— Миңа? Юк... Әйе... Миңа...

Мин, мөлдерәп, тилмереп, ниндидер могҗиза көткәндәй, аллам итеп, аңа карыйм. Күзләрендә — һаман шул моңсулык, һаман шул арыган-

лык. Мине сискәндереп уятып та, үзенең инде мәңге уяна алмаслыгын аңлау арыганлыгы. Бүлмәгә кемнәрдер керәләр, чыгалар, әллә авырулар, әллә медсестралар. Мине приемга килгән бер авыру дип уйлыйлар ахры — карашларында җансыз битарафлык. Өстәлдә секундомер ята. Акыл чиген сикереп узучыларның соңгы талпынышларын санаучы. Финишка килеп җиткәч кенә китереп басасың да — вакыт туктады!

— Әхнәф абый?! Вакытны туктатып буламы?

Я, әйт инде?! Туктат, диген! Мин синең ап-ак вакытыңны туктатыйм да, үземә кушыйм. Мин бит сиңа шуны әйтү өчен бөтен шәһәр буйлап йөгереп килдем! Гомерем буе йөгереп килдем. Сиңа шушы сүзләрне әйтү өчен бит...

— Вакытны туктатып булмый шул, Алсу... Булмый.

Секундомерның тимер бөҗрасы, минем калтыранган бармакларым арасыннан сикереп чыга да, нечкә уклар, бәгырьне телә-телә, тагы котырынып чабышырга тотыналар. Мин вакытны туктата алмадым, Әхнәф абый!! Мин вакытны туктата алмадым бит!

— Тынычлан, Алсу! Сиңа борчылырга ярамый.

— Мин тынычланырга куркам. Тынычлансам, кабат йокыга китәрмен дә, инде мәңге уяна алмам кебек... Зинһар, китмәгез миннән... Куркам мин ялгызым бу дөньяда... Куркам...

Ул, тынычландырырга теләп, кулларымнан ала. Куллары аша вакытның миңа күчүен тоям. Менә бу кулларның мине тормышта бердәнбер тотып тора алырлык көч икәнен тоям. Минем ул кулларга сыенасым, һәр бармагын берәм-берәм үбәсем, гомер буе тәнемдә аларның кайнарлыгын тоясым килә! Ләкин ул, минем кулларымны көч белән үзеннән аера да, читкә борыла. Я хода! Мин бит аңа бөтенләй кирәк түгел!.. Бөтенләй кирәк түгел...

Кемнәргәдер бәрелә-бәрелә, урамга чыгып йөгерәм. Тик... барыр урыным, миллион җанлы шәһәрдә килеп сыенырр кешем юк. Ә иң авыры, иң куркынычы, бирерә мин кирәк булган, минем килүемне көтеп торган бер генә урын да юк иде... Мин гомер буе йөгергәнмен, эзләнгәнмен, шулай йөгерә-йөгерә инде гомеремнең яртысын үтеп киткәнмен. Һәм менә уянгач, котым чыгып карап торам: бу дөньяда мин япа-ялгыз икәнмен бит! Мин тормышта иң зур байлыктан мәхрүм ителгәнмен — Кешеләрсез калганмын! Артык болай яшәргә ярамый иде. Болай яшәү җинаять иде.

Мин зур шәһәрнең тар бүлмәсен калдырырга булдым. Әйберләрем бер чемоданга сыйды. Анысы да китаплардан гына тора. Минем белән тар бүлмәнең теге ягына чыгарга аларның гына хакы бар. Хатирәләргә, авыруларга, бәргәләнүләремә — үткәннәргә анда урын юк.

Әни бер ялгызы мине вокзалда озатып кала. Әни дә кечерәйгән, ябыккан. Гаебе бар кешедәй, астан мөлдерәп миңа карый. Аның бу карашыннан күзләремне кая яшерергә белмим. Мин сине кайтып алырмын әле, әнием! Мин сине һичшиксез кайтып алырмын. Без синең белән тагы шау чәчәкле болыннар дөньясында, карурманнар дөньясында яшәрбез...

Әни абына-сөртенә поезд артыннан йөгерә. Күзе һаман миндә, кулларын сузып, нидер әйтә-әйтә, поезд артыннан йөгерә. Бу хәлне күрмәс өчен башымны читкә борам. Миңа инде әйләнеп кайтырга ярамый, үткәннәргә юл — юк!

Бөтен хыялым болынлы, урманлы бер авылда балалар укыту иде. Кеше, гадәттә, бу хыялын 20—21 яшьләрдә тормышка ашыра. Мин менә утызны үткәч шул эзгә төштем. Артта тау-тау газап калдырып, ярты җанымны калдырып, Алмазны, Әхнәф абыйны калдырып...

Урман куенында утырган кечкенә генә бер авылда урнашып кал-

дым. Зур бер шәһәрне ташлап, авылга, чит тел укытырга килүемне белгәч, укытучылар арасында гаҗәпләнебрәк, шикләнебрәк караучылар да булды. Аннан тора-бара нияләнделәр. Ләкин мине иң куандырганы балалар булды. Шулкадәр ышану, зурлау, ярату иде аларның күзләрендә, миңа әле дөньяда берәүнең дә болай караганы юк иде. Беренче дәрес бетү белән, учительскаяга чыккач, сөенечемнән өстәлгә капланып еладым. Инде бераз тынычланып, башымны күтәрсәм, үземне укытучылар әйләндереп алган. Кайсы юата, кайсы тынычландыра — барысы да минем янда. Дөньяда беренче тапкыр кешеләрнең якынлыгын тоям. Үземнең моңа кадәр иң зур җәзага — ялгызлыкка дучар булуым исемә төшә. Шуларны оныттыра, мине үз араларына сыендыра алган бу зур җанлы кешеләр каршында тезләнеп рәхмәт әйтәсем килә...

Ә бер көнне, җыйнак кына фатирымда әнигә хат язып утыра идем, бер укучымның ашыга-ашыга безгә таба килүен күрдем. Җиденче класста укый ул. Алмаз исемле. Нишләптер, күңелемә якын шул малай. Якын иткәнемне үзе дә сизә ахры, апа, дип, күземә генә карап тора.

— Апа, апа! — дип кычкырды Алмаз ачык тәрәзә аша. — Анда сезнең янга бер кеше килә. Мин велосипед белән яныннан үтеп киттем. Безнең авылны сорады. Сезне сорады.

Йөгереп урамга чыктым. Йөрәгем, хәлсезләнеп, тибүеннән туктар кебек. Егылып китмәс өчен Алмазның велосипедына тотынам.

— Нindirәк кеше иде ул, Алмаз? — Могҗиза көткәндәй, малайның күзләренә карыйм.

— Ап-ак чәчле. Ап-ак чәчле бер абый.

Алмазның соңгы сүзләрен ишетмим. Авыл аша олы юл ягына чыгып йөгерәм. Авыл яныннан ук болын башлана. Ул шул юлдан килергә тиеш! Ул миңа шул юлдан гына килә ала!

Мин, кулларымны алга сузып, болын буйлап йөгерәм. Минем тыным бетә, күз алларым бер караңгылана, бер яктыра, ләкин мин туктый алмыйм, миңа туктарга ярамый! Чөнки болынның теге башыннан ул да миңа таба йөгереп килгәнен беләм мин. Без гомер буе бер-беребез каршына йөгергәнбез, бер-беребез яныннан үтеп киткәнбез, менә хәзер, кире борылып, тагы бер-беребез каршына киләбез!

Мин, йөгереп килгән уңайга, аның күкрәгенә капланам. Аның ап-ак чәчләре минем чуалган кара чәчләрем белән бутала, йөзендәге җыерчыклар кипшергән иреннәрем астында калып тигезләнә, юкка чыга. Аның ап-ак җаны аша үтеп, вакытның үземә күчүен тоям. Менә бу күзләргә, бу кулларга, бу җанга мин кирәк икән бит! Мин кирәк икән...

Ә болын яши...

Үзенең мең кошы, мең төрле чәчәге белән яңа җәйгә керә. Гасырлар буе шулай булган. Тере җан иясенә салкын кышлардан соң барыбер язлар, җәйләр килгән...

— Бу безнең болын булыр, ярыймы, Әхнәф абый?

— Безнең болын булыр, Алсу. Безнең дөнья...

## Фәнис Яруллин

### Ишекләр

Шаштың, күңел, шаштың
Һәм күкләргә аштың:
Җиде кат күкләрнең
Ишекләрен ачтым...
Иң беренче катта
Балачагым ишеге:
Болытларга эленеп
Калды шунда бишегем.
Ә икенче катта
Мәктәп дигән ишек:
Ачтым-яптым. Еллар
Тиз үтteләр ничек?!
Өченче катында
Яшьлек иде бугай:
Күренеп кенә калды
Чәчәкле бер тугай.
Дүртенчегә менгәч,
Сөю ишеген кактым.
Бәлки аңа минем
Булмагандыр хакым?
Ә бишенче катта
Каршылады урман:
Үз юлымны эзләп
Киттем әнә шуннан.
Алтынчысын ачкач,
Тирән диңгез күрдем —
Иҗат диңгезенә
Күмелгәнче кердем...
Инде ишекнең мин
Иң соңгысын кактым.
...Шушы биеклектән
Төшәргә юк хакым.

### Картлар һәм яшьләр

Иң зарлы, иң ярлы кеше — карт кеше,
Югалткан ул бөтен-бөтен байлыгын:
Алтын кебек балачагын, яшьлеген,
Иман кебек тазалыгын-саулыгын.
Югалткан ул кыргый болан көнләрлек
Өлгерлеген, елгырлыгын, тизлеген.
Югалткан ул дастаннарда сөйләрлек
Чибәрлеген, зифалыгын, төзлеген.
Ваклаган ул гомеренең көннәрен,
Өләшкән ул бәхетенең гөлләрен.
Инде аның берние дә калмаган —
Еллар аны әкрен-әкрен талаган...
Юк, дөньяда иң бай кеше — карт кеше,
Булмаса да җыйган алтын-көмеше,—
Алтыннардан кыйммәт картлар акылы.
Безгә күчкән шул акылның ялкыны.
Шуңа бай без, шуңа көчле, шуңа шәп —
Картлар калдырган дөньябыз бай гаҗәп.

●

Тын да алмый басып торам,
Уч төбемдә тәмле икмәк.
Шушы тәмле икмәк белән
Сыйламакчы булам песнәк.
Күңелемдә бер хәйлә юк,
Уем матур, ният изге.
Ботактагы яшел түштән
Ала алмый торам күзне.
Ә песнәгем әйләнә дә
Кире китә, кунмый кулга.
Бу дөньяда күп тапкырлар
Алдангандыр ахры ул да.

## Әнкәй бишек тирбәтә

Кышкы кич. Авыл өе.
Бозланган тәрәз, ишек.
Мондый теләкләр теләп,
Әнкәй тирбәтә бишек:
«Батыр булып үс, улым,
Җитмеш дәрья кич, улым.
Җитмеш юлның төенен
Акыл белән чиш, улым.
Бөркеттән син канат ал,
Боланнан син аяк ал.
Юлбарыстан куәт ал.
Арысланнан йөрәк ал.
Тургай дәртле моң бирсен,
Иман таза сын бирсен.
Кояш якты йөз бирсен,
Лачын үткен күз бирсен».

Акладыммы әнкәйнең
Бөтен изге теләген?
Һәрнәрсәгә түзәрлек
Көчлеме соң йөрәгем?
Күтәрелә алдыммы
Бөркет кебек югары?
Тиңме тургай моңына
Күңелемнең моңнары?
Дус кайгысын күрерлек
Үткенме минем күзем?
Ил йөзенә багарлык
Яктымы минем йөзем?
...Күз алдымда кышкы кич.
Бозлы тәрәзә, ишек.
Изге теләкләр теләп,
Әнкәй тирбәтә бишек.

## Ике бокал

Аның бүген туган көне.
Ул бик иртә торып басты.
Тар өйләрем киңәйсен дип,
Тәрәзәсен киереп ачты.
Өстәленә алтын билле
Чынаяклар куйды тезеп.
Бакчасыннан ал чәчәкләр
Алып керде сайлап өзеп.
Һәр тавышка колак салып
Хуҗа бүген кунак көтте:
Сый-нигъмәтләр әзерләнде,
Өйдә эшләр күптән бетте.
Җиз самавыр өсләрендә
Нурлар ялт-йолт торды уйнап.
Урындыклар зарыгышып
Сабыр гына көтте кунак.

Кунак көтеп, ташыды аш,
Кунак көтеп, бәлеш көйде.
Тәрәзәдән карый-карый,
Кызыл гөлләр башын иде.
Ишекләрнең тоткалары
Көтте куллар кагылганын.
Кунак көтеп арыды күк
Хәтта ризык тулы табын.
Ә ишеккә ялгышып та
Кагылмады җылы куллар:
Ачык тәрәзәдән өйгә
Тулды бары сагыш, моңнар.
...Буп-буш өйдә ялгыз хуҗа,
Бер минуты — бер ел аңа.
Ике күзе — ике бокал:
Бокаллардан мөлдер-мөлдер
Ачы-ачы шәраб тама.

## Сабый сагышы

Әнкәсенә сорау бирә
Гөнаһсыз сабый:
— Әтиебез кайда безнең,
Ник һаман кайтмый?
Нәрсә әйтсен инде ана
Сабый балага:
— Әтиең укый шул,— ди ул,—
Читтә, калада...
Көннәр үтә, бала көтә,
Күзләре юлда:
«Их, укысын иде әти
Кайтып шушында.
Янында әни булмагач,
Икеле аладыр.
Икеле алгач, класстан
Күчми каладыр.
Кышкы каникулларга да
Кайтмый икән ник?
Әллә инде укытучысы
Усал микән бик?!»
Баланың әле күңелендә
Гел якты сагыш...
Якты сагышларын аның
Каралтмыйк ялгыш.

## Йокысыз төн

Минә тагын төнгә керәм,
Төнгә түгел, күлгә керәм.
Ә күл тирән, ә күл шомлы,
Суы салкын — куыра тынны.
Мин шул судан йөзеп барам,
Тыгыз суны сөзеп барам.
Арганлыкны сизеп барам.
Көчкә-көчкә түзеп барам.
Менә-менә батам димен,
Төпкә төшеп ятам димен.
Мәшәкатьле бу дөньяга
Инде кабат кайтмам димен.
Шулчак кинәт нидер була —
Офыкларда таң сызыла.
Хәлсезләнгән юлаучыга
Әйтерсең лә нан сузыла.
Үреләмен шушы нанга,
Өмет нуры тула җанга.
Кара төнне куган өчен
Рәхмәт укыйм гүзәл таңга.
...И йокысыз озын төннәр,
Көчне суыра торган җеннәр!
Сез караңгы булган саен,
Якты тоела миңа көннәр.

## Рәшит Әхмәтҗанов

### КОЛ ГАЛИЛӘР РУХЫ

●

*Туган көнемнән үк бәхет биреп,*
*Азат балам диеп атадың.*
*Авыр чакларыңда Кол Гали күк*
*Колың булыйм, газиз Ватаным.*

●

Еллар — йолдызлы елгалар.
Агалар... ярсу алар,—
Үз кыяңа утырталар —
Кемнәрдер батырсалар.

...Йолдызлар белән кайнадым...
Кадалдым дымлы ярга.
Тагын таң нурлары тамды
Ямь-яшел яфракларга.

### Кош язмышы

Җанкыярлар үтергәннәр аны
Таң атканда... гөлләр күз алдында.
Егылган ул җиргә... каурыйлары
Күккә менә җилләр канатында.

Күтәрелә.
Иле — зәңгәр күге
Шундый аяз аның, шундый биек!
Укка каршы очкандыр ул, ахры,
Илем исән-имин калсын диеп.

### Сау бул, болыт...

Сау бул, болыт, мине оныт! —
Киттең дөнья читенә.
Юк, син түгел,
синнән шулай
Гөл-чәчәкләр читенә.

Сау бул, болыт, мине оныт,
Йөгермим эзләреңнән.
Таң чыкларын җыеп киттең
Гөлләрнең күзләреннән.

Күз яше булып тамачак
Чит җиргә тамчыларың...
Сау бул, болыт, чәчкәң булып
Беркайчан ачылмамын.

Я төшем булыр ул минем,
Я булыр якты өнем —
Килсен ул, килсен ерактан,
Ерактан — синең тарафтан
Бер хәбәр алган көнем.

Тик кайчан килер ул хәбәр?—
Иртә дә, кич тә көтәм.
Сизенә күңел, ышана —
Сак белән Сокның дөньяда
Кавышыр көне җиткән.

## Нәкъ синең шикелле

Дәрьясы тар кебек аңарга —
Менә дә сикереп ярларга,
Бар дөнья оныткан чагында,
Өлгерә җанымны барларга.

Һәм кабат чигенә... мине дә
Чуерташ хәлендә калдырып.
Ә алтын балыкны үтерә,
Сүндерә... кояшта яндырып.

Нәкъ синең шикелле бу дулкын —
Җандагын белә ул барын да.
Килә дә сибелә... һәм Сөю
Сау кала үлемнәр ярында.

## Давыт Гобәйди[1]

Күзләргә сукты, күзләргә дошман,
Кояшны бүтән күрмәсен, диеп.
Ә үлемеңне озак суздылар —
Шагыйрь тиз генә «үлмәсен» диеп.

Хөкем карары булып сүзләрең
Палачларыңның җанын актара:
— Я, кулны артка каерып кара!
— Я, безне илдән аерып кара!
— Я, бөгеп кара безнең беләкне!
— Я, җиңеп кара безнең йөрәкне!

Син гомереңнең дәвамы иттең
Муенга элгән элмәкнең очын!..
Җиңдек! Тезләргә бәреп сындырдык
Башны кисәсе дошман кылычын.

Илгә — ирек! дип, карурман кичтек,
Җил булып истек; ут булып яудык.
Тау булып бастык дошман каршына,
Дошман өстенә тау булып аудык.

Син табигатьтә бер имән идең,
Иелдең бары илең каршында.
Үлем алдыннан әйткән сүзләрең
Ник язылмаган кабер ташыңа?

Ник язылмаган?!
Ә бит аларны
Безнең йөрәкләр кабатлап бара:
— Я, кулны артка каерып кара!

---

[1] Татар шагыйре. Аны 1919 елда Колчак бандалары ерткычларча җәзалап үтерәләр.

— Я, безне илдән аерып кара!
— Я, бөгеп кара безнең беләкне!
— Я, җиңеп кара безнең йөрәкне!

## Иң соңгы йолдызга җиттем...

«Хуш, улым!» дидең дә...
Самолет
Кузгалып юл ярды биектән.
Син идең ул көнне, син, әнкәй,
Күк белән шигъри элемтәм.

Кояшны болытлар капласа —
Синең җан нурлады күгемне.
Берьюлы балкыды бәхетем! —
Шикләндем... күбрәк түгелме?
Берьюлы балкыды, берьюлы...
Ал булды, гөл булды яшәвем.

Тик күкне җир итте,
җиремне
Күк итте яңадан дәшмәвең.

Күкләргә менәм дә эзлимен —
Йөрәгең, күзләрең исәнме?
Синең төс бар, әнкәй, болытта,
Танымас идем мин бүтәнне.

Иң соңгы йолдызга җиттем мин —
Бусы да син түгел... мин кётәм...
Өзелде, күрәсең, өзелде
Иң соңгы шигъри элемтәм.

## Көзге рәсем

Офыкларга түгел, карлы-бозлы
Болытларга төште кояш баеп...
Кызыл, сары, яшел яфракларын
Саклый каен... саклый
хәлдән таеп.

Сүнми утлар кызыл яфракларда,
Сары яфракларда сагыш дөрли,
Яшелләрен дөнья юри күрми...
Яна-яна каен күккә үрли!

## Борынгы кылыч

Җир казыганда табылды —
Яткан янәшә генә.
Күгәреп беткән... Бер гасыр
Бардыр күмелгәненә.

Бер утка куеп кызартам,
Бер аны суга салам...

Хәзер инде йөзендәге
Язуны укый алам:

«И, углан, дошманың керсә
Син яши торган илгә —
Уе белән башы бергә
Өзелеп төшсен җиргә!»

●

Мин саргаеп сагынгач,
Очырдым бер карлыгач...
Зәңгәр диңгез ягына —
Синең йөрәк янына.

Очты таулар артына.
Мин аның канатына
Өмет җебе урадым,
Изге уйлар юрадым...

Карлыгачым исәнме,
Канатын җил кискәнме,
Егылганмы диңгезгә? —
Бер хәбәр дә юк безгә.

Хәбәрләре юк аның.
Көтәм давыл тынганын. —
Карыйм кара болытка —
Болыт ага офыкка...
Бәлки сине табар ул,
Керфегеңә тамар ул.

Ә карлыгач, карлыгач...
Егылгандыр арыгач.
Диңгез ярын буйла син,
Аны мин дип уйла син.

## Тамчы турында соңгы шигырь

Мин диңгез булалмас идем,
Ярый ла сине сөйдем.
Югыйсә, сине күргәнче
Бер тамчы гына идем...

Хыянәт диңгез киптерә,—
Мин бүген кабат тамчы...
Әй, кояш, мине тизрәк
Үзеңә тартып алчы!

## Унөченче аем

Таллар арасыннан күтәрелеп,
Очып китте кошлар төркеме.
Кояш батты... Үтте бу гомернең —
Асыл чакның тагын бер көне.

Бар да китә... Син каласың сыман.
Ялгыз булмасын дип, мин калам.
Көннәр белән балкып киләмен дә,
Кара төнең булып югалам.

Сүнәр-сүнмәс янган йолдызлардан
Сорап уза кошлар төркеме:
«Безнең белән ник сәфәрдә түгел,
Ул ирегең җуйган кешеме?»

Әйт аларга: сине күрмәгәнгә
Унике ай инде, унике...
Иреклә мин, кемнеке дә түгел,
Тик син генә бары минеке.

Унөченче аем — син мәгаен.
Күрмәсәм дә аның балкышын —
Сине сөйгәч,
кара язмышымда
Тамчы да юк минем ялгышым.

## Яшәдем

Дөньяның караңгы ягына
Барыбер төшкәндер бер нурым,—
Хәтта мин агулы еланга
Эндәштем: саумы, дип, матурым...

●

Ташка тамды яшем. Бу — куаныч!
Әр-яңасы әле... быелгы.
Һәлакәтем булып таммады ул,
Хәрәкәтем булып уелды.

## Кышкы моң

Сандугач кайта язгы таңнарда,
Сагынып кетә аны гөлҗимеш.
Чүт, чүт, чүт...
Сайрый сандугач,
Яшәгез диеп мәңге яшь килеш.

Яшел юллардан җәйләр дә үтә,
Сиздерми генә күзләр дә җитә.
Чүт, чүт, чүт...
Сайрап сандугач,
Урманнарымны саргайтып китә.

Карлар өстендә ут булып янган
Гөлҗимешләрне күрәм еракта.
Чүт, чүт, чүт...
Сайрый сандугач,
Уйларымдагы яшел куакта.

●

Хәтерләүләр... миңа хәтәр сагыш,
Хәтәр аның хәтта бер көне.
Шул бер көннең мин учагын күрәм —
Кояшларны каплый төтене.

●

Сахраларда шактый йөрелгән —
Бармактагы балдак эрегән:
Кайткан идем ярым янына —
Килмә, килмә, диеп ялына...

## Әнкәмне сагынганда

Сезнең якка очкан кошлар канатын
Кара күзем белән карап агарттым.
Агардылар... ап-ак булып очтылар...
Йөрәгемне тагын бер кат канаттым.

●

Иле янды Гөлбикәнең,
Ире янды Гөлбикәнең...
Көл булганын онытса да,
Онытмады гөл икәнен.

## Былбыл моңы

Патша булгач, читлегеңә яшер,
Тәхетеңдә тыңла! Соңыннан...
Ирек турындагы җырым белән
Сөрәчәкмен сине мин моннан.

●

Кагылмагыз! Сукса — яшен суксын! —
Кодрәте тиң минем ярсуга.
Рухым булып күктә балкыр да бер...
Күкрәп яңгыр явар басуга.

●

Бар гөлләр балкый. Канатлар бакый!
Җиремнең һәр көн төсе үзгәрә.
Илен сөйгәннәр яшәрә һаман,
Ә тамырсызлар көеп күгәрә.

# Әхмәт Гадел

## Алпамша

*Казакъ драматургы Уразбек Бадыковка*

Мин — Алпамша,
Әкияттәге батыр.
Мәхәббәтне әзлим, хаклыкны:
Минем куллар күпме
ханнарның
Еланнардан күчкән
канын сыкты.
Мин — Алпамша.
Мин меңләгән куйның
Йонын кыркып, аркан үрәм...
Җеннәр хуҗа булган
Җәһәннәмгә төшәм,
Ярым үбәм.
Ничә тапкыр дуслар хыянәтен
Бәла итеп кичергәнем булды,
Ләкин һәрчак исән чыктым
Мин — Алпамша —
Җиңү, хаклык улы!
Шуны кисәтеп
Әйтәмен сезгә,—
Моны күңелегез
Түренә салыгыз:
Мин — Алпамша,
Тик әкияттә ялгыз,
Ә тормышта — халык,
Белегез, мин — халык!
Шуңа үлемсез мин,
бакый Алып!

## Кабырчыклар

Уйчан таулар. Телсез калган гүя диңгез.
Чыкмас кебек бүтән дулап ярларыннан.
Салкын төште. Кипарислар арасыннан
Әкрен генә, уйчан гына ялгыз барам...

Сихри ярлар, гүя, төшләр күреп ята,
Әнкәемнең күзләредәй моңлы диңгез.
Су мохиты сагышларны белгән чакта,
Сагынуларны нигә инде онытыйк без?!
...Кинәт чатта, юл өстемдә юан хатын
Таудай калкып чыкты; димен, бу ни хата!
Таш аткандай күкрәгемә тавыш ата.
Кабырчыкны — диңгез жанын шулай сата...

Җил-давыллар, зилзилә һәм туфаннарны
Күргәндер бу табигатьнең могҗизасы.
Өйрәнгәндер дулкынарның саф җырларын,
Кешеләрдәй, яшәгәндер ярсып, шашып!..

...Хатын сата тәсбих итеп диңгез жанын,
Кабырчыкның бәгырендә диңгез ярсый...

## Кырым. Диңгез буе

Монда юллар диңгезгә,
диңгез — күккә,
күк галәмгә тоташа...

Барысы да үтә минем йөрәгем аша.

●

...Йөрәк, хисләр аксый башладымы,
Калдыр өең, оныт рәхәтне...
Ireklektə генә табып була
Чын сөюне, олы бәхетне!

...Җилләр кирәк җанга, җитми аңа
Төзелешләр,
утлы карашлар!..
Кайда икән дала уртасында
Шаулап үскән алтын арышлар?!
Кайда алар?!

●

Ник булмадым утлы вулкан —
дәһшәт яшергән чатыр,—
яндырыр, көйдерер идем,
көл итәр идем, матур!

Ник булмадым тирән дәрья —
җирнең серле көзгесе?!
Назлар идем, алдар идем —
бәгырьләрең өзелсен!

Ник булмадым, ник тумадым?!—
Ләкин нигә соң зар, я?!
Баксаң, мин хәтәр вулканмын,
туфан яшергән дәрья!

## Кичке авыл

Һай, ул гүзәл тонык кичләр,
Кырдан көтү кайтуы!..

Һич тә китми, китми истән
Киң урамга йомшак кына
Көтүдән соң,
Кичке тузан ятуы...
Күңелемдә сулмый яши
Бакча башы таллыгында
Төнге былбыл сайравы...

Мәңге, мәңге онытылмас
Елгыр атларның кешнәве,
Кыңгыравы тайларның...

Кичке авыл, кичке авыл,—
Үткәннәр хатирәсе!..
Көтү кайткан изге мәлдә,
Сагыну сагышларын басып,
Их, бер кайтып киләсе!

●

Далада ак кылганнар.
Моңкан ахры туганнар...
Чәчрәп чыга яшьләрем...

Кылган булып шыткан кебек,
Гомере буе улын көтеп,
Сулган Ана чәчләре.

●

Дөнья гүзәл, могҗизалы, серле.
Табигатьнең үз көй-җыры...
Көзге яңгыр моң еләшсә,
Язның да үз көе булыр...

●

Сөйләмәгез илем-җирем диеп,
Сөйләмәгез сөю хакында.
Аңлашылыр, әйтелер барысы да
Туфрак булып яткан чагында.

## Яшь кыз җыры

Уйларымның иң пакьләрен
Мандым ак бүзгә генә —
Зәңгәр күкнең чиксезлеген
Салдым мин күзләремә.

Урманнарның дәртле җырын
Сыйдырдым йөрәгемә,
Гүя табигатьнең бөтен
Шатлыгы миндә генә!

●

Үз бәхетем-михнәтем бар,
Үз фәлсәфәм, үз уем...
Иске булса да — бишмәтем,
Ачы булса да — туем...

Үз көнем бар, үз төнем бар —
Төндә — ай, көндә — кояш...
Үз-үземә мин үзем бар —
Үзем каш һәм үзем — баш.

Тормышта өзелеп сөям мин
Күңелемнең кошларын...
Үз кайгым, үз шатлыгым бар,—
Дошманнарым, дусларым...

Бу юлларны укырсыз да
Сәер... диярсез җәһәт.
Кем белә, бәлки сезгә дә
Охшаганмын мин — Әхмәт?!.




Әхмәт Рәшитов

# СЕЗ КЕМНЕҢ ВАРИСЛАРЫ?

ОЧЕРК-УЙЛАНУ




рак өсте иде. Авыл кешесенең йокысы качкан, йөрәге җилкенгән, өметләре яңарып, канатланган көннәре.

«Газигы» белән килеп туктаган колхоз председателе Әхмәт Сибгатуллин ындыр табагы мөдире Әсгат Габдрахманов белән киңәш тота:

— Амбарга сыймаганын ангарга!..

«Ангар» дигәннәре кышкы чорда техника һәм ашлама саклау өчен төзелгән биналар. Алар «Үзәк» колхозында өчәү. Идәне асфальт, түбәсе ябулы. Эш күбәя инде күбәюен, аның каравы ашлык — ышанычлы җирдә.

Ындыр табагы бу чорда бөтен яшәешнең үзәге гүя. Мин, тәэсирләнеп, кулы кулга йокмаган япь-яшь кызларның йөзләренә карыйм. Алар бәхеттән шулай алсуланганнардыр сыман.

Таныш. Җирләре дә таныш, кешеләре дә таныш миңа.

**Ана сөте — тана сөте түгел,**
**Яшьли канга сеңгән — гомерлек;**
**Шуңа күрә, кайда яшәсәң дә,**
**Туган җиргә башлар орырлык.**

Ындыр табагында туган ягым моңы яңгырый сыман. Ел саен урак өстендә мине, мөгаен, нәкъ шул моң чакырып кайтарадыр. Заманында атам сабан сөргән, анам урак урган җирләр, аякларымны камылларда тырната-тырната башак җыеп йөргән басулар.

Сугыш башланган елның язы иде ул. Әти мине көннәрдән бер көнне нәкъ менә шушы Мулла Күле дигән җиргә алып килде. Үзе җир тырмалап йөрде, үзе гадәтенчә яраткан көен суздьі. Мин күл яңгыратып «сайраучы» сары түшле, озын койрыклы бакаларны — тритоннарны күрмәкче булып әллә ничә тапкыр чак-чак кына суга барып төшмәдем.

Әти Бөек Ватан сугышыннан кайтмады. Инде күл дә кипкән — хәзер монда ындыр табагы. Үткәннәрдәге тагын әллә нәрсәләр юк. Ләкин хәтер исән, истәлекләр исән. Авыл картлары хәтерли әле: сугыш чыккан елны колхозның һәр гектар җире 16 шар центнер икмәк биргән. Их, шулай гына дәвам итсә... Дүрт ел буе җиргә ирләр кулы тимәде — кыргыйланды кыр, баш бирмәс булды. Уңыш 7—8 центнердан артмады.

**Сугышларны кичеп,**
**Ертыкларны**
**Ямаштырып торган чор иде —**
**Бары бергә, югы уртак иде —**
**Каты кура баскан кыр иде...**

Әмма күмәкләшүнең беренче еллары авылдашларыма зур шатлык китергән. Төзелүенең өченче елында ук һәр хезмәт көненә яртышар пот ашлык биргәннәр. Җәләлетдин Шәрәфетдинов, Латыйф Рәхимов, Зыятдин Гыйлаҗев кебек алдынгыларның амбарына 25 әр центнер икмәк кергән.

Республикабызның, авыл хуҗалыгы продуктлары җитештерүдәге уңышлары өчен, Ленин ордены белән бүләкләнгән елы — тарихи 1934 ел бу. Димәк, потенциаль мөмкинлекләр ул чорда ук булган. Хәтта Бөек Ватан сугышы барган иң авыр чорларда хуҗалыкның ел саен дәүләткә 4 мең центнер икмәк озата алуы үзе генә дә күп нәрсә турында сөйли.

Муллык өчен көрәш сугыштан соң яңа көч, яңа омтылыш белән дәвам итте. Җир, үткәндәге бурычларын, ниһаять, кире кайтарырга теләгәндәй, уңышны башта килограммлап, аннан потлап-центнерлап арттыра барды. Хикмәте нидә булган соң? Орлыкның иң уңардае, югары кондицияле чәчелде. Иң отышлы агротехник сроклар. Ашлама. Органигы да, минерале дә — аз да түгел, күп тә түгел, җаен-чамасын белеп кенә.

Колхозның баш агрономы Азат Хәйретдинов уңыш артуның серен бик ачык аңлата:

— Яссы кискеч...

Һәм ул, җирне яссы кискеч белән эшкәрткәндә, уңдырышлы катламның буталмавы, Себер академигы Т. С. Мальцев киңәшләренең файдасы турында сөйләп китә.

— Элек бит нишли идек? Сабанны кызыл балчык актарылып чыкканчы җиргә батыра иде. Тирән булсын! Тирән булсын!» — дип тырыштык. Андый җирдә шайтан таягы да үсми икән ул.

1982 елны гектардан 30,7 центнер җыеп алынды. Мондый уңышны күргән юк иде әле. Күпме бу, азмы?

— Аз,— ди колхоз председателе Әхмәт Сибгатуллин.— Аз. Ни өчен аз, дисезме? Кайбер басулар 50 центнерга хәтле бирде. Беренче бригадада сабан ашлыгы — 38 центнер, икенчедә 32 генә. Резервлар бар, димәк...

Яңа Чәчкап авыл Советының январь азагында булган сессиясе колхозда Азык-төлек программасының үтәлешенә багышланган иде. Депутатлар зур кайгыртучанлык белән хәл ителәсе проблемалар турында сөйләштеләр.

— Яки менә карәбодайны алыйк. Шушы ук шартларда аннан 30—40 центнер уңыш алучы колхозлар булды,— дип дәвам итте председатель.— Без алардан киммени?

Бик хаклы сүзләр! Кешеләре дә булдыклы, җире дә уңдырышлы бу колхозның үзе шундый сыйлы, юмарт туфраклы 3533 гектар җирдән тагын да әллә нинди нигъмәтләр көтәргә мөмкин. Колхоздагы техниканың куәтен меңләгән ат көче белән генә үлчәп була торгандыр. 41 трактор, 14 ашлык комбайны, күпләгән тагылма машиналар, 24 автомобиль һәрвакыт сугышчан әзерлектә. Ашламага да кытлык булганы юк.

Икмәк — яшәеш чыганагы дибез. «Үзәк» колхозы эшчәннәре өчен дә ул гомер-гомергә шулай булып килде. Былтыргы 1.550 000 сум керемнең 559.200 сумы игенчелектән алынган.

Шикәр чөгендере бирердә икенче икмәк урынында йөри. Керемнең 334.800 сумы аның өлешенә туры килә. Һәр гектардан 265 әр центнер чыккан. Шикәр чөгендере — ифрат та күп көч, түземлек, сабырлык таләп итә торган нәзберек үсемлек. Механизмнар белән ничек кенә кыландырма, кул хезмәтеннән башка барыбер булмый. Бу эшне иң күп очракта хатын-кызлар башкара. Чөгендер игү звеносы җитәкчесе Рифкат Камалов аларның фидакарь хезмәтенә сокланып сөйли:

— Ир-егетләр түзә алмаслар иде,— ди.

Колхоз җиде ел буе шикәр чөгендере игүдәге уңышлары өчен СССР Авыл хуҗалыгы министрлыгының һәм ВЦСПСның Күчмә Кызыл Байрагын яулап алды. Ә аннан, ярыш—ярыш инде, берничә ел алдынгылыкны башкаларга биреп торырга туры килде. Ләкин бөтенләйгә түгел. 1982 ел нәтиҗәләре буенча җиңү байрагы яңадан әйләнеп кайтты. Звено башлыгы «Почет билгесе» орденына һәм СССР Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсе медальләренә лаек булды. Фидакарь

чөгендерчеләр хезмәтенә дә тиешле бәя бирелде. Шул уңганнарның берсе — Әлфинур Габдрахманова — ТАССР Верховный Советы депутаты.

Әле моннан 30—40 ел элек кенә гаиләдә чәй эчкәндә теш арасына кыстырырлык бәләкәй генә шикәр кисәге булса, ул зур нигъмәткә саналә иде. Кесәләрендә йөри-йөри шомарып беткән шикәр сыныгы белән яраткан оныкларын сыйлаган мәрхәмәтле әбиләребез кайсы гына язучының хикәя-романнарына үтеп кермәде икән?! Хәзер шикәр комы чөгендерче өендә капчыгы белән тора — һәм моңа беркемнең дә исе китми.

Шикәр чөгендере колхозны бөтен Советлар Союзына танытты. Илебезнең данлы юбилеен бәйрәм иткән көннәрдә колхозга СССРның 60 еллыгы дигән мактаулы исем бирелү дә, мөгаен, чөгендерчеләрнең фидакарь хезмәте хәлиткеч роль уйнагандыр.

Бу хуҗалык илле елдан артык бер исем белән — «Үзәк» исеме белән яши.

Эреләндерү чорында да алар бик ашыкмадылар. Яңалыкның өстенлекләренә инангач кына, 1958 елда Кыр Тәүгелдесе, Әхмәт, Кужак авыллары белән бер хуҗалыкка берләштеләр.

Авыл кешесенә еш кына очракта инертлык хас. Бу хакыйкатьне заманында В. И. Ленин да ассызыклап билгеләп үткән иде. Өйрәнелгән эшне кичә дә, бүген дә, иртәгә дә шул ук ысуллар белән башкару, күрәсең, аның канына сеңгән. Яңалык борын төртте исә, аңлашылмаучылык башлана. Терлекчелектә специальләшү хикмәте килеп чыккач та «үзәклеләр» белән шулайрак булды. «Ничек инде тавыксыз? Ничек инде сарыксыз? Йомырка, йон сорарга күрше колхозларга барырбызмыни?..»

Әйе, бар иде шул заманнар — анысын мин дә хәтерлим әле — колхозда арыш, бодай, солы, арпа, борай, тары борчак, вика, карабодайдан тыш, киндер, көнбагыш, ясмык, чина, фасоль, люцерна, клевер, хәтта көньяк үсемлеге саналган күксагыз һәм цикорий кебек техник культуралар игелә иде. Болай төрле якка сибелүләр ризык төрләндерү өчен яраса да, экономик яктан үзен акламады. Терлекчелекнең керәгеннән артык күп тармаклы булуы да рентабельлелеккә аяк чала.

Хәзер колхоз нәселле таналар үстерә. Шикләнеп-шөбһәләнеп кенә башланган эш шактый табышлы булып чыкты. Авыл агае яңача санарга өйрәнде. Хуҗалык башка колхозлардан ике-өч айлык бозауларның һәркайсын уртача 288 сумга сатып ала. Аны сыер хәленә җиткереп, яңадан шул колхозларга 828 сумга сата. Бестужев токымлы бу башмак таналар узган ел колхозга 551500 сум саф табыш биргән. Белгечләр исәпли-хисаплый торгач тагын шундый фикергә килгәннәр: бозауларны ике-өч атналык чагында ук алырга кирәк.

— Бу терлекләрне юнәлешле үстерү һәм сыйфат күрсәткечләрен яхшырту өчен киң мөмкинлекләр тудыра, колхозларны бозау карап үстерү кебек артык мәшәкатьле эштән азат итә,— ди председатель.— Экономик яктан да отышлы.

Колхозның өч бригадасында да менә дигән терлек абзарлары. Комплексның икенче чиратын төзү төгәлләнеп килә. Кадрлар тәҗрибә тупларга да өлгергәннәр инде. Яшьләр зооветеринария укуларына тартылган. 1990 елда бирелә 5000 тана, сөтлебикәләргә әверелеп, Буа районының «Үрнәк», «Красный Октябрь», «Рассвет» кебек колхозларына озатылачак.

— Азык мәсьәләсе ничек соң?

— Соңгы елларда табигать безне күп нәрсәгә өйрәтте,— ди ферма мөдире Фәргат Насретдинов.— Ике еллык запас булдырдык: печән дә, сенаж да, яфрак-азык та, фураж да, печән оны да җитәрлек.

Бу якларда табигый болыннар да, куе урманнар да юк. Төп авырлык культуралы көтүлекләр җилкәсенә төшә. Азык кытлыгыннан, силос өчен, көнбагыш һәм кукуруз игеп котыласың. Башка чара юк. Терлек азыгы мул елларда шәхси хуҗалыкларга да яхшы гына өлеш чыга. Колхозда батырып эшләгән уңганнар гаиләсенә икешәр-өчәр олау (машина олавы) печән тия. Пенсионерларны, интеллигенция вәкилләрен дә читтә калдырмадылар. Сыерын да, сарыгын да рәхәтләнеп асрасыннар — сөтләр, майлар, итләр күп булсын. КПСС Үзәк Комитетының май (1982) Пленумы кабул иткән Азык-төлек программасын тормышка ашыруга шәхси хуҗалыклар да үзләреннән лаеклы өлеш кертә бит. Нәтиҗә инде беренче елда

ук сизелерлек: сыерлар саны 1982 елда 250 баш булса, быел 262 гә җиткән, сарыклар 1520 дән 1679 га арткан.

Яңа Чәчкап авыл Советы председателе Илгизәр Исмәгыйлов статистик мәгълүматлар китерә:

— Былтыр шәхси хуҗалыклар дәүләткә 898 центнер сөт, 35 мең данә йомырка, 525 тонна бәрәңге, 47 центнер йон саттылар. Планнар барлык күрсәткечләр буенча арттырып үтәлде. Г. Әскәрова, Г. Каюмова, М. Сираҗова, Г. Гыйльмиева, Ф. Вәлиуллина, З. Саттарова кебек уңганнар елның елында дәүләткә 500—900 литр сөт саталар...

Азык-төлек программасын уңышлы төстә тормышка ашыру һәр гаиләнең, һәр кешенең олы максатына әверелә бара. Хезмәте белән авылдашларының игътибарын казанган, дип, кемне генә атасаң да, ялгыш булмас төсле...

Колагыма чүкеч тавышы бәрелде. Әйе, бу ул — аргы яктан Сәгытдин абзый Шәрәфетдинов. Гомере буе диярлек тимер кыйнады. Әле мастерскойлар, ремонт базалары булмаган елларда сабанын-тырмасын, чәчкечен-ургычын төзәтеп торды. Хәзер инде үзе юк, ләкин варислары исән. Малайларына да ул тимер җене ияләштереп калдырды. Куллары теләсә кайсы эшкә ята. Узган ел төпчек улы Әхмәт, Әлифә килен белән «Колос» комбайнында эшләп, социалистик ярышта иг алга чыкты.

Яки менә яшьрәк буын вәкиле Надир Гатиятуллин. Аның белән без бергә укыган идек. Ул игенче һөнәрен сайлаган, 25 ел инде комбайнчы булып эшли, «Хезмәттәге батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән. Тәүгелде бригадасында Гатиятуллиннарның сугышчан экипажы икәү. Үзе «СКД-5»тә, армиядә хезмәт итеп кайткан улы Фаикъ «СКД-6»да, ә Васил белән Наҗи исемле уллары әле өйрәнчеклек мәктәбен үтәләр. Эстафета дәвам итә.

Күз алдыннан иң авыр елларда колхоз мәшәкатьләрен үз иңнәренә алган ир йөрәкле хатын-кызларыбыз Мөршидә Әхмәтова, Бибизәһрә Сәләхова, Гарфиҗамал Халитова, Мәрзия Габдрахманова һәм башка бик күпләрнең гыйбрәтле язмышы уза. Хәзер инде алар — лаеклы ялдагы әбиләр, оныкларын үстерәләр. Алардагы җиргә, хезмәткә булган мәхәббәт балаларның ялкынлы йөрәкләренә күчкән. Мәрзия апаның кызы Дилә — атаклы терлекче, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалеры. Ә ире Корбан абый авыр сугыш елларында колхоз председателе булды, яраланганга кадәр фашистларны тукмап кайтырга да өлгерде.

Хәзерге председатель Әхмәт Сибгатуллин — ышансагыз — ышаныгыз, ышанмасагыз — юк, нәкъ уноченче председатель. Казан авыл хуҗалыгы институтының агрономия факультетын тәмамлагач, ул биредә агроном-селекционер булды, авыл Советы председателе итеп тә сайланды. Басынкы табигатьле, сабыр, итагатьле бу ир-егетне авылдашлары күптән, сынап, күз алдында тотканнар иде. Ни әйтсәң дә, Зәйдулла абзый малае. Бөтен нәселләре уңганлык белән дан тота.

Зәйдулла абый — үзе җанлы тарих, авылның беренче тракторчысы да, комбайнчысы да ул. 1935 елдан бирле күпме җир сөргәндер дә, күпме игенне урып җыйгандыр. Балалары да үзенә тартты. Кайсын гына алма,— бары да — кешеләр ихтирамын казанган уңганнар.

— Ветераннар тәҗрибәсе — безнең өчен алтын хәзинә,— ди партоешма секретаре Фазулла Бикмуллин.— Алар безне киләчәккә юл күрсәтеп озатып калучылар.

Яшьләргә яшәү өлгесе булырдай язмышлы шәхесләр байтак бу якларда, байтак. Колхозның беренче персональ пенсионеры, гомере буе агротехник вазифаларын башкарган, инде фән белән коралланган белгечләр килгәч тә, кешеләргә, җиргә кирәк булып калган Габделхак Гыйлмиевне ничек телгә алмыйсың?!

32 ел буе трактор йөгәнләгән Газулла Шиһаповны ничек читтә калдырасың да, сугышка кадәр үк авылның беренче «полуторка»сын йөртеп, аннан әллә ничә егеткә шоферлык «чире» йоктырган Сәлимулла Яруллинны ничек искә төшермисең!

Авыл тормышы катлаулы. Сандугачлы ялары, шау чәчәкле җәйләре, җимешле көзләре бар аның. Әмма, һәркем белә: аннан җир һәм тир исе килә. Ул — мазутка буялган киемнәр, ул — вакыты белән таңнан төнгә кадәр сузылган эш көне, ул — салкын яңгырларда, тездән ашкан пычрак. Ә шулай да авылда яңа

урамнар пәйда була. Колхоз яшьләр өчен өйләр сала башлаган. Тормыш елдан-ел ямьләнә бара.

Былтыр авылда 26 туй уздырылган. Колхозчыларның хезмәт хакы арта бара. Белгечләр нигездә югары яки урта махсус белемле. Хуҗалыкның ун стипендиаты бар. Тиздән авылга инженер-механиклар, агроном, ветфельдшерлар, бухгалтерлар һәм... рәссам кайтачак. Бүгенге авылда рәссам да кирәкле кеше. Бәлки аңа — Казан художество училищесында укучы Айдар Газизовка — тиздән өлгерәчәк Культура сараен бизәргә туры килер, ул ясаган стендлар, афишалар, лозунг — транспарантлар колхоздашларын яңа каһарманлыкка чакырып торыр. Бәлки ул якташларының фидакарь хезмәтен зур полотноларда да чагылдырыр. Бусы — киләчәк эше.

Яшерен-батырын түгел, колхоз җитәкчеләре еллар буе төп игътибарын хуҗалык корылмалары булдыруга, төп фондларны ишәйтүгә юнәлттеләр. Кирәк тиракне ега диләр, әмма... ул тирәкләр күбрәк егылмады микән? Урамнардан атлыйсың — алпавыт утарыдай йортлар — таштан, агачтан... Тәрәзәләр бизәкле, түр бакчада декоратив куаклар, чәчәкләр. Терлек абзарлары да шифер яки калай түбәле. Бер-берсеннән көнләшеп, уздырышып салалар. Әмма, клубка дип төшәсең (ул уртак шаукымга ияреп, культура йорты дип үзгәртелгән) — бабайлардан калган иске бина. Үзгәрешләр бармы? Элек, тузан болыты күтәреп, «алтылы» әйләнәләр иде, хәзер... шәһәрдән ял көннәрендә әти-әниләреннән ит, май, яшелчә төяп китү өчен авылларына кайткан егетләр һәм кызлар яшьтәшләрен заманча ритмнарга биергә өйрәтәләр. Нәрсәдер үзгәргән, ниндидер изге матурлык югалган сыман. Пумала чәчле егетләр, «заграничный» ямаулыклар ябыштырган джинсилы кызлар пәйда булган. Вакыт-вакыт мин аптырап та куям: безнең авылмы соң бу? Үзенең беркадәр консервативлыгы, кадимлеге һәм хәтта диндарлыгы белән заманында күрше авылларның «түбәтәй дәүләте» дип үртәвенә дучар булган Яңа Чәчкапмы бу? Моннан 25—30 ел элек урамда эчеп-исереп йөрү түгел, хәтта картларга күрсәтеп тәмәке тартуны да иң зур әдәпсезлек санийлар иде. Ә узган ел авылга хәтта айныткычтан берничә кәгазь килгән.

Һәр йортта муллык, җитешлек. Ләкин... нәрсәдер җитми. Күрәсең, байлык — шыгырдап торган нарат өй, каралты-кура, терлек-туар, машина яки мотоцикл гына түгелдер. Фәнни-техник революция парадокслары шул бу — кеше рухы, кеше күңеле ниндидер мизгелдә игътибардан читтә калган.

Хуҗалык эшләренә башаяклары белән чумган җитәкчеләр, ниһаять, моңа да игътибар иткәннәр инде. Колхозның үзәк утары — Яңа Чәчкапның көньяк-көнбатыш читендә Культура сарае төзелә. «300 урынлы, иҗат түгәрәкләре өчен бүлмәләре булган, халыкка рухи азык бирү өчен бөтен мөмкинлекләр тудырылган»,— дип, кат-кат әйттеләр. Аңа терәлеп яңа урам башланачак — колхозда калучы яшьләр өчен яңа йортлар. Тора-бара бөтен авылның шушы якка күчүе күздә тотыла — генераль планда шулай каралган. Тик ул йортларга муллык белән бергә халкыбызның күркәм гореф-гадәтләре, гаилә татулыгы һәм бәхет кенә керсен иде. Ул йортларда колхозның матур традицияләрен дәвам итәрдәй, матди һәм рухи яктан бай кешеләр яшәсен иде!

## БҮГЕНГЕ ПРОЗА: ГЕРОЙЛАР, ПРОБЛЕМАЛАР

**Флера Ганиева**

# ӘДӘБИЯТ — УЛ СҮЗ СӘНГАТЕ

Әдәбият — сүз сәнгате дигәндә без аның төп вазифаларын: җәмгыять интересларына хезмәт итүне, кешене югары идеаллар яктылыгында тәрбияләүне һәм укучыны дулкынландырырлык, аның хисләренә, рухи дөньясына үтеп керә алырлык көчкә ия булуны күздә тотабыз. Әдәбият үз бурычын бары тик сүз ярдәмендә генә үти ала, бары тик җанлы булып күз алдына килерлек, күңелдә терелерлек сурәт ярдәмендә генә!

Татар прозасының классиклары Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Камалларны өйрәнгәндә без аларның әсәрләрендә куелган проблемалар, характерлар, тормыш материалы, сюжет-композиция үзенчәлекләре белән рәттән бик хаклы рәвештә һәм табигый буларак бу художникларның телен дә өйрәнәбез, сүзлекләрен төзибез, сүз запасын, байлыгын туплыйбыз.

Бүгенге проза әсәрләренә килик.

«...Көне... Иртәнге сәгатьтән үк бөркү эсселек үзен шулчаклы да сиздерә башлар икән. Гаҗәп! Хәтта төне дә җиңеллек китермәде — суынырга өлгермәгән таш йортлардан, таш урамнардан тузан, асфальт исе аңкытып һаман бөркелеп торды бу китмәскә килгән эсселек... Көне... Булыр икән бу хәтле дә теңкәгә тигән эсселек!.. Өченче атнага китте бит инде, зур бер афәткә әйләнмәсә ярар иде. Игеннәр ни хәлдә икән, ялан-кырлар, болыннар? Терлекләр дә интегә торгандыр... Чакырып кына китерәсеңмени шифалы яңгырларны... Юк шул әле, юк кешедә андый кодрәт!»

Әмирхан Еникинең «Тынычлану» хикәясе шундый хәвефле бер тонда башланып китә. «Көне...», «Эсселек...» Әсәр барышында язучы бу сүзләргә, җөмләләргә тагын әйләнеп кайта. Табигатьне генә сурәтләү түгел бу. Беренче чиратта халәтне, кешенең үзен ничек хис итүен сурәтләү. Нәкъ менә шушы рәвешле хикәяләүдә өзек-өзек тыч алган сулышны ишетәбез, фикер агышын сизЕмлибез. Шул сүзләрдән автор фикер йомгагын сүтә башлый. Нинди көн турында сүз бара соң әле? Фикер йөгерек су кебек ул — тармаклана, төрле катламнарга төшеп китә. Җыйнак кына хикәядә Ә. Еники бүгенге көннең вакыйга, күренеш булып күзгә күренеп тормаган, әмма без сизеп, тоеп йөргән, аңлатырга сүзләр таба алмаган катламнарын, мәсьәләләрен күтәрә.

Авторның хикәяләү үзенчәлеге, осталыгы шунда: укучы Галим Сәләховичның чарасызлыгын, гаҗизлеген гел тоеп, сизеп тора. Эсселектән интеккән йөрәк кислород бөртекләрен тамчылап йота-йота, әле рәтләнеп китеп, әле хәле бетеп тибә. «Соңгы вакытларда йөрәге аның нәкъ менә йоклаганда яки уянгач үзен ныграк сиздерә башлады. Нидән, ни өчен?» Хәлсезлек Гасим Сәләховичны чоңгылга таба илтә кебек. Фикере дә шул чоңгыл үзәге тирәсендә әйләнә. Сәбәп нәрсәдә, кайда? Кайсы көндә эшләнде ялгышлык? Нигә бүген ул — семьясы, дәрәҗәле эше булган кеше — ялгыз, чарасыз, гаҗиз хәлдә? Зур ялгышлык та эшләнмәде кебек, беренче карашка әһәмиятсез адымнар гына ясалган, ләкин алга таба түгел, кыенлыкларны җиңү, түөннәрне чишү ягына түгел икән. «Иң яхшысы — чигенү, нервны бозмас өчен, йөрәкне саклар өчен бары тик чигенү — калганы ник шунда чәнчелеп китми!» Азмы-күпме татулык, вакытлы тынычлык хакына чигенүләр. Үз вакытында дөрес кебек, акланган кебек булып күренгән чигенүләр китергән икән аны шушы хәлгә. Гасим Сәләхович дөньяда яшәп тә аны аңлап бетермәгән, хәзер дә аңламый. Хәер, аңларга бик ты-

рышмаган да, әлеге дә баягы тыныч урынга, тыныч позициягә чигенә-чигенә тормыш белән дә, хатыны һәм улы белән дә, фән белән дә алыш-биреше өзеп бетергән. Әйтерсең башкалар бер телдә, ул икенче телдә сөйләшәләр. Ул аларны, башкалар Гасим Сәләховичны аңламыйлар, аңларга теләмиләр дә, тырышмыйлар да. Гомере буе теләгән, омтылган тынычлыгы аңа әнә шулай ялгызлык, аңлаша алмау, битарафлык һәм эгоистлык булып килгән. Үлеме дә физик үлемнән бигрәк әнә шул рухи үлем булып, яшәү өчен көрәшмәү нәтиҗәсе булып кабул ителә.

Автор сөйләмен без персонаж сөйләменнән гадәттә бер карауга, язылу рәвешеннән үк аера алабыз. «Тынычлану» хикәясендә сөйләүче, фикер йөртүче кем соң? Төп урынны алып торган Гасим Сәләхович фикерләренә шушы хикәянең авторы сиздермичә генә, бик табигый рәвештә кушылып китә. Геройның язмышы турындагы уйланулардан ул бүгенге көн кимчелегенә чыга, аның гаять үткен мәсьәләләренә кагыла. Монысы хикәяләүдәге тагын бер катлам, шәхес буларак Ә. Еникинең үзен гәүдәләндергән, аның иҗатында расланып килә торган фикерләр катламы.

Моннан тыш әле укучы дәвам итеп алып киткән, үз тормышы, мисаллары белән бәйләп, киңәйтеп җибәргән фикер дулкыннары да бар. Гасим Сәләхович хатыны, улы белән каршылыкка кермим, җан тынычлыгын бозмыйм дип, ике арадагы стенаны үзе хасил иткән. Ә менә улы да аның хәленә калмасмы соң? Бу нинди аңлаша алмау — актив һәм пассив кешеләр арасындагымы, өлкәннәр һәм яшьләр мөнәсәбәтенә бәйлеме, әллә заман чиреме? Салкын битарафлык, исәп-хисап, апатия каян килә хәзерге активлык һәм тизлек заманында? Гомумән, әсәр укучыны уйландырды, яңа фикерләр, проблемаларга этәргеч булды. Кыска гына хикәягә тормышның катлаулы мәсьәләләрен сыйдыра алуга һәм шул ук вакытта ачык, конкрет сурәтләр тудыруга Ә. Еники гаять җентекләп уйланган хикәяләү үзенчәлеге һәм тел осталыгы ярдәмендә ирешкән.

Гомәр Бәшировның «Сарут» хикәясе дә башка хикәяләрдән көтелмәгәнлеге, яңалыгы белән аерылып торды. Бәлки шуңа күрәдер дә бу әсәр каршылыклы фикерләр уятты, Гомәр ага табигатенә хас булмаганча кискен, буяулар артык куертылган, яктылыгы җитенкерәмәгән әсәр булып тоелды. Мондый караш безнең бертөрлелеккә, яманатлары таралган урта кул әсәрләргә күнегеп һәм күмелеп баруыбыздан киләдер. Һәрхәлдә, жанры озын хикәя дип билгеләнгән җыйнак кына әсәр яныннан ваемсызрак үтеп кителде, аның художество көче, матурлыгы нәрсәдә икәнлеге тулысынча аңлашылмый калды кебек.

Мифтах Шамгуновны авылдашлары приговор җыеп, трибунал каршына китерәләр. Шаһит булып килгән авыл агае Хәйретдин белән Корбангали картның рәискә биргән җавапларыннан хәл ачыклана.

Корбангали: «Элек-электән безбашка булып үсте инде ул. Умарта басып та тотылды, базларда сөт-каймактан авыз иткәндә дә эләккәләде, кыен да ашады... Ну соңгы айларда бөтенләй чыдар әмәл калмады, гүпчи дә азынды, кызыл әрмиягә ихтыярыйлар җыя башлагач бигрәк тә... Барып теркәлә дәген, өр-яңа солдат киеме киеп кайта бу. Анысын сатып эчә дәген, яңадан барып теркәлә бу! Алып кайта дагын, сата бу, сата дагын, эчә бу, янәдән барып теркәлә бу!.. Биччут!

Үзе турында приговор чыгарганны ишеткәч, бөтенләй котырды бу. Бомба ташлап авыл сәвите кәнсәсен шартлатты. Ике кеше яраланды, алар бүлнистә ята, кәнсә җимерелде, яңаны салмыйча булмый».

Иң башта шуңа игътибар итик: Хәйретдиннең сөйләме гаҗәп дәрәҗәдә җанлы һәм үзенчәлекле. Ул сөйләүчене характерлый — эчкерсез, беркатлы, әмма гадел, туры сүзле крестьян. Икенчедән, бу нәкъ үз чорының җанлы сөйләме, образлы халык теле. Өченчедән, шушы ук сөйләм мәсьәләне бик аңлаешлы итеп төшендереп тә бирә. Бер генә артык, буш сүз юк, иң кирәкле сүзләр белән төп фикер генә белдерелә. Мондый сөйләм хезмәтнең дә, сүзнең дә кадерен түбән белгән кешеләрдә була.

Вакыйгаларны гына әйтеп чыксак, хикәя авыл халкына күп җәбер-золымнар салган бер егетнең атарга хөкем ителеп тә качып котылуы, әмма, ахыры килеп, үзе эшләгән явызлыгының җәзасын алуы, үлүе турында. Менә шундый хәл булды дип автор сөйләп кенә чыкса, әсәрнең эмоциональ көче артык зур булмас иде. Г. Бәширов

үзе тасвирлаган вакыйга-хәлләрнең эчке мәгънәсен ача, әһәмиятле нәтиҗәләргә алып килә.

Авыл халкының әхлакый көче, олы җанлылыгы художникларча осталык белән ачыла әсәрдә. Мифтахка рәнҗүләре ташып аккан, шулай да үзләре рәхимсезләнмәгәннәр, явызлык, үчлек алар күңеленә үтеп кермәгән. Алар рәхим-шәфкатьле, кешелекле булып калганнар. Моны без әсәрдә ачык күрәбез.

Явызлык, үч алу теләге Мифтахта иң түбән, кыргый хисләрне уята. Шул хисләр аны шашар хәлгә җиткерә, Мифтахны кешелектән алып китәләр, ерткычлык чигенә китереп, аңын томалыйлар. Язучы бу кичерешләр давылын, аның хәрәкәтен ачык тасвирлый, Мифтахның һәр хәрәкәте, эше-гамәле шушы эчке көчкә буйсындырылган, һәм без аны күреп торабыз.

Әсәрнең төп конфликты нидән гыйбарәт? Мифтах белән авылдашлары арасындагы каршылыкны сурәтләүдән башланган конфликт үзенең асылында рәхимлек һәм явызлык көрәшенә әйләнә.

Конфликтның аеруча көчәеп киткән урыннары — драматизмга лирик дулкын кушылган эпизодларда. Драматизм трагедиягә якынлаша, киеренкелек соң дәрәҗәгә җитә. Бу кешеләр дөньясына, алар конфликтына өченче көч — табигать килеп кушылганда шулай.

Җирән кашка белән аның колыны — сокландыргыч матур образлар. Әсәрдә аларга зур мәгънә салынган: аларга кул күтәрү — ул табигатькә, яшәүгә кизәнү дигән сүз. Шуңа күрәдер инде кешеләр җиңеп бетерә алмаган явызлыкны җирән кашка җиңә, үзен җәзалаган дошманын тибеп очыра. Шәфкатьле, кешегә тугры булган җан иясе бу очракта шулай рәхимсез кылана һәм Мифтахның үлеменә сәбәпче була. Үзен дә, кешеләрне дә бер явыздан коткара. Ләкин әсәр моның белән генә дә бетми әле. Җиңү дигән төшенчә соңгы эпизодта тагын да мәгънәлерәк, гуманлырак итеп ачыла.

Рәхимсезлекне җирән кашка явызлыктан да түгел, хәтта үзен коткару өчен дә түгел, ә колыны хакына, аны саклап калу өчен эшли. Бәлки нәкъ шушы фидакарьлек ахыр чиктә Мифтах күңелендәге кешелекне уяткандыр да...

Без бу әсәрдән нинди нәтиҗә чыгарабыз соң? Рәхимлек белән явызлык көрәше — төрле өлкәдә даими бара торган көрәш, тормышның драматизмын, фаҗигаларын тудыра торган көрәш. Явызлык кешенең җанын агулый, кешелеген җимерә, иң беренче чиратта аның үзен бәхетсез итә, һәлакәткә китерә. Ул — җимерүче көч, һәр очракта, һәр урында.

Әсәр һәр җөмләсе, сүзе белән безне шушы нәтиҗәгә алып килә, автор шушы хакыйкатьне раслый.

Ике әсәргә иркенләбрәк тукталу һәм проза турындагы сүзне романнардан түгел, ә хикәяләрдән башлап китү белән шуны әйтергә телим: Ә. Еникинең «Тынычлану» һәм Г. Бәшировның «Сарут» хикәяләре — бүгенге көн прозасында вакыйга булган әсәрләр. Югары сәнгатьле телдә язылган булулары, фикер тирәнлегенә һәм ачыклыгына ия булу, хис-кичерешләр байлыгына тәңгәл килгән форма бөтенлеге аларны башка әсәрләр арасыннан аерып куя. Авторлар кеше җаны аша вакыт катламнарын бәйлиләр, фәлсәфи дәрәҗәдәге зур күренешләрнең мәгънәләрен ачалар. Шушы сыйфатлары белән алар хикәя жанрының офыкларын киңәйттеләр, аны яңа баскычка күтәрделәр.

А. Гыйләҗевның кайнарланып язган мәкаләсе авторның әдәбият алдында торган бурычларга, хәл ителәсе проблемаларга битараф булмавын күрсәтә. Чынлап та: битарафлык бүгенге көн әдәбияты өчен шактый куркынычлы, йогышлы чиргә әйләнеп бара бит.

Т. Галиуллин, Р. Мостафин һ. б. авторларның мәкаләләре дә мәсьәләгә төрле яктан килеп, конкрет анализ, дәлилле фикерләр белән бүгенге проза дигән зур һәм катлаулы күренешне аңларга ярдәм иттеләр, уйланырга этәргеч булдылар.

Роман — прозаның үсеш дәрәҗәсен билгеләүче, җәмгыять тормышын иңләп алырга, тирән анализларга мөмкинлек бирүче жанр. Соңгы елларда Шамил Бикчурин,

Эдуард Касыймов, Мәхмүт Хәсәнов һ. б. бер-бер артлы калын-калын романнар яздылар. Бу авторлар таланттан мәхрүм түгелләр, эшләргә иренми торган, хезмәтләре белән ихтирамга лаек язучылар. Тормышның кайнап торган урыннарында, зур вакыйгалар үзәгендә яшиләр алар. Бүгенге көнгә, хезмәткә, яшәешкә кагылышлы кайнар материалларга тотыналар. Ләкин учактан алган кайнар күмерне ялкынга әйләндерәсе, яңа сәнгать учагы кабызасы урынга, еш кына очракта сүндереп куялар.

Ш. Бикчуринның «Каты токым» романы бездә шактый игътибарны җәлеп итте. «Каты токым»ның әһәмиятен һич киметмәстән, әдәби процесста яңгыраш тапкан, Союз күләменә чыккан әсәр дип куанган хәлдә, авторның «Тирән катлам» романы турында җаваплылык тоеп иҗат ителгән дип әйтеп булмый. Чимал килеш татарча басылган әсәрнең русчага тәрҗемә ителүе дә бу юлы куандырмады, чөнки ул татар әдәбиятының мактанычы булырлык әсәр түгел инде.

«Урта кул» дип нинди әсәрләрне санныйбыз дигәндә тәнкыйтьтә дә, әдәбият белемендә дә фикер каршылыгы юк. Проблемасыз, авторның нәтиҗәсе, ачык мөнәсәбәте, фикере булмаган, укучының да фикерен кузгатып, аны уйландыра, дулкынландыра алмаган әсәрне уртача дибез. Алай булгач, нәрсә, нинди сыйфат, җирлек яшәтә аларны? Урта кул икән, мәктәптәге билге шкаласы буенча аларга «өчле» билгесе куябыз дигән сүз. Димәк кай яктандыр кирәкле, әһәмиятле булган сыйфатлар аларда, әлбәттә, бар. Сурәтләргә алынган материал кызыклы, заманча, актуаль булырга мөмкин. Мондый очракта тема «коткара». Яисә әдәбиятның үзәк проблемаларыннан булган мораль-әхлак турында сүз бара. Яки яңа өлкәләр, яңа профессияләр кызыксындыра. Урта кул әсәрләр гадәттә сурәтләү, тасвирлау урынына информация генә бирә, сөйләп кенә чыга. Нәтиҗә «тормышта менә мондый хәлләр дә була» дигән дәрәҗәдә кала, сәбәпләре турында фикер йөртелми, тормышның катлаулы бәйләнешләре эзләнми.

Бүгенге көн прозасын иңләп алып карарга тырышсак, беренче чиратта, әлбәттә, әдәбиятның үсешен билгеләгән һәм аның казанышы булган әсәрләрне барлап чыгабыз. Мондый әсәрләр әдәбиятның йөзен билгели, хәзерге хәлен чагылдыра.

Аяз Гыйләҗевның «Җомга көн кич белән» һәм «Әтәч менгән читәнгә» повестьлары, исемнәре белән генә түгел, материалы, формасы белән дә оригиналь әсәрләр булды. Мәсьәләне бу рәвешле куеп, тормышка бу ноктадан торып караган һәм кызыклы нәтиҗәләргә китергән әсәрләр авторның үз иҗаты өчен дә яңалык, үсеш иде.

Әсәрләр турында фикерләр күп булды һәм алар хакында сөйләшү әле дә дәвам итә. Бу урында тулы анализ ясауны максат итеп куймастан, берничә сүз генә әйтеп үтәсе килә.

Рухи көч — кешене матурлый торган иң зур сыйфат. Беренче әсәр герое Бибинур үзендәге рухи көчне тулысынча аңлап бетерә микән, әмма аның күңел дөньясын тузудан, җимерелүдән шул көч саклап тора. Тормыш авырлыгы, Зөһрәбануның гомер буе аны сындырырга, буйсындырырга тырышуы, үзе тәрбияләп үстергән балаларның онытып бетерүләре — боларны фаҗига итеп тә сурәтләп булыр иде. Ләкин Бибинур образы яңача, көтелмәгән мәгънәләр белән ачыла. Олыгаю, картаю ул югалтулар гына түгел, ә күңел сизгерлеге, хәтергә язылып барган истәлекләр, байлык та икән.

Әсәрнең хикәяләү стиле, тел үзенчәлекләре борынгы риваятьләрдән үк килгән яңгырашка ия. Мәңгелек күгендә кабынып алган йолдыз кебек, Бибинурның үз теле, уйлау-тою авазы әсәрнең теленә тирән моң өсти. Автор хикәяләве бик табигый һәм шул ук вакытта хикмәтләргә, мәгънәләргә бай, искиткеч сурәтле.

А. Гыйләҗевның «Әтәч менгән читәнгә» әсәре дә повесть жанрына яңалык өсти. Әйтерсең автор «язарына азык» табып ала да, аның белән тәҗрибә ясап карый. Менә мин хәзер бер сынау үткәрәм, карыйк әле нәрсә килеп чыгар икән дигәндәй, укучыларны тамаша карарга чакыра. Хикәяләвендәге ачык беленеп торган ирония, «борын-борын заманда»... дип әкият сөйләгәндәге интонация материалның характерына гаять туры килә. Яшәгәннәр ди ике күрше, бер заман шайтан алар күңеленә коткы, ягъни көнчелек уты салган ди... Чынлап та, кая кадәр китереп җиткерә ала икән көнчелек хисе кешене? Ахырына кадәр барып карасаң, бу юлның ахырында нәрсә икән? Һәм автор шулай эшли дә.

Дөрес, бүгенге көндә мал артыннан куу, әйбер колы булу хәвефле бер хәлгә

әйләнеп бара, авыл кешеләре дә элекке матур гадәтләрне онытып, үз тормышларын да, башкаларныкын да ямьсезләп яши башладылар дигән әһәмиятле проблема, чаң сугып алу да бар әсәрдә. Өлкән буынның Хәйретдин агайлары дөньядан китеп бара, киң холыклы кешеләрдәге, тормышка карата фидакарь була белгән хикмәтле кешеләрдәге сыйфатларны үзебезгә кабул итеп алырга сәләтлеме без?

Автор шул фикерләрне, нәтиҗәләрне әйтү өчен язгандыр әсәрен. Бу урында мин бары повестьның яңалыгы, аеруча кызыклы ягы аның художество алымнарында дип әйтергә телим. «Әтәч менгән читәнгә» дип укыгач, нинди әтәч, нинди читән турында сүз бара дип уйламый калмыйсың. Җавабы да күп мәгънәле. Бер мәгънәсен: әтәч ул — көнчелек, читән — кешеләр арасындагы мөнәсәбәт дип карарга мөмкин. «Алтын әтәч» әкиятендәге кебек, куркынычның кайсы яктан киләсен хәбәр итеп торучы символик образ дип тә уйларга буладыр. Һәрхәлдә әтәч образы әсәрдә бик мәгънәле урын алып тора, әтәчне «законный» үз урыныннан куып төшергән күршеләрнең үзләрен дә кукраерга, ялтырарга яратулары белән әтәч итеп кабул итә башлыйсың.

Повестьта документаль әдәбият алымы — автор тарафыннан бирелеп барылган белешмәләр дә үзенчәлекле роль уйный. Алар әсәрнең реальлеген көчәйтәләр, автор белән укучы үзара килешеп куйган уен кагыйдәсе булып кабул ителәләр.

А. Гыйләҗевның бу ике повесте шулай ук бүгенге көн прозасының күренекле әсәрләре булып саналырга хаклы.

*

*  *

М. Мәһдиевнең «Кеше китә — җыры кала», «Исәнме, Кәшфи абый!» повестьларының уңышлы якларын, эстетик кыйммәтен билгеләделәр һәм кимчелекле якларын да күрсәттеләр: баштан ахырына кадәр хәрәкәт иткән, әсәрне бәйләп торган герой юк; сюжет таркау, композицион төзеклек җитми диделәр. Тәнкыйть фикерендә хаклык бар иде. М. Мәһдиевнең талант көчен тулысынча гәүдәләндергән әсәрләре янында соңгы повесть фикер һәм хис тирәнлеге, бөтенлеге ягыннан түбәнрәк дәрәҗәдә тора.

Ә мин «Кеше китә...» повестена карата әйтелгән «таркаулык, сюжетсызлык» дигән билгеләмәләр белән килешмәс идем. Без сюжет-композиция мәсьәләсендә беркадәр шаблонга, традицион формаларны калып итеп күрергә ияләнеп китмәдекме икән?

Күрер күзгә әсәр чынлап та вак өлешләрдән, бер-берсенә турыдан-туры бәйләнмәгән эпизодлардан тора кебек. Шуңа да карамастан, әсәр бөтен, тәгәлләнгән. Хикмәт, минемчә, әсәрнең материалы үзенчәлекле булуда, авторның форманы шушы үзенчәлеккә буйсындыруда. «Кеше китә...» әсәрендә, исеменнән үк күренгәнчә, вакыйга бер генә — кешенең сугышка китүе. Китү, аерылу кузгаткан уйлар, истәлекләр, хисләр өермәсе... Кыска гына бүлекләрдә кешеләрнең җан җылысы, өзелеп калган өметләр, тормышка ашып җитмәгән хыяллар, тәгәлләнмәгән эшләр, ярты юлда калган җыр... Кеше сугышка китә, әйләнеп кайта аламы әле ул аннан, юкмы — шуны аңлаган хәлдә китә. Аның җырланып бетмәгән җыры кала... Әйләнеп кайта алмаганнардан исәннәргә истәлек булып бергә яшәгән гомер, балалар, сагынып сөйләрлек мәхәббәт кала — җыр кала... Кеше җирдән китә икән, эшләгән эше, туган-үскән җире, иле кала, тормыш кала — җыр кала.

Дулкын-дулкын булып әсәрдә шушы фикер кабатлана, расլана. Әсәр үзәгендә — һәр героен аңлап, кичерешләрен танып, тоеп торган автор образы. Кешеләрне яратуы, соклануы, ачык белдерелгән теләктәшлеге аның үзен дә укучыга якын, кадерле итә. Шактый чуар характерлы персонажлар, озату ыгы-зыгысы. Болары — тышкы билгеләр, художник аларны да бик характерлы детальләр, штрихлар белән сурәтләп үтә. Әмма бу тышкы чуарлык күмеп китә алмаган (һәм күммәскә дә тиешле) төп кыйммәтләр, төп мәгънәләр бар. Шушы мизгелдә — аерылу минутында — әллә ни булдыклылар, уңганнар санында йөрмәгән гап-гади генә кешеләр дә яңача ачылып

китәләр. Кызык, сәер, әкәмәт бу кеше дигәнең. Аның наив ихласлыгы авторда юмор, елмаю уята. Серле, тирән, катлаулы бу кеше дигәнең — автор сокланып тасвирлый. Әнә шулай һәр персонажны яратуы, аңа битараф булмавы өчен язучыны хөрмәт итәсең, әсәрләрендәге моң чыганагы авторның үз күңелендә икәнен ачык тоясың.

«Торналар төшкән җирдә», «Исәнме, Кәшфи абый!» повестьларында да шушы моңы, үткен сурәтләү манерасы, чын мәгънәсендә сәнгатьле теле булган авторны күрәбез. М. Мәһдиевнең тормышка карашлары, позициясе ачык. Ул аларны әсәреннән-әсәренә кабатлап, раслап килә. Фикерләре, мөнәсәбәтләре эмоциональ, шуңа күрә әсәрләрен дулкынланып укыйсың. М. Мәһдиев иҗатын мин әсәрләрен үз шәхесе тирәсенә туплаган компактлы, тыгыз иҗат итеп күз алдына китерәм һәм, үзенә таләпчәнлекне киметмәгән хәлдә, бай бер сәнгать дөньясы булып яшәр дип ышанам.

*

* *

Бүгенге прозада игътибарны җәлеп итә торган кызыклы бер күренеш формалашып килә. Бу — берничә яшь прозаикка хас булган, аларны традицион проза стиленнән, агымыннан аерыбрак куйган иҗат манерасы.

Марсель Галиев һәм Әхәт Гаффарны яшь прозаиклар дип өйрәнчек мәгънәсендә түгел, алардан өлкәннәр белән, үзләренең остазлары белән чагыштырып әйтәбез. Иҗатлары турында сөйләгәндә яза-яза остарыр әле дип түгел, зур, җитди таләпләр куябыз, киләчәкләренә өмет баглыйбыз. Нинди сыйфатлары, үзенчәлекле яклары игътибарны җәлеп итә соң?

М. Галиев беренче хикәяләрендә үк заманның яшь кешесен, үз буынын тасвирлый башлады. Геройлары белән бергә үзе дә әсәрдән-әсәргә күчә, катлаулана, фикерләре-хисләре белән кызыклырак була бара. Аның соңгы повестьлары («Ул чакта» һәм «Ерак урман авазы») шәхес һәм дөнья, тормыш-чынбарлык мөнәсәбәтләрен аңларга тырышуы, шушы өлкәдәге эзләнүләре, уйланулары белән әһәмиятле булдылар.

Тормышның нигезен хасил иткән төп кыйммәтләр бар, үзгәреп торса да, асыл сыйфатларын, билгеләрен югалтмый торган матурлык бар. Шул мәсьәләләр кызыксындыра бу ике авторны. Геройларында аларның үз интереслары, дөньяга карашлары, танып-белүләре, бәяләре. Шуңа күрәдер геройлар һәм автор арасындагы бу бәйләнешне, уртаклыкны ачык сиземлисең һәм әсәр геройларын лирик герой рәвешендәрәк кабул итәсең. М. Галиев һәм Ә. Гаффаров геройлары яшьлеккә хас булганча романтиклар да, бүгенге яшьләрчә үз шәхесләрен танырга һәм танытырга омтылган кыюлар да, заманча рационалистлар да. Аларны кабул итәргә яки итмәскә мөмкин, алар белән бәхәсләшергә яки килешергә була. Әмма аларның бүгенге көн кешеләре икәнен танымый калып булмый. Язучыларның профессиональ осталыкка таба баруларын мин геройларның җанлы, аңлаешлы булуларында, автор мөнәсәбәтенең, фикерләренең ачыклыгында күрәм.

М. Галиев кеше аңы, кеше җанының катлаулы дөньясын алгы планга куеп өйрәнә. Әсәрләренең формасын, образлар системасын, хикәяләү рәвешен шушы материалга, төп максатына буйсындыра. Әсәрләренең кадерен белеп, яратып яза. Бу сыйфаты белән мин аны Хәсән Сарьянга охшатам. Телнең көчен, чиксез мөмкинлекләрен тою, күрәсең, табигатьтән килә торган сәләттер. М. Галиевның шагыйрьлеге һәм рәссамлеге шулай ук аның прозасын баетып торган сыйфатлар. Вакыйга һәм күренешләрне эчке яктан тасвирлап баруда, сурәтне картина ясагандай төсле итеп гәүдәләндерә алуда аның әсәрләренең сәнгатьчә матурлыгы. Әдәбият коточкыч фаҗигаләрне, ямьсез күренешләрне тасвирлаганда да үзе нәфис, матур булып калырга тиеш бит әле. Нәкъ шушы сыйфат М. Галиев әсәрләрен башлап язучы һәм яшьләрдән аерып куя.

Әхәт Гаффаровның «Бишек» повесте 1982 ел прозасын төрлеләндереп җибәрде, миңа бу әсәр сурәтләү алымы белән кызыклы тоелды. Аит дөнья белән алыш-бирешен өзеп, отшельник булып яшәү өчен туып-үскән өенә кайткан. Кеше тормышындагы критик мизгел, борылыш моменты. Бу үзе инде кызыксыну уята — нигә алай булган,

алга таба ни булыр? Автор бу сорауларга җавап бирергә ашыкмый, укучыны Аитның кичерешләр дөньясына алып кереп китә һәм шактый озак адаштырып та йөртә. Шулай да без геройның кичерешләрен, настроениесенең үзгәреп торуын күрәбез. Үткән тормыш эпизодлар булып һәм яңача күреп, төшенеп алган мәгънәләр булып бүгенге көн кичерешләре белән аралашып бара. Әсәрдә шулай ике катлам сиземләнә: үз дөньясына кереп бикләнгән Аит һәм барыбер качып котылып булмый торган тормыш, зур дөнья. Үзен изоляторга ябып куйган яшь бер кеше күңел дигән келәткә ревизия ясый — күпме байлык тупланган, табышлар, уңышлар бармы, әллә барысы да җимерелеп-кырылып беткәнме, кыйпылчыклар өеменә әйләнгәнме? Герой үзе дә, автор да һәм укучы да шушы сорауларга җавап эзли.

«Бишек» повестенда авторның максатын, фикер юнәлешен, ниятен сиземлисең, үзең өчен ниндидер нәтиҗәләр дә ясый аласың. Әмма, авторның үз ачышлары, үзе әйтергә теләгән фикерләре бишектә килешрәк калган, ачыкланып бетмәгән.

Әдәбият, сәнгать тормыштагы проблемаларны табарга, ачык, конкрет итеп куярга гына тиеш, аларны хәл итү исә тормышның үзенең вазифасы дип әйтәләр кайвакыт язучылар. Шулай да сәбәпләр, җирлек турында уйлану, иртәге көнне дә күреп, бүгенге көндә барган хәрәкәтләрнең, процессларның дәвамын аңлата алу язучы өчен зарурый. Әсәрнең үзендә үк сизелеп торган мөмкинлекләрне Ә. Гаффаров сорауларга ачык җавап бирмәве, киресенчә, җеп очларын махсус яшереп торуы белән чикләп куйган.

Серлелек ул йомгакны чишәргә, аңларга омтылганда кызыклы. Ләкин әгәр дә ул серлелек ясалма булса, ягъни, автор аны мотивлаштырса, әсәр белән логик бәйләнеше булмаса, ул очракта серлелек автор куерткан томанга әйләнә, ачуны китерә башлый.

Тышкы атрибутларга да урын күбрәк бирелә кебек тәэсир калды (бәллүр кубоктан Камю коньягы эчү, ишегалдында төсле слайдлар кебек сибелгән заманча мебель, спорт инвентарьлары һ. б.). Бу эффектлы детальләр әсәрдә беркадәр театр декорациясе ролен үти башлыйлар. Һәрхәлдә, әдәби әсәрдә художестволы детальләр үзмаксатка әйләнмәскә, чама хисе югалмаска тиеш.

М. Галиев һәм Ә. Гаффаров иҗатлары — көч алып, үсеп килә торган иҗатлар һәм шушы мәгънәдә яшь иҗатлар. Катлаулы тормыш күренешләрен кеше күңеле аша ачарга, фәлсәфи планда фикер йөртергә омтылган, шул юнәлештә үсәргә тиешле иҗатлар.

Һәм аларга бер теләк әйтәсе килә.

Хис-кичерешләр, һичшиксез, әһәмиятле, кирәкле өлкә, бары тик сәнгать кенә анализлый, тасвирлый ала торган материал. Ләкин аның белән генә мавыгып яшәү, минемчә, иҗатны чикли. Проза — әдәбиятның тормышны иңләп ала торган, вакыт һәм урын мәгънәсендә чиксез киң чынбарлыкның үзен гәүдәләндерә ала торган төре бит. Язучылар менә шушы зур дөньяга кыюрак чыксалар иде. Җәмгыять тормышының актив хәрәкәтенә игътибарларын юнәлтсәләр иде.

*

* *

Әдип үзенең иҗаты белән әдәбиятка, димәк, аерылгысыз рәвештә, әдәби телгә хезмәт итә, аны камилләштерүгә үзеннән дә өлеш кертә, төрле чүпләнүдән, җимерелүдән саклый.

Нинди тел белән язуы әдипнең үз зәвыгына гына бәйле шәхси мәсьәлә түгел. Үз әсәрен ярату гына аз, шул әсәрне укырга алынган кешене — укучысын да хөрмәт итәргә тиеш язучы. Бу — бик мәгълүм хакыйкать. Тик аның белән исәпләшү генә җитми.

Менә «Казан утлары» журналының быелгы беренче саны һәм һәр язган әсәре белән диярлек кызыксыну, фикерләр, бәхәсләр уята торган, әдәбиятта үзенчәлекле юлдан бара торган язучы Әхсән Баяновның «Таш китап» романы.

Ә. Баянов гаять актив язучы: күп яза, тормышның төрле якларына мөрәҗәгать итә, әсәрләрендә көтелмәгән яктан килеп тасвирланган материал, яңача формалар,

алымнар була. Табигать һәм кеше, техника һәм кеше, кеше һәм сәнгать кебек төшенчәләр турында уйлана ул һәм кызыклы ачышлар да ясый. Нәрсә турында сүз барса да ул үз тавышы белән сөйли.

Ә. Баянов иҗаты игътибардан читтә яшәми, әсәрләре үз вакытында анализлана, бәяләнә киләләр. Бу урында мин аның «тавышы» — проза әсәрләренең теле турында гына әйтергә телим.

«Наладчик, күкрәгеннән кирәк дәрәҗәдә калку тотып, тиешле сәдәфкә басты. Бер дә тәэсире булмас сыман юк кына хәрәкәткә буйсынып, ямь-яшел чатыр — мич түбәсе — өскәрәк күтәрелеп җәелде дә, аннары машинаның корыч корсагы киңәеп, кулына көкре трубка тоткан наладчикка эчкәрәк керергә юл ачылды... Аны тыңлап, өлешләп бүлү приборы чүмечле кулы белән тарту мичинә таба ашыкмыйча гына сузылды, чүмечне алсу сыеклыкка батырды да, шуны алагаем чумырып алгач, иплэп кенә күтәрде, машина янына китерде һәм аның өстендәге бүрәнкәгә — пресс агрегат стаканына агызырга тотынды».

Бу романның иң әйбәт яки иң начар җөмләләре түгел, иң урталары, ягъни, иң типик, характерлылары. Бу җөмләләрнең һәр сүзе саен абынасың, ахырына барып җиткәндә беренче сүзләре хәтердән коелып калган була.

Дөрес, безнең җанлы сөйләм телебез соңгы елларда шактый үзгәрде: экономияле, эшлекле булып китте, төрле профессионализмнар, терминнар белән дә чуарланды. Кинаяле, иронияле сөйләм манерасы да модага керде. Әмма бит әдәби тел модалы кием түгел, әсәрдә бер стиль бөтенлеге сакланырга тиеш.

Ә. Баянов исә махсус катлауландырылган ясалма теле белән әсәрләренең фикеренә, җанына үтеп керергә үзе үк ирек бирми. Әсәр чәнечкеле тимер чыбыктан ясаган чәчәкне хәтерләтә, андагы сурәтләрне һич күңелгә якын алып булмый. «Таш китап» исеме бу кадәр дә әсәргә туры килер икән диган фикер беренче һәм иң көчле тәэсир. Романның әһәмияте, темасының актуальлеге, заманчалыгы, проблемалар һәм нәтиҗәләр турында әсәргә тулы анализ ясалганда әйтелер, әлбәттә. Мин, бернинди дә прогноз бирмәстән, бер генә фикерне кабатларга телим — бу мәсьәләләргә барып җитү өчен сабырлык һәм түземлелек белән Ә. Баянов әсәрләрендәге тел барьерын үтәргә кирәк.

Ә. Баянов иҗатындагы мөстәкыйльлек һәм эзләнү сыйфаты, әлбәттә, ихтирамга лаек. Аның телгә үз карашлары бар, ул үз тел-стилен тудырырга омтыла. Шуңа күрә һәр әсәрендә аңа гына хас алымнар, җөмлә төзелеше, фикерләү формасы кабатланып килә. Бу мәгънәдә, һич икеләнмичә, Ә. Баянов хикәяләвендә максатлы бер юнәлеш бар дип әйтә алабыз. Ләкин язучының үз ниятләре, максатлары изге булган хәлдә дә, объектив нәтиҗә башкачарак килеп чыга. Чөнки телнең үз гомуми законнары бар, алар белән исәпләшми башладыңмы, ул синнән үч ала, шул телдә әйткән фикереңне имгәтә, сурәтне җимерә.

Телгә карата әйтелгән сүзләр бер Ә. Баяновка гына кагылмый, әлбәттә. Аның исеме биредә аталган икән, үзенчәлекле бу шәхес үзенә читтән торып карасын иде дип борчылудан гына. Бүгенге прозаның хроник авыруга әйләнеп бара торган кимчелеге — әдәби телне төссезләндерү, зәгыйфьләндерү. Моңа мисалларны санауга караганда киресен эшләү — сәнгатьчә телне иҗат итүчеләрне күрсәтеп чыгу бик күпкә җиңел.

Мәсәлән, Нурихан Фәттахның иҗаты үзе бер сәнгать дөньясы икәнлегенә һәм аның нәкъ менә сүз сәнгате булуына әсәрләрен укыган саен ышана барабыз. Ул билгеле бер мәгънәдә уникаль иҗат, күп әдәбиятлар кызыгырлык, сокланырлык иҗат. Н. Фәттах әсәрләрен бөтен тирәнлегенә төшеп анализларга әлегә тәнкыйтьнең белемеме, кыюлыгымы җитми тора. Хәлбуки, мондый анализ язучыга, әдәби тәнкыйтьнең үзенә һәм укучыга да файдалы булыр иде.

Матур традицияләр бирел калдырган Хәсән Сарьянның музыкаль аһәңле теле бүген дә яңгырап тора, бүгенге байлык булып яши.

Сабыр гына, ашыкмыйча гына, тормышны күзәтеп, уйланып иҗат итүче Вакыйф Нуруллин повестьлары шулай ук тәрбияви әһәмияте һәм тәэсир көче белән бүгенге прозаның төп юлындагы әсәрләр, татар әдәбиятының матур традицияләрен дәвам иттерүче әсәрләр...

Сүземне йомгаклый төшеп, мин «Бүгенге прозага ни җитми?» дигән сорау куяр идем. Һәм үзем үк аңа болай дип җавап бирер идем:

— Безнең бүгенге прозада үзенең эшчәнлеге, зур максатлары һәм көрәше белән укучыны рухландырырлык киң мәгънәсендә уңай герой юк. Сөйләшүдә телгә алынган әсәрләрнең геройлары да бары шул әсәр чигендә генә, шул әсәр өчен генә геройлар, ә әдәбият өчен зур герой түгелләр. Чагыштырып әйтсәк, хор бар, ә солистлар, корифейлар юк. Мине Йосиф Герасимовның «Предел возможного» романындагы Ремез образы сокландырган иде. Иң кыен вакытларда авырлыкларны үз җилкәсенә алуы, кеше мөмкинлекләренең чиген гел киңәйтеп һәм алга таба күчереп яшәве, меңнәрчә кешеләрне — коллективны үз артыннан ияртүе, аларга йогынты ясавы белән зур шәхес, эре фигура булып күз алдына килә ул. Аның шәхси тормышы, үзен бәхетле итеп тоюы да шул көрәш һәм җиңүләрдә. Юк, ул аскет та, монах та түгел, тик ул үзенә хыянәт итми, нинди хәлләрдә дә үзен югалтмый.

— Безнең прозага гражданлык, иҗтимагый активлык җитми, аны бүгенге көннең көндәлек һәм вак мәшәкатьләре күмеп китә. Гадилеккә омтылу дип аклансак та, бу — җирдән бер карыш та күтәрелмәгән, илһамсыз, канатсыз гадилек. (Пегасның гади аттан аермасы да шул канатлы булуында лабаса.)

— Прозабызда матурлык, нәфисләк югалып бара. Хәтта ярату турында да ир белән хатын арасында хыянәт иту-итмәү планында гына язылa, бәхет төшенчәсе дә примитивлаштырылып, вакланып тасвирлана. Мораль-әхлак мәсьәләләре кешенең җәмгыятьтә тоткан урыныннан, тормыш белән мөнәсәбәтләреннән, максатларыннан чыгып түгел, семья эчендә, ике яки өч кеше арасында гына хәл ителәләр.

— Безгә эпиклык җитми. Соңгы еллардагы романнарны ирексездән Габдрахман Әпсәләмов романнары белән чагыштырып карыйсың. Алардагы кискен конфликтлар, ачык һәм тәмамланган фикерләр, тормышның алгы сызыгында яшәгән геройлар бүген таркау хәлдәрәк яшәп яткан проза янында аеруча сизелә.

Шактый озынга киткән сүзне йомгаклап, кабаттан шуны әйтәсе килә: матур әдәбият үзенең профессиональ дәрәҗәсен саклаган хәлдә, үзен хөрмәт иткән, үзенә гаять таләпчән булган чакта гына алга таба үсә ала. Кабатланып килгән бу хакыйкать язучыларны, редакторларны һәм тәнкыйтьчеләрне гел искәртеп торсын иде!

# ДИСКУССИЯГӘ УКУЧЫ КУШЫЛА...

*
* *

Бик дөрес: тынычлану зарарлы. Һәр яктан да. Шуңа күрә тынычлыкны бозган Аяз Гыйләҗевка рәхмәт белдермичә булмый. Җитешсезлекләрне күреп, аларны танырга кыюлык җиту генә түгел, ә тамырларын ук актарып карарга тырышу — мактауга лаеклы хәл. Ләкин Мостафин кебек, Гыйләҗев кебек язучылар да кайбер сорауларны җавапсыз калдыра икән, бу җитди мәсьәлә зур сөйләшүгә мохтаҗ дигән сүз.

Американы ачарга җыенмыйча, прозаның сыйфатын күтәрүдә ярдәм итәрлек бер аспектка игътибарны җәлеп итәргә уйлыйм.

Прозабызның күптәнге авыруы бар — ничек кенә булса да бәхетле бетемгә омтылу. Мәсәлән, «Хәзинә» романында Г. Ахунов үзенең яраткан героена зур кресло өстенә сабан-туй батыры сөлгесе биреп кенә калмый, аның шәхси тормыш сукмагына да ак келәмнәр җәеп куя. Героебызның күзе хатыны сеңелесенә төшеп өлгерми, үз хатыны үлеп тә китә. Автор яраткан героен кызгангандыр инде: ул ике ут арасында яна башласа, аңа кыен булу мөмкин ич! Ә болай — барыбызга да яхшы.

А. Расихның «Сынау»ы — бик яхшы әсәр. Проблематикасы зур, сюжеты мавыктыргыч, сурәтләве тормышчан, диалоглары җанлы. Ләкин тагын шул: А. Расих та бөтен ноктаaларны урынына куеп бетереп кенә саубуллаша. Әгәр Фәритнең соңгы хаты булмаса, укучы бераз уйланыр иде, һәр укучы геройларның язмышын үзенчә күз ал-

дына китерер иде. Авторга ул да җитмәгән — эпилог өсти әле. Шул эпилогта автор Әлфиянең бәхетле булуына, калганнарның андый бәхеткә ирешә алмаячагына ышандырырга тырыша. «Бәхет» дигән асыл кошның нәрсә икәнен аңлатырга тырышучылар бик күп булса да, борын заманнан бирле кешене канәгатьләндерерлек аңлатучы юк әле. А. Расих та соңгы сүздә үз өстенә күтәрә алмаслык бурыч йөкләгән.

Ф. Галимуллин: «...ничектер бераз кыюсызрак безнең укучы»,— дип яза. Юк, егетләр, укучыны соры масса дип санасаң гына шулай тоела ул. Әнә Р. Мостафин да язучыларыбызда укучыга андый мөнәсәбәт булганын билгеләп үтә. «Еш кына безнең прозаиклар укучының уйлый белүенә, акыл сәләтенә ышанып бетмиләр, бөтенесен аңлатып бирергә, чәйнәп каптырырга тырышалар»,— ди ул.

Укучы буларак, шуны әйтәсем килә: безгә, ташка басылган сүзне олылау ана сөте белән кергән булса да, чынны ясалмадан, сәләтне булдыксызлыктан, кыюны куркактан аера белү сәләтен тормыш тәҗрибәсе генә түгел, башка әдәбиятлар белән танышу да бирә.

Бер генә мисал. «Казан утлары»ның 3 нче санында, прозаның сыйфаты турында җитди әңгәмә барганда, Газиз Кашаповның «Җир җылысы» дигән повесте бирелгән. Автор «үткен момент»ларны бераз кетеклэп ала: сугыштан соңгы башак җыюлар, әтисеннән формаль рәвештә ваз кичәргә мәҗбүр булуның фаҗигасе, мәктәптәге ханҗалык... Ул бүгенге көндәге иң мөһим темаларның берсенә тотынган.

Әмма нәрсә әйтергә теләгән соң Г. Кашапов? Әсәрдә аның максаты — колхозга яхшы рәис кирәк дигән сүзне әйтү. Моны кем белми соң? Ә бәлки авторыбыз артта калган колхозны ничек итеп алга тартып чыгару юлларын яңа рәис аша эзлидер? Юк, юк һәм тагын да юк! Кинода да күрдек, радиодан да ишеттек, китаплар да укыдык андый рәисләр турында. «Литературная газета»дагы Б. Можаев, К. Кожевникова, В. Шубина кебек корреспондентларның бер мәкаләсе нык югары тора бу повестьтан. Нәрсә эшли соң яңа рәис повесть буенча? Бер утырыш үткәрә, 5 минут радиодан сөйли, аның өстәвенә Закирҗан картка «нәчәнникчә» түгел, кешечә сөйләшә белүен күрсәтә. Чү, тагын бер эше бар: яшьлек гөнаһын хәтерләп ята. Хәер, ул гөнаһ та бик уңай булып чыга. Туган авылына колхоз рәисе булып кайтканчы чын тормыш юлдашы очрамаган икән. Ә хәзер — яшь чактан ук сөйгән кызына өйләнергә була, җитмәсә, 18 яшьлек җиткән кызы белән дә таныша. Килә икән бәхет бер килгәч: бу кыз главбух урынына рөхсәт алып кайткан икән, ә элекке начар рәис элекке начар главбух хатынны үзе белән алып киткән икән.

Повесть дигән әсәргә сюжет кирәк, төйнәлү, чишелү, конфликт, кульминацияләр белән. Начар тип Разаев райкомга жалу белән барган иде дә — үзен фаш итеп кенә кайтты. Бәлки колхозчылар бик ялкаудыр? Ялкаулык белән көрәшү җиңелләрдән түгел ич! Юк инде, авыл халкы тырыш. Халыкның йөзе саналган Закирҗан карт әйтүенчә, «башлап җибәрүче» генә кирәк булган. Димәк, конфликт юк — геройның да кирәге юк.

Герой турында сүз барганда укучының Хафизовка мөнәсәбәте мөһимдер. Укучы буларак, аны яратып булмый (үзе ярата белмәгәнгәдер, мәгаен — яратса, яшьтән сөйгән кызын эзләп табар иде ул), сокланырга сәбәп юк, ошарга тырышырлык сыйфатлар табылмый — кешегә охшаган кеше генә. Уртача статистик индивидум.

Р. Мостафин мәкаләсен укыганда бу фикер тагын да көчәя. Гыйләҗевның өч олы язучыны аерып алып, аларга ышаныч белдерүе тәнкыйтьчегә ошамый. Берсен мактап, берсен мактамасаң, соңгысы гарьләнеп куяр. Шуңа күрә давай, мактауларны тигезләп бүлик, ди ул... Безнең күренекле тәнкыйтьчебез Мостафин да шундый принципка, дөресрәге, принципсызлыкка күнектерүче мәкаләләр язгач, башкаларга ни кала инде?!

Сүз юк: Гомәр Бәширов, Габдрахман Әпсәләмов агалар безнең әдәбиятта «Намус» белән эшләп, «Сүнмәс утлар» кабыздылар. Моның белән Аяз Гыйләҗев тә ризадыр. Әмма ул үзенең мәкаләсендә прозага күзәтү ясау максатын куймаган. Аңа күренекле проза әсәре кирәк, кемнән көтеп алырга мөмкин аны — менә нинди сорауга җавап эзли Гыйләҗев. Бу мәсьәләдә Гыйләҗев чыннан да эзлекле. Ул нәрсә теләгәнен белә, ул критерийлар куйган һәм нәкъ шул критерийлардан чыгып сайлый өметле авторларны.

Критерий дигәннән. Минемчә, әсәрнең үзәк нәшриятта басылу-басылмавы аңа бәя биргәндә төп критерий була алмый. Ә менә «традицияләрне инкарь итүгә» чакырып, Мостафин артыкка җибәрде инде. Бары тик бөтенсоюз әдәбияты дәрәҗәсенә күтәрелер өчен генә традицияләрне инкарь итү — бик кыйммәт бәя ул.

Юк, егетләр, традицияләр калыбрак торсын әле — нигилист булмыйк. Новаторлык ул — «дөрес, иҗади үзләштергән» традицияләрне тагын да ныграк үстерү чараларын эзләү. Ә моның өчен башка әдәбиятларның казанышларын, алымнарын... юк, файдаланырга түгел (Р. Мостафин өндәгәнчә), ә өйрәнергә кирәк, яңа казанышларга, алымнарга ия булыр өчен.

Ә менә Мостафинның прозабызга кыюлык җитми дигән сүзенә ике кул белән риза. Чынлап та, әдәбият тирәсендә кыюсызлык яхшы гына тамыр җәйгән.

Автор башта үзеннән курка: языйммы, юкмы, барып чыгармы соң? «Язмыйча булдыра алмасаң гына яз»,— дигәнне онытып инде, әлбәттә.

Аннан соң ул укучыдан курка. Аңламавы мөмкин, ди, ярып салыйм әле, аңлатыйм барысын да. Укучыны канәгатьләндерер өчен, азагында да «безнекеләр җиңде» булсын.

Хәзер редактордан курку чираты җитә. Шуңа күрә, автор әсәрен сыйпый, тарый, сылый, аклый — кыскасы, формасын китерә. «Бәлки, бу Хәлли абзый бер метр ярымга сулдарак басып торырга тиештер, күчереп куйыйм әле»,— ди.

Ә Шукшин... Нәрсә ул Шукшин? Ул популярлык өчен дә, гонорар өчен дә тырышмаган. Шуңа күрә генә кыю язган. Үзенчә язган — язмыйча булдыра алмаган. Шукшин белән чагыштыручыларга бер соравым бар: сезнең ул үлгәнче, аның хикәяләрен укып караганыгыз бар идеме соң? Менә шул-шул!..

Дөньяда шәхси эз калдырам дигән кеше дөнья кызыклары артыннан куаламый, тирә-якка карап «кеше ничек — мин дә шулай» булырга тырышмый, кеше белән мөнәсәбәт бозмыйм дип буш опуслар язмый — кеше булып кала.

Менә шундый уңай геройлар кирәк безнең әдәбиятка. Персонаж сыйфатында да, автор сыйфатында да.

**АЙРАТ ИБРАҺИМОВ**
Ульяновск.

* * *

Зур әдәбиятыбызның проблемалары да байтак. Тормыш үзе киң адымнар белән алга барган саен яңадан-яңа проблемалар күтәрелеп чыга. Хуҗалык, социаль-культура төзелеше өлкәсендә бишьеллык планнар булган кебек, әдәбиятның да үз планнары булырга тиеш.

Татар язучыларының яңа романнары, повестьлары әледән-әле басылып тора. Пьесалары башкалабыз Мәскәү театрларының сәхнәләренә дә менә. Ләкин ирешелгәннәр белән тынычлану һәр эштә дә безнең өчен чит нәрсә — коммунистлар партиясе шуңа өйрәтә.

Укучы мәхәббәтен казанып, совет әдәбиятының алтын фондына кергән әсәрләребез күп безнең. Алар бүген әдәби осталыкка өйрәнү мәктәбе булып хезмәт итәләр.

Күптән түгел Ә. Еникинең «Соңгы китабын» бик яратып укыдым. Тик китапның исеменнән сизмәстән сискәнеп куясың. Әмирхан ага кебек талантлы язучының соңгы китабы була микән? Аның язылган әсәрләрен халык яратып укый һәм укыячак, алар әледән-әле басылып торалар, ә мондый әсәрләрне, һичшиксез, килер буыннар да яратып кабул итәр. Ә талантлы әсәрне уку һәрвакыт һәм һәркем өчен ерактагы якын дустың белән очрашу бәхетенә тиң нәрсә.

Әсәрләре популярлашып киткән язучы өчен ике-өч әсәр белән генә чикләнеп калу укучыны бу язучы өчен «аңа ни булды икән» дип борчуга төшерә. Драматург Ш. Хөсәенов белән дә шулай. Язганнары өчен рәхмәтен рәхмәт тә, ләкин үзен зур талант иясе итеп таныткан әдип өчен бу гына аз, чөнки А. П. Чехов алай эшләмәгән, врачлык һәм язучылык эшен бер генә минутка да туктатмаган, үз максатына ахырынача турылыклы булып калган.

Әдәбиятта билгеле бер тема буенча специальләшүне хупларга кирәк. Ләкин язучының иҗаты күпкырлы булырга тиешлеген онытырга ярамый. Мисал өчен ерак барасы түгел. Г. Әпсәләмов иҗатын алыйк. Авыл тормышыннан — «Газинур», шәһәр тормышыннан — «Сүнмәс утлар», медицина профессоры турындагы «Ак чәчәкләр»е...

Ә Н. Исәнбәт? Драматург та, шагыйрь дә һәм фольклор, тел белгече дә ул. Ни язсаң да ярый, ләкин ул көннең кадагына сугып барырлык оста һәм укучының күңеленә хуш килерлек итеп язылган булырга тиеш.

Әдәби тәнкыйтьнең тоткан урыны искерүне белми. Аның урыны — тормышчан әдәбият өчен көрәшнең алгы сафында. Элек тә шулай иде ул, бүген дә шулай. Тәнкыйтьне хөрмәт итмәүче автор үзен дә хөрмәт итми дигән сүз. Тәнкыйтьче шул ук укучы бит ул. Ә язучы укучы өчен иҗат итә. Үз укучысын, аның фикерен ишетергә теләмәгән «мин-минлек» чире йоккан автор язган «әсәрнең» кемгә кирәге бар? Халык әйтсә, хак әйтә. Ә ул болай дигән: «Сүзгә әйтелгәнче син хуҗа, авызыңнан ычкынгач ил хуҗа». Татар халкына хас әдәплелек, оялчанлык дигән сыйфат бар. Ләкин кайбер әсәрләрдә моның кересен күрәбез. Сүзсез дә аңлашыла торган табигый нәрсәләр турында язу белән мавыгу безнең әдәбиятка килешеп бетми.

Яшь авторларның зур күләмле булмаган повестьлары белән еш очрашабыз һәм аларга өметләр баглыйбыз. Зур әдәбиятка уңышлы старт булсын иде алар. Г. Бәширов, М. Әмир, Г. Гобәй, И. Гази да бит романнар язганчы повестьлар иҗат иткәннәр. Ә повестьлары нинди! «Сиваш», «Агыйдел», «Маякчы кызы», «Катя Сорокина...»

«Казан утлары»ның быелгы 2 нче санында басылган Ә. Мушинскийның «Кайту» повестен кызыксынып укыдым.

Бер гаилә хроникасы ул. Берәүләре хезмәт итә, икенчеләре укый, зур тормышка әзерләнә, гыйшык дигән нәрсә дә читләтеп үтелми. Барысы да үз урынында, тормышчан, бүгенгебез өчен актуаль тема яктыртыла. Ләкин Сания белән Тәлгатьнең үзара мөнәсәбәтләре турында төгәл бер фикергә килә алмадым. Егет ятимә кыз Санияне баласы белән калдырып Мәскәүгә укырга дип китә, анда җилбәзәк күңелле Майя белән яши башлый. Барысының күз алдында яшь гаилә җимерелә. Моңа берәү дә игътибар итми. Тәлгатьнең әти-әнисе дә, остазлары да, дуслары да үз эшләре белән генә мәшгульләр, егетне берәү дә тәртипкә чакырмый, җәмәгать оешмаларының да йогынтысы сизелми. Ә бит гаилә ул җәмәгатьчелек эше дә. Минемчә, әсәрнең тәрбияви әһәмиятен арттыра төшәргә иде. Безнең көннәрдә гаять катлаулы мәсьәләне укучы хөкеменә генә чыгару җитми. Автор үз позициясен дә ярыгы салырга тиеш.

Укучы язучыларыбыздан гер оик чорыбызга лаек әсәрләр көтә. Мондый әсәрләрне тормыш эчендә кайнап һәм халкыбызның бай, күпкырлы тормышын өйрәнеп кенә иҗат итәргә мөмкиндер дип әйтәсем килә.

**ӘНВӘРБИК МӨХСИНОВ.**
Горький.

*
* *

Бу минем редакциягә беренче хатым. Моңа кадәр күп тапкырлар җыенсам да, язмый калына иде. «Казан утлары» журналында чыккан Рафаэль Мостафинның «Перспективаны югалтмыйк», Аяз Гыйләҗевның «Тынычлану зарарлы», Тәлгать Галиуллинның «Нәфисәләр юксындыра» мәкаләләрен укыгач, ничектер, кем беләндер фикер уртаклашасы, сөйләшәсе, бәхәсләшәсе килеп китте. Хәзер генә андый мөмкинлек юк һәм мин үземдә туган фикерләрне сезгә язмакчы, күңелемдәген әйтмәкче булдым.

Моңарчы мин журналның һәр санын укып барырга тырышсам да, тәнкыйть мәкаләләренә күз йөртеп кенә чыга идем. Болай бирелеп, автор белән бәхәсләшә-бәхәсләшә укыганым юк иде.

Мин әле яшь, әдәбиятны яхшы беләм дип әйтә алмыйм. Шулай да әйтәсем килә. Сез язган фикерләр инде укучыларда да туа башлаган иде: Нигә алай? Нигә әсәрләр тоссез? Яңа әсәрне укыйсың, инде берничә көннән аның исемен, хәтта баш геройларын да онытасың. Нигә элекке классиклар кебек язучылар юк хәзер? Язучылар күп,

белеп бетереп тә булмый, һәм нигәдер татар әдәбияты казанышлары турындагы чыгышларда гадәттә әдәбиятыбызның казанышлары итеп ниндидер әсәрләр исеме саналмый, ә язучылар саны әйтелә.

Аннан соң, мәкаләләрдә уңай яктан телгә алынган әсәрләр арасында никтер Атилла Расихның «Сынау» романы телгә алынмаган, ә аны укучылар бик яраттылар бит. Бәлки, язучылар күзлегеннән караганда ул кадәр үк югарылыкта түгелдер? Ләкин ул, әле яңа китап булуга карамастан, инде таушалып өлгерде.

Тагын Рафаэль Мостафин язучы Габдрахман Әпсәләмов турында матур фикерләр әйтә. Нигәдер, аның турында бездә, яшьләрдә, ялгыш фикер дип әйтимме, уяткаңнар. Мин, мәсәлән, аның әсәрләрен кабат кайтып укысам да, тәнкыйть күзлегеннән карап укыйм, яратып укыйм.

«Казан утлары» журналы бүгенге проза турында сөйләшүдә зур мәсьәләләр күзгата. Укучыны яңа әсәрләр укыганда анализлап укырга, уйланырга өйрәтә.

**ФӘНЗИЛӘ ГОМӘРОВА,**
Әгерҗе районы, Тәбәрле авылы.

**Хөрмәтле укучылар!**

**Бүгенге проза турында дискуссия дәвам итә. Сездән хатлар, фикерләр, мәкаләләр көтәбез!**

# ХАЛАТЫҢ АК, КҮҢЕЛЕҢ ПАКЬ БУЛСА...

Бүгенге буын кешесенең күңелендә нинди утлар яна, аны нәрсәләр борчый, ниләр дулкынландыра? Шуны тирәнтен өйрәнеп, күрсәтеп бирү — әдәби иҗат эшенең зур бурычы.

Башка әдипләребез кебек үк, прозаик Мәдинә Маликова да бу хакта уйлана, аны үзенчә хәл итү омтылышы белән иҗат итә. Ул соңгы вакытта, «Ак давылда тал бөресе» дигән роман язып, укучыларга ирештерде. «Казан утлары» журналының быелгы дүртенче-бишенче саннарында басылып чыккан бу әсәр — әдәбиятыбыз тарихында хатын-кыз язучы иҗат иткән беренче роман.

Хатын-кыз язучылар иҗаты күп очракта фикерләү пөхтәлеге, кеше күңеленең бик тирәндә яткан кичерешләрен нәфис итеп бирә белү белән аерылып тора. Татар хатын-кыз язучылар иҗатына күбрәк камералык хас кебек. Әмма бу — ниндидер чикләнгәнлек түгел, күңел шундый җылылык бөркеп торган шигъри прозаны сагына.

М. Маликова да үзенең иҗатында әнә шундый интим почеркка тугры. Роман җиңел укыла, тәле йөгерек, сурәтләве самими. Әсәрнең эчтәлеге белән таныштыру ихтыяҗы юктыр. Фикерләремне романны укырга өлгергән кешеләр белән уртаклашасым килә.

Әсәрнең исеме үк аның битләрендә ниндидер давыллар уйнап аласына ишарәләп тора: «Ак давылда тал бөресе». Мәгънәле исем. Әле әсәрне укыганчы ук, конфликтның шактый җилле булып, аның агач бөресе кебек көчсез берәүгә кагылып узасы күңелгә килеп куя. Ул шулай булып чыга да.

Әле яңа гына врач дипломы алып, үзе укыган институт кафедрасында эшкә калдырылган Зәйтүнә, автор уйлавынча, үзктә торырга тиешле образ. Укучының игътибары аңа юнәлә дә. Дөрес, Зәйтүнә Мәжитованың хезмәт юлында әллә ни катлауланулар килеп чыкмый. Аны тыныч табигате, пөхтәлеге, эшенә намуслы караганы өчен хөрмәт итәләр, хәтта катлаулы операцияләр ясау эшен ышанып тапшыралар. Шулар өстенә аның фәнни эзләнүләре дә уңышлы бара.

Бүгенге кеше бервакытта да бары тик эшнеке яки шәхси тормышныкы гына була алмый. Тулаем яшәешнең бу ике өлкәсе бер-берсе белән бик нык керешә һәм үзара тәэсир итешә. Кешегә шатлык китерүче һәм аны борчуга салучы сәбәпләр шушы ясселыкларда хасил була. Зәйтүнә өчен дә көннәрнең берсе аеруча «давыллы» булып чыга: иртән аның кулына иренең хыянәте турында язылган хат китереп тоттыралар; гомерендә беренче тапкыр мөстәкыйль рәвештә уңышлы һәм тәвәккәл операция ясый; профессорның фаҗигага юлыгуы аңа олы хәсрәт алып килә. Болар аңарда капма-каршы эмоцияләр китереп чыгаралар.

Врач хезмәте Зәйтүнәдән күңел ныклыгын, сүзләренә башкаларны да ышандыру, аларны үз ихтыярына буйсындыру сәләтенә ия булуны сорый. Уңай һәм тискәре кичерешләрне китереп чыгарган сәбәпләргә ул гадәттә актив хәрәкәт белән җавап бирми, аның каравы күңелендә көчле кичерешләр хәрәкәте барлыкка килә. Зәйтүнә образын сурәтләүнең үзенчәлеге шуннан гыйбарәт тә.

Язучы үз героинясын врачлар эшчәнлегенең тар даирәсендә генә калдырырга теләми, аның гомумкешелек проблемалары турында фикер йөртерлек дәрәҗәдә торуын ассызыкларга омтыла. Кешеләрнең үз көчләрен бер-берсенә хәсрәт китерүгә түгел, бәлки чир, табигать афәтләре белән көрәшүгә туплавын күрергә тели. Чөнки Зәйтүнә кайберәүләрнең караңгы эшләреннән рухи газаплана: иң якын дусты Лариса аның ирен үзенә тартып алу өчен

хамелеонга әйләнә; доцент Дәүләтшин остазына хыянәт итә... «Мәңнәрчә еллар буе гаделлек, дуслык, мәрхәмәт-шәфкать турында сөйли кешелек, ә шулай да бу хакыйкатьне барча балаларына сеңдерә алмый». Бу сүзләр Зәйтүнәнең гуманлы табигатен шактый тәгәл ачып бирүгә хезмәт итәләр. Әнә шундый якты уйлары, саф күңеле, пакь эшләре аны коллегалары һәм пациентлары арасында сөйкемле итә.

Әйе, эш буенча Зәйтүнәнең моңланып җире юк. Аның каравы, автор аны гаилә тормышында сынарга ниятләнә. Әмма уңай героебыз биредә дә үзенең горурлыгын, өстенлеген саклап кала. Сабырлык һәм аек акыллылык күрсәтә, нәтиҗәдә ире белән араның төзәлүенә ирешә. Ак давыл бөрегә әллә ни зыян-зәүрәт ясамыйча гына узып китә.

Зәйтүнәнең тигез-сабыр холыклылыгының тамыры татар хатын-кызларының гасырлардан килә торган күркәм сыйфатларына барып тоташа. Алар элек-электән мәхәббәт утын, гаилә иминлеген, татулыгын сакларга тырышканнар, балаларын яхшы традицияләрдә, хезмәт белән тәрбияләгәннәр. Зәйтүнә дә шул яхшы гадәтләргә тугрылыклы. Бу бигрәк тә аның остазларына, олыларга ихтирам белән каравында чагыла. Без моны иренең абыйсына булган мөнәсәбәтеннән дә күрәбез: «һәр сүзен зурлап кабул итә, сораганына төгәл җавап бирә, аның алдында юк-бар сөйләшми, һәр даим зурлавын сиздереп тора».

Кыенлыкларны җиңәргә ярдәм итә торган иненче чыганакны язучы Зәйтүнәнең хезмәт сөюендә, эшен яратуында күрә. Ни авыр кеннәрдә дә ул врачлык вазифаларына хилафлык китерми. Эш һәм башкалар турында кайгырта белүнең үзе бер күңел дәвасы икәнлеген тирәнтен аңлый һәм ялгышмый. Мәхәббәт хисе һәм хезмәт — кешене кеше иткән төп нигезләрдән, дип әйтергә тели әдибә.

Зәйтүнәнең үз-үзен тотышын укучылар хуплый, ул билгеле күләмдә алар өчен якты үрнәк хезмәтен үти. Кешене тискәре күренештән гыйбрәт алу планында гына түгел, матур үрнәкләргә таянып тәрбияләүнең дә ролен киметергә кирәкмидер. Социалистик җәмгыятьтә матур әдәбият әсәренең кыйммәтле вазифаларыннан берсе яшь буынны яхшы әхлаклы итеп тәрбияләү икәнлеген кем инкарь итә алыр икән? Гаилә булу, аны, Хәсән ага Туфан әйткәнчә, «аерылмыйча, каерылмыйча» озак еллар яшәтү мәсьәләләренә шактый җиңел караучылар күбәеп киткән бүгенге көндә бу бигрәк тә шулай. Лариса Сөнгатовна кебекләр мондый сабырлыкка, тәпле фикер йөртергә сәләтле түгел. Андыйларга бер ирне икенчесенә алыштыру гадәти эш булып әверелә. Ул гына да түгел, хезмәтләрендә дә алар гаять талымсызлар, керле куллылар. Башка кешенең гомер буе җыйган материалларын, күзәтүләрен үзләштерү дисеңме, авыруларга махсус анализлар ясауда очраклы нәтиҗәләр чыгаруга юл куюмы — алар кулыннан барысы да килүе мөмкин.

Автор бер урында болайрак уйлый: медицина өлкәсендәге карьеристларны, әшенә хилафлык китерүчеләрне тану шактый кыен. Чөнки алар эгоистлык максатларына да авыруларга ярдәм итәм дигән пәрдә артына яшеренеп киләләр. Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романындагы профессор Янгураны гына искә төшерик. Мәһабәт гәүдәле, интеллигентлык манераларына ия булган, үзе эшли торган өлкәне яхшы гына белүче кеше итеп гәүдәләнә ул. Ләкин шушы кешенең бөтен кылган гамәлләрендә никадәр икейөзлелек, үзенең чын асылын яшерергә азаплану. Кеше уңышларын куралмау, кара уйлылык — менә аның чын эчтәлеге. М. Маликова да шуңа охшаш типны бирә. Килеш-килбәтенә генә карасаң, «...сокланмый мөмкин түгел доцент Дәүләтшинга! Аның очарга талпынган бөркет шикелле чак кына алга авышкан сынында, коңгырт ботинкалар белән паркет идәнгә нык басып баруында ук көч, көне-ае белән арта барган гайрәт сизелә. Биек, иркен коридорларны кысанлап, ашкынулы адым белән киләчәк үзе барадыр шикелле». Дәүләтшинның уңай сыйфатларын беркем дә инкарь итми. Коллегалары һәм студентлар аны популяр лектор буларак беләләр. Мәскәүдәге белгечләр арасында да үзе турында яхшы фикер тудыра алган. Ләкин аңа болар гына җитми. Зур аренага чыгу өчен аңа биредә — Казанда ныклы старт мәйданы булдырырга кирәк. Ә мондый мәйдан аның өчен — бары тик кафедра мөдире урындыгына утыру. Менә шуңа Дәүләтшин, үзенең остазы Җәмилә Закировнаның яше олыгаеп килүдән файдаланып, ничек кенә булса да әлеге урынны эләктереп калырга уйлый. Максатына ирешү өчен остазы өстеннән шикаять язу, төрле имеш-мимешләр уйлап чыгару кебек түбәнлеккә төшә.

Романдагы Җәмилә Закировна образы

исә үз эшенә бирелгән, намуслы, кешелекле булуы белән безгә бик якын. Медицина өлкәсендәге олы казанышлар, алга китеш — әнә шундый фидакарьләр хезмәте нәтиҗәсе. Профессор кешеләргә якын булуы, аларга хезмәт итүне үзенең иң төп миссиясе итеп каравы белән матур. Кызганычка каршы, аның олы тормыш юлы бары тик бик кыска итеп искә төшерүләр ярдәмендә генә бирелгән. Информация образлылыктан күбрәк. Бу — медицина өлкәсенә бәйле геройларны теге яки бу халәттә сурәтләү өчен аларның шул мизгелдәге тойгыларын тулы күзаллап бетерә алмау нәтиҗәсе. Әлбәттә, әдәбиятны, барыннан да элек, теге яки бу махсус өлкә түгел, бәлки әлеге контексттагы кеше үзе кызыксындыра. Әмма кеше абстракт төшенчә түгел, ул яшәгән тирәлекне дөрес бирми торып, әсәрдә табигый тормыш, хәрәкәтне тасвирлап булмый. Доцент Дәүләтшинның кафедра мөдире урыны өчен көрәшкә ташлануы да әнә шуңа күрә ышандырырлык итеп мотивлаштырып җиткерелмәгән һәм эзлекле бер юнәлеш алмаган. Мәгълүм булганча, кафедра мөдире урынын фән докторы дигән гыйльми дәрәҗәсе, профессор дигән исеме булган кеше генә дәгъвалый ала. Ә бу килештән, романда бик дөрес сурәтләнгәнчә, әрсез доцентны үзенә тиешле арбага утыртып куюю берни дә тормый. Шушы хәлнең конфликтны йомшартуы да аңлашылып тора.

Була шундый кешеләр — аларның тырышып эшләүләренең төбендә хезмәт баскычларыннан югары күтәрелергә омтылу ята. Бу омтылыш үзе ике төрле аңлатылырга мөмкин. Берәүләр, өсләренә җаваплылыкның зуррагын алып, илгә күбрәк файда китерергә телиләр (М. Әмирнең Миңлекамалын искә төшерик), икенчеләргә властьның үзе ошый, андыйлар шул юл белән үз шәхесләрен расларга тырышалар. Доцент Дәүләтшин соңгылары исәбенә керә.

Кеше нинди дә булса җитәкчелек урынына хезмәт баскычларының түбәненнән алып югарысына кадәр тир түгә-түгә, һәр звенодагы кешенең бурычларын, вазифаларын башкара-башкара, аларның психологик халәтен тирәнтен аңлап килсә яхшырак була. Тормышны, кыенлыкларны, бигрәк тә кешеләрне дөрес аңламаучыларның җитәкче булып алуы күмәк эшкә зыян, төрле күңелсезлекләр китерүе мөмкин.

Җәмилә Закировна шәкерте Зәйтүнәдә үзенең еракта калган яшьлеген, хезмәт юлын башлап җибәргән вакытлардагы халәтен күрә икән, моның тирән мәгънәсе бар. Чөнки профессор әлеге хөрмәтне, тормыштагы урынын армый-талмый хезмәт итүе, кешеләргә игелек күрсәтергә теләве белән яулап алган. Аның эстафетаны Зәйтүнә кебек саф күңелле, хезмәтеннән тәм табучы, шушы эшне алга алып китәргә сәләтле яшь буын вәкилләренә тапшырырга теләве табигый кабул ителә. Җитәкче кеше әйбәт белгеч булган тәкъдирдә дә, аңарда кешеләрне ярату сыйфаты юк икән, ул үз вазифаларын нәтиҗәле итеп башкара алмый. Шул рәвешле, хезмәт мөнәсәбәтләренең әхлакый ягы алгы планга килеп чыга. М. Мәликова әсәрендә бик хаклы рәвештә шул фикер ассызыклана.

Роман язу — тормышны, яшәешне, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне бөтен катлаулылыгында, шул ук вакытта ачык бер концепциягә буйсындырып сурәтләүне таләп итә торган зур эш. Әлбәттә, М. Мәликова әсәре кимчелекләрдән тулысынча азат түгел әле. Сурәтләп бирү урынына сөйләү, кеше күңелендә барлыкка килгән кискен борылышларны сәнгать чаралары белән мотивлаштырып бетермәү кебек яклар күзгә чалына. Язучы болар турында уйланмый калмас, әсәрне камилләштерү өстендә эшләүне дәвам итәр. Романнан алган беренче тәэсирләр, аның моңа таланты да, тырышлыгы да җитәрлек, дигән фикер тудыра.

**ФОАТ ГАЛИМУЛЛИН.**

# БӘХЕТЛЕ ИҖАТ ЮЛЫ

Һәр иртәдә опера һәм балет театры баскычыннан пөхтә киенгән, мөлаем йөзле бер кеше күтәрелә... Тыныч һәм шул ук вакытта максатка омтылучан йөреш, ягымлы тавыш, игътибарлы караш, әдәплелек хас аңа.

Бу — Нияз Курамшевич Даутов. Совет музыка сәнгатенең күренекле вәкиле, РСФСРның халык артисты, Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге премиясе лауреаты, опера һәм балет театрының әйдәп баручы солисты, танылган опера режиссеры ул...

Бу шәхес турында уйланганда, сәнгатебезнең олы вәкилләре искә төшә. Кешеләр белән аралашканда, тыйнак, намуслы булу һәм бөтен вакытын үзе яраткан олы иҗат эшенә багышлау — Н. Даутовның да шәхесен билгеләүче төп сыйфатлар әнә шулардыр, мөгаен.

Репетицияләр вакытында мизансценаларны эшләү бик файдалы әңгәмәләр белән бергә үрелеп бара. Нияз Курамшевич җырчылар рольгә тирәнрәк керә алсын, музыка нечкәлекләрен, аның серләрен тулырак аңласын өчен, спектакль драматургиясен, теге яки бу операдагы вакыйгаларның кайсы чорда баруын яхшы белсен дип эшли моны. Мондый иҗади сөйләшүләрдә рольне башкару проблемалары, әдәбият, драматургия, музыка, балет жанры һәм, гомумән, бөтен дөнья сәнгате мәсьәләләре хакында сүз бара. Н. Даутовның эрудициясе, репетицияләрдә өйрәтү-аңлату рәвеше яшьләрне һичшиксез ышандыра. Алар үз яннарында кешелекле, зур талантлы шәхес барлыгын тоялар. Ә бит уйлап карасаң, Нияз Курамшевичның үзенә дә бу дәрәҗәгә ирешкәнче шактый озын тормыш юлы үтәргә туры килгән.

Н. Даутов 1913 елның 23 сентябрендә Казанда туа. Урта мәктәпне тәмамлагач, авылда укытучы булып эшли. Аннан соң ул — Мәскәүдә гади эшче, студент-биолог. Ә сәнгатькә музейлар, театрлар, концертлар, китаплар, ягъни үз «университетлары» аша килә. Театр институты каршындагы музыкаль драма курсларына укырга керә. Бер ел узгач, Мәскәү консерваториясе студенты була, татар опера студиясенең вокаль факультетында М. Мирзоева һәм А. Аскоченский классында (1939—1943 еллар) укый. Аннары опера театры труппасы белән фронтта, К. С. Станиславский һәм В. И. Немирович-Данченко исемендәге Мәскәү музыкаль театрында күп санлы чыгышлар... Шушы чорда Н. Даутов чын музыкант булып җитлегә. Г. Нейгауз, А. Гедике, К. Дорнак, А. Нежданова, Н. Голованов кебек музыкантлар белән бергә эшләүнең көчле тәэсире дә булмый калмагандыр, әлбәттә.

Шуннан соң Н. Даутов иҗатының яңа чоры башлана: 1943—1956 елларда ул солист, ә 1964 елга кадәр — солист һәм Свердловск опера-балет театры режиссеры, 1956 елдан башлап татар опера һәм балет театрының баш режиссеры, Казан дәүләт консерваториясенең операга әзерләү кафедрасы мөдире. Хәзер аның опера җырчысы һәм режиссеры буларак совет сәнгате үсешенә керткән гаять әһәмиятле өлеше турында зурдан кубып сөйләшергә була.

Лирик-драматик тенор һәм актерлык ялкыны артистка барлык классик опералардагы партияләрне дә башкарырга мөмкинлек биргән. Зур сәләткә ия булуы, сәхнә өчен яратылган кыяфәте һәм башка бик күп табигый сыйфатлары, мөстәкыйльлеге Н. Даутовка бер-берсеннән нык аерылып торган партияләрне җырлауда ярдәм итә. Аның опера җырчысы буларак репертуарында егермедән артык зур хезмәт бар. Аларның кайберләрен генә искә төшереп узыйк: А. Рубинштейнның «Иблис» әсәрендә — Синодал, Дж. Россининың «Севиль чәчтарашы»нда — граф Альмавива, Ш. Гуноның «Ромео һәм Джульетта»сында — Ромео һәм башка бик күпләр. Алар арасын-

да П. Чайковский иҗат иткән «Евгений Онегин»дагы Ленскийны, Дж. Вердиның «Травиата»сындагы Альфредны, Н. Җиһановның «Җәлил», «Алтынчәч» операларындагы Җәлил һәм Җикне, Х. Вәлиуллинның «Самат»ындагы баш рольне башкару осталыгы аеруча зур әһәмияткә ия. Н. Даутов вокаль сәнгатьнең иң яхшы традицияләрен дәвам итә. Ул үзе Шаляпин, Собинов, Нежданова һәм башка күренекле сәхнә осталары шикелле үк берьюлы ике төрле талантка ия. Аларның берсе — музыкаль һәм вокаль талант, икенчесе — актерлык сәләте. Опера партияләрен җырчы ачык драматик уен белән баетты, психологик шартларны яңача ачып бирде, гадәти булмаган яңа мизансценалар тапты, тапталмаган сукмаклардан барды. Н. Даутовның шулай ук катлаулы хисләр һәм кичерешләр дөньясында яшәүче драматик образлар иҗат итәргә яратуын да ассызыклап әйтеп узыйк. Шуңа күрәдер, ул эшләгән партияләр бөтенләй көтелмәгән яклары белән ачылалар. 1944 елда И. Кальманның «Сильва» исемле опереттасы буенча төшерелгән кинофильмда исә аның көлкеле рольләрдә дә уйный алу сәләте ачылды.

Н. Даутовның актерлык эшчәнлеге аның режиссерлыгының да иң мөһим якларын билгели. Классика буенча куелган опера исемнәрен генә санап китәр өчен дә шактый вакыт кирәк булыр иде. Алар арасында татар композиторларының әсәрләре дә бик күп. Спектакльләрне өйрәнгәндә, режиссер аның эчтәлеген төгәл һәм реалистик тирәнлектә ачып салуны үзенең төп эше итеп саный. Иң әүвәл аны кеше — психологик драманың герое кызыксындыра. Н. Даутовның үз юлы, үз алымы бар: тавыш, моң — болар барысы да сәхнәдә күренә торган булырга, хәрәкәткә әйләнергә тиеш. Ә сәхнәнең бизәлеше, яктылык-ут һичшиксез музыкага кушылырга, аңа ярдәм итәргә тиеш. Н. Даутов әнә шул рәвешчә «Травиата» операсында лирик-психологик теманы ача, ә «Алтынчәч»тә ирек сөюче халык турындагы героик эпосны булдыра, «Самат»та бүгенге көн тормышына мөрәҗәгать итә.

60—70 нче елларда күп кенә театрлар үзләренең элекке тәҗрибәләрен яңадан карый, тикшерә, спектакль куюның яңа төрләрен эзли, бүгенге көнгә якынлашу турында ныклап уйлый башладылар. Бу катлаулы һәм бер-берсенә каршы килә торган тенденцияләр булган чорда Н. Даутов, безнеңчә, дөрес юл тапкан. Ул хаклык һәм хисләр театрына тугры булып кала. Бу тугрылыкка тагын спектакльнең чишелеше буенча гади, образларның ачылуы һәм сәхнәнең образлылыгы тирән булу да өстәлә.

Яшь җырчылар тәрбияләү, опера сәхнәсенең яңа солистларын әзерләү Н. Даутов эшчәнлегенең бик күркәм бер тармагы булып тора. Соңгы елларда гына да аның җитәкчелегендә татар опера театрында Л. Бәширова, Ю. Борисенко, З. Сөнгатуллина, Х. Бегичев, Р. Сәхәбиев, Р. Дәминов, Г. Казанцева, Х. Ижболдин кебек әйбәт җырчылар барлыкка килде.

Аны еш кына завод цехларында, мәктәпләрдә янсә телевизор экраннарында күрәсең. Ул халыкка музыка турында гади һәм бик аңлаешлы итеп сөйли, чөнки ул үзе муеннан моңга гашыйк һәм бөтен кешеләр дә музыканы ихлас күңелдән яратачак вакыт җитү турында хыяллана.

— Музыка, шигърият, сынлы сәнгать, театр... Дөньядагы мондый гүзәлләкләр белән кушылу үзе зур бәхет,— ди Нияз Курамшевич.— һәрбер бөек иҗат әсәре мәңге гаҗәпләндерә, мәңге сокландыра. Күптән таныш булган әсәрдә дә өр-яңа ачышлар ясыйсың... Мин сәнгатьнең шундый могҗиза булуына сокланып бетә алмыйм.

Чыннан да, Нияз Курамшевич Даутов әле һаман да дәртләнеп иҗат итә, туган халкыбызны югары сәнгать әсәрләре белән куандыру теләге белән яши.

**ФӘРИДӘ ШӘМСЕТДИНОВА.**

Миркасыйм Госманов

# ТИРӘН ЭЗЛӘР, ҮЗӘК ТАМЫРЛАР

## Иске җырлар нәрсәгә кирәк?

Борыңгылык яисә яңалык мәсьәләсенә кагылган чакта әсәрләрнең эчке рухы турында сүз кузгатмый булмый. Чөнки фольклор истәлекләренең билгеле бер чорга бәйләнешын аларда очраган аерым сүзләр яисә грамматик формалар гына тәэмин итми, бәлки аларның эчтәлеге белән омтылышын бергә кушучы гомум поэтика, шулай ук иҗат итүчеләрнең дә, башкаручыларның да дөньяга карашларын, эстетик идеалларын сәнгатьчә гәүдәләндергән, һаман гәүдәләндерә торган күңел халәте — настроениесе чагылдыра. Иске сүзләрнең, архаик формаларның чагыштырмача яңарак чор әсәрләренә килеп керүләре ул традицион әдәби телнең, китаби фикерләүнең генә тәэсире булырга мөмкин. Мондый тышкы стилистик чаралар күп очракта субъектив омтылышларга, хосусый зәвык интересларына җиңел буйсыналар. Әмма әлеге гомум поэтика, эстетик идеал һәм настроение дигән эчке сыйфатларны исә бармак белән генә әвәләп, каләм белән генә сызгалап барлыкка китереп булмый. Чөнки формаль тел-стиль чаралары кебек тышкы күренешләр, лексик берәмлек, грамматик форма ише күзгә ачык күренеп, колакка анык ишетелеп тора торган, хәтта бармак белән төртеп күрсәтерлек «матди» гәүдәләнеш сыйфатына ияләр. Шигъри образлар комплексыннан, дөресрәге, аларның төрле комбинациядә органик хәлдә кушыла алуы нәтиҗәсендә генә туа торган гомум поэтиканы һәм шуннан хасил була торган настроениене исә гадәти көнкүрештә бары сизәргә, тоярга, хис кылып кичерергә, ягъни интуитив рәвештә кабул итәргә яки кире кагарга мөмкин. Монда инде «капшап карарлык», астына сызып күрсәтерлек «матди гәүдәләнеш» тышта ялтырап ятмый.

Ул эчтә, образлар системасында, дөресрәге, шул образларның төрле комбинацияләреннән чыгып, күңелдә туа торган реакциядә — моңда һәм хистә.

Моң, хис дигәч тә, аны интим кичереш кенә дип аңларга ярамый: зур иҗтимагый мәсьәләләрне күтәрүче әсәрләр дә, әгәр алар күңел кылларын чиертә алмасалар, сәнгатьчәлек көченнән мәхрүм калалар. Шул ук вакытта бу моң, хис һәм настроение дигән нәрсәләр бөтен чорларга бертигез дәрәҗәдә яраклы абсолют категорияләр дә түгел. Алар, гәрчә тик аерым шәхесләрнең генә күңелләрендә яңгырап, яңгыраш табып, һәм бары шул рәвешчә генә үзләренә гомер юлый алсалар да, әлеге эстетик идеал аша, ягъни дөньяны танып-белү, танылган һәм беленгәннәрдән чыгып, яңага, башкага омтылу аркылы билгеле бер тарихи чорларга, конкрет иҗтимагый даирәләргә барып тоташа. Икенчерәк итеп әйткәндә, һәр чорның үз идеалы булган кебек, үзенә генә хас моңы, хисе, үзенә генә характерлы, аңлаешлы настроениесе дә була. Шушы конкрет тарихи настроение, киңәйтебрәк әйткәндә, күңел кылларын кузгата алырлык эстетик идеал моңы, сүз сәнгате әсәрләренә гомер дә бирә, бер үк вакытта аларны алдан ук «үлемгә» дә хөкем итеп куя. Димәк, халык авыз иҗаты репертуарының гел үзгәреп, яңарып торуын, әйтик, бер әсәрләрнең онытылып, икенчеләренең барлыкка килүләрен субъектив омтылышлар, ягъни аерым ке-

---

«Каурый каләм эзеннән» дигән әсәрдән өзек.

шеләрнең тынгысызлыгы, «яңа такмак» уйлап чыгарырга яратулары түгел, бәлки аларның эстетик идеаллары, рухи-иҗтимагый ихтыяҗлары үзгәрү, яңару тәэмин иткән.

Үзгәрү, яңару дигәч тә, аны начар әйберләр генә онытылып («үлеп»), әйбәттән әйбәтрәгә туу дип аңларга да ярамастыр. Тарихи процесста үсү юлы һаман яңа үрләргә күтәрелештән тормаган кебек, әдәбият һәм халык иҗатындагы һәрбер яңа күренеш тә гел «зур казанышлан» гыйбарәт була алмый. Бер генә мисал. Әйтик, әдәби репертуардан эпос-дастан жанры кысрыкланып, аның урынын профессиональ язма әдәбият яулап алу, һичшиксез, алга бару, ягъни прогресс галәмәте. Әмма кысрыкланган дөньяви дастаннар урынына тәмамән суфыйчылык рухы белән сугарылган гел дини һәм ярым дини әйберләр кире кайтып, яңадан ажгырып хөкем сөрә башласа, моны инде чын алга барыш дип әйтеп булмас. Мәсәлән, безнең әдәби чынбарлыкта Әхмәт Ясәви, Сөләйман Бакыргани шигырьләренең XVIII—XIX йөзләрдә яңадан киң таралуы, ә кайбер төбәкләрдә (әйтик, Малмыж-Түнтәр якларында, Төньяк Уралдагы мәшһүр Таныл мәдрәсәсе тирәләрендә) «төп әдәби репертуар» әсәрләренә әверелә язуы гадәти генә эстетик ихтыяҗ билгесе түгел, ә иҗтимагый тормышыбызда хөкем сөргән авыр социаль үзгәрүләрнең нәтиҗәсе дә иде. Чөнки биредә сүз аларның элек гомумән укылу-укылмавы хакында түгел, бәлки әлеге гасырларда гадәттән тыш активлашуы турында бара. һәм бу бер дә очраклы күренеш түгел.

Мәгълүм булганча, XVI йөзнең уртасы һәм икенче яртысында ил белән бер үзе генә идарә итү, хезмәт иләрен теләгәнчә эксплуатацияләү хокукын югалткан татар феодаллары XVII—XVIII гасырларда, рус дворяннарына мәйдан яулаган патша хөкүмәтенең әзлекле политикасы нәтиҗәсендә тагын да зәгыйфьләнә, бердәм, оешкан иҗтимагый көч булудан туктый һәм шул рәвешчә элгәрге хаким сыйныфның ярчыклары, калдыклары дәрәҗәсенә төшеп кала. Аның каравы руханилар, җәмгыятьтәге дөньяви феодаллардан «бушаган» урынга үрмәләп, иҗтимагый тәэсирләрен икеләтә арттыралар. Патша хөкүмәте алып барган миссионерлык хәрәкәте дә ахыр чиктә мөселман руханиларының активлыгын үстерүгә китерә. Котб, Сәйф Сараи, Мөхәммәдъярлардан соң дөньяви язма әдәбиятның мәйданын дини әдәбият әсәрләре яулый башлау менә шушы катлаулы, каршылыклы процессның бер нәтиҗәсе иде.

Дөньяви феодаль сыйныфның иҗтимагый мәйданда зәгыйфьләнүе фольклор репертуарындагы үзгәрешләрне дә барлыкка китерә. Фольклорны, ягъни халык авыз иҗаты дигән төшенчәне болай феодал сыйныфы белән баглап караудан гаҗәпләнергә урын юк: әгәр һәр чорда хаким сыйныф идеологиясенең изелгән массалар аңына тәэсир ясавы марксистик аксиома булса, феодал сыйныфы вәкилләренең фольклор аша халыкка тәэсир ясарга омтылулары да бик табигый хәл. Борынгы рус әдәбиятының мәшһүр белгече академик Д. С. Лихачевның кат-кат күрсәтүенә караганда, Урта гасыр рус фольклорында бу тенденция бик ачык күренә. Европа халыкларының Урта гасыр авыз иҗатында да шундый ук хәлне күзәтәбез. Феодализм чорындагы төрки җәмгыятьләрдәге фольклор да хаким идеология тәэсиреннән азат булмаган. XVIII йөздән соңгы татар халык иҗатындагы дини мотивларның вакыт-вакыт көчәеп китүен, дөресрәге дөньявилык белән динилек арасында көрәш һәм ярыш хасил булуын да шул ук гомум закончалык — сыйнфый көрәш закончалыгы, аның сүз сәнгате өлкәсендәге гәүдәләнеше белән аңларга кирәк.

Әлбәттә, халык иҗатындагы сыйнфый һәм идеологик көрәшне вульгар социологик алым белән примитивлаштырып, формаль образларга, аерым сурәтләргә генә таянган хәлдә, фольклор әсәрләрен ике төркемгә — «прогрессив һәм реакционнарга» — механик рәвештә генә бүлгәләү белән дә мавыгырга ярамастыр. Кайчакларын иҗат ителгән һәм яшәгән даирәләре буенча югары катламнарга караган әсәрләр үзләренең функцияләре, эстетик идеаллары буенча түбәнрәк катламнарда барлыкка килгән, актив таралган җырларга караганда иҗтимагый өстенрәк булырга мөмкин. Әйтик, рус халкының «Игорь полкы хакындагы җыр» дигән әсәре феодаль катламнардан булган дружинниклар даирәсендә туган булуына карамастан, чыгышлары җәһәтеннән күпкә «демократрак» былиналардан эстетик кыйммәте һәм тарихи әһәмияте буенча әллә ничә башка югары тора. Кайбер борынгы төрки һәм татар фольклор истәлекләре, мәсәлән, аерым дастаннар, героик җырлар, борынгы бәет-балладалар белән дә шундый ук хәл.

Ләкин шуны да ачык әйтергә кирәк: ахыр чиктә андый борынгы истәлекләрне без аларның эстетик идеалларын «тәгәл» кабул итү, «бөтенләй» үзләштерү өчен түгел, бәлки алар ярдәмендә билгеле бер чорларны танып-белү, аңлау, бәяләү өчен югары куябыз. Чөнки өстән катлам вәкилләренең субъектив сыйнфый, иҗтимагый омтылышлары бер нәрсә булса, алар даирәсендә туган, таралган әдәби һәм фольклор әсәрләрендә дөнья һәм тормыш хәлләренең чагылу дәрәҗәсе бөтенләй икенче нәрсә. Мәсәлән, фольклорда ил-дәүләт язмышы, зур сугышлар мәсьәләсе ничек чагылуны алып карыйк. Мондый «гомумхалык» («гомуммилли») вакыйгалары темасын яктырткан чакта нинди даирә фольклор әсәрләре мәсьәләне киңрәк, колачлырак яктырта ала — түбән катламнар арасында стихияле рәвештә туган лирик җырлар, хосусый бәетләрме, әллә хаким сыйныфлар даирәсендә махсус тудырылган героик җырлар һәм дастаннармы?

Бу — мәсьәләнең бер ягы, һәм монда без кемнең «манарасы» биегрәк, кемнең иҗтимагый аң күзлегеннән мөмкинлеге зуррак икәнлеген истән чыгармаска тиешбез. Тарихилык, фәннилек принцибы шуны сорый.

Ләкин мәсьәләнең икенче ягы да бар: кемнең дөньяга карашы объективрак һәм социаль омтылышлары, иҗтимагый таләпләре гаделрәк? Тарихилык, фәннилек белән бергә сыйнфыйлык принцибы шушы сорауга да тәгәл җавап бирүне таләп итә.

Кыскасы, җыеп әйткәндә, узган чорларга караган фольклор истәлекләрен барлаган чакта без, һәрбер яңа табылган текстларны «фәнни яңалык» сыйфатында теркәп барудан тыш, аларның гомумхалык авыз иҗаты системасындагы конкрет урыннарын ачыкларга, шуннан чыгып, һәр төр табышка махсус бәя бирергә тиешбез.

Мәсьәләгә шушы принцип белән якын килүнең икенче бер мөһим өстенлеге дә бар: тарихилык һәм сыйнфыйлык мөнәсәбәтенең бергә үрелүе, бергә кулланылуы моңарчы мәгълүм һәм яңа табылган истәлекләрнең конкрет үзенчәлекләрен, хосусый сыйфатларын билгеләүдән тыш, аларның элек яшәгән, гамәлдә булган системадагы урыннарын, иҗтимагый һәм эстетик функцияләрен төгәлрәк ачыкларга да ярдәм итә. Элгәрге заман фольклор «чылбырларның» буыннарын шул ысул белән тарихи эзлекле билгеләү, дөрес ачыклау исә, соңгы дәвер халык иҗаты әсәрләренең үзенчәлеген, гомум һәм хосусый сыйфатын аңларга да мөмкинлек тудыра. Менә шуның өчен дә без борынгырак чорларга караган истәлекләргә — гәрчә алар телстиль, рух-омтылыш җәһәтеннән тәмам искергән булсалар да — аерата әһәмият бирәбез, аларны аерата югары бәялибез. Чөнки бүгенгенең, якын узганның «серләрен» белер өчен ерак калган чорларның «тамыр тибешен» капшап, тыңлап карарга кирәк. Чөнки бүгенге белән узган көн, якын узган белән ерак калган дәверләр аерылгысыз рәвештә бергә тоташкан. Фольклор дөньясында да ул нәкъ шулай.

Әмма ләкин бу «бергәлекне», бу «тоташканлыкны» аңлау юллары җиңел түгел, аңлату ысуллары исә тагын да кыенрак. Кыенлыкның күп өлешен сакланып калган күчеш буыннарының җитәрлек булмавы, зәгыйфь чалымлануы тудыра. Моның шулай икәнлеген берничә мисалда күрергә мөмкин.

## Тирән катламнарга үтешли

Әлбәттә, күчеш буыннары ачыграк чагылган, образлар системасы эзлеклерәк сакланган аерым текстлар да очраштыргалый. Андыйлар арасындагы уртаклыкны күрү һәм кайсысының чагыштырмача яңарак вариантны, яисә искергән версияне гәүдәләндерүен ачыклау әллә ни кыенлык тудырмый. Мондый очракта мисал рәвешендә түбәндәге фактларны китерергә мөмкин.

1966 елны Курган өлкәсенә М. Мәһдиев җитәкчелегендә оештырылган фольклор экспедициясенә барган студентлардан Н. Әхмәдиев, С. Таһировалар Шатрово районындагы Кызылбай авылында бер иске кульязма табалар. Аны беренче булып тикшергән профессор Хатип Госман китапның XVIII йөздә үк күчерелүен һәм аның безгә берничә әһәмиятле җыр тексты алып килүен ачыклый. Аларның кайберләрен ул 1967 елны студентларның практик дәресләре өчен чыгарылган кулланмада бастыра. Шулардан ике җыр үзенең рухы белән миңа аерата кызыклы булып тоелды. Басма

вариант белән танышкач, төпченә төшеп, университет китапханәсендә 2185 т. номеры[1] белән саклана торган әлеге кулъязманың үзенә мөрәҗәгать иттем һәм түбәндәге текстларны укыдым:

**Мән сәнең улсам ирде,**
**Куйныңа тулсам ирде;**
**Караңгы кичәләрдә**
**Ләб кенәң сурсам ирде.**
**Мән сәнең улсам ирде,**
**Куйныңа тулсам ирде;**
**Сән кигән китән күлмәк —**
**Якасы булсам ирде.**
**Су акар нәзек-өзек;**
**Кулымда алтын йөзек;**
**Бу шәһәрдән азып-гизеп,**
**Тапмадым сәндин нәзек.**
**Буз атым кешән кара;**
**Башың чиш, сачың тара;**
**Имди мән китеп барам,**
**Исән кал, кашың кара.**

**Ак атым аргамагым,**
**Артымдин карамагын;**
**Имди мән китеп барам,**
**Кайгырып егъламагын.**

**Ак атым арслан егет,**
**Буз атым бостан егет;**
**Каләм тотып хат беткән егет,**
**Мелладыр хафиз егет.**

**Буз атым буза-буза,**
**Буйнында алтын куза;**
**Яр гынам кәлүр булса,**
**Йибәрәй тезә-тезә!**
**Бу көн азына микән,**
**Яр гынам багыда микән!**
**Яр гынам багыда булса,**
**Мәне сагына микән!**

**Кашың карасы йитәр,**
**Сөрмә тартмасаң — бетәр,**
**Сән көйдермәсәң бу көн,**
**Үзем көйгәнем йитәр!**

(Улсам ирде — булсам иде; ләб — ирен; хат беткән — хат язган; хафиз — монда: секретарь, укымышлы; куза — кыңгырау; багыда — багында, бакчасында; кәлүр — килер)

Кызылбай авылында табылган, телендә кайбер борынгы «мишәрлек» элементлары чагылган бу җырларга махсус игътибар итүнең сәбәбе шунда: алар нигезендә «оешкан» башка бер вариант үз заманында Пермь, Свердловск, һәм Курган якларында гаять киң таралган икән. Мәсәлән, шул өлкәләргә оештырылган экспедицияләр вакытында дистәләгән шәкерт дәфтәрләрендә аның төрле сыйфаттагы текстлары очрады. Аларны чагыштырып карау җырның үзенә күрә кодификацияләнгән, ягъни бер калыпка утырып җиткән варианты барлыкка килүе хакында сөйли. Шул ук вакытта бу башка вариантта, гәрчә аның тел-стиле өлешләп бераз яңарып өлгергән булса да, борынгылык рухы калкурак сакланган. Ул бигрәк тә соңгы строфада яңгыраган егетләрчә кискенлектә, тәвәккәллектә үзен нык сиздерә.

**Буз атым бузай-бузай,**
**Буйнында алтын кузай;**
**Бер матурга гашыйк булып,**
**Гомерем зая узай.**

**Буз атым бостан кара;**
**Иртән торып сачың тара.**
**Бән китәм, сән калырсың,**
**Исән бул, кашың кара.**

**Буз атым бостан егет,**
**Ак атым арслан егет;**
**Яз китсәм, көз килермен,**
**Исән бул, мелла егет.**

**Ак атым арымагыл;**
**Бән китсәм, кайгырмагыл.**
**Бән киткән юлны карап,**
**Сагынып саргаймагыл.**

**Ук аттым уйга төште,**
**Күгәрчен андин очты;**
**Кирәк сәү, кирәк сәүмә —**
**Гыйшыкым сәңа төште.**

**Су агар нәзек-өзек:**
**Кулыңда алтын йөзек.**
**Күп илләрдә бән йөрдем,**
**Тапмадым сәндин нәзек.**

**Су агар гөлдер-гөлдер;**
**Без сәүгән нәзек билдер.**
**Бәндин үзгә ярны сәүсәң,**
**Ал пычак — санчып үлтер!**

(Буйнында алтын кузай — муенында алтын кыңгырау. Уй — уйсу, җир, иңкүлек.)

*(Пермь, Көңгер районы, Камышлы авылы, Уинск районы, Түбән Сеп авылы.)*

[1] Т — төрки, татар кулъязмаларны белдерә.

Игътибар итегез, егет кызга үз гыйшкы хакында хәбәр итеп, аның үзенә игътибарлы, мәрхәмәтле булуын гына сорамый, гыйшкына җавап бирмәсә, үзенең газап чигәсен әйтеп зарланмый, бәлки мәсьәләне, хәзергечә әйтсәк, кабыргасы белән куя: сөй мине, әгәр сөймисең икән, мә пычак — чәнчел үтер!

Мәхәббәт нәтиҗәсен эзләгәндә бары ике генә юлны сайлау, «яки — бар, янсә — юк» принцибын тану, көч кулланып булса да, уңай җавапка ирешергә омтылу һәм бу юлда катгыйлыкны идеал итү ул асылда әдәбият һәм фольклорда рыцарьлык рухы хөкем сөргән Урта гасырлар фикерләвенә хас. Безнең соңгырак дәвер гади крестьян стихиясендә туган мәхәббәт җырларында исә «йә ирештем, йә үлдем» принцибы түгел, бәлки «менә ничек газапланам» янсә «газапка ничек түзәрмен икән» диган мотив алгы планга чыга һәм өстенлек итә (әгәр соңгырак дәвердә җырланган җырларда әлеге рыцарьлык галәмәтләре очраса, аның борынгы чыганагы булуы бәхәссез). Минемчә, мондый хәл беренче чиратта гомер-гомергә төрле хәлләргә түзеп яшәргә мәҗбүр ителгән крестьяннарның сабыр табигатенә бәглы булса кирәк.

Мәхәббәт мәсьәләсен хәл кылганда, бары ике генә юлны күрү, шуның да тәвәккәллек, катгыйлык сорый торганын сайлау XVIII йөздә теркәлгән башка җырларга да хас. Мәсәлән, 1790 еллар тирәсендә төзелгән бер җыентыкта (ул хәзер Ленинградта саклана) теркәлгән үзенчәлекле җырда әлеге мотив болайрак хәл кылына.

> **Бу кичә — аяз кичә, йиле алкын,**
> **Аһ яр генәм, сәнең күңлең нәдин салкын!**
> **Аһ яр генәм, тоткыл кулым, күргел хәлем,**
> **Валлаһ, юктыр сәндин үзгә сәвәр ярым.**
> **Кашкаеңның карасына каткыл бәне,**
> **Буйкаеңның зифасына кушкыл бәне;**
> **Хезмәт итеп, хезмәтеңә яр (ама) сам,**
> **Гыйшыклык базарына саткыл бәне!**

(Каткыл — кату — кушу, аралаштыру.)

Ягъни: сөй мине, әгәр мин сөюгә лаек булмасам, кол итеп сатып җибәр үземне! Монда, шулай итеп, үтенү, ялвару түгел, бәлки корбанга әзерлек идеясе аша таләп итү, хәтта үзенә күрә басым ясау мотивы өстенлек кылу ап-ачык күренеп тора.

Борынгырак чор җырларына хас булган, әлек еш яңгыраган рыцарьлык рухының заманалар узу белән әкренләп кими төшүен, тора-бара беленер-беленмәс вак детальләрдә генә саклануын, хәтта беренче карауга төрле текстлар арасындагы уртаклыкны билгеләве шактый кыенлык тудыра торган фактларга да мөрәҗәгать итик Бу юлы инде яңарак версияләрдән искеләренә таба күчү принцибыннан файдаланыйк.

Буа районында Кырык Садак дигән бер борынгы авыл бар. Степан Разин сугышлары вакытында ук аның исеме тарихи документларга кереп калган. 1968 елны анда кульъязмалар эзләп йөргәндә табылган, башы-ахыры югалган, бары ун гына кәгазе сакланып калган бер дәфтәр кисәгендәге җыр үзенең стиле, рухы белән игътибарны җәлеп итте. Менә аның тәгәл тексты:

> **Кыш көнендә алма кызыл пешмәс ирмеш,**
> **Ике матур бер җирләргә дөшмәс ирмеш,**
> **Ике матур бер җирләргә дөшәр булса,**
> **Дөньяның нәчеклеген белмәс ирмеш.**
> **Теләгем булса ирде ярдин гына,**
> **Җалан аяк йөгерер ирдем кардин гына.**
> **Алтын иде иңремнең баш кынасы,**
> **Сәвәр идем яр гынамның яшь кенәсен —**
> **Култыгымдан чыгармай баш кынасын.**
> **Ак Иделнең буйларында саллар тора,**
> **Сал өстендә тутый кош тик ярлар тора;**
> **Тутый кошны тирләмәккә җефәк кирәк,**
> **Кызлар берлән сүләшергә хәйлә кирәк.**
> **Ак Иделнең буйларында болыт тора,**
> **Яңа ярлар иске ярны оныттыра,**

**Яңа ярлар таба[к]да аш китерә,**
**Иске ярләр күз[ләр]дин яшь китерә...**

(№ 2283 т., тирләү — бәйләү.)

XIX йөзнең урталарында күчерелгән бу әсәрдә күзгә бәрелеп торган һәм безнең күпчелек җырларыбызга охшап җитмәгән «ятрак» детальләр сыйфатында «ялан аяк йөгерер идем кардин гына»ише беркадәре чаярак, «култыгымдан чыгармай баш кынасын» кебек ихтыярлы ирне — сөйгәненә ялынып-ялваручы тыйнак, сабыр егетне түгел, ә үзенә күрә «көч кулланучыны» гәүдәләндергән юллар игътибарга лаек. Тик, кызганычка каршы, Кырык Садакта табылган текстның бераз бозылган, өтекләнә төшкән вариант икәнлеге дә сизелеп тора. Һәм ул шулай булып чыкты да.

Күп тә узмый, бу җырның тулырак һәм тагын да элегрәк күчерелгән икенче версиясен күрергә туры килде. XVIII йөздә күчерелгән, мәгәр нибары 5 кенә кәгазе сакланган бу дәфтәр өзеге 1970 елда Югары Балтай авылында (Апас районы) табылды.

**Ярны сәүсәң, сайлап сәү яшь кенәсен,—**
**Култыгыңдин чыгармас баш кынасын.**
**Кызларның сикереп менәр күмәсе бар,**
**Аршынлаган ак ефәк түмәсе бар.**

**Кешенең яшь баласын ник алдайсән!**
**Нәзек билдин кочып-кочып ник сәүмәйсән!**
**Биек тау[ның] башында авы[лы]ңыз;**
**Исәдер кырлы таудан давылыңыз.**
**Бән әйтмәсәм, сез үзеңез белмәймесез! —**
**Түш өстендә пешеп торган кавыныңыз.**

**Кызлар чыгар күмәдин айдай булып,**
**Буйлары яңа үскән талдай булып,**
**Шул кызларга егетләрнең кулы тисә,**
**Ятырлар баглап салган куйдай булып.**

**Беләзекең, йөзекең чындыр көмеш;**
**Егермегә йиткәнче булына тормыш**
**Ике тартып бер үпсәм, вай сылуым,**
**Булмак дәгел булырсың җандай белеш!**

**Бәнем ярым менгәне кызыл турат,**
**Кызыл турат менгәне җанга куәт;**
**Мал биреп ярым димәк шулдыр морат,**
**Мал бирмәй ярым димәк халыкдин оят.**

**Һавадин чарлап очар кыр[гый] казлар,**
**Бу дөньяны пор кылган зифа ярлар.**
**Кайда гына егетләрне күрсә кызлар,**
**Кяшки бәнем яр генәем булса дирләр.**

**Кыз угланың сикереп менәр күмәсенә,**
**Ак ефәкдин элгәк тагар түмәсенә;**
**Кызларның шул гадәте бик үк яман —**
**Бер әйләнеп карамас сәүмәсенә.**

**Кызлар чыгар күмәдин айдай булып,**
**Яңа үскән буйлары талдай булып,**
**Артыңдин карап калдым мәхруб булып,**
**Һич әйләнеп карамадың бәне күреп...**

(1 № 2429 т., күмә — көймә, борынгы арба төре, карета; түмә — төймә; пор кылу — тулы кылу, бизәү мәгънәсендә; кяшки — эх, әгәр дә; мәхруб булу — җимерелеп, өмете челпәрәмә килеп калу...)

Шулай итеп, бер карауга бу текст мөстәкыйль җырны хәтерләтсә дә, анда Кырык Садак версиясенең кайбер характерлы детальләре кабатланып, әле билгеләнгән егет чаялыгы тагы да калкурак чагыла икән. Әйтик, кызларга егет кулы тисә, алар «бәйләп салган куйдай булалар», ягъни ихтыярларын югалталар, өстәвенә «ике тартып бер убү-нең» дә кызны үз ихтыярыңа буйсындыру өчен әһәмияте зур икән... Аннары җырга «мал биреп яр сөю», ягъни калым түләп кәләш алу мотивы да килеп керә. Кыскасы, әсәрдәге образлар системасында, җыр җырлаучы егетнең психологиясендә социаль-иҗтимагый аңга бәйле күзаллаулар — борынгылык галәмәтләре тагы да ачыграк күренә.

Җырның өченче варианты белән танышу исә әлеге фикерне янә дә куәтләде һәм көчәйтте. 1785 елны төзелгән, хәзер Ленинградта саклана торган күчермәдәге бу текстта ат менеп ил гизүче коралы ир-егетнең образы, фикерләү үзенчәлеге, социаль психологиясе тагын да калкурак гәүдәләнә. Дөрес, гаять үзенчәлекле җыр текстының ахыр өлешендә кайбер юлларның җитеп бетмәве, ягъни чак кына бозылган булуы бераз кәефне китәрә. Шулай да ул — тулы килеш күчерелергә лаек мөһим истәлекләрнең берсе.

**Төркестанның юлына төште томан;**
**Аягын аркылы баскан юрга конан.**
**Гәр кулымда булса иде сыяһ, каләм,**
**Хат бетеп әэмәсмидим кызга сәлам.**

**Төркестанның юлында җәйләгәнем,**
**Колынчакны кызыл гөлгә бәйләгәнем;**
**Һич исеңдә юкмыдыр, әй, сылуым,**
**Ак түшеңә кулым салып уйнаганым!**

**Мылтыгымның мелтидер таш кынасы;**
**Осталарның атып алган кош кынасы.**
**Ярны сәүсәң, сайлап сәү яшь кенәсен,**
**Куйныңдан һич чыгармай баш кынасын!**

**Карчыга кош каеп очар казны күрсә,**
**Ир-егет кылыч алыр ауны күрсә,**
**Ир-егетнең күңелендә нәләр юктыр —**
**Баглы коштай талпыныр кызны күрсә.**

**Кара тауның башында авылыңыз,**
**Исәдер кырдан [каты] давылыңыз;**
**Бән әйтмәсәм, сез үзеңез белмәймесез —**
**Түш өстендә пешеп торган кавыныңыз.**

**Кызлар чыгар көймәдин айдай булып,**
**Яңа үскән буйлары талдай булып;**
**Шул кызларга егет кулы тия калса,**
**Ята куяр баглап салган куйдай булып.**

•

**...Артыңдан карап калдым мәхрүм булып,**
**Бер әйләнеп карамадың бәне күреп.**

•

**Кыз угълан йөгереп төшәр көймәсендән,**
**Җефәкдин төймә тагып якасына;**
**Кыз угъланның шул кылыгы бигүк яман —**
**Бер әйләнеп карамас сәүмәсенә!**

**Кыз [ыл! га!] мәхбүб [!] такыям кыз башында,**
**Хатын мидең, кыз мидең яр каршында;**
**Кызларның хатынлардин артыклыгы —**
**Алтмыш хатын бер кызның садакасы [!]**

•

**Фәлән суның буенда җәйләгәнем,**
**Колынчакны бәйл [әү]гә бәйләгәнем...**

•

**Кайда матур шәкертләр күрсә кызлар**
**Кяшки минем яргынаем булса дирләр.**

•

**Мал биреп ярым димәк шулдыр морат,**
**Мал бирмәй ярым димәк — халыкдин оят...**

(Каеп ачу — кыеклап очу; кылык — холык; конан — өч яшьлек ат, яшь ат; сыяһ — кара; әэмәс-мидем — җибәрмәсме идем, күндермәсме идем; мәхбүб — сөелгән, яратылган ир; садаха — садәка.)

Күренә ки, бу текстта ризыгын гына түгел, хәтта хистәге бәхетен дә корал ярдәме белән яулап алырга әзер торучы сугышчы ир-егетнең, европача төшенчәдән файдаланып әйткәндә, чын рыцарьның әдәби кыяфәте элгәрге яңарган вариантларга караганда тагы да әтрафлырак, янә дә төгәлрәк сурәтләнгән. Җырга терлекчелек төшенчәләре һәм яшь ат образы (юрга конан, колынчак), каеп, ягъни «коелып» очкан ау кошы — карчыга, корбанына ташланырга теләгән бәйле лачын, сугышчы кораллары мотивы (мылтык, кылыч) килеп керүе аның ханлыклар хөкем сөргән чордагы төрки-татар дөньясы белән тыгызрак, ныграк бәйләнгән булуына ишарә ясый. һәрхәлдә бу вариант артындагы протографларның (ягъни үзеннән элгәрге язма чыганакларның) XVI йөздә яшәгән, аннары чак кына үзгәрә, яңара төшкән халдә XVII гасырда да яңгыраган булуы шик тудырмаска тиеш. Мылтык образының кулланылуына да гаҗәпләнергә, шуннан чыгып, җырның борынгылыгын инкарь итәргә ашыкмыйк: дары-ядрәле ату коралларыннан татар сугышчылары Казан ханлыгы җиңелгәнче үк файдалана башлаганнар. Ә яңа сугыш коралы, мәгълүм булганча, фольклорга тиз килеп керә һәм уңган, булдыклы ир-егетләрнең символы, иярчене булып хезмәт итә.

Җырга ярдәмче сурәтләү чаралары сыйфатында булса да килеп кергән «Төркестан юлы» мотивы, варианттан вариантка күчә барган пешкән кавын кебек йомры күкрәк образы да игътибарга лаек фактлар. Төркестан атамасының кечкенә шәһәр исеме сыйфатында түгел, ә олы юллы ил мәгънәсендәрәк кулланылуы, Урта Идел һәм Урал буйлары өчен ят кавын образының алынуы да җыр тукымасының борынгылыгына — Казан ханлыгы чорындагы татарларның Урта Азия, Хива яклары белән тыгыз элемтәсенә ишарә ясый. Чөнки, ханлык җимерелгәч, бу тарафларның элекке Төркестан якларындагы халыклар белән тыгыз хәрби-политик, сәүдә-экономик һәм рухи-мәдәни элемтәләре кискен рәвештә зәгыйфьләнеп, XVIII йөз ахырларына кадәре яңадан терләнә алмый. (Яңа дәвергә якынрак чорлар өчен хас Идел буе һәм Урта Азия арасындагы тыгыз культура мөнәсәбәтләренең электән үк өзлексез килә торган элемтә дәвамы түгел, ә Пугачев восстаниесеннән соң яңадан тергезелгән идеологик хәрәкәтнең бер чагылыш икәнлеген һич тә онытырга ярамый.)

Шулай итеп, Казан университетыннан Ленинградка күчкән кульязмада сакланып калган әлеге версиянең элгәрге «татар рыцарьлары» җыры икәнлеге шактый ачык күренеп тора.

Истәлекнең тагын да элегрәк кәгазьгә теркәлеп калган дүртенче версиясе исә белемебезгә бөтенләй яңа мәгълүматлар өсти. Ул хәтта үзенең башкарылу формасы, поэтик үзенчәлеге һәм иҗтимагый функциясе буенча безне ир-егетләр чаялыгын мактый торган сюжетлардан алып чыгып, фольклор мирасыбызның икенче өлкәсенә — борынгы йола җырлары дөньясына алып керә. Сүз 1773 елга хәтле, ягъни Пугачев восстаниесенә кадәр үк теркәлеп калган бер үзенчәлекле версия хакында бара.

## Хөкемгә тартылган дәфтәр

Бу текстны эченә алган шәкерт дәфтәре хәзер Мәскәүдәге Борынгы актлар дәүләт архивында саклана. Аның архивка килеп керү тарихы болайрак.

Емельян Пугачев восстаниесенә каршы рәхимсез көрәш алып барган патша хөкүмәте органнары баш күтәргән крестьяннарның кулга төшүчеләрен ату, кисү, асу белән генә чикләнми. Алар, азатлык өчен көрәш хәрәкәтен төбе-тамыры белән йолкып ташлау ниятеннән чыгып, «гадел падиша Питыр Фидраучка», ягъни Е. И. Пугачевка ышаныч баглаучыларның, ул җиңелгәч яшеренеп калучыларның да һәммәсен эзләп табу һәм аларны эзлекле рәвештә җәзалау максаты белән баш күтәрүчеләргә караган һәрбер документны җыялар, җентекләп өйрәнәләр. Шул рәвешчә тупланган документлардан гыйбарәт зур «эш» хасил була. һәм ул хәзер Борынгы актлар архивының Алтынчы фондындагы VI разрядның 416 номерлы «эшенең» икенче кисәген тәшкил итә.

445 кәгазьдән торган бу калын һәм зур «эшнең» эчендәге 300 дән артык документның һәммәсе дә диярлек восстаниегә катнашучылар лагерыннан чыккан булып, алар тулысынча Идел—Урал буе халыкларыннан татарлар, башкортлар һәм чирмеш-

мариларның восстаниегә ничек кушылулары, ничек социаль гаделлек өчен сугышулары хакында шаһитлык итәләр. Аларның бер өлеше Көнгер—Оса тирәләренә, икенчеләре Уфа өязе якларына караса, өченче мөһим зур өлеше хәзерге Татарстан җиренә мөнәсәбәтле. Архивта «Төрле Пугачев атаманнарыннан кулга төшерелгән кәгазьләр» дип исемләнгән бу документларның зур өлеше патша җәзалаучылары кулына атаклы Пугачев яраны, мишәр старшинасы «пулкауник» Бәхтияр Канкаевның поход канцеляриясе белән берлектә эләгә.

Мәгълүм булганча, 1774 елның июль ахырларында, Хәзерге Балык бистәсе тирәләрендә барган көчле бәрелешләр нәтиҗәсендә, Бәхтияр Канкаев отряды тар-мар ителә һәм аның актив ярдәмчеләреннән булган писарь Әбүбәкер Теләчев, ул җитәкчелек иткән поход кәнсәләре җәзалаучылар кулына төшә. Кәнсәләр «архивында» исә йөзгә якын документ — эш кәгазьләре белән бергә башка характердагы язмалар да була. Димәк, монда тасвирлана торган, фән өчен гаять кыйммәтле 416 «эшнең» икенче кисәгенең якынча өчтән бер өлешен шул Бәхтияр Канкаев кәнсәләреннән чыккан документлар тәшкил итә. Бу — безнең өчен гаять мөһим факт.

Әлеге саннарга басым ясап әйтүнең сәбәбе шунда, 416 нчы «эштәге» документлар арасында эчтәлекләре буенча восстаниегә турыдан-туры карамаган язмалар да шактый. Мәсәлән, анда кечкенә форматлы берничә шәкерт дәфтәренең өзекләре дә бергә тегелгән. Әйтик, 210—212, 236—238, 370—377 кәгазьләрдә төрле җыр текстлары китерелсә, 261—264, 316—317 битләрдә «Тәгъбирнамә» — төш юрау китабыннан өзекләр сакланган; 324—335 кәгазьләрдә исә шәкерт әдәбияты репертуарында киң таралган «Кисекбаш» поэмасын күрәбез. Димәк, тасвирлана торган «эштә» барлыгы 30—40 бите генә килеп җиткән берничә әдәби шәкерт дәфтәре дә сакланып калган икән.

Шушы дәфтәрләрнең бер өлеше үзенең эчтәлеге буенча турыдан-туры безнең темага карый. Чөнки анда элекке татар шәкертләре традициясе буенча «Илаһи бәет» дип аталган дүрт-биш җыр, бер-ике шигырь китерелә. 377 кәгазьдәге кыскача белешмәгә караганда, дәфтәрнең бу өлеше һиҗричә ел исәбе белән 1155 елда, ягъни хәзергечә исәпләгәндә 1742—1743 елларда күчерелгән.

Әмма бу дәфтәр — восстаниегә хәтле 30 ел элек үк төзелгән шәкерт кулъязмасы — җәзалаучыларга ничек килеп эләккән соң? Минемчә, ул патша офицерлары кулына әлеге Бәхтияр Канкаев кәнсәләре составында кергәнгә охшый. Мондый фаразның дөреслеккә якынлыгын түбәндәгечә расларга мөмкин.

Беренчедән, ул дәфтәрләрдә очрый торган текстлар шул чор татар әдәбияты һәм фольклоры репертуарына тулысынча туры килеп бетәләр. Әйтик, әлеге «Тәгъбирнамә» белән «Кисекбаш»ның тагын дистәләгән татар җирлеге күчермәләре булганы кебек, алга таба махсус тикшерелә торган ике җырның да татарча версияләре барлыгын күрербез.

Икенчедән, ул дәфтәрләрдәге әдәби текстларның тел-стиль үзенчәлеге, ягъни лексик һәм грамматик хосусиятләре дә иске татар әдәби теле нормаларыннан чыкмый, дөресрәге аның мишәрләр арасында таралган төренә тартымрак.

Өченчедән, алардагы җыр-фольклор текстларында да китаби стиль, төгәлрәк әйткәндә, зур мәдрәсә күргән, шактый белем алган укымышлы шәкертләрнең сөйләү, фикерләү рәвеше нык чагыла. Пугачев явына кадәрге зур татар мәдрәсәләренең бары патша хөкүмәтенә лояльлек саклаучы мишәрләр даирәсендә генә һәм берән-сәрәнләп кенә Казан арты якларында да яшәп килүләре тарихта мәгълүм факт.

Дүртенчедән, һәм иң мөһиме, йөзләгән рәсми эш кәгазьләре — чын «фетнәчел документлар» арасына бер-ике нейтраль эчтәлекле әдәби дәфтәрнең килеп кысылуы, аларның, җәзалаучылар күзлегеннән караганда, тикшерү һәм хөкем итү өчен мөһим урында, ягъни «җинаятьче» белән бергә «кулга алынуына» күрсәтсә кирәк. Шулай булмаган тәкъдирдә җәзалаучылар андый әдәби кулъязмаларны яки һәр очраган саен тулаемы белән җыярлар да, шул рәвешчә йөзләгән әдәби, дини кулъязмаларны бергә туплаган булырлар иде. Димәк, әлеге дәфтәрләрнең шулай махсус «хөкемгә тартылуы» аларның кем милкендә булуына ишарә итсә кирәк. Минемчә, алар патша башкисәрләре тарафыннан әлеге Бәхтияр Канкаев писаре Әбүбәкер Теләчев белән бергә «әсир ителгәнгә» охшый.

1774 елның 27 июлендә кулга төшкән Әбүбәкерне, каләмне кылычка алмаштырганы өчен, архив документлары күрсәткәнчә, «элек халыкка язган уң кулын кисеп, аннары башын чабып үтерәләр».

Әбүбәкер Теләчев төзегән документлар исә аның чагыштырмача югары грамоталы, стиле чарланган, әдәби зәвыгы да оешкан укымышлы булуы хакында таныклык бирәләр. Димәк, андый кешенең поход-сугыш шартларында да үзе белән бергә әдәби җыентыклар йөртүе ихтималга якынрак икән.

Әлбәттә, ул дәфтәрләрнең восстаниегә актив катнашкан икенче бер татар укымышлысының язмышына барып тоташуы да ихтимал. Шулай да аларның Бәхтияр Канкаев, Әбүбәкер Теләчевләр белән бер юлда булуы, ахыр чиктә аларның катлаулы, мактаулы язмышларына шаһит икәнлеге, шуңа күрә «җавапка тартылуы» бернинди бәхәс тудырмый.

Безнең игътибарны менә шулай Бөек восстаниегә «катнашкан», шуңа күрә гаепләү факты рәвешендә «хөкемгә тартылган» дәфтәрдәге бер борынгы җырның тексты җәлеп итә.

Дөресрәге, монда бер генә түгел, бәлки өч аерым әсәрнең тышкы форма җәһәтеннән бер калыпка салынган төрле җырлар циклының уникс строфадан гыйбарәт җыелма тексты бергә бирелгән. Истәлек моңар хәтле ике мәртәбә басылган булса да (Әхнәф Харисов һәм Хатип Госманнар тарафыннан), аның төзелешен, аерым сүзләрен аңлауда буталчыклыклар бар. Мәсәлән, Ә. Харисов аны бербөтен әсәр рәвешендә кабул итсә, Х. Госман аерым «парчалар» сыйфатында бәяли. Минем фикеремчә, әлеге уникс строфаның беренче дүрт строфасы борынгы йола җыры «Яр-яр»дан үзгәртелгән булса, бишенчесе башка бер сюжетлы җырдан алынганга охшый. Чөнки андагы мәхәббәт объектының персоналаштырып бирелүе, ягъни Сария дип телгә алынуы аның йола җыры буларак төгәл абстрактлылыкка ирешкән «Яр-яр» такмакларының иҗтимагый функциясенә туры килеп җитмәвен күрсәтә шикелле. Менә ул строфа:

**Егерме тугыз хәреф, берсе «ләм»дер [1],**
**Корбымдим Сариямне сәвәмендер, ярәй;**
**Ир-егет ярлы булса, тәңре байдыр,**
**Сариямә таянсам, һич үлмәндер, ярәй.**

(Ләм — «Л» хәрефенең исеме; корбы — кордаш; үлмәндер — үлмәмдер.)

Моннан соң килә торган җиде строфа без элекке бүлекчәдә махсус анализлаган ир-егетләр, ягъни «татар рыцарьлары» җырының тагы да борынгырак һәм шактый үзенчәлекле версиясеннән гыйбарәт. Дөрес, ул да «җиңгәй, җизнәй» рәвешендәрәк формалашкан эндәш сүзе төсмерен алган «ярәй» рефрены белән тәэмин ителгән.

**Башыңдагы кыңгыравың калтырай ла,**
**Алтын микән йөзегең — ялтырай ла, ярәй;**
**Мән күргәндә кыңгыравың юк иде лә.**
**Котлы булсын кыңгыравың — шалтырай ла, ярәй.**

**Һавадан коңгылдашкан каз имәсме!**
**Егетне шайда кылган кыз имәсме, ярәй!**
**Кызның малы кырык тәвә — аз имәсме!**
**Кыш көне кочып ятсаң, яз имәсме, ярәй!**

**Күксү илә комда батар, кандым тәмам (!)**
**Бер кызның гыйшкындин яндым (тәмам), ярәй;**
**Сусадым, су тапмадым, көйдем тәмам,**
**Ләбләрендән тартып үпдем — кандым тәмам, ярәй.**

**Мәнем атка менгәнем кызыл турат,**
**Кызыл турат менгәнем җанга морат, ярәй,**
**Мал биреп, ярым дисәң — улдыр морат,**
**Мал бирмәй ярым димәк халыкдин оят, ярәй.**

Аркадин болан уйнар чүлгә батып,
Сез кызларны алырмын малга сатып, ярәй;
Сез кызларны алыр булсам малга сатып,
Тирәзәдән каратырмын алгасатып, ярәй.

Кыз углан сикереп менәр көймәсенә,
Ефәкдин элгүк тагар төймәсенә, ярәй.
Кыз угланның гыйшкы яман — шул кылыгы:
Бер әйләнеп карамас сәумәсенә, ярәй.

Әссәламегаләйкүм, өлкән кызлар,
Оят булыр, бөркәнчегең бөркән, кызлар, ярәй;
Бөркәнчегең күтәреп кем күрәдер —
Сезнең өчен назик җан шул уладыр, ярай.

(Имәсме — түгелме; шәйда кылу — акылдан яздыру; ләб — ирен; алгасату — интектерү; элгүк — элмәк; назик — нәфис; кадерле).

Гәрчә бу текстта, Ленинград кулъязмасындагы нөсхә белән чагыштырганда, ир-егетләр җыры өчен характерлы кайбер галәмәтләр (корал-ярак, лачын образлары) кимрәк булсалар да, борынгылыкның рухы икенчерәк планда тагы да ачыграк яңгырый. Бу — кыз башының бәясе (40 тәвә!), кәләшне сатып алу һәм шулай малга алынган хатынны җария-кәнизәк дәрәҗәсендә «тирәзәдин алгасатып» — тилмертеп өйдә тоту белән горурлану мотивы.

Мондый рух хәләл җефетен иген игү, урак уру вакытында үзе белән бер дәрәҗәдә тиң эшләтергә мәҗбүр ителгән, шул мәҗбүриятне гадәти генә хәл дип инанган, шуңар күнеккән крестьян психологиясенә ят нәрсә, әлбәттә. Хәер, «сусадым, су тапмадым, көйдем тәмам, ләбләреңдән тартып үптем — кандым тәмам» дигән юллардагы көч куллануга ишарәдән гадәти мужик егетнең психологиясеннән бигрәк әлеге «рыцарьның» кызга караганда үзенең ихтыяр көченә күбрәк гашыйк булуын күрәбез.

Урта гасыр ир-егетләрнең поэтик символына әверелгән корал-ярак образларының җыр текстыннан төшерелүенә килсәк, бу да очраклы хәл түгел: мондый характерлы үзгәртү, ягъни «юашлануга» таба бер адым ясау ул борынгы ир-егет җырының түйларда башкарыла торган йола җыры рухына якынлаштырылуы нәтиҗәсе.

Мондый яраклаштыру, ягъни үзгәртү тенденциясе исә үз нәүбәтендә икенче бер мөһим факт хакында хәбәр итә: борынгы «героик» табигатьле егет җырының XVIII йөз урталарына хәтле үк шулай үзгәртелүе әлеге жанр репертуарының кризис кичерүенә, ягъни актив гамәлдән төшә бару процессына күрсәтә.

Әйе, бу чыннан да шулай һәм ирешелгән хөкемнең дөреслеген күрер өчен моңарчы анализланган дүрт версияне үзара хронологик тәртиптә чагыштырып карау да — Ленинград дәфтәрендәге тексттан Кырык Садак авылында табылган версиягә кадәрге үзгәрүләрне ачыклау да артыгы белән җитеп тора.

Димәк, без моңарчы җыр сыйфатында тасвирлаган, анализлаган әлеге текстлар, чынлыкта, борынгы ир-егет җырларының төгәл үзләре булудан бигрәк, аларның өлешчә сакланган калдыклары, ярчыклары гына икән.

Хәер, андый ярчык-калдыкларның табыла торуы да фән өчен зур әһәмияткә ия. Моның шулай икәнлеген кайбер борынгы йола җырлары язмышында да күрәбез.

Ләкин андый җырларга күчкәнче, югарыда китерелгән мисалларга мөнәсәбәтле рәвештә, тагын бер мәсьәләгә — борынгырак чор җырларыбызның кайбер шигъри-техник һәм строфадагы композицион үзенчәлекләренә дә тукталыйк.

Беренчедән, аларның вәзен-үлчәме игътибарга лаек: строфалар нигездә 11—12 иҗекле юллардан төзелгән (көйләп әйтелгән, ягъни җырланган текстларда иҗек санының теге яки бу якка бер санга үзгәрүе — артуы, кимүе әллә ни әһәмиятле түгел). Бу хәл исә соңгы дәвердә казакъларда күбрәк сакланган, тюркология фәнендә «асыл төркичә халык шигыре» рәвешендә танылган 11 иҗекле үлчәмнең элек бездә дә актив кулланылышта булганлыгын расласа кирәк. (Идел буенда таралган иң бо-

рынгы язма истәлекләрдән «Кыйссаи Йосыф» китабының да шул үлчәүдә язылганлыгын онытмыйк!) Әгәр киләчәктә бу нәтиҗәнең дәреслеге расланса, фольклор фәнебез өчен тагын бер методик чара артачак: шигъри юлларының үлчәме буенча да иске дәвер истәлекләребезнең хронологик классификациясен, ягъни борынгылык-яңалык мәсьәләләрен шигъри-типологик ысул ярдәмендә дә хәл кылу мөмкинлеге туар иде. Әлбәттә, моны төгәл ачыклар өчен әле күп эшләргә — язма рәвештә теркәлеп калган борынгы текстларның санын ишәйтеп, махсус гыйльми-тикшерену эшләрен башкарырга кирәк булыр.

Икенчедән, югарыдагы мисаллар моңарчы да галимнәрнең башын катырган татар җыры строфасының «сәерлегенә» (баштагы ике юл белән соңгы ике юллык арасындагы мәгънәви бәйләнешнең булу-булмау «бәхәсенә») яңа фактлар өсти. Әйтик, типик татар халык җыры строфасындагы дүртъюллыкның ике өлешенә туры мәгънәви бәйләныш түгел, бәлки күчерелмә, аналогик яисә параллель настроение уртаклыгы хас. Андый бәйләныш кайчак бик ачык, кайчакларын исә гаять яшеренгән була; кайбер очракларда андый «яшеренгәнлек» бөтенләй мөнәсәбәтсезлеккә дә китерә. Мәсәлән:

•

**Һаваларда йолдыз, әй, ничәдер,**
**Ничә генә баксаң күчәдер;**
**Ничә генә айлар, ничә еллар**
**Гомерләрем заигъ кичәдер.**

•

**Китәннәрне элдем мин киртәгә,**
**Җилфер дә генә җилфер итәргә;**
**Мөкаддәрдә безгә язган икән**
**Туган җирне ташлап китәргә.**

•

**Өстемә лә кигән бишмәтемнең**
**Буй-буй гына булыр буявы;**
**Егет башларына ни эш төшмәс,**
**Һич сизгертмәс аның уявы.**

(Заигъ — зая; мөкаддәр — тәкъдир.)

XVII һәм XVIII гасыр текстларында андый мисалларның дистәләп-дистәләп очравы (монда аларның барысын да китереп тормыйбыз) татар җыры строфасы хакындагы моңарчы яшәп килгән фикерләрне тулыландырыр, тарихи планда үстерер һәм ныгытыр өчен дә өстәмә материаллар бирә икән.

## Кулъязмалар чыгарган хөкем

Мәскәү архивында сакланып калган әлеге ир-егет җыры, югарыда әйтелгәнчә, икенче бер йола җырыннан үзгәртелгән дүрт строфадан соң китерелә. Ул строфалар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

**Бисмилланың әүвәл башы әлиф торыр,**
**Сүзләмәккә сүз мәгънәсе килеп торыр, ярәй;**
**Уйнаңыз да көлеңез тереклектә,**
**Замананың ахры явук (килеп) торыр, ярәй.**

**Бисмилланың әүвәл башы тәбарәкдер,**
**Яхшының сүзләр сүзе мөбарәкдер, ярәй;**
**Яхшы берлә бер заман уйнап-көлең,**
**Яман берлә күп сүләмәк нә кәрәкдер, ярәй.**

**«Колһуаллаһ» сурәнең башындадыр,**
**Пәйгамбәрләр алланың кашындадыр, ярәй;**

Пәйгамбәрнең бер кызын Гали алган,
Туй туйлап, үләң әйтмәк шундин калган, ярәй.

Бисмилланың әүвәл башы әл-гасрый[дыр];
Егетнең кылган эшен кыз яшерер, ярәй;
Уйнаңыз да көлеңез терәклектә —
Адәм угълан берләп-берләп йир яшерер, ярәй.

(Әлиф — гарәпчә әлифбадагы беренче хәреф; явук — якын; тәбарәк һәм колһуаллаһ — коръәндәге сүрә исемнәре; кашында — янында, каршында; үләң — җыр, көй.)

Беренче карауга бу җырлар дини эчтәлекле көйле «иманнарны» хәтерләтә кебек: һәр дүртъюллык дога сүзеннән башлана. Тик, игътибар белән укысаң, аларның, киресенчә, гел дөньяви рух белән сугарылган, хәтта кешеләрне гыйш-гыйшрәткә, уенкөлкегә чакырган булуын күрәсең. Әмма истәлекнең фольклор фәнебез өчен чын әһәмияте анда гына түгел әле. Ул аның формасында, дөресрәге һәр бәет, ягъни һәр икеюллыктан соң кабатлана торган «ярәй» рефренында. Чөнки ул «ярәй» гади генә «әй сөйгән яр» мәгънәсендә эндәшүдән бигрәк борынгы бер йола җырында «яр-яр» рәвешендә кабатлана торган махсус рефренга кайтып кала. Бу хәл исә йола иҗатыбыздагы бер кызыклы, мөһим эволюциянең, тарихи үзгәрүнең табигатен дөрес аңларга, моңарчы фольклор белемебездә яшәп килгән бер бәхәскә соңгы ноктаны куярга ярдәм итә. Фикерем аңлаешлырак булсын өчен, сүзне беркадәре ерактанрак башлыйм. Кемгә ничектер, белмим, әмма минем өчен әлеге бәхәс 1961 елны Бараба сахраларында халыктан җыр язып, кулъязма эзләп йөргән көннәрдә үк башланып китте.

Шулай, картлар белән әңгәмәләшә торгач, элек Бараба татарларында «Яр-яр» дигән махсус туй җыры булганлыгын ишеттем һәм шуны яттан белүчеләрне эзләп киттем. Барабалыларның хәтер капчыгы «зур тишекле» булып чыкты: кайчандыр андый җыр җырлануын картларның барысы да диярлек хәтерли, әмма берсе дә яттан ике строфаны әйтеп бирә алмый — онытылган... Әйтелгәннәрнең күпчелеге кабатлаудан гына гыйбарәт.

Юлдашларыбызның берсе — ул чакта әле тел белеме өлкәсендә материал туплап йөрүче, соңрак фольклор белгече булып киткән кеше — минем болай нәтиҗәсез йөрүемнең сәбәбен үзенчә аңлатты:

— Ул «Яр-яр» дигәнең татарныкы түгел, безгә ул читтән — мөгаен казакълардан килгән, шуңа күрә дә аны монда белмиләр!

Ләкин мин мондый хөкем белән килешмәдем: төрки халыкларның күпчелеге өчен уртак булган бу йола җыры ни өчен бер татарларда гына булмаска тиеш?! Әгәр фольклор тирәсендә йөрүче һәр икенче кешенең «юк» дигәненә ышана башласаң, бездә эпос-дастаннар да булмаган булып чыга!..

Күп тә узмый тырышлыгым нәтиҗәсен бирде: Новосибирск өлкәсенең Шагыр һәм Тандау авылларында, бабайлары ярдәмендә ике әбине җырлата-җырлата, әлеге «Яр-яр»ның аерым строфаларын җыеп, шактый тулы бер вариантын булдыра алдым. Ләкин, Казанга кайтып, җырны журналда бастырып чыгаргач та («Совет әдәбияты» 1962, 6 сан), бәхәс туктамады, бәлки минем өчен кискенрәк кыяфәт алды: хосусый әңгәмә вакытында күренекле әдәбиятчыларыбызның берсе минем юк-бар белән шөгыльләнүемне, «Яр-яр» ише нәрсәләрнең татар халкы рухына «ят» әйбер икәнлеген әйтте... Икенче олырак яшьтәге агай да шул ук фикерне кабатлады. Ләкин мин барыбер килешмәдем:

— Ни өчен ят? Башка тугандаш халыкларга «үз» булган һәр истәлек безнең өчен шулай ят булырга тиешме?!

Татар халык авыз иҗатына багышланган хезмәтләрне күпме актарсам да, әлеге «Яр-яр» кебек әсәрләрне бер дә очрата алмадым. Күңелгә бераз шик тә йөгерә башлады...

Сорауларыма җавап эзләп, шөбһәләргә чик куярга теләп, тагын фәнни хезмәтләргә, башка тугандаш халыкларның фольклор хәзинәләренә мөрәҗәгать иттем. Әйе,

бу «Яр-яр», элек мин белгәнчә, бер казакъларда яисә уйгурларда гына түгел, башка төрки халыкларда да киң таралган йола җыры икән.

Атаклы тюрколог В. В. Радловның Россия дәүләте составындагы бараба һәм казакъ кабиләләре арасында төрле вакытларда язып алып, 1870 һәм 1872 елларда үзенең «Образцы народной литературы тюркских племен» исемле бөек хезмәтенең III һәм IV кисәкләрендә бастырган текстлардан, этнограф Әбүбәкер Диваевның Сыр-Дәрья буйларында тапкан вариантыннан тыш, «Яр-яр»ның тагын мәгълүм татар тарихчысы Корбангали Халиди тарафыннан Кытай Төркестанында яшәүче казакълардан алган версиясе дә барлыгын белдем. Ул текст галимнең 1915 елда басылып чыккан «Тәварихи хәмсәи Шәркый» исемле китабында китерелгән.

XX йөз ахырында Кытайдагы уйгурлар арасына сәяхәт ясаган Н. Ф. Катанов исә ерак Хами шәһәрендә дә «Яр-яр»ның уйгур версиясен язып ала һәм Казанга кайткач, бастырып чыгара.

Үзбәк, каракалпак поэзиясе антологияләрендә дә аның милли версияләре китерелә. В. Беляев тарафыннан нәшер ителгән «Очерки по истории музыки народов СССР» исемле китапта (Мәскәү, 1962 ел) үзбәкчә, каракалпакча яңа вариантлардан тыш, җырның төрекмәннәр арасында таралган версиясе дә китерелгән.

Шулай итеп, күпчелек төрки халыкларда бар икән әлеге җыр, хәтта хәзер дә җырлана икән ул! Әмма бары безнең Казан татарларында гына ни өчендер бер дә очрамый... Әллә чыннан да ул безнең халык өчен ят нәрсә булганмы?

Шулай икеләнебрәк йөргән көннәрнең берсендә татар теле диалектлары белгече Леонид Арслановны очраттым. Әле генә Әстерхан якларындагы нугайлар арасыннан кайткан икән.

— Карале, аларда «Яр-яр» җырын ишетергә туры килмәдеме сиңа?

— Ишеттем, хәтта язып та алдым...

Тиздән Леонид миңа әлеге текстны җибәрде. Димәк, «Яр-яр» безгә иң якын халык — нугайларда да булган! Ни өчен, алайса, Казан татарларында гына юк ул? Әллә аның функциясе безнең гореф-гадәтләргә туры килеп бетмиме?

Болай уйларга да нигез юк. Чөнки җырның бер халыкларда кияүгә бирелгән кызны туй көнендә кияндергән чакта, икенчеләрендә кәләшне озаткан вакытта, өченчеләрендә исә озатыла торган кыз белән хушлашып алдыннан җырлануы аның форма һәм функция җәһәтеннән шактый сыгылмалы булуын күрсәтә. Татар туйларында да кыз кияндерү, кәләш озату, аның белән хушлашу, килен каршылау, шундый чакларда аңар изге теләкләр әйтү йолалары булгандыр бит! Димәк, мәсьәлә формада да, функциядә дә түгел икән... Шуңа күрә бу җырның кайчандыр бездә дә җырлануы, йола гамәлендә булуы шик тудырмаска тиеш. Ләкин, алайса, нигә аның текстлары бер дә табылмый?

Мәгълүм фольклорчыларыбызның берсенә мөрәҗәгать итеп, әлеге «Яр-яр»ның профессиональ язучыларыбыз әсәрләрендә, мәсәлән, Әхмәт Уразаев-Кормашиның «Буз егет»ендә, Мирхәйдәр Фәйзинең «Кызыл йолдыз» исемле пьесасында китерелүенә, әмма Казан татарларының авыз иҗатында бер дә очрамавы хакында үземнең гаҗәпләнүемне белдергәч, ул уйчан гына әйтеп куйды:

— Очрамый дип кырт кистереп әйтергә дә ярамастыр, ахрысы. Мәсәлән, безнең фондта аның 1939 елда Мөслим ягындагы Теләче авылында теркәлгән һәм 1952 елны Саба районында язып алынган вариантлары бар. Дөрес, алар Уразаев-Кормашиның «Буз егет»ендәге текстны хәтерләтә төшәләр... Аның әлеге әдәби әсәрләргә Себер татарларыннан, хәтта казакълардан килеп кергән булуы да ихтимал...

Мондый уйланырга урын калдыра торган аңлатма минем элекке ышанычымны шактый нык какшатты. Нәтиҗәдә үземнең ялгышуыма күбрәк ышана башладым...

Ләкин тиздән күңелдә ныгый башлаган әлеге шөбһәләр дә, татар фольклорчылары күптән тукып килгән «бездә юк» иманы да — барысы бергә челпәрәмә килде. Һәм моңа шәкерт дәфтәрләре сәбәп булды. Мәсәлән, әлеге әңгәмәдән соң ике-өч ай узмагандыр, Кама тамагындагы Иске Казиле авылында кульъязмалар эзләп йөргән чакта XVIII йөздә төзелгән шәкерт дәфтәреннән өзелеп төшкән бер генә биттә мондый юлларны уку бәхетенә ирештем:

**Илаһи бәет будыр**

**Әүвәл башта тәңрене яд итәлем, яр-яр,**
**Гыйшык тоткан күңелне шад итәлем, яр-яр.**
**Бу җиһанда егеткә кыз гөл кебек, яр-яр,**
**Кызым гашыйк булган егет былбыл кебек, яр-яр,**
**Һай егет, һай егет, йөзем сытак [!], яр-яр,**
**Сезнең өчен бездән һәм күптер теләк, яр-яр.**
**Тел яратты хак безгә сөйлә [гәле], яр-яр!**

(№ 2379 т.)

Язу шулай тәмамланмыйча калган. Әмма ләкин барыбер минем башым күккә тия язардай булган иде: татар «Яр-яр»ының эзенә төштем, ниһаять!

1970 елны, Апас районындагы Иске Йомралы авылында эзләнгән чакта, бик бозылган булса да, тагын «Яр-яр»ның бер строфасына тап булдым:

**Кыз сүзе:**
**Минем алда йөземне күргел, егет, ярәй-яр,**
**Күшәгәмне югары ит, керсен егет, ярәй-яр.**

**Егет сүзе:**
**Кара атка [атланган] сәрвәт руйы, ярәй-яр...**

(Күшәгә — ишек пәрдәсе; сәрвәт руйы — матур йөзле.)

Текст шулай бик өтек булса да, мөһим факт иде бу!

Югарыда бер мәртәбә телгә алынган Курган өлкәсе, Шатрово районындагы Кызылбай авылыннан кайткан дәфтәрдә әлеге җырның 24 юллы башка версиясе бар икән. Үзе традицион рәвештә башлана ул. Тик ни өчендер күчерүче җырның дөньяви-йола өлешен төшереп калдырган да, гел дини рухтагы строфаларын гына теркәп барган.

Күп тә узмый, Ленинградтагы татар кулъязмалары белән танышып утырган чакта, җырның 160 юлы сакланып калган бик озын, гаять әчтәлекле текстына очрадым. Ул 1792 елга хәтле төзелгән типик татар дәфтәренә теркәлеп калган икән. Күчереп язучысы Аллабирде исемле татар шәкерте. Җыр болай башланып китә:

**Әүвәл башлап ходаны яд итәле, яр-яр,**
**Пәйгамбәрләр рухыны шад итәле, яр-яр.**
**Шад булдык — шадиман, безне күрең, яр-яр;**
**Һич рәхиме килмәде безне күреп, яр-яр.**

**Йосыф берлә Зөләйха яр иделәр, яр-яр,**
**Бер-берене күрмәгә зар иделәр, яр-яр,**
**Йосыф берлә Зөләйха күреште бер көн, яр-яр,**
**Мосафирлык шәһренә төште бер көн, яр-яр.**
**Чөн Зөләйха Йосыфка мәгъшукъ иде, яр-яр,**
**Аңа Ләйли сыйфатлы мәҗнүн иде, яр-яр...**

Моннан соң тагын башка пәйгамбәрләрнең үрнәк булырлык тормышлары, изге гадәтләре тасвирлангач, өйләнешүче кыз белән егеткә күчеп, аларның яхшы сыйфатлары мактала:

**Яшь булса да баш кына кызым минем, яр-яр,**
**Һәр белгәне күңелендә дана кызым, яр-яр,**
**Шикәрмедер, балмыдыр һәрбер сүзе, яр-яр,**
**Фәрештәдән зиядә холкы үзе, яр-яр...**
**Сөмбел кебек баглаган башындадыр, яр-яр,**
**Күшәгәнең эчендә хурлар бардыр, яр-яр...**

**Угыл-кызга туй кылмак морат имеш, яр-яр,**
**Һәрни барың сарыф итмәк морадыңдыр, яр-яр...**

(Дана — белемле; зияда — артык.)

Аннары яшь гаиләгә фәрзәндле, ягъни балалы булуның файдасы, шатлыгы хакында үгет-нәсихәтләр, изге теләкләр әйтелә:

**Угыл-кызсыз куймагай һич кемсәне, яр-яр,**
**Бу хәсрәттә куймагай һич кемсәне, яр-яр.**
**Адәм затның мивәсе фәрзәнд имеш, яр-яр,**
**Фәрзәндсезләр гамь белән пәйванд имеш, яр-яр...**
**Фәрзәнд дигән кешегә дәркяр икән, яр-яр,**
**Бу дөньяның зиннәте фәрзәнд икән, яр-яр...**

(Мивә — җимеш; пәйвәнд — бәйләнгән; дәркяр — кирәкле.)

Моннан соң җырчылар яшьләргә мәрхәмәтле, ярдәмчел булырга, гарип-гәрәбәләрне онытмаска киңәш игәләр:

**Гарибләрнең күңелене шад итәле, яр-яр,**
**Гарибләрне һәр заман яд итәле, яр-яр...**

Ниһаять, озатыла торган кызның күңеле сынык (шикәстә) икәнлеге искәртелеп, туган өеннән аерылучыга юату һәм изге теләк сүзләре әйтелә:

**Кыз угланлар дөньяда булыр күңеле шикәстә,—**
**Күңеле шикәстәләрне шад итәле, яр-яр.**
**Кыз угланлар күңлидә йөз-мең төрле әрман бар,**
**Сәр-пайлары бетмәсә, әрман булыр, яр-яр.**

(Күңеле шикәстә — күңеле сынык; әрман — теләк; сәр-пай — баш-аяк.)

Күп еллар дәвамында эзләнүдән соң мондый табышларга ирешү мине, әлбәттә, шактый кыюландырды. Шуңа күрә, мәсьәләнең төп өлеше һаман хәл кылынып бетмәсә дә, 1971 елны мин чираттагы гыйльми конференциягә татарча «Яр-яр»лар хакында бер доклад тәкъдим иттем. Нәтиҗә көткәннән дә артык булды: моңарчы «Яр-яр»га карата иң тискәре мөнәсәбәттә торучылар да мәсьәләнең «тәмам хәл ителгәнлеген», шуңа күрә татар фольклор белемендә «Яр-яр» йоласына тулы гражданлык хокукы бирергә кирәклекне икърар иттеләр. 1980 елда чыккан академик характердагы «Йола һәм уен җырлары» томында беренче мәртәбә «Яр-яр»ның биш варианты урнаштырылу факты исә әлеге хокук мәсьәләсенең практик гамәлгә ашуы нәтиҗәсе иде.

Әмма ләкин, әлеге докладны укыган чакта мин кайбер мөһим факторларны әле белеп җиткермәгән икәнмен. Мәсәлән, Альберт Фәтхинең Актаныш ягындагы Куҗәкә авылыннан 1969 елны ук алып кайткан бер дәфтәрендә «Яр-яр»ның тагы да сыйфатлырак, янә дә күркәмрәк татар версиясе бар булып чыкты.

Кульязманың гаять борынгылыгы да игътибарга лаек: ул Россиядә бары XVII йөзнең азагында һәм XVIII гасыр башында гына кулланылган Голландия кәгазеннән эшләнгән китап иде!

Дөрес, 69 юлдан гыйбарәт бу зур гына текстның кайбер кимчелекләре дә бар икән: мәсәлән, аның 40 нчы юлы бөтенләй төшеп калып, 46 һәм 47 юлларның икеөч сүзе танылмаслык дәрәҗәдә бозылган булып чыкты. Шулай да, төгәл сакланган 65 юлдан чыгып та, истәлекнең дөньяви йола фольклорыбызда тоткан урынын, сәнгатьчә әһәмиятен шактый төгәл билгеләргә мөмкин. Шуңа күрә кульязмада «Хикмәте хәким» дип аталган текст биредә төгәле белән күчерелә.

**Әүвәл алла атыны яд итәлем, яр-яр;**
**Пәйгамбәрләр рухыны шад итәлем, яр-яр.**

Боерыгын тотыңыз бер алланың, яр-яр;
Салаватын әйтеңез Мостафаның, яр-яр.

Һәр эшнең башы килгәй бисмиллаһи, яр-яр;
Туеңыз котлыг булгай, әйт «аллаһу», яр-яр.

Без һәм үлән башладык, үләндәшем, яр-яр;
Үлән әйтә килепмез, карендәшем, яр-яр.

Йөз генәсе ләгаль [тик], үләндәшем, яр-яр;
Күз генәсе гәүһәр тик, үләндәшем, яр-яр.

Буеңыз гөлме ирде, үләндәшем, яр-яр;
Сачыңыз сөнбелме ирде, үләндәшем, яр-яр.

Туйның үлән[ен] әйтәмез сез яр өчен, яр-яр;
Соңра никях итәләр, үләндәшем, яр-яр.

Хак тәгалә әмере коллар үз[р]ә, яр-яр;
Һәм Мостафа сөннәте анлар үз[р]ә, яр-яр.

Һәм бу ислам диненең зиннәтедер, яр-яр;
Мөҗәррәдлек бу диннең афәтедер, яр-яр.

Туйны төзек кылдылар сезләр өчен, яр-яр;
Нитәк ки баг төзделәр гөлзар өчен, яр-яр.

Хак мөбарәк әйләсен туеңызны, яр-яр;
Алтын-көмеш коршасын буеңыз[ны], яр-яр.

Сөләйманның тәхте тик тәхтең булсын, яр-яр;
Пәйгамбәрләр кызы тиң бәхтең булсын, яр-яр.

Йыглама, бикәм, йыглама, туең[ыз] будыр, яр-яр;
Алтын-көмеш коршаган буеңыз булыр, яр-яр.

Гүзәл, шәһир шәкелле мона егет, яр-яр;
Сезгә кияү хуш гакыйлле, дана егет, яр-яр.

Бәхетең монасыйб булды, — килде кияү, яр-яр;
Дәүләтең васлын йитәр булды кияү, яр-яр.

Нунга охшар кашларың пәйвәстәдер, яр-яр;
Кияү кызны күрмәккә һәвәстәдер яр-яр.

Ни бу галәм йөзендә кыз гөл ирмеш, яр-яр;
Кыз монасыйб егетләр былбыл ирмеш, яр-яр.

Атлас, кәмха тун кием ясандыңыз, яр-яр;
Ганбәр-йопар йызы дик йызландыңыз, яр-яр.

Галәматлек дөньяда кыз булдыңыз, яр-яр;
Егетләрнең фикере сез булдыңыз, яр-яр.

Кыз углан — йөзе кызыл — багның гөледер, яр-яр;
[. . . . . . . . . . . . . . . . . . . ].

Егет зәйн имешдер адәм ара, яр-яр;
Кыз углан хуш бизәнер галәм ара, яр-яр.
Җәннәт-фирдәвес, илла, гөле ирмеш, яр-яр;
Ганбәр-йопар йызы дик буе ирмеш, яр-яр.

**Чулпан яңлыг бадым дик күзләредер, яр-яр;**
**Ширин бал вә шикәр дик сүзләредер, яр-яр.**

**[.......] алсалар биш-ун көндер, яр-яр;**
**[.......] гомре озындыр, яр-яр.**

**Ахыр егет кыз углан элгусыдыр, яр-яр;**
**Баг гөле дик йөзләре сулгусыдыр, яр-яр.**

**Күгәреп күренәдер күлнең башы, яр-яр;**
**Каләмдик кыйылмышдыр ярның кашы, яр-яр.**

**Ун [биш] яшькә йитдисә кыз угланың, яр-яр;**
**Җөмлә галәм бәһасы ялгыз кашы, яр-яр.**

**Җөмлә сәчәкләр суладыр хәзан булса, яр-яр;**
**Кыз углан йөзе сула[р] дәүре узса, яр-яр.**

**Язын сәчәкләр ачылыр галәм бизәр, яр-яр;**
**Анасы кызы берлә күңлене тезәр, яр-яр.**

**Гъөндәҗин гөл очкандик кызы китәр, яр-яр;**
**Ялгызлык анасының бәгърен кисәр, яр-яр.**

**Нитәк ки атасы [дин] кызын сорармыш, яр-яр.**
**Ана берлә сүзләшеп йыглар имеш, яр-яр.**

**Ике күзе анасы гирьян имеш, яр-яр;**
**Кызы өчен атасы [солтан] имеш, яр-яр.**

**Кызы әйтүр анага бараем, анам, яр-яр;**
**Асрадың, хәләл ит, китәм, атам, яр-яр.**

**Өзәңегә аякым куйдым, атам, яр-яр;**
**Ак сөтеңне хәлал кыл, бардым, анам, яр-яр!**

(Ләгаль тик — ләгаль шикелле (кызыл төсле, асыл таш шикелле); нитәк — ничек; шәһир шәкелле — горур кыяфәтле; кәмха — атлас, парча; Үлән яки үләң — җыр; үзрә — өстендә; Мостафа сөннәте — пәйгамбәрнең кушканы; мөҗәррәдлек — ялгызлык; васлын йиту — очрашуга ирешү; нун — гарәпчә «н» хәрефе; пәйвәстә — тоташкан; йыз — ис; зәйн — зиннәт; яңлыг — төсле; бадым — бадам чикләвеге; хәзан булу — көз булу; гъөнҗә — чәчәк бөресе; гирьян — елаучы.)

Әгәр шушы конкрет җырны эзлекле рәвештә анализлап, аның форма һәм сыйфат үзенчәлекләрен, идея һәм максат эчтәлеген анықласак, шул рәвешчә ирешелгән нәтиҗәләргә алдарак китерелгән фактларны да кушып карасак, «Яр-яр» әйтү гадәтенең борынгы татар чынбарлыгында киң таралган йола икәнлеге тулысынча раслана. Димәк, безнең элекке «татарларда андый йола булмаган» дигән карашыбыз фактларны җитәрлек дәрәҗәдә белмәүнең (яисә белергә дә теләмәүнең) нәтиҗәсе икән. Бу — беренчедән.

Икенчедән, югарыда ясалган кыскача күзәтүгә караганда, «Яр-яр» әйтү йоласы элек безнең бабаларыбызда географик җәһәттән дә шактый киң таралган икән: җыр текстларының Иделнең һәр ике ягында да, Урал һәм Себер татарлары арасында да очравы шуны күрсәтә.

Чор мәсьәләсенә, ягъни җырның кайчан актив гамәлдә булып, кайсы дәвердә туй ритуалыннан төшеп калуына килсәк, монда мәсьәлә артык катлаулы түгел. XV йөздә яшәгән (1501 елны үлгән) бөек үзбәк шагыйре Галишир Нәваиның «Вәзеннәр үлчәве» («Мизан-ул-әвзан») исемле теоретик хезмәтенә караганда, халык шигыре үлчәмендә иҗат ителгән һәм гел «яр-яр» рефрены белән әйтелә торган «үләң» дигән туй

йоласы җыры шагыйрьгә мәгълүм төрки кавемнәр арасында киң таралган икән (1949 елгы Ташкент басмасы).

XVI йөздә иҗат итеп, классик төрки поэзиядәге гаруз вәзене (үлчәме) хакында махсус трактат язган күренекле шагыйрь һәм зур дәүләт эшлеклесе Заһиретдин Мөхәммәд Бабир да «Яр-яр» хакында якыннан хәбәрдар булган: «Төркиләр арасында,— дип яза ул,— бер җыру бар, аңа үләң диләр, аны күбесенчә туйларда әйтәләр, бу (бишенче) үлчәү шуңар хас. Җыруны шул үлчәүгә салып әйткәндә, һәр берьюллыктан соң яр-яр сүзен китерәләр» (1972 елгы Мәскәү басмасы, факсимиле буенча 147-а бит).

Димәк, югарыда күчерелгән татарча «Яр-яр» текстларының һәммәсе дә үлчәмвәзен, эчтәлек-форма җәһәтеннән, ниһаять, махсус рефрены буенча да Нәван белән Бабир биргән билгеләмәләргә тәмам туры килеп бетә икән. Бу хәл исә әлеге йола җырының бездәге актив кулланылыш чоры төрки-татар халыклары дәверенә, ягъни XIV—XVI йөзләргә карый дип нәтиҗә чыгарырга тулы мөмкинлек тудыра.

Югарыда конкрет каралган татарча вариантлардан Куҗәкә авылы дәфтәрендәге текстның хәзергә мәгълүм иң борынгы һәм иң сыйфатлы истәлек икәнлеге дә апачык күренеп тора. Соңгырак елларда табылган һәм сәнгатьчә кыйммәтләре буенча аның белән бәйгегә керә алырлык башка текстлар да бар әле; ләкин борынгылык колориты тулырак чагылу җәһәтеннән аларның берсе дә Куҗәкә версиясе белән ярыша алмый. Шуңа күрә югарыда тулы китерелгән җырны үзенең XVI гасырда кулланылышта булган протографларыннан (элгәрге нөсхәләреннән) әллә ни ерак китмәгән истәлек дип бәяли алабыз. Күчермәдәге кайбер архаик сүзләрнең язылышы бозыла төшүе дә әлеге версиянең XVII йөз ахыры — XVIII гасыр башы күчерүчесе өчен беркадәре искереп, аңлаешсызрак булып өлгерүенең нәтиҗәсе дип аңларга кирәк.

Һәрхәлдә, Куҗәкә дәфтәрендәге текстның табылуы бездәге «Яр-яр» мәсьәләсен чишүгә хәлиткеч өлешне кертте дип әйтсәк, берни арттыру булмас. Чөнки аның ярдәмендә без әлеге йола җырының элекке тормышыбыздагы урынын, махсус функциясен тәгәлрәк, әтрафлырак билгеләүдән тыш, аның йола фольклорыбыз кичергән үсү, үзгәрү процессындагы язмышын да тирәнрәк аңлый алабыз.

Татар туйларында «Яр-яр» әйтүнең кайчан, ни өчен һәм ничегрәк гамәлдән төшеп калуы, бары аерым төбәкләрдә генә зәгыйфьләнгән йола, архаик ритуал рәвешендә саклана алуы мәсьәләсенә килсәк, аны конкрет пунктларга бүлеп карарга кирәк.

Иң элек әлеге йоланың кайчан сүрелә, сүнә бару процессы башлануын алыйк. Бу процесс, минемчә, XVII—XVIII йөзләрнең чигендә үк үзен белдергәнгә охшый. Чөнки XVIII гасыр урталарындагы кайбер истәлекләрдә очраган «яңару» күренеше, әйтик, Пугачев явы чорында «әсир төшкән» дәфтәрдәге текст формасының үзгәртелү факты — махсус йола җыры рефренын «әй яр» ише гадәти өндәүгә әйләндерү тенденциясе — репертуарда киң таралган җыр текстына икенче йөкләмә бирелә башлауга ишарә итә. Моның шулай икәнлеген ачыграк аңлар өчен шушы бүлекчә башында китерелгән «әсир» дәфтәрдәге «ярәй» рефренлы дүрт строфага чак кына реконструкция ясау да артыгы белән җитә. Мәсәлән, андагы һәр строфаны:

> «Колһуаллаһ» сүрәнең башындадыр, яр-яр,
> Пәйгамбәрләр алланың кашындадыр, яр-яр,
> Пәйгамбәрнең бер кызын Гали алган, яр-яр,
> Туй-туйлап, үләң әйтмәк шуннан калган, яр-яр!

— дип, бары рефренын гына үзгәртеп укысак, элек нейтральрәк төс белән яңгыраган әлеге текстның Иске Казиле, Куҗәкә дәфтәрләрендәге чын йола җырларына тулысынча тәңгәл яңгыравын ишетербез.

XVIII йөздә үк традицион «яр-яр» рефренының әкренләп «ярәй» формасын ала башлавын, әлеге «әсир дәфтәрдән» тыш, Иске Йомралыда табылган дефектлы текст та ачык күрсәтә: «Минем алда йөземне күргел, егет, ярәй-яр»...

Җыр рәвеше үзгәрү тенденциясенең шул юнәлештәрәк баруын Иске Чүпрәледә табылган XVIII йөз ахыры дәфтәрендәге мөнаҗәт сыманрак бер текст та куәтли төшә:

Михнәт сүзен әйтәем, тыңлармысыз, ярәй,
Бу михнәтнең сүзләрен аңлармысыз, ярәй;

Дөнья тулы фәрештә Хакъ кашында, ярәй,
Һәрберсен бер эшкә Хакъ яраткан, ярәй...

Шушы текстны да югарыдагы үрнәк буенча реконструкцияләп карасак («ярәй» урынына «яр-яр» рефренын кулланып), тагын бер өстәмә мөһим фактка ия булабыз.

Шулай итеп, «яр-яр»ның әкренләп «ярәй»гә әверелүе, шул рәвешчә чын йола репертуарыннан лирик (шаян яисә моңсу) җыр барлыкка килү факты аның гамәлдән механик рәвештә генә төшеп калмавын, ә билгеле бер эчке закончалык нигезендә эволюция кичереп үзгәрүен күрсәтә. Бу күренеш исә фольклор текстологиясе дигән махсус белемнең гаҗәп катлаулы, нечкә, бер үк вакытта бик тә өметле яңа юнәлеш икәнлеген расласа кирәк.

Әлбәттә, традицион «Яр-яр» әйтүнең бетүе, юкка чыгуы бер «ярәй» күчеше белән генә тәмам аңлатылып җитмәгән кебек, ул йоланың гамәлдән төшү процессы да тиз генә, җиңел генә булмаган. Татарлар яшәгән кайбер аерым төбәкләрдә «яр-яр» әйтеп кыз озату гадәте (Түбән һәм Бараба якларындагы кебек үк) безнең гасыр башына кадәр дә дәвам иткән икән. Мәсәлән, Уфада яшәүче татар фольклоры белгече Риф Мөхәммәтҗановның зур тырышлыгы нәтиҗәсендә Ык буе татарлары арасында җыелган әһәмиятле материалларга караганда, ул якларда озатыла торган кызга туй киеме киендергән, аның чәчләрен тараган чакта «яр-яр» такмагын әйтү гадәте безнең заманнарга кадәр килеп җиткән икән. Бу фактлар исә туйларда «яр-яр» әйтүнең кайчандыр яшәгән, аннары бөтенләй юкка чыккан, «эзе дә үчкән» искелек кенә түгел, бәлки күпкә катлаулы күренеш, шактый озын гомерле милли йола, димәк, фольклорыбызда, этнографиябездә өйрәнелергә, яктыртылырга тиешле мөһим тарих күренеше икәнлеген раслый. Бернинди йоланың да үзгәрмичә яши алмавын, бик күп гореф-гадәтләрнең алмашынып, яңарып торуын һәм мондый процессның тарихи объектив, хәтта зарури икәнлеген онытмасак, әлеге нәтиҗәнең дәреслеге тагы да куәтләнә төшә. Шул ук вакытта Р. Мөхәммәтҗанов ирешкән табышның икенче гыйбрәтле әһәмияте дә бар: фольклорыбызның борынгы йола катламнарына үтеп керер өчен кечкенә төбәкләрдә төпченеп эшләү, эзләнүне комплекслы рәвештә башкару зарур икән (карагыз: Р. Мөхәммәтҗанов. Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты. Уфа, 1977).

Безнең туйларда «яр-яр» әйтүнең ни өчен пассивлашуы, тора-бара кайбер төбәкләрдә бөтенләй юкка чыгуы мәсьәләсенә килсәк, монда да чишелмәслек әллә нинди зур серләр юк. Ул йоланың актив хәрәкәттән төшүе, бер сүз белән әйткәндә, әлеге чорларда тормышыбызда йөз биргән гомум социаль-идеологик үзгәрүләргә— мәгълүм иҗтимагый артка китүгә барып тоташа.

Социаль үзгәрүне телгә алган чакта мин иң элек XVII—XVIII йөзләрдә татар җәмгыятендә югары катламнарның, ягъни феодалларның оешкан сыйныф буларак тәмам таркалуын, экономик яктан да бик нык зәгыйфьләнүен күздә тотам (моның очраклы хәл түгел, ә закончалыклы сыйнфый көрәш нәтиҗәсе икәнлеге хакында югарыда бер тапкыр әйтелгән иде инде). Шул рәвешчә җәмгыять эчендәге хәлле катламнарның сыйфат ягыннан да кайтышлануы, сан буенча да күзгә күренеп кимүе нәтиҗәсендә зур туйларда башкарыла торган тантаналы «яр-яр» әйтү йоласының да әһәмияте кимегән. Чөнки башкаруда билгеле бер эзлеклелек, конкрет ситуациягә мөнәсәбәттә тиешле оперативлык таләп итә торган әлеге җырны кем теләсә шул башкармаган, ә тәҗрибәле җыручылар-уләңчеләр, үзенә күрә «профессиональ» яр-ярчылар әйткән. Җыр текстының шактый тотрыклы вариантлары кәгазьгә махсус теркәлү фактлары (алар югарыда китерелгән мисаллар белән генә чикләнми) «Яр-

яр»ның билгеле бер дәрәҗәдә кодификацияләнү процессы кичерүен, ягъни нормага салынуын күрсәтә. Бу исә «яр-яр» такмакларының асылда хәлле кешеләрнең туйларында башкарылуына ишарә ясый. Димәк, XVII һәм XVIII йөзләрдә, татар феодалларының саннары да кимеп, сыйфатлары да кайтышланган дәвердә, «яр-яр» такмагын башкарулар да елдан-ел азая барган.

Шул ук вакытта дөньяви феодалларның позицияләре какшап, алар урынына рухани феодаллар үрмәләү, җәмгыятьтә аларның тәэсире елдан-ел ныгу, көчәю, үлем-җитем, туй-тумалак кебек мөһим көнкүреш актларының башкару процессында саф дин ритуалларының өлеше артуга китергән. Шушы процесс чыгышы буенча асылда борынгы инануларга барып тоташкан, соңрак кына тыштан бераз «мөселманлашкан» (бары алла исемен атау, пәйгамбәрне олылау кебек формаль детальләр өстәлгән) «яр-яр» әйтү йоласының элек икенче планга күчүен, аннары ныграк кысрыклануын, шул рәвешчә тора-бара гамәлдән бөтенләй диярлек төшүен тәэмин иткән.

Борынгырак теркәлгән версияләрдә уй-хыялның, яшьләргә багышланган теләкләрнең гомуми характерда булуы, җырның исә киң җәмәгатьчелек каршында башкарылуы, соңрак дәвер текстларында хосусый ритуал мотивлары көчәюе дә шул ук гомум процессның, зур иҗтимагый үзгәрешләрнең нәтиҗәсе иде.

Димәк, йола фольклоры репертуарының үзгәрүе, яңаруы ул очраклылык яисә субъектив, тар милли (этник), психологик факторларның гына түгел, бәлки киң пландагы социаль-иҗтимагый һәм идеологик үзгәрүләрнең дә конкрет нәтиҗәсе икән. Шушы хосусыять йола фольклоры табигатендә сыйнфыйлык һәм иҗтимагыятьнең ныграк чагылуын раслый. Шуңа күрә теге яки бу әсәрнең бездә «булу» яисә «булмау» мәсьәләсенә кагылганда, ул мәсьәләгә тар кабиләчелек позициясеннән чыгып түгел, ә киң тарихи, иҗтимагый планда карарга кирәк икән.

Шулай итеп, шәкерт дәфтәрләрен җентекләп өйрәнү нәтиҗәсендә без халык иҗаты фондыбызның гаять катлаулы бер өлкәсендәге — йола фольклоры репертуарындагы мөһим тарихи фактларны ачыклау, ул фактларның үсү, үзгәрү үзенчәлекләрен дә беркадәре күзәтү, закончалыкларын билгеләү мөмкинлегенә ирештек.

Йомгаклап шуны гына әйтергә кирәк: фольклорыбыз текстологиясенең киләчәген кульъязма мирасыбыздан, шәкерт дәфтәрләреннән башка күз алдына китерүе мөмкин түгел. Бигрәк тә элгәрге чор истәлекләрен барлау, тәгаенләү юлында без аларның хәзинәсенә ешрак мөрәҗәгать итәргә, кайчан нинди репертуар актив яшәвен ачыклаган чакта да аларның документаль хөкемен зур игътибар белән тыңларга тиешбез.

# «ЯШЬ ЛЕНИНЧЫ» ҺӘМ «ЯЛКЫН» БЕЗДӘ КУНАКТА

Мин, «Яшь ленинчы» газетасы, 1924 елның 10 октябрендә, Казан шәһәрендә туганмын. Гомеремнең беренче көннәреннән үк Татарстан пионериясе белән, гомумән, Коммунистлар партиясе эше өчен көрәшкә әзер торган барлык татар балалары белән бер сафта атлыйм. Аларның шатлыклары һәм борчулары, эшләре, омтылышлары һәм хыяллары белән яшим.

Егерменче елларда пионерлар ярдәме белән мин ятим калган балаларның күңелләрен җылыттым, укый белмәгән кешеләрне укырга өйрәттем, кулаклар белән көрәштем, колхозлар төзештем.

Мәктәптә, колхоз кырларында, походларда һәм пионер сборларында мин һәрвакыт ал галстуклы балалар белән бергә булдым. Учак янында без җырлар җырладык, җиңүләребез өчен шатландык.

...Сугыш елларын һич онытасым юк. Ул чагында мин әлеге рәвешемдә яши алмадым. Канлы көрәш елларында мин яшь ленинчыларның күңелләрендә булдым, пионер стена газеталары булып яшәдем.

Малайлар ул чагында әтиләре урынына станоклар артына бастылар, авылда малайлар да, кызлар да колхозда эшләделәр: утын кистеләр, печән чаптылар, ашлык ташыдылар. Мин рухым белән гел алар янында идем.

1961 елда яңадан сугышка кадәрге хәлемә — әлеге хәлемә кайттым. Үземнең укучыларым — татар пионерлары белән иңгә-иң торып, дөньядагы иң гүзәл җәмгыять — коммунизм төзүдә катнашам.

Биографиям Татарстан пионериясенең 60 еллык биографиясеннән аерылгысыз. Минем тормышым, пионер оешмасының тормышы кебек үк, елдан-ел яңара, рухи яктан байый бара. Киләчәктә дә укучыларым белән без «Эндәш» клубының утырышларына катнашып, отряд, дружина эшләре турында сөйләшербез, ярышларда ничек җиңәргә икәненә өйрәнербез, бәхәсләр алып барырбыз. Ильичның көрәштәшләре белән, коммунизмны якынайтучы кешеләр белән танышырбыз, «Алар Ильичка ант иттеләр», «Туган ягым — яшел бишек», «СССР — минем Ватаным» дигән операцияләрдә катнашырбыз. «Сакчыллар походы»на чыгарбыз, фермада эшләүчеләргә булышырбыз.

Туган телебезнең гүзәллеге, бетмәс-төкәнмәс серләре турында сөйләшербез. Ул әңгәмәләрне без «Әткәм-әнкәмнең теле» дип исемләрбез. Яшь сәләтләр өчен оештырылган Абдулла Алиш исемендәге әдәби берләшмәдә чыгышлар ясарбыз. Язучыларның яңа әсәрләре, чит ил пионерларының тормышы белән танышулар, төрле конкурсларда, сәяхәтләрдә катнашулар — менә безне нәрсәләр көтә...

Әгәр без «Яшь ленинчы»ның үзенә сүз бирә калсак, ул менә шушыларны сөйләр иде. Ә ни өчен «иде»? Сөйләр ул аларны, һичшиксез сөйләр! Сиңа да, миңа да, барыбызга да сөйләр. Сөйләшер! Ә сөйләшер өчен ул турыдан-туры синең өеңә килергә тиеш!

**САИМӘ ИБРАҺИМОВА,**
«Яшь ленинчы» газетасының җаваплы секретаре,
ТАССРның атказанган культура работнигы.

**«Яшь ленинчы» газетасы Бөтенсоюз каталогына кертелгән. Индексы — 54124.**

*Абдулла Алиш исемендәге республика әдәби берләшмәсе членнарына сүз бирәбез.*

## Минем нәни көчегем

Минем нәни көчегем бар —
Койрыгы шундый кыска,
Башы — кара, тәпие — ак,
Ипле дә ул, тупас та...

Әгәр дә шундый көчекнең
Исеме ничек дисәгез —

Тәпиләре ак булганга
«Актырнак!»— дип дәшәбез.

«Йөгер!» дисәм — уттай чаба,
«Утыр!»— дисәм — утыра.
Шундый да акыллы маэмай
Бу дөньяда юктыр ла!..

**ВЕНЕРА МӘГЪДӘНОВА,**
Мөслим районы Яңа Сәет мәктәбенең
VII класс укучысы.

## Болын

Алсу таңнар, яшел болын —
Җиләкнең туган йорты,
Ераклардан очып килгән
Аны эзләп бал корты.

**РАФАКЪ ГАЗИЗОВ,**
Актаныш районы Пучы мәктәбенең
V класс укучысы.

## Сагынам

Их, иң-иң якын дусларым
Илдар һәм Илдус иде.
Алар безнең күрше өйгә
Ерактан күчеп килде.

Өч кенә ел тордылар да
Күчтеләр Мамадышка.

Алар белән чана шуып
Булмый инде бу кышта.

Бәйрәм саен,
кайтырлар, дип,
Мин гел аларны көтәм.
Бик нык көткәнгә аларны
Сагынып арып бетәм.

**НӘФИСӘ ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА,**
Әлмәт районы Елховой урта
мәктәбе укучысы.

## Аш кайчан тәмле була?
хикәя

Кичке аш вакыты. Зәйтүнә, әнисе һәм әтисе өчәүләшеп өстәл тирәли утырыштылар. «Син әле кечкенә»,— дип, кызга әнисе ашны сай гына тәлинкәгә салып бирде. Өйгә таралган тәмле исе күптән борынын кытыклап торса да, Зәйтүнә ашын ашап бетерә алмады. Бер бүген генә түгел, һәркөн шулай.

Иртәгесен әнисе кызын иртәрәк уяткан иде. Башка вакытта өйдәге эшләрне үзе генә эшли иде ул. Ә бүген Зәйтүнә белән икәүләп эшләделәр: өйләрне җыештырып чыктылар, табак-савытны юдылар, гөлләргә су сиптеләр. Әллә инде Зәйтүнә булышканга, өй чип-чиста, яп-якты булып калды.

Бераздан ишегалдына чыктылар. Кар көрәделәр, мал-туарны карадылар, күп итеп су ташыдылар. Зәйтүнә коега кечкенә чиләкләрен күтәреп барды.

Алар төшке ашка утырыштылар. Әнисе әтисе белән кызына карап бер елмайды да, өчесенә дә бертигез итеп аш бүлде. Башка вакыт булса, Зәйтүнә ашның күплегенә игътибар иткән булыр иде. Тик бүген ул бернигә карамыйча ашарга кереште.

Менә ул тәлинкәне ялт иттереп куйды. һәм әнисенә карап:

— Рәхмәт, әнием, ашны шундый да тәмле итеп пешергәнсең,— диде.

**ФИЛИЗӘ СӘЛӘХОВА,**
Актаныш районы Кужәкә урта мәктәбе укучысы.

# БАЛАЧАКНЫҢ КАДЕРЛЕ БҮЛӘГЕ

Бүгенге көндә илебездә балалар өчен 49 журнал һәм 24 газета чыгарыла. Төрле төсләр, рәсемнәр белән бизәлеп чыккан бу журналлар зур чәчәк бәйләмен хәтерләтәләр. «Ялкын» — шул чәчәк бәйләменең үзәгендә. Чөнки ул илебездә иң өлкән журналларның берсе. Үзәк «Пионер» журналы белән бер үк вакытта, киләсе елның мартында, «Ялкын» журналы чыга башлауга 60 ел тула.

«Ялкын» — пионер журналы.

Республикабыз пионерлары, яшь ленинчыларның Бөтенсоюз Маршына кушылып, үзләренең Тантаналы вәгъдәгә, пионер Законнарына тугрылыкларын исбат итәләр. Ленин васыять иткәнчә, Коммунистлар партиясе өйрәткәнчә яшиләр, укыйлар һәм көрәшәләр.

«Ялкын» — әдәби-нәфис журнал. Язучыларның балаларга атап язган иң яхшы хикәя-повестьлары, шигырьләре, китап булып чыкканчы, башта «Ялкын» битләрендә дөнья күрә. Соңгы елларда журнал үз укучыларын Мәхмүт Хәсәновның «Шайтан малае», Әхсән Баянның «Җыр дәвам итә», Нәби Дәүлинең «Агат» повестьлары белән куандырды.

Журналның һәр санын шагыйрьләрнең балаларга аталган шигырь тәлгәшләре бизи. Нәкый Исәнбәт, Нури Арсланов, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Роберт Миңнуллин, Разил Вәлиев шигырьләрен нәни укучылар аеруча яратты.

Журнал тышлыгының өченче бите — әкият дөньясы. Бу әкиятләрдә җир йөзендәге халыкларның гасырлар буе тупланган тапкырлыгы, акылы, тәҗрибәсе, дөньяны танып-белүе тупланган. Рәссам Т. Хаҗиәхмәтов тарафыннан матур итеп бизәлгән бу әкиятләрне сабыйлар көтеп ала. Әкиятләрдән алар үзләренә «акыл туплыйлар», үгет-нәсихәт алалар, яхшыны начардан аерырга өйрәнәләр.

Журналның бөтен игътибары яшь буында Ватанга мәхәббәт, хезмәтне ярату, ата-анага ихтирам, олыны — олы, кечене — кече итә белү, әдәплелек, итагатьлелек тәрбияләүгә юнәлгән. Рубрикаларны санап чыгу гына да «Ялкын» күтәргән проблемаларны күзалларга мөмкинлек бирә: «Минем язмышымда пионер оешмасы», «Алар безнең сафта», «Кызыл йолдыз», «Ак күгәрчен», «Сакчыллар посты», «Әдәплеләр клубы», «Кызыл китап», «Кырык тартма», «Пионер отрядында — китап» һ. б.

«Ялкын» сәхифәләрендә балалар иҗатына да киң урын бирелә. «Чаткы конкурсы», «Тимур штабы», «Пионер почтасы» — болары балаларның үзләренең иҗаты.

«Чаткы конкурсы» журналда егерме елдан артык дәвам итә. Бу конкурска яшь

иҗатчылар үзләренең хикәяләре, әкиятләре, шигырьләре, җырлары, рәсемнәре белән катнашалар. Конкурска һәр ел азагында йомгак ясала.

Һәр елны журналның июнь санын тулысынча диярлек балалар иҗатына багышлау традициягә әйләнде.

«Ялкын» журналын укып үскән егетләребез Магниткалар төзеделәр. Бөек Ватан сугышында һәм сугыштан соңгы чорда тиңдәшсез батырлык үрнәкләре күрсәттеләр. Безнең көннәрдә «Ялкын» журналының элекке укучылары КамАЗлар, атом электростанцияләре төзиләр, мул иген үстерәләр — республикабыз данын югары тоталар. Аларга алмашка бүгенге пионерлар үсә.

«Ялкын»— балачакның кадерле бүләге ул. Бер генә бала да бу бүләктән мәхрүм калмасын иде.

**РОЗА ХАФИЗОВА,**
«Ялкын» журналының баш редакторы,
РСФСРның һәм ТАССРның атказанган
культура работнигы.

**«Ялкын» журналы Бөтенсоюз каталогына кертелгән. Индексы — 73582.**

*«Чаткы конкурсы»на катнашкан яшь иҗатчылар сүз ала.*

## Кырмыска малае

әкият

Бер кырмыска малаеның дәү буласы бик килә икән.

— Әни!— ди ул.— Нигә мин бик кечкенә?

— Үсәсең бар әле, нәнием,— ди әнисе.

Ал эшләпәле юантык гөмбә янына бастыра да улының буен үлчи, баш өсте турысына кирт ясап куя.

— Буең менә ничаклы, нәнием. Күпме үскәнеңне белү өчен шушында килеп үлчәнерсең,— ди.

Икенче көнне иртә таңнан кырмыска малае гөмбә янына йөгерә. Килеп тә җитә, үлчәнергә дә баса. Караса, кичәге кирт әллә кайда өстә, ди. Аптырый малай. Төн үткәнче гөмбәнең шулай нык үскәнлеген аңларга башы җитми аның. Уйлый-уйлый да:

— Әни, кара әле, никадәр үскәнмен!— дип шатлана.

**НУРАНИЯ КАШАПОВА,**
Актаныш районы Зәбәер сигезьеллык
мәктәбенең 5 нче класс укучысы.

## Куян — фотограф

әкият

Бүренең фотоаппарат сатып алуы турындагы хәбәр урманга бик тиз таралган. Җәнлекләрне фотога төшерә, ди.

Һәркайсы бүре янына ашыккан.

Үзенең елмаеп төшкән рәсемен куян бик ошаткан. «Нигә әле миңа да шулай эшләмәскә?»— дип уйланган ул. Киткән ди кибеткә. Ләкин фотоаппаратның ничек аталуын белми икән. Шулай да сатучыга аңлаткан:

— Миңа «тек» итә торган әйберне бир әле!— дигән.

Сатучы: «Ни сорый икән соң бу?»— дип уйлап-уйлап торган да моңарга мылтык китереп тоттырган. Мылтыкны җилкәсенә салып киткән ди куян урманга. Юлында төлке очраган.

— Төлке апай, әйдә, фотога төшерәм үзеңне. Әнә теге каен төбенә бас,— дигән аңа озын колак.

Төлкебикә шатланып риза булган. Төзәтенеп, бизәнеп үзен фотога төшерүне көтә башлаган.

— Елмай, төлке апай, елмай,— ди икән куян, «фотоаппаратын» тегеңә төзәп.

Урманны гөрселдәтеп мылтык тавышы яңгыраган.

Бераз вакыттан соң гына һушына килгән куян. Торып утырган. Колагы шаулый, ди. Тирә-юньдә мылтык тәтене икән.

— Иртәгә рәсемеңне алырга кил, төлке апай,— ди икән үзе, тәтенне куа-куа.

Тик төлке аны ишетмәгән. Чатанлый-чатанлый урманга таба җилдергән генә, ди.

САНИЯ ХӘБИБУЛЛИНА,
Башкортстандагы Краснокама районы Яңа Хаҗи
сигезьеллык мәктәбенең 5 нче класс укучысы.

## Алтын күз

Тик кояшның гүя гамендә юк,
Күрми дә ул гүя күз барын —
Алтын көянтәсен күтәргән дә
Менә һаман, менә югары.
Чайпалыпмы китә чиләкләре —
Алтын суы җиргә түгелә.
Әрәмәле күлләр, авылыбыз —
Барча дөнья нурга күмелә.

РӘФИЗӘ ХӘЙБУЛЛИНА,
Әлки районы Иске Салман сигезьеллык
мәктәбе укучысы.

## «Батыр» аучы

Менә эзе куянның,
Артыннан барам аның.
Хәйләкәр икән куян —
Эзен чуалтып куйган.

Көтмәгәндә сикереп
Каршыма чыкты куян.
Шул куянны күргәч,
Егылганмын куркудан.

Атмады агач мылтык,
Атыйм дигәч куянны.
Торып чаптым артыннан,
Барыбер тоттырмады...

Әйдә, ярар, шул куян
Тоттырмаган ачудан,
Ял көне генә җитсен —
Бүре ауларга чыгам!

**САЛИХ АЛИМОВ,**
Горький өлкәсендәге Кызыл Октябрь районы
Зур Рбишча урта мәктәбенең 8 нче класс укучысы.

## Йолдыз сөйли

Йолдызлар ява ак кар өстенә,
Җемелдәп куна безнең иңнәргә.
Берсе пышылдый:
— Күтәрелик,— ди,
Могҗиза тулы күкне иңләргә!

Каушап калдым мин. Йолдыз сөйлиме?!
Әйдә, бергәләп меник, дидеме?
— Йолдызым минем, серенне әйтче!
Җирне калдырып, күкне сөйдеңме?

Сөйдем күгемне, сөйдем җиремне!
Ике дөньяны сөю җиңелме?
Сөюем мине тоташ нур итте,
Яктымны мәңге сүнмәс зур итте.

**ВЕНЕРА СӘЛӘХОВА,**
Чүпрәле районы Иске Кәкерле урта
мәктәбе укучысы.

# *Каләмдәшләребез — СССР Язучылар союзының яңа әгъзалары*



## Нурия Измайлова

Нурия Халит кызы Измайлова 1950 елның 1 январенда Башкортстанның Благовар районының Кучәрбай авылында туган. Шаран районының Базгыя мәктәбен, 1971 елда Казанда В. И. Ульянов-Ленин исемендәге дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. Үзбәкстанда — укытучы, Уфада һәм Мәскәүдә китап нәшриятларында редактор булып эшли. Беренче шигырьләре «Кызлар жыры» (1977) исемле коллектив җыентыкта басыла. 1981 елда шагыйрәнең «Яратам» исемле шигырьләр китабы дөнья күрде.



## Җәүдәт Дәрзаман

Җәүдәт Дәрзаман (Җәүдәт Харис улы Дәрзаманов) 1945 елның 13 октябрендә Татарстан АССРның Лениногорск районы Сугышлы авылында колхозчы-крестьян гаиләсендә туган. 1972 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. 1971 елдан бирле Татарстан радиосында редактор булып эшли. 1979 елдан КПСС члены.

Шагыйрьнең татар һәм рус телләрендә балалар өчен «Ирбатыр» (1975), «Солдат булдым» (1977), «Төнге маҗара» (1980) һәм «Гөлназ мәктәпкә бара» (1983) исемле әкият, шигырь китаплары басылып чыкты.



## Тәүфикъ Әйди

Тәүфикъ Рамазан улы Әйди (Әйделдинов) 1941 елның 1 маенда Мәскәү өлкәсенең Шатура районы Туголевский Бор поселогында сезонлы эшче гаиләсендә туа, Татарстанның Апас районы Түбән Балтай авылында үсә. 1957 елда Урта Балтай урта мәктәбендә 7 классны бетергәннән соң, Алабуга китапханә техникумын (1960) һәм Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген (1973) тәмамлый.

Китапханәче, аппаратчы, бригадир, укытучы, методист һ. б. һөнәрләр үзләштереп, төрле оешмаларда эшли. Матбугатта, башлап, хикәяләре һәм очерклары күренә, 1978 елда «Божра» повесте, 1983 елда очерклары («Кайда да кадерле») аерым китап булып басылып чыга.

### ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

26 июльдә Татарстан язучыларының ачык партия җыелышында КПСС Үзәк Комитетының июнь (1983 ел) Пленумы йомгаклары, КПСС ҮК Генеральный секретаре иптәш Андропов Ю. В. речe һәм пленумда кабул ителгән карар яктылыгында партия оешмасы алдында торган бурычлар турында җитди сөйләшү булды.

Доклад белән партия оешмасы секретаре Ринат Мөхәммәдиев чыкты. Доклад буенча фикер алышуда, Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов, язучылар С. Хәким, Р. Кәрами, Р. Гатауллин, Н. Дәүли һ. б. катнашты.

Югары күтәренкелек белән узган бу җыелышта татар совет әдәбияты алдында торган яңа, принципиаль мәсьәләләр кузгатылды.

### КҮЧМӘ УТЫРЫШ

Казанда РСФСР Язучылар союзының әдәби тәрҗемә буенча советы һәм «Современник» нәшриятының күчмә утырышы булып узды. Бирегә «Современник» нәшриятында Идел белән Урал арасындагы автономияле республикаларның әдәби әсәрләрен бастырып чыгару мәсьәләсе каралды.

Утырышны РСФСРның нәшрият эшләре буенча Дәүләт комитеты коллегиясе члены, «Современник» нәшрияты директоры Г. М. Гусев ачты. Утырыш эшендә Мәскәүдән һәм автономияле республикалардан килгән нәшрият хезмәткәрләре, язучылар һәм әдәбият тәнкыйтьчеләре катнашты.

«Современник» нәшриятының РСФСР халыклары әдәбияты редакциясенең бүлек мөдире В. В. Дементьев докладын тыңладылар. Аннары СССР һәм РСФСР Язучылар союзы идарәләре секретаре, Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Г. А. Ахунов чыгыш ясады.

Фикер алышуларда «Литературная Россия» газетасы редколлегиясе члены М. Н. Ломунова, РСФСР Язучылар союзы идарәсе члены, Мари АССР Язучылар союзы идарәсе председателе В. С. Столяров, Удмуртия АССР Язучылар союзының рус секциясе һәм тәнкыйтьчеләр секциясе председателе З. А. Богомолова, мордва язучысы К. Г. Абрамов, Татарстан Язучылар союзы партия оешмасы секретаре, тәнкыйтьче Р. С. Мөхәммәдиев, Брежнев шәһәре язучылар оешмасының җаваплы секретаре Р. И. Вәлиев, «Современник» нәшриятының РСФСР халыклары әдәбияты редакциясенең бүлек мөдире урынбасары Е. И. Корнеева, язучы Н. Х. Дәүли һәм тәнкыйтьче Р. Ә. Мостафин катнашты.

Утырышта катнашучыларны КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев кабул итте.

Кунаклар Татарстан башкаласының Ленинга бәйле истәлекле урыннарында булдылар, М. Җәлилнең музей-квартирасын карадылар, Х. Ямашев исемендәге Татарстан мех производство берләшмәсе эшчеләре, Балык бистәсе районы хезмәтчәннәре, Татарстан китап нәшрияты һәм «Казан утлары» журналы редакциясе коллективлары, галимнәр белән очраштылар, Актерлар йортында уздырылган әдәби кичәдә катнаштылар, Казан сабантуен карадылар.

Күчмә утырыш эшендә КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.

### ҖӘЙГЕ ГАСТРОЛЬЛӘР

*
* *

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының илебез башкаласы Мәскәүдә сугыштан соңгы чорда гына да инде алтынчы мәртәбә чыгыш ясавы иде бу. Ул чын мәгънәсендә театр һәм башкала тамашачылары өчен олы бәйрәмгә әверелде. Бу юлы гастрольләр өчен атаклы МХАТ сәхнәсе бирелү менә шушы олы ихтирамның матур чагылышы булып тора.

Гастрольләрне ачу тантанасында СССР культура министрының беренче урынбасары Ю. Я. Барабаш, РСФСР культура министры Ю. С. Мелентьев, КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, ТАССР культура министры И. Н. Алиев катнашты.

Иҗат отчеты программасына театр репертуарындагы иң яхшы үрнәкләр кертелде. Гастрольләр «Монда тудык, монда үстек» исемле спектакль белән ачылды. Билгеле булганча, әлеге спектакль «Драматургиядә һәм театрда бүгенге заман эшчесе образы» дигән девиз астында үткәрелгән Бөтенроссия смотрында күрсәтелде һәм диплом белән премиягә лаек булды. Ә драматург Туфан Миңнуллинга шушы пьесасы өчен махсус диплом бирелде.

Мәскәүлеләргә Т. Миңнуллинның тагын ике әсәре «Әлдермештән Әлмәндәр» һәм «Моңлы бер җыр» исемле пьесалары буенча куелган спектакльләр тәкъдим ителде. Әлеге спектакльләрнең беренчесе РСФСРның К. С. Станиславский исемендәге премиясенә лаек булды, икенчесе Бөтенсоюз театр сәнгате фестивалендә лауреат исемен алды.

Болардан тыш, милли классика үрнәкләреннән «Качаклар» (Н. Исәнбәт) һәм «Казан өлгесе» (К. Тинчурин) спектакль-

ләре күрсәтелде. Ә рус классикасыннан тамашачыга «Бирнәсез кыз» (А. Островский) һәм «Ябырылу» (Л. Леонов) спектакльләре тәкъдим ителде.

Гастрольләр башлану алдыннан РСФСР Культура министрлыгы залында матбугат конференциясе үткәрелде. Иҗат отчеты барышында хезмәт коллективларында очрашулар оештырылды.

Гастрольләр программасында совет драматургиясенең классик әсәрләреннән берсе — Ленин һәм СССР Дәүләт премияләре лауреаты, Социалистик Хезмәт Герое Леонид Леоновның «Ябырылу» пьесасы буенча куелган спектакль дә бар. Гастрольләр барышында театр коллективы вәкилләре әдипнең Переделкинодагы дачасында күренекле язучы янында кунакта булдылар.

Күренекле совет язучысы Л. Леоновның «Ябырылу» дигән әсәре буенча театрның баш режиссеры М. Сәлимҗанов куйган спектакль труппа өчен аеруча җитди имтиханга әверелде. Бу кичтә театрда автор үзе дә булды. Ул камаллыларның эшен бик яратып карады, режиссер һәм артистларны чын күңелдән котлады, аларга зур рәхмәтен белдерде.

Спектакльдән соң язучыны сәхнәгә чакырдылар, аңа чәчәк бәйләмнәре тапшырдылар.

Илебез башкаласындагы бу иҗат отчеты зур уңыш белән узды.

*
* *

Татар дәүләт драма һәм комедия театры 11 июльдән 5 августка кадәр Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында үзенең 50 еллыгына багышланган иҗат отчеты уздырды.

## РӘСЕМНӘРДӘ — А. М. ГОРЬКИЙ

17—18 майда А. М. Горький музеенда бөек язучы фоторәсемнәренең төп нөсхәләреннән күргәзмә ачылды. Ул Халыкара музейлар көненә багышланды.

Музей фондларында кадерләп саклана торган бу фоторәсемнәрнең күбесе беренче тапкыр күрсәтелә. Заманында аны шәһәргә язучының хатыны — Екатерина Павловна Пешкова бүләк иткән иде.

Рәсемнәр язучы тормышының төрле чорлары — Петербургта, Италиядә булуы белән бәйле. Алар арасында профессионаллар да, һәвәскәрләр төшергән рәсемнәр дә бар.

## ШАГЫЙРЬНЕ ХӨРМӘТЛӘҮ КИЧӘСЕ

23 майда Казанның Төзүчеләр сараенда өлкән әдип, Бөек Ватан сугышы һәм хезмәт ветераны, коммунист шагыйрь Мөхәммәт Садрига 70 яшь тулуга багышланган кичә уздырылды. Әдипнең тормыш һәм иҗат юлы турында шагыйрь Рәдиф Гатауллин сөйләде. Соңыннан Татарстан сәнгать осталары башкаруында М. Садри әсәрләреннән торган зур әдәби-музыкаль кичә булды.

## КҮРЕНЕКЛЕ МӘГЪРИФӘТЧЕГӘ БАГЫШЛАП

7 июньдә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының әдәбият, сәнгать, иҗтимагый фикер тарихы секторларының берләштерелгән гыйльми утырышы булды. Анда журналист, нәшир һәм җырчы Камил Мотыйгыйның тормышы һәм иҗаты турында докладлар белән тарих фәннәре докторы Н. Г. Юзиев чыкты. Фикер алышуларда галимнәрдән М. Нигъмәтҗанов, Я. Абдуллин һ. б. чыгыш ясады.

## ӘЛМӘТ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

10—22 майда, Пицундада Май Пленумының еллыгына багышлап, яшь язучыларның Бөтенсоюз семинар-киңәшмәсе булып узды. Семинар утырышында яшь әдипләр Мәскәүдә «Яшь гвардия» нәшриятында басылып чыгачак әдәби-документаль әсәрләрне тикшерделәр. Татарстаннан бу семинар-киңәшмәдә Әлмәт язучылар оешмасының җаваплы секретаре Әхәт Гаффар катнашты һәм Татарстан авылларының хәзерге проблемалары турында чыгыш ясады.

*
* *

Брежнев язучылар союзы оешмасының чираттагы утырышында КПСС Үзәк Комитетының июнь (1983 ел) Пленумы йомгаклары яктылыгында алда торган бурычлар хакында эшлекле сөйләшү булды. Доклад белән оешманың җаваплы секретаре Разил Вәлиев чыкты. Фикер алышуда Э. Касыймов, Х. Хөснуллин, Г. Кашапов, Р. Хисмәтуллин, Р. Бәшәр һ. б. катнашты.

Киңәшмәдә язучыларның хезмәт коллективлары һәм авыл белән бәйләнешен тагы да тирәнәйтү һәм активлаштыру турында конкрет чаралар планлаштырылды.

*
* *

Брежнев язучылар союзы оешмасы белән Түбән Кама шин производство берләшмәсе арасында иҗади дуслык договоры төзелде.

Предприятиенең генераль директоры Н. А. Зеленов, партком секретаре А. И. Пиков һәм язучы Разил Вәлиев үзләренең чыгышларында бу килешүнең һәр ике як өчен дә зур әһәмияткә ия вакыйга булуын билгеләделәр.

## Я. ГАШЕК ИЛЕНДӘ

Июнь аенда язучылар Р. Кәрами һәм М. Маликова Я. Гашекның тууына 100 ел тулу уңае белән чакырылган махсус туристик группа составында Чехословакиягә барып кайттылар. 24 июньдә Гавричков Брод шәһәрендә Я. Гашекның тормыш юлына һәм иҗатына багышланган симпозиум булды. Анда Р. Кәрами чыгыш ясап, Совет-Чехословакия дуслыгы җәмгыятенең Казан бүлеге һәм бөек чех язучысының

Бөгелмә шәһәрендәге эшчәнлеге хакында сөйләде. Икенче көнне татар язучылары Липницы шәһәрендә Я. Гашекка бюст ачылу тантанасында катнаштылар, әдипнең музеенда булдылар, каберенә чәчәкләр салдылар.

* * *

Апрель аенда РСФСР язучыларының махсус туристик группасы составында татар шагыйрьләре Равил Фәйзуллин һәм Рәдиф Гатауллин Испаниядә булып кайттылар. Алар анда Барселона, Сеговия, Авила, Мадрид, Толедода булдылар, Барселона университетының рус теле бүлеге студентлары белән очрашуда катнаштылар.

## ӘДӘБИ ОЧРАШУЛАР

Татарстан Язучылар союзының матур әдәбиятны пропагандалау бюросы июнь аенда республикабыз районнарына язучылар җибәрүне дәвам итте. Шагыйрьләр Г. Латыйп, С. Шакир, Ж. Дәрзаманов, яшь әдипләр К. Кәримов, Э. Мостафин, Ф. Низамова, яшь композитор Р. Гатауллин һәм ТАССРның атказанган артисты Х. Жәләлов Аксубай, Куйбышев, Әлки районнарында булып кайттылар. Алар көндез механизаторлар һәм терлекчеләрнең эш урыннарында, ә кичен культура йортларында әдәби-музыкаль кичәләр үткәрделәр. Татар әдәбиятына кагылышлы бу очрашулар бик җанлы үтте.

## ХЕЗМӘТЛӘРЕН ХӨРМӘТЛӘП

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисткасы Гәүһәр Абдулловна Камаловага, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1983 ел, 27 июнь Указы белән, «РСФСРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Совет сынлы сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен түбәндәге иптәшләргә, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1983 ел, 28 июнь Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде:

Адылов Нәүфәл Исмәгыйловичка—скульптор.

Ситдыйков Эмил Гарифовичка — художник-график.

* * *

Совет кинематографиясендә озак еллар нәтиҗәле эшләгәне өчен һәм алтмыш яше тулу уңаеннан Татарстан АССР Кинематографистлар союзы идарәсе секретаре, кинорежиссер Фатыйх Миңнеханович Шәрәфиев КПСС өлкә комитеты һәм Татарстан АССР Министрлар Советының Почет грамотасы белән бүләкләнде.

Кама Аланында «Союзпечать»нең беренче киоскы эшли башлады. Татарстан атом электр станциясен һәм яңа шәһәрне төзүчеләр вакытлы матбугаттан даими рәвештә файдалану — газета, журналларны үз вакытында сатып алырга, дөнья хәлләре белән көнендә үк танышып барырга мөмкинлек таптылар. Моннан тыш Кама Аланы поселогында ачылган элемтә бүлегендә барлык газета-журналларга язылу мөмкинлеге дә булдырылды.

* * *

Апрель ае азагында Тат АЭС һәм булачак шәһәрне төзүче комсомолларның беренче җыелышы булды. Ләкин бу бер дә очраклы хәл түгел иде. Удар төзелештә эшләүче комсомоллар үзләренең оешмасы пролетариатның бөек юлбашчысы Владимир Ильич Ленин туган көнне оештырылсын дип уйладылар. Яңа сайланган комсомол комитетының җитәкчесе итеп моңарчы төзелешне механикалаштыру идарәсендә прораб булып эшләгән Әмир Гайнуллинны сайладылар. Яңа комитет җиң сызганып эшкә керешә — беренче өмәләр, ял сәгатьләрен файдалы үткәрү чаралары оештырылды.

* * *

Күптән түгел Кама Аланында төзүчеләр тырышлыгы белән яңартып төзелгән клуб үзенең ишекләрен ачты. Шул ук вакытта биредә төзелеш мәйданындагы берләштерелгән партия комитеты һәм комсомол оешмасы җитәкчелегендә тупланган беренче үзешчән сәнгать коллективлары төзүчеләр каршында үз осталыкларын күрсәтергә дә өлгерделәр.

* * *

Брежнев шәһәренең олы төзелешләрендә чыныгу алган комсомол оешмасы — шәһәр комитеты кече туганы — Тат АЭС комсомолы һәм яшьләренә культура хезмәте күрсәтүне үз өстенә алды. Моның беренче нәтиҗәләре — күз алдында. Брежнев яшьләренең үзешчән осталары «Ника» театр студиясе һәм «КамАЗ» культура сараеның Ренат Гобәйдуллин җитәкчелегендәге «Сердәш» вокаль ансамбле АЭС төзелешендә чыгыш ясады.

# РӘССАМ ТАВИЛ ХАҖИӘХМӘТОВ

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Тавил Хаҗиәхмәтов иҗат иткән портреттан безгә XIII гасыр җәүһәрләреннән саналган «Кыйссаи Йосыф» поэмасының авторы — легендар шагыйрь, зирәк һәм какшамас рухлы Кол Гали карап тора. Аның якты, киң маңгае, тынгысызлык уты тулган тәвәккәл күз карашы шундук игътибарны үзенә җәлеп итә, аннан тиз генә аерыла алмыйсың. Капма-каршы көчләр бәрелешкән ерак-ерак чорларда яшәгән кеше ниндирәк? Халкына булган мәхәббәт хисләрен, ышаныч-тугрылыгын, үзенең кешелек дәрәҗәсен монгол яулары һәм ут-төтен аша ничек исән-сау алып чыга алды икән ул? Әсәргә карап, әнә шундый уйларга бирелэсең.

Бу — рәссамның иң катлаулы сәнгать жанрларыннан саналган тарихи портреты. Автор героеның төгәл кыяфәтен, йөз чалымнарын белмәгән килеш, аны хыялында тудыра һәм һәркемне ышандырырлык итеп сурәтләп бирә. Мондый уңышка ул шагыйрьнең Ватанын, Болгар чорын өйрәнү нәтиҗәсендә ирешә. Балкып торган Идел буе, кауры каләм, күн белән тышланган китап — болар барысы да безнең борынгы бабаларыбыз гомер иткән ерак гасырлар турында уйландыралар. Биредәге орнамент исә шагыйрьнең зур сәнгать кешесе булуына ишарә ясый. Портрет, әйтерсең лә, Кол Гали поэмасын укыган бик күп кешеләрнең аны ниндирәк кыяфәттә күз алдына китерүләрен бергә туплаган.

Кол Гали иҗаты белән Тавил Хаҗиәхмәтов күптәннән кызыксына. 70 нче елларда ук инде ул саф мәхәббәткә дан җырлаган Йосыф белән Зөләйха образын иҗат иткән иде. Гомумән, художник әдәби әсәрләрдән бик еш илһам ала, яңадан-яңа хезмәтләр тудыра. Рәссам Г. Тукайның «Эш беткәч, уйнарга ярый», татар халык мәкальләре һәм әйтемнәре тупланган «Хезмәт батыр», Н. Исәнбәтнең «Мырауҗан маҗаралары» кебек җыентыклардагы сурәтләре белән бүгенге китапларны бизәү тарихына зур өлеш кертте. Ул татар китабы битләренә беренчеләрдән булып халык сәнгатенең нәкыш һәм орнаментлар дөньясын алып килде. Алар ювелирлык сәнгатенә хас осталык белән эшләнгәннәр. Һәм бу гаҗәп тә түгел. Чөнки Т. Хаҗиәхмәтов — Саба районының нәселдән килгән ювелир улы.

Герой-шагыйрь Муса Җәлил китапларын бизәүдә дә рәссам үз сүзен әйтә алды, бөтен кешелек дөньясына мәгълүм шигъри юлларның, җырларның фәлсәфәсен, ватандарлыгын, фаҗигале язмышларны ачып бирде. Галимҗан Ибраһимов, Һади Такташ кебек классикларыбызның китапларын бизәде. Ул, билгеле, бүгенге язучыларның әсәрләре белән дә кызыксына, аларны да нәкъ үзенчә аңлатырга омтыла.

Тавил Хаҗиәхмәтов — киң белемле һәм күпкырлы рәссам. Әйтик, ул сынлы сәнгать, театр бизәү, костюмнар булдыру өлкәсендә дә үзен танытты. Ләкин аның төп иҗат юлы әдәбият дөньясына килеп тоташа һәм ул хәзерге китап бизәү сәнгатенең иң югары ноктасына күтәрелгән.

**Р. ШАҺИЕВА,**
Татарстанның сынлы сәнгать музее фәнни хезмәткәре.

●

**Тышлыкның дүртенче битендә:** «Кол Гали» спектакленнән бер күренеш. Кол Гали ролендә — РСФСРның һәм Татарстанның халык артисты Ринат Таҗетдинов (уртада), сугышчылар — артистлар Илдус Әхмәтҗанов (сулда), Шамил Бариев.

**Рөстәм Мансуров слайдлары.**

# «КАЗАН УТЛАРЫ» 1984 ЕЛДА

Татар совет әдәбиятының иң күренекле әсәрләре укучыларыбызга иң элек «Казан утлары» аша барып ирешә. СССР һәм РСФСР Дәүләт премияләре лауреатлары да, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреатлары да үзләренең әсәрләрен беренче булып журнал битләрендә бастырдылар. «Казан утлары»нда басылып чыкканнан соң ул әсәрләр әлеге югары бүләкләргә лаек булдылар. Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты шагыйрь Муса Җәлилнең ерак Европа илләрен гизеп кайткан атаклы «Моабит дәфтәре» дә «Казан утлары» аша бөтен дөньяга танылды. Бу традиция дәвам итә.

«Почет билгесе» орденлы «Казан утлары» бүген дә чорыбыз белән бер сафта атлый. Ул халкыбыз тормышына торган саен ныграк якыная. Журнал битләрендә «Бүгенге проза: геройлар, проблемалар» исемле дискуссия дәвам итә. Быел Татарстан атом электр станциясендә «Казан утлары»ның әдәби посты оештырылды.

1984 елда да «Казан утлары» үзенең укучыларын яңа романнар, повестьлар, пьесалар, җырлар, авыл кешеләренә багышланган очерклар, язучылар, артистлар, рәссамнар, композиторлар турында мәкаләләр, шигъри әсәрләр белән таныштырып барачак. Алар арасында, мәсәлән, Мөхәммәт Мәһдиевнең «Торналар кайтыр» романы, Чиләбедә яшәүче язучы Рөстәм Вәлиевнең Тукай турындагы яңа романы, Әмирхан Еникиның «Соңгы китабы» (өченче кисәк) бар.

Г. Бәширов, С. Хәким, А. Шамов, Н. Дәүли, Г. Ахунов, И. Юзеев, Ш. Галиев, Р. Фәйзуллин, Н. Фәттах һ. б. әдипләр журнал битләрендә үзләренең яңа әсәрләре белән катнашачаклар. Ел дәвамында татар халкының килеп чыгышы, гореф-гадәтләре, культурабыз тарихына кагылышлы материаллар да басылачак. Күренекле әдипләрнең архивларыннан яңа публикацияләргә, М. Җәлил, Г. Ибраһимов, Х. Туфан турындагы истәлекләргә урын биреләчәк.

Укучыларыбыз игътибар иткәндер: быел безнең журнал яңача бизәлештә чыга башлады. Алдагы елларда да тышлык Татарстан рәссамнарының киң билгеле картиналарыннан фоторепродукцияләр белән бизәләчәк. Анда спектакльләрдән төсле фотолар, күренекле артистларның, җырчыларның, сәнгать эшлеклеләренең портретлары булачак. Журналның эчке битләрендә роман-повестьларга, шигъри әсәрләргә рәссамнар тарафыннан иллюстрацияләр дә ясалачак.

«Казан утлары» Бөтенсоюз каталогына кертелгән. Аның индексы — 73210. Журналга Советлар Союзының барлык почта бүлекчәләрендә язылырга мөмкин. Еллык бәясе — 10 сум 80 тиен.

**Редакция.**

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)